С(Башк)
П58

Суфиян Поварисов

АККАЕНЛЫ ИЛЕШЕМ

Шигырьләр
поэмалар

ЛИСТОК СРОКА ВОЗВРАТА
КНИГА ДОЛЖНА БЫТЬ
ВОЗВРАЩЕНА НЕ ПОЗЖЕ
УКАЗАННОГО ЗДЕСЬ СРОКА
Колич. пред. выдач. ....

С(Башк)
П58

С.Ш. ПОВАРИСОВ

АК КАЕНЛЫ ИЛЕШЕМ

(юбилярның иҗатына багышлана)

Шигырьләр, поэмалар

Уфа
РИЦ БашГУ
2014

НБ РБ
0000177054

УДК 800
ББК 80/84
П42

Рецензент:

филология фәннәре докторы, профессоры, шагыйрь **Фәнил Күзбәков**
(БДУ, г. Уфа)

Поварисов С.Ш.
П42 Ак каенлы Илешем (юбилярның иҗатына багышлана): шигырьләр, поэмалар / С.Ш. Поварисов. – Уфа: РИЦ БашГУ, 2014. – 292 с.
ISBN 978-5-7477-3657-3

Башкортстанның халык язучысы Суфиян Шәмсетдин улы Поварисовның “Бәхет” дигән беренче шигыре 1953 елда дөнья күрә. Берүк вакытта диярлек ул проза белән дә җитди шөгыльләнә башлый. Хикәяләр, унлап повесть иҗат итә. Янә, берүк вакытта дип әйтергә мөмкиндер, драма жанры белән дә җитди шөгыльләнә. Сәхнә әсәрләре Башкорт академия драма театры, Сибай дәүләт драма театры, Чиләбе дәүләт драма театрында һ.б. урыннарда куела. Профессор, филология фәннәре докторы, БР һәм ТРның атказанган фән эшлеклесе, РФ югары мәгарифенең шәрәфле хезмәткәре С.Ш. Поварисов фән өлкәсендә дә уңышлы эшли. Ул роман бастырып, үзен сүз сәнгате остасы икәнлеген дә танытты. Нинди генә авыр хезмәтләр башкармасын, йөрәгендәге шигъри ялкын сүнмәде. Бу җыентык шуның бер үрнәге.

УДК 800
ББК 80/84

ISBN 978-5-7477-3657-3

© Поварисов С.Ш., 2014
© БашГУ, 2014

-166675-
ГБУК
Национальная библиотека
имени Ахмет-Заки Валиди
Республики Башкортостан

Шәфкатьле, шәрәфле, шәфәгатьле

...Бу җырны моннан байтак вакытлар элек тәүге тапкыр кайда ишеттем икән? Нәкъ менә авылда булды ул. Эңгер төшкән мәл иде. Айлы кич иде. Бөреләрнең шартлап ачылганын ишеттередәй тыныч кич. Әле ут алып өлгермәгән өйнең ачык тәрәзәсеннән җыр ишетелә:

Язгы моңнар чишмә кебек агыла,
Шаулап тора басу эшләре.
Нурлар бөркеп кырдан каршы ала
Авылымның айлы кичләре.

Урамнарда тәмле булып аңкый
Яңа пешкән икмәк исләре.
Иркәләнә гармун моңнарында
Авылымның айлы кичләре...

Соңыннан белдем: мине – авыл дөньясында иртәләрем-кичләрем хозурлыкны үткән тәэсирле җанны – аһәңдәшлеккә, аваздашлыкка чорналган җырның сүзләрен Суфиян Поварисов язган икән. Бу олпат һәм мөлаем затны мин Бөек Ватан сугышы каһарманы, аннан да болай, язучы һәм галим буларак белә идем.

Үзе туып-үскән бәрәкәтле Илеш районына, бай төбәкнең билгеле кешеләренә багышланган мәдхияле әсәрләрен, азаграк килеп, бер-бер артлы туган бай, тирән өстенлекле калын-калын романнарын укып, якташыбыз, остазыбыз Галимҗан Ибраһимовның тормышын-язмышын, шул дәвернең сулышын, тагы килеп, Ватан өчен ил-кавемнең тиңдәшсез алышын, барлык шул касафатларда чыныккан саф мәхәббәтнең булмышын күңелдән кичерүләр – болар хәтердә уелып калды. Әдәбиятның, талантның көче дә, төбәлеше дә шунда шул.

Карасаң, Суфиян абый шигырьләр дә яза икән. Һәрхәлдә, иҗат юлын шигырьләр белән башлаган."Авылымның айлы кичләре" дигән баягы җыр аның шигъриятенә дә алып керде. Күренекле профессор-педагог, әдәби тел-стиль, гомумән, сүз сәнгатенең эстетик асылы буенча гыйльми хезмәтләре белән билгеле галим, күренекле публицист, драматург, Башкортстанның халык язучысы Суфиян Поварисов – шагыйрь дә ул, дип әйтерлек икән лабаса. Ә, бер уйласаң, барлык бу иҗтиһатның, һәммә бу эшчәнлекнең һәр тармагы үзе бер гомергә торырлык бит. Сирәк очрар күренеш бу. Димәк, нинди олуг шәхес.

Күпне күргән зыялы затлар шулай инде – ә үзе нинди гади, итагатьле, басынкы, дөнья алдында – кечелекле, чордашлары янында – ифрат кешелекле, инабатлы. Шигырьләре, мәдхияләре дә шулай – көн кебек якты, гади. Аларда да күркәм сыйфатлары чагыла. Төп таләпне искә

төшерә алар: үз асылында, үз җирлегендә язылса, шул инде ул күңелгә үтеп керер шигъри сүз.

Үз җирлегендә дип юкка гына әйтелмәде. Суфиян Поварисовның шигъриятендә дә яши туган җирнең – Илешнең каеннары. Ватан аңа гүя шул каеннардан башлана.

Илештә мин, шөкер, күп тапкырлар булдым. Һәр барганымда да каршы алды, озатып, калды ак каеннар. Алар ак моңга, ак нурга коенган. Суфиян абыйның каеннары. Илһамын менә ничек ургыта алар:

Илеш җирен урап алган ак каеннар,
Каеннарда Аллаһ рухы – ак илаһ бар.
Илеш халкы йөзе ак каеннардай ак,
Илеш күңеле каен суыдай саф һәм пакъ.
Бу төктә булган Нух пәйгамбәр туфрагы,
Төккә сеңгән скиф, шумер, кыпчак каны.
Чал Иштау бар горур Илеш күкрәгендә,
Һич селкенми утлы күкләр күкрәгәндә.

Бу юллар Суфиян абый гыйльми тикшеренүләрендә үзе бер ачыш дәрәҗәсендә кулланган сүз-сурәт, сүз-фикер, сүз-тойгы дигән хосусиятләрдән тукылган, алар көйле дә, мәгънәле дә. Мондый юлларда гүя борынгылык белән бүгенгебез кавыша, киләчәккә омтыла. Үзе бер затлылык, зыялылык, үзе бер үзенчәлек бар.

Шушы ук сүзләрне, мәсәлән, аның "Ак каенлы Илешем!.." дигән мәдхия-эссесына карата да әйтеп була. Анда моннан да хәтсез элек үз исемен алыр төяккә нигез салган Илеш тә, мәхәббәт шифасыннан савыккан, Илешне гашыйк иткән Шәфәкъ тә, Ак әби дә ак каеннар белән бергә оҗмах итә газиз җирне.

Илешнең әнисе улына вәгазен, васыятен әйтә:
Яшәү өчен иң кадерле ак нәсыйхәт:
Гадел булу, кешелекле, кечелекле,
Шәфәгатьле, ягымлы һәм дә эшлекле.

Шул васыятькә тугры ул Илеш бабайның варисы Суфиян абый – Поварисов. Бу аның булмышыннан да, әсәрләренең аерып әйткәндә, шигъриятендә язылышыннан да бөркелеп тора. "Ак" дигән эпитетның үтәдән-үтә килүе дә кинаяле. Ул йөрәк принцибын аңгарта.

Кешеләрне ул йөрәк белән яратты,
Яхшылык ак савантай үзенә кайтты, –

Дип әйтерлек тә шул. Чынлап та, "иманлыны бәхет үзе эзләп таба, имансыз җан шайтан авызына каба".

Янә килеп, шушы юлларны һәркемебез аксакал тарафыннан әйтелгән изге теләк дип кабул кыла:

Булсак иде ак каендай ак күңелле,
Ап-ак итсәк иде газиз бу гомерне.

Әмма Җир шарында, тоташ кешелектә, катлаулы тормышта ак күңелләрне дә, ил алдындагы, мәхәббәт каршысындагы иманны да меңмең сынаулар сагалый, хәтта сугыш гарасатлары, яу дәһшәте әллә нинди уйларга сала. Шунда да ак каеннар да, ак күңелләр дә үз асылында кала. Моны, әлбәттә, Бөек Ватан сугышы ветераны, хезмәт каһарманы Суфиян Поварисов үзе кичереп белә. “Ак күбәләкләр”, “Солдат йөрәге” дигән шигъри әсәрләре дә төп шуны якты хисләр, сынмас рух, тугрылыкка яу ялкыны сеңгән дәлилләр белән исбатлый. Гомумән, шигърияте менә шулай хаклык кебек гади дә, шәфкатьле дә, шәфәгатьле дә.

Шуңа да инанып әйтәм: Башкортстанда да, Татарстанда да, бүтән тарафларда да киң билгеле шәхесебез, халык язучысы, күренекле галимебез Суфиян Порварисовның шигъри әсәрлдәре дә кавемебездә танылу яулар. Шаулар, һәрвакыт шаулар Илеш каеннары. Алар Суфиян абый Поварисовның шигъриятендә дә моң сирпеп, фәһем биреп шаулаячак.

Дөньяны кабатлаудан иман искерми, дигән сымак, бер үк сүзләр кабатлана анда: шәфкатьле, шәрәфле, шәфәгатьле зат ул аксакалыбыз. Зур гомер, зур иҗат өчен бик тә куанычлы бу.

Хәсән НАЗАР,
Салават Юлаев исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты.
8. 08. 2014.

Шигърият – аң, хистәге мәдәният

"Бәхет" дигән беренче шигырем "Кызыл та"да басылган иде. Миңа – 29 яшь. Шатлыгымның чиге юк. Мин – шагыйрь янәсе. Шулай да нык уйланырга туры килде. Тукай 27 яшьтә данлыклы шагыйрь булган. Такташ – 30да. Шигырь бөртекләп җыйган алтын кебек. Кайчан мин Тукай булам да, кайчан Такташ булам? Шушы сорау борчый күңелне. Мәгәр Тукай һәм Такташ моңы ярсыта иде инде йөрәкне. Казан дәүләт педагогия институтында укыганда (1951-1955 еллар) Байронның Җир шарында иң оста шагыйрь булуы хакында беләм. Лермонтовның шигъри йөрәге Байрон дәрәҗәсенә күтәрелергә куша икән. Аның бу поэтик хыялын Тукай эләктереп ала. "Пушкин, Лермонтов. Тукай өч йолдыз ул, ди. Байронны мин укыдым. Кыскача гына әйтсәк, аның аң-хистәге шигъри мәдәнияте – сүз энҗесендәге тәгълиматы.

Ни өчен "Бәхет" дигән шигырь язылa? Үз бәхетеме? Кешеләрнекеме? Гаиләнекеме? Илнекеме? Милләтнекеме? Җир шарыныкымы? Барысы да сыйгандыр, бәлки. Бәхет – хезмәттә. Әмма ул иманлы булырга тиеш. Имансыз хезмәт бәхетле итә алмый адәм баласын. Имансыз шигырь шагыйрьнең үзен генә түгел, милләтен дә хур итәргә мөмкин. Ничек кенә булмасын, үзем өчен, чыннан да, әйткәндәй, алтын бөртекләредәй сүз-сүрәт, сүз-фикер, сүз-тойгы кебек әсәрнең канын, җанын, ямен, тәмен күркәмләүче тел чараларына да игътибар ителә, шикелле. Алар "Бәхет" исемле беренче шигыремдә дә бар. "Җәймә, әнкәй, мамык түшәгеңне", "Исмә, әй, җил, чиртмә тәрәзәсен", "Син күңелдә һаман тулган ай" һ.б. шигырьләремдә, "Ак күбәләкләр", "Солдат анты", "Ләлә", "Ак каенлы Илешем" дигән поэмаларымда күбрәк тә, гыйззәтлерәк тә, мәгънә ягыннан канатлырак та, эстетик зәвык буенча фикер йөртсәк, бәлзәмлерәк тә.

Җир шары – мәхәббәт йомгагы. Җир шары – чагыштырулар дөньясы. Җир шары – шигърият шаукымы. Кеше – Җир һәм Күк мәхәббәте җимеше. Мәхәббәттә - иманлы шигърият. Иманлы шигърият йөрәкләребезгә көчә. Безгә шат, хөр, матур, күңелле, бәхетле яшәргә ярдәм итә. Ә мин, әллә үз кадеремне үзем белмәгәнлектән, шушы бөек хискә хыянәт иттем. Язмый башладым бервакыт шигырьне. Тукай, Такташ, Пушкин, Байрон була алмагангамы? Анысы да бардыр. Минемчә, шигърияттәге намус аклыгы – оҗмахтагы Кәүсәр күле сафлыгы. Бу сафлык – шигърияттәге мәгънәви аклык.

Мондый уйлар гына шигырьдән читләштермәгәндер мине. Башка жанрларга караганда шигъри кыса таррак тоелды сымак. Күп вакыйгаларны сыйдыру кыен. Прозага күчтем. Байтак хикәя, унлап повесть язылды. Бервакыт сәхнә сәнгате "җене" кагылды. Вак актлыларын да исәпләсәк 20ләп әсәр иҗат ителде. 1969 елның декабрь

аенда "Туй бүләге" дигән драмам Сибай дәүләт драма театрында куелды (драма сатучылар намусы турында). 1947 елның апрелендә "Кәрлә йолдыз" исемле комедиям Башкорт академия драма театрында уйнала башлады (вуз укытучылары намусы хакында). Ректор – СССРның халык артисты Арыслан Мөбәрәков. Алар гастрольдән кайтканчы "Кадер кичәсе көнендә" дигән трагедия әзерләп куйдым. Режиссеры – Р. Исрафилов. Театрның бер еллык мизгелендә өч күп актлы сәхнә әсәре язуның авырлыгын үзем генә беләм. Җитмәсә, өчесе өч төрле жанрда (драма, комедия, трагедия) бит әле. Белинский әйткәнчә, сәхнә әсәре – иң авыр жанр. Минемчә, сәхнә әсәре үзе бер шигърият дөньясы. Драматургның шигъри иманлы булуы да шарт. Поэтик шартлык – аң-хискә юмартлык.

Сәхнә әсәренең кысасы да поэманыкы шикеллерәк икән. Шуны уйлап, романнар иҗат итәргә тотындым бервакыт. Тугызы дөнья күрде инде. Унынчысы басылып ята. Икенчесенә 90 яшемнең алтын ачкычын учыма йомарлаган көнне нокта куйдым. Рәхмәт Ходайга! Ярдәмен ташламый. Газраилга да рәхмәт! Ашыйкмый (халык әйтмешли, мал малга җиткәнче Газраил җанга җитә).

Шигърият сөйкемлелене ярата. Шул үзенчәлеге буенча аны егет белән кыз мәхәббәтенә охшатырга да мөмкиндер. Тик мәхәббәт гаҗәп каршылыклы бит ул. Аның шулай икәнлеген Йосыф белән Зөләйха, Ләйлә-Мәҗнүн, Таһир-Зөһрә, Галиябану-Хәлил мәхәббәтләре дә аңлатып тора. Шигърият һәм сөйкемлелек дөньясына кереп китсәң, аларныкына караганда да авыррак хәлләр бар. Борынгы шагыйрьләр әсәрендә, бал бакчасына корт чагудан куркып керергә дәрт итмәүчеләрдәй, халык теленнән ераклашу булып оешып алгач, аңа кадәр "кыерсытылган" сүзләр, тәртипле Суворов солдатларыдай, әдәби әсәрнең үзәгенә килеп басты. Шулай да октябрь түңкәрелешеннән соң да әле сүзләрдән, сурәтләү-тасвирлау чараларыннан ышандырмый торган сүз-сурәт ясау дәвам итте. 1924 елда "Чаян" журналы андыйлар турында язып та чыкты. Журналның бер битендә — Кояш. Кулына бораү тоткан Г. Кутуй: "Мин Кояшны арт ягыннан бораулыйм", — ди. Кулына утлы факел тоткан Һ. Такташ: "Мин Кояшка ут ягам", — ди. Аларга карап торган бер эшче: "Боларга җирдә эш юк микәнни соң", — дип аптырый.

Бөек Ватан сугышыннан соңгы елларда "аңлашылмаган шигырьләр язу "модасы" басты әдәбият мәйданына. И. Нуруллин белән Р. Фәйзуллин: "Аңлашылган һәм аңлашылмаган шигырьләр" дигән мәкалә бастырды "Казан утлары" журналында. Шул хакта "Казан утлары" сәхифәләрендә күп кенә бәхәсле мәкаләләр дөнья күрде. Миңа да соңгы елларда нәшер ителгән шигырьләрнең сәнгатьчә эшләнеше турында язарга кушылды. Мактама, тел-өслүб (стиль) чире белән зәгыйфьләнгән шигырьләр хакында гына яз", — диделәр. Алай гына булмый ул, әлбәттә. Иманлы шигырь янында имансызлының да иманланып китүе бар. Шул

хакта уйлап язарга туры килде. Шигъриятне мин ул вакытта "Гөл-бакча" дип атадым. Гөлгә тиңләшердәй шигырьләр күп. Гөл-бакча ямен җибәрүче чүплеләре дә аз түгел. Аңлашылган шигырь сүз-сурәт, сүз-фикер, сүз-тойгы кәрәзе белән нурлана. Аңлашылмаган шигырь шул кәрәзне бал кортыныкыдай итә алмаудан хурлана. Катлаулы метафора харап итә (сүзләрдәге күчерелмә мәгънәлелек). Сүз кылтымлыгы — мәгънә бозыклыгы.

Поэзия яктылыкка омтыла. Иманлы Армия (Совет Армиясе) имансыз армияне (Гитлер армиясе) җиңеп чыккан сымак, иманлы шигърият, караңгылыкка капкан кора. Төркиләр (20дән артык милләт)нең йөрәге шигъри моң белән мәдәниятләнгән. Аң, хистәге мәдәният шәүкәтлелеге ул. Русиянең "Фронтовик" дигән сүзе Җир шарында фашизмны җиңү символы булып яңгырый. Тукай белән Җәлил шигърияте җилендә дөнья йөзендәге кара көчләр калтырый. Татар кызлары Алсу белән Динә моңы Тукай, Җәлил шигъриятендәге гыйззәтлелекне күркәмли. Соңгы вакытта иман кайтуны, дини тәрбия артуны да искә алып, яшәешкә аң-акыл, хис-тойгы кардәшлеге белән карасак, шигърият фронтын ныгыту, Тукай әйтмешли, кирәкле шәйдер.

Бал өчен күп чәчәкләр сайлаган корт кебек, язарга жанр төрләренә сикерүем сәбәбе аңлашылды булса кирәк. Күптән түгел "И, газиз илем — иманлы Илешем!" ("Гыйлем", 2013, 401 бит, 33, 74 басма табак) исемле китабым дөнья күргән иде. Анда "Ак күбәләкләр" дигән поэма да бар. Ул үзе теләп сугышка киткән Илеш кызына багышлана. Шушы китап буенча Илешнең сигез авылында фикер алышу оештырылган. Тугызынчысына үземне дә чакырдылар. Рәхмәт Илеш халкыма! Бик матур, җентекле, мәгънәле сөйләшү булды. Илештә ачык йөзле, киң күңелле, тырыш, мәдәниятле, мәгънәле халык яшәгәнлек мәгълүм инде. Аларның таләбе дә бик зур. "Суфиян абый, Илеш бабайның үзе турында нигә поэма язмыйсыз?" — диде берсе.

Яздым. Илеш җире ак каеннар белән уратып алынган. Илеш бабакаебыз ак каеннар яраткан, имеш. Үзе аларны күп утырткан. Башкаларны да шуңа өндәгән. Ак каеннар Илеш бабай өчен ак күңел, ак йөрәк, ак яшәеш, ак бәхет, ак иман төсле тоелгандыр, бәлки. Илеш районындагы үз авылым Тыпыйны гына алыйк. Анда күккә ашкан Очлы тау (шулай атала да ул) бар. Очлы тауны әйләндереп Тыпый халкы каен утырта. Ак каеннар тирә-якка ак моң тарата-тарата үсеп китә. Җәй көне анда яшьләр кичке уенга җыела. Күпләрнең дуслыгы әнә шунда мәхәббәткә әверелә. Ак каенлы Кәсәй тавы да бар Тыпыйда. Уфа ягыннан килгән кунакларны иң тәүдә Илеш каеннары каршы ала. Киткәндә шул ук ак каеннар озатып кала. Кунаклар Илештән ак күңел белән кайтып китә. Киләчәктә дә шулай булачак. Бирсен Ходай!

Соңгы поэмамны "Ак каенлы Илешем" дип атау сере аңлашылды

булса кирәк. Китапка да шундый исем кушу хәерлерәк тоелды. Алай гына түгел әле ул. Поэмаларым да, шигырьләрем дә ак каеннар арасында күбрәк язылды. Каен образы теләсә нинди авыл, теләсә нинди район өчен сүз-сурәт була алмаска мөмкин. Ак каенлы Илеш өчен иманлы образ ул. Сүз-сурәт, сүз-фикер, сүз-тойгы — мин уйлап тапкан терминнар. Образлылык, идеялелек, эмоциональлек дип әйтү дә бар. Аерым сүзләр (лексик берәмлекләр)нең, генә түгел терминнарның да мәгънәдәшләре (синонимнары) була. Сүз-сурәт, сүз-фикер, сүз-тойгы һәр жанр өчен кирәк. Шигырь өчен алар аеруча көтелгән кунак. Берсе генә җитмәсә, шигырь — яфраксыз агач. Бер мисал. 1982 елда Галимҗан Ибраһимов әсәрләренең сәнгатьчә эшләнеше турында докторлык диссертациясе яклаган идем (Бакуда). Тора-бара төрки халыкларның бөек язучысы Г. Ибраһимов хакында трилогия ("Пәйгамбәр таңы", "Күкнең җиденче катында", "Оҗмахта бер адым" романнары) да иҗат иттем. Шуны уйлаптыр, бәлки, Г. Ибраһимовның бер юбилеен үткәрүне БДУ миңа йөкләде. Хәзерлек ярты ел чамасы алдан башланды. Башкорт, татар шагыйрьләренең иң асылларына Г. Ибраһимов турында шигырь язарга куштым. Шигырьләр үземә килде. Шактый күп иде. Ләкин "Кызыл таң"га икесен генә тәкъдим иттем: Уфадан — берәү, Казаннан — берәү. Казанныкы үтте. Уфаныкын (кем икәнен әйтмим инде) яратмадылар. Ул урта куллыдан өстенрәк иде. Әлеге иманлы шигырь таләп иткән сүз-сурәт, сүз-фикер бар. Хәтта артыгы беләң. Ләкин сүз-тойгы юк. Г. Ибраһимов — "усал" атамасы алган шәхес. Мәгәр хис-тойгыга бай булган. Аның шулай икәнлеге "Сөю — сәгадәт", "Диңгездә", "Яшь йөрәкләр", "Кызыл чәчкәләр", "Казакъ кызы" һ.б. әсәрләрендә дә сизелеп тора бит. Хис-тойгыга ярлы, салкын йөрәкле әдипнең шундый укып туйгысыз әсәрләр язуы мөмкин түгел. Кыргызның "Манас", башкортның "Урал батыр" поэмасындагы сүз-сурәт, сүз-фикер соклангыч. Алардагы сүз-тойгы сурәт һәм фикергә нәзакәтле канат куйдык. Канат, Сәмруг кошка әверелеп, җир йөзенә изгелек өләшә.

Җир йөзендә иң оста шагыйрь — Байрон. Ә проза буенча кем? Юк. М. Горький, академик Коган фаразлавынча, Г. Ибраһимов булырга тиеш иде. Фаразга репрессия давылы ут якты. 20 елдан соң акланды. Г. Ибраһимов. Дөнья әдәбияты әсәрләренең урысчага тәрҗемә ителгәннәрен укып барам. Минемчә, прозадагы беренче урын һаман әле Г. Ибраһимов осталыгында. Аның шулай икәнлеген ачыклау өчен урыс телендә "Галимджан Ибрагимов — величайший мастер художественного слова" (Уфа, "Гилем", 2012, 375 ст. 27,9 п.л.) дигән китап бастырып чыгарырга туры килде. Инглиз теленә тәрҗемә итеп, чит илгә тарату дәрте дә бар. Татар милләтенең данын Г. Тукай дөнья даирәсенә бер гыйззәтлелек, М. Җәлил икенче шөһрәтлелек белән балкытса, Г. Ибраһимов өченче нәзакәтлелек көдрәтендә шәүкәтле. Г. Ибраһимов турында бозлы йөрәк

белән шигырь язган теге шагыйрь бу хакыйкатьне аңладлы булса кирәк. Хәер, салкын аңлау гыйззәтлегенә кайнар тәгълимат булмый.

Мин артык чәчеләм шикелле. Хәлбуки, фәлсәфәдәге бердәнберлек, гомумилек, аерымлылык шулай булырга куша. "Слово — полководец человеческой силы" ди В. Маяковский. "Для познания нравов какого ни есть народа старайся прежде изучить язык" (Пифагор). Р. Гамзатов та бик каты әйтә: "Тупой язык для самой острой мысли — все равно что волк для ягненка". Минемчә, шигъри тел — яшәештәге иң асыл гөл. Замана заңы фикерләр гөлләнүен таләп итә. Фикер гөле киләчәк яктылык өчен чәчәк атсын. Амин! Чәчәкләр аң-хистәге мәдәниятне иманлы итсен. Ярабби!! Җир шары иманлы мәхәббәт йомгагы булып нурлансын!!!

2014 — мәдәният елы. Ни өчен шигъри мәдәниятлелек турында фикер йөртүем аңлашыладыр. Мәдәниятлелекнең ата-анасы — тел. Әнә шунда инде без өмет иткән гөл. XXI гасыр — эштә. Поэтик тел — үсештә. Башка милләтләрнеке белән чагыштырып карасак, башкорт, татар шигърилтендә яңалыкның күбрәк икәнлеге сизелә. Киләчәк өчен аларның зур мөмкинлеге бар. Мөмкинлекне мин дә шөһрәтләячәкмен. Алар хәзергә күңел сәхифәсендә дәртләнә. Дәрманын поэма һәм шигырьләремне ак кәгазьгә күчергәч күрерсез. Башкортстан җире үзе бер шигърият оҗмахы ул!!!

Ак күбәләкләр
Поэма-эссе

Үзе теләп Бөек Ватан сугышына киткән
Илеш кызларына багышлана

Җир йөзендә канат кага зур мәхәббәт.
Канатларда якалаша нәфрәт һәм шәфкать.
Зур мәхәббәт бер агара, бер карая,
Карайганда жир йөрәге нык тарая.
Зур иде бит безнең мәхәббәт тә шулай,
Булды бит анда агы да, карасы да,
Ут-давылы, дәһшәт, гарасаты, бары
— Йөрәк сыкрайткан канлы ярасы да.
Мин, Гәүһәрем, шашам, ярсыйм, нык уйланам:
Сине сагыну йомшарта да, зурайта да.
Хәтирәләр тулы шаулы тормыш безнең
Үтеп киткән искән җилдәй ни арада.
Син калдырган гөлнең алсу чәчәгенә
һәр яз саен ак күбәләк килеп куна.
Бу күбәләк беләм, иркәм, синең җаның,
Шуны уйлап сагыш тулы еллар уза.
Нык көрәшә хәзер инде ак һәм кара,

Җир йөзендә хөкем сөрә канлы яра.
Уңалдырып канлы яраларны кат-кат,
Без яшәдек кара гөнаһларны таптап...

II

...Җәйге иртә.
Гөлләр хуш-ис бөрки.
Яшел үлән чыкка туенган.
Зәңгәр ефәк төсле юка томан
Күтәрелә елга буеннан.
Мин шуларга чиксез гашыйк идем,
Бөтен матурлыкка шат идем;
Ямьле иртәләрнең котын алып,
Кара кайгы салды фашизм.
Җәйге иртә.
Сиңа сүзем күп тә...
Сөйләр идем, ләкин вакыт тар.
Юл капчыгым тора мине көтеп,
Соңгы сәгать,
Соңгы минутлар...
Син торасың,
Йотып күз яшеңне...
"Уф!" дисең дә эчтән янасың.
Озын керфекләрең сирпеп-сирпеп,
Миңа еш-еш карап аласың.
Син аннары,
Җыеп хисләреңне,
Акрын гына миңа атладың:
Күз яшеңә тулы ирек биреп,
Күкрәгемә килеп капландың.
Мин дә китәм, дидең,
Аңла, Сәлим, Теләгемне какма – калдырма;
Аерылудан ачы кайгы бармы,
Сагыш утларында яндырма.
Азмыни соң
— Ире белән бергә
Походларда парлап йөргәннәр,
Мәхәббәт һәм иле хөрмәтенә
Ут эченә бергә кергәннәр.
Икеләнмә... Миннән куркасың,
Фәкать хатын булган өченме?
Авырлыкка сыкрап баш имәмен,
Һәм түзәрмен кысып тешемне, —

Диден дә син,
Сыйпап чәчләремне.
Күзләремә өздереп карадың.
Берни әйтмә, Күңеленңне
Аңладым мин барын...
аңладым. Киттем тиздән...
Синең үтенечне,
Теләгеңне катгый кактым мин.
Шуның белән яхшы эшләдемме,
Әллә инде
Йөрәгеңә ут кына яктым мин.

III

Мин киткәчтен сиңа кыен булган,
Көннәр үткән авыр, күңелсез.
Шатлыгыңны әрнү алыштырган,
Сагыш иткән сине түземсез.
Уйлар сине һаман талаганнар,
Ялгызлыктан иза чиккәнсең.
Мәхәббәтем белән утка керәм,
Дигәнсең дә беркөн киткәнсең.

IV

Юеш окоп.
Үтеп җилекләргә
Төн ягыннан салкын жил өрә.
Атакага дүрт-биш бардык бүген,
Әҗәленә фашист жилкенә.
Авырлыклар...
Бары истән чыга,
Онытылмас ләкин бу дата.
Мин окопта фикер йөртеп ятам –
Армиянең гади солдаты.
Кеше туа,
Үсә,
Тормыш кора,
һәркемнең бар җитди хыялы;
Ул казына,
Эшли,
Ижат итә,
Матурларга тели дөньяны.
Ә фашистлар барын утка тота.
Ул җәлләми кеше көчен дә.
Бер уйласаң,

Кеше дошманының
Гомере кыска шуның өчен дә.
Алга карыйм:
Бодай чәчә торган
Кыр өсләрен мина талаган.
Җир-анакай сыкрап ята кебек,
Сызлама күк тирән ярадан.
Без ятабыз –
Салкын, юеш окоп...
Чеметем вакыт солдат ял ала.
Минем уйлар,
Йөгерек җил шикелле,
Үткәннәргә барып ялгана.
Сине уйлыйм, иркәм,
Буй-сыныңны
Күз алдыма кат-кат китерәм.
Бакчаларда куышып уйнап йөрим,
Әллә ничек шулай тилерәм.
Кара чәчләреңне шашып үбәм,
Нечкә билләреңнән алам мин.
Синең белән йөрим болыннарда,
Идел буйларына барам мин.
Әгәр, иркәм,
Килсәң күз алдыма,
Бөтен кайгы кинәт юк була;
Ул, күрәсең,
Барлык көчтән бөек
Сөю хисе шулай нык була.
Ә бит менә,
Фашист искә төшсә,
Җылы окопта да туңасың;
Аны шулчак,
Буып муеныннан,
Чәйнәп ыргытырдай буласың.
Шулай уйлап,
Яткан чакта минем
Күзләремә кинәт чагылдың.
Үз күземә үзем ышанмадым,
Җуйган кебек булдым аңымны.
Бу син идең,
Соры шинель киеп,
Каеш белән билең бугансың.

Солдат киеме килешеп тора сиңа.
Курчак кебек матур булгансың.
Кушылгандай ике ташкын суы,
Бер-беребезгә кинәт ташландык.
Бар солдатлар катып калды кинәт.
Безгә карап алар шаккатты.
Син килгәнсең утлар, сулар үтеп,
Мәхәббәт һәм сөю хакына;
Син үткәнсең озын көрәш юлы,
Тап төшерми солдат антына.
Санитарка булып,
Күпме кешеләрнең
Гомерләрен саклап калгансың.
Ут эченә мәхәббәтем белән
Бергә керәм инде моннан соң.
Алда әле
Фронт юлы озын,
Атакалар саны меңләгән.
Бу кадәрле каты көрәшләрне
Моңа чаклы тарих күрмәгән.

V

Калыкты чулпан,
Сызылып таң ата.
Бүген булачак
Көчле атака.
Катюша уйный,
Туплар ярыла.
Күзләр текәлгән
Дошман ягына.
Кузгалдык алга,
Өермә кебек.
Күпләр егыла,
Кара кан түгеп.
Кайда карама
— Яралы солдат.
Синең юлараң
— Фронт һәм санбат.
Син ышанычлы
Гомер сакчысы.
Сизелми синдә
Курку чаткысы.
Җирләр тетрәтә

Тупларның маршы.
Ятып шуасың
Шуларга каршы.
Яралыларны
Утлар эченнән
Алып чыгарга
Җитә көчеңнән.
Син үзең матур
Кечкенә хатын.
Ихтыяр — таудай.
Акылың — алтын.
Безнең ис китә
Кыюлыгыңа.
Тап төшермичә
Гомер юлыңа,
Син аяк бастың
Фронт юлына.
Батыр ир кебек
Көрәшкә чыктың.
Син иркәлекнең
Барын оныттың.
Төннәр күп була
Керфек какмаган.
Көннәр күп була
Ризык капмаган.
Сыкрау күрмәдем
Ичмасам, бер кат,
Син безнең кебек
Гади бер солдат.
Утларга кердең,
Суларда йөздең,
Авырлыкларга
Теш кысып түздең.

VI

Тагын бер көн.
Киттек атакага.
Дала көйри сугыш утыннан.
Барган чакта, кискән агач кебек,
Егылып калдым дошман угыннан.
Син килдең дә
Йомшак кулың белән
Ак марляга мине биләдең.

Ярам сызласа да,
Уртым чәйнәп түздем,
Авыр миңа, авыр, димәдем.
Бик күпләрнең гомерен саклап калган
Кулларыңа карап алам мин.
Тыштан сиңа берни белдермичә,
Эчтән генә сызып янам мин.
Гарип булып кайтып китәм инде,
Син көрәшче булып каласың.
Элекке күк мәхәббәтем диеп,
Янарсыңмы? Беләм:
Янарсың. Көрәш бара.
Чыжлап уклар оча.
Тирә-якта туплар ярыла.
Дары төтеннәре
Зәңгәр болыт сыман
Җир өстенә ята, сарыла.
Сугыш шулай икән:
Очып барган чакта,
Канатыңны кинәт каера.
Язмыш безне китереп кавыштыра,
Һәм шунда ук тагын аера.

VIII

Сугыш бетте.
Дөнья тынды хәзер.
Савыкты инде тәндә ярам да,
Мин күп вакыт тирән уйга талам,
Кәртечкәңне кулга алам да.
Көләч йөзең,
Шаян күзләреңдә
Балкып тора яшәү шатлыгы.
Сугыш бетеп,
Бер ел үтте инде,
Бүген менә майның актыгы.
Син һаман юк.
Каты яраланып,
Госпитальгә сине салдылар.
Кайтыр юлларыңнан күзем алмый,
Керфекләрем инде талдылар.
Бер уйласаң,
Кавышканга кайчан.
Ул көннәрнең юктыр саны да.

Бары да бар: сөю, мәхәббәт тә,
Тик үзең юк һаман янымда.
Бары да бар: Сагыну, көтүем бар,
Мәхәббәтнең кадерен белү бар.
Менә шулар алдап яшәтә дә,
Шулар белән матур дөньялар.
Беркөн кайттың,
Бәхет, шатлык булып,
Без кавыштык шулай яңадан.
Кантузия синең нервыларны,
Йөрәгеңне бик нык талаган.
Хәлең авыр иде. Комиссия
Инвалидка сине чутлады.
Вакыт-вакыт кинәт һуштан яздың.
Синең йөрәк тибүдән тукталды.
Җәллим сине.
Әгәр мөмкин булса,
Бирер идем ярып йөрәкне.
Ә юк, иркәм,
Артык йомшаклыкка
Бирелмик без – алай кирәкми.
Сиңа карап фәкать горурланам,
Ил кайгысын
Ирләр белән бергә күтәрдең;
Җылы почмак табып яшеренмәдең.
Давыл, ялкыннарны үткәрдең.
Сугыш шулай икән: Тәндә, Ил өстендә
Уелып калды тирән яралар.
Улын көтеп күпме күз алмады
Тәрәзәдән газиз аналар.

VIII

Көчсез булсаң,
Куркак, йомшак булсаң,
Авырлык ул,
Буып ала хәзер якаңнан.
Утлы кисәү күзгә ыргытса да,
Артка чигенмәдек без аннан.
Шатлык та бер.
Кайгы, хәсрәте дә,
Безнең өчен уртак барысы да.
Авыр чаклар килеп китә бирә,
Сыкранмыйбыз аның ансына.

–16697–

УК
Национальная библиотека
имени Ахмет-Заки Валиди
Республики Башкортостан

Авыруны да дару белән түгел,
Көчле ихтыяр белән җиңдек без,
Хезмәт фронтына җиң сызганып,
Зур дәрт белән кабат килдек без.
Мин мәктәптә.
Ә син конторада
һаман шулай чутлар тартасың.
Эшең бетсә,
Язгы кояш төсле,
Көлә-көлә өйгә кайтасың.
Шундый чаклар булды ул елларда:
Бер кабымны икегә бүлдек без.
Тик шулай да
Барлык авырлыкны
Җиңеләйтеп үткәрә белдек без.
Ләкин тормыш
һич тә исәпләшми,
Таләп куя һаман алдыңа.
Карышмыйча,
Җыеп түземлекне,
Үтәү кирәк икән барын да.
Урта белем инде җитеп бетми,
ВУЗ җилкетте минем күңелне.
Без икебез һич тә яратмыйбыз
Бер максатсыз үткән гомерне.
Мин укыдым ВУЗда,
Син, Гәүһәрем,
Курс бетеп главбух булдың.
Биек киртәләрне үтә-үтә,
Тормыш юлын шулай без уздык.
Карыйм сиңа:
Үзең кечкенәсең,
Көлеп тора һаман күзләрең.
Авырлык та берни түгел сиңа,
Бар кайгылар, гүя, нуль генә.
Шул күзләрең бөтен нәрсәне дә
Сөеп карый төсле гел генә.
Син беркайчан килгән авырлыкны
Каршы алмадың кайнар яшь түгеп.
Хатын-кызча күңелең йоп-йомшак,
Ихтыярың ләкин таш кебек.

IX

Тик шулай да таш та эри һәм корыч та,
Яшәп булмый без дигәнчә бу тормышта.
Көтмәгәндә алды Алла синең жанны,
Мин каршылыйм ялгыз гына һәрбер таңны.

X

Чәчләремне сыйпап исә язның җиле:
Бу бит безнең изге төяк — Илеш иле.
Офыкларга баксам, күрәм алсу йөзең,
Ә йолдызлар — сихри, серле, чая күзең.
Сине сагына Илештәге ак каеннар,
Каеннарда тирән, моңлы, ак сагыш бар.
Агыйдел, Базы, Сөн дулкыны ага уйнап,
Мин йөримен, Гәүһәр жаным, сине уйлап.
Син калдырдың туган жирдә нур-матурлык,
Матурлыкта кәрәзләнгән таж-батырлык.
Батырлыкта нәкышләнгән көрәш каның,
Мәңге балкыр Байракларда изге жаның.
Сине мактап монда сандугачлар сайрый,
Минем өчен моңлы кәккүк еллар саный.
Дөнья матур, иркәм! Анда — илаһият!
Тик югала вөждан, намус, иман, оят.
Жиһанны чолгый сугыш кабызган утлар.
Тураклар кебек жирне бомбалар, туплар.
Кояш оча Алла сызган тугры юлдан,
Ычкындырмый дилбегәсен һичбер кулдан.
Кешеләр күк ул ялгышмый, һаман оча.
Ә кешеләр караңгыга кереп поса.
Чыга алмас бәндә ул юлдан ак очка,
Кара урын эзләгәннең гомере кыска.
Ак көндә ялгышса кеше ябалактай,
Карага ташлана ерткыч арысландай.
Болай дигәч тә мин куркытып әйтмим бит,
Алла хөкемен, хакыйкатьне сөйлим тик.
Хәзергә бит ак караны жиңеп килә,
Һич тә киләчәктә шулай булмас димә.
Кара көчне жиңгән Бәйрәм дәвам итә,
Аның шан-шәрәфе гарьше көрсигә китә.
Кайт Бәйрәмгә бакчабызга, ак күбәләгем.
Кун чәчемә, үп битемне, жан түгәрәгем!
Сөй, назла, элеккечә һаман нык ярат,

Кара җирләрем күренсә, син аны агарт!
Мин дә булыйм синең төсле ап-ак күбәләк,
Очып йөрербез парлашып дөньялар күзләп.
Ак күбәләкләр күп булса дөнья нурланыр,
Каралары безне күреп качар, хурланыр.
Ак күбәләк бәхет булгач — без бик бәхетле,
Күктән җиргә күп ташырбыз акыл-бәхетне.
Син гөнаһсыз булып киттең бу дөньядан,
Мин дә шуны сорыйм һаман бер Алладан!

XI

Кунды күбәләк,
Маңгайга кунды;
Мин катып калдым,
Селкетмим кулны.

Тотасым килә,
Килә сөясем;
Мәхәббәткәем
Тик син, диясем.

Тотар идем лә,
Куркам — сытармын;
Бу зур гөнаһ дип,
Утлар йотармын.

Мине сөйгәчтән,
Китте күбәләк;
Агарды җаным,
Күңелем түгәрәк.

Очты күкләргә
Ак мәхәббәтем;
Аклады мине —
Дөнья бәхетем.

Кычкырдым кинәт:
— Каршыла оҗмахта;
Мин ак күбәләк,
Әйт шуны Хакка!

Ак каенлы Илешем!..

Мәдхия-эссе

I

Сине бүген төштә күрдем Илеш бабай!
Син әле жир кендегендә шаян малай.
Булырсыңмы илгә иш-куш, илгә зәвык?
Шундыйларны гына зурлый бит ул халык.

Адәм баласын табигать сынап тора,
Гөнаһ кылсаң, күктән өскә ком-таш коя.
Кайчак шаша җәйнең уттай кайнар җиле,
Вата, җимерә, ега агачларны — тиле.

И, масаеп ишә көзге кара яңгыр,
Әйтерсең ул яуда җиңгән батыр яугир.
Кышкы буран, гүя, зобани шайтан,
Безнең бәхетләргә корып йөри капкан.

II

Син тугансың сандугачлы алсу таңда,
Купкан моңлы аһәң замандагы заңда.
Собханалла! Зәңгәр-яшькелт күзкәйләрең,
Ак якутташтай пакъ һәм саф йөзкәйләрең.
Бу якларда моңлы аһәң — Тәңре рухлы,
Газиз әткәң Илбайның изге язмышы;
Әнкәң Илбикәнең күкрәк сөте, каны,

Киләчәкнең бәхетле, иманлы таңы.
Рухи байлык атаң, анаң күңелендә,
Яктылыгы балкый мәгърүр ил йөзендә.
Илгә иш булсын дип кушканнар бит — “Илеш”,
Бөреләнсен жан-каныңда изге жимеш.

III

Синең тәүдә шаккатырган матурлыгың,
Тора-бара шатландырган батырлыгың.
Һич куркытмый җәйдә янган кояш уты,
Көзге мәлдә давылланган яңгыр коты.
Кыш чумасың кереп карлар буранына,
Әллә шатсың дөнья шулай булганына?
Хезмәт сөюдә күрсәттең чын егетлек,
Сиңа карап кими ялкаудагы “этлек”.
Сабан сөрү, урман кисү, печән чабу... —
Кеше итте кара эштән ак нур табу.

Җиңгән өчен сабантуйның уенында,
Сикереп менде симез тәкә муенына.
Тәкәләргә ач бүреләр һөҗүм иткәч,
Ир гарьлеге бугазыңа килеп җиткәч,
Кулга алдың атадан калган мылтыкны,
Һич күрсәтми ирлектәге кылтымлыкны.
Киттең бүреләрнең ерткыч оясына,
Эзли торгач, барып чыктың дөньясына.
Аттың бик күп, эзләгәннәрең табылды.
"Бүре Илеш" дигән атама тагылды.

IV

Син солтанат кыяфәтле гаярь егет,
Әкияттәге Алып батыр гаме кебек.
Атаң язган Коръән битенә әманәт,
Итмә дигән кешеләргә һич хыянәт.
Кушкан булырга ил һәм ир арысланы,
Шунда балкый адәм баласының даны.
Ана да язды кыскача вәгазь-васыять —
Яшәү өчен иң кадерле ак нәсыйхәт:
Гадел булу, кешелекле, кечелекле,
Шәфәгатьле, ягымлы һәм дә эшлекле.

V

Шулай да канәгатьләндерми бу урын,
Балкытып булмас монда яшәү нурын.
Син уйлыйсың: авырлыкка һич бирмәм мах —
Җир йөзендә кешеләргә кирәк оҗмах.
Таптың аны. Басып торасың бер җайга,
Ләкин түгел бит ул Урал, түгел Тайга.
Шыр-ялангач кырлар йокымсырап ята.
Һәр иртәдә сызылып алсу таң ата.
Очып килгән җитез Сәмруг кош та хәтта
Ярлылыкка карап, әрнеп, шаклар ката.
Килеп җитте бермәл кинәт Хызыр-Ильяс,
Карашы каты, тик шулай да йөзе — Кояш:
— Нинди кайгыга тарыдың и Син, бәндә?
— Оҗмах эзләп килеп чыктым яман җиргә.
— Ирләр зарлана җирләр бездә яман дип,
Җирләр зарлана ирләр бездә надан дип.
— Бөртек бодай сорый ирдән ике пот тир,
Ялкауларга куш йодрык күрсәтә җир.
Сүз өзелде. Очты Сәмруг. Китте Хызыр.
Тик егетнең башкаенда кайгысы зур.

VI

Юл газабы — гүр газабы, диләр иде,
Бу газапка Илеш-Батыр да баш иде.
Хис-тойгысы талпынса да юлларында,
Акыл дилбегәсе булды кулларында.
Яхшы кешегә һәрвакыт Хызыр юлдаш,
Тапкан Сәмруг Илеш өчен чибәр туташ.
Биле нәзек, гүя, Кәүсәр-күл камышы,
Сүзләрендә сандугачның моң тавышы.
Күпереп торган чәчкәйләре нәфис җылым.
Аркасында сузылып ята ике толым.
Сөю серен җемелдәткән күз карашы —
Әллә инде фәрештәнең изге җанашы?
Елмаюы мөселманча итагатьле,
Күз карашы нык сөйкемле һәм тәртипле.
Чибәркәйгә килешмәс күк яла яксак,
Гәүдәсе гөлдәй булса да, аяк — аксак.
Сиздермәскә тырышса да моны кызыкай,
Ярамый икән алдашу ай-һай-һай...
Егылып китте бара-бара аксап-туксап,
Ята бирә өнсез-тынсыз җир кочаклап.
Күтәреп алып китеп барды егет кызны,
Кайнар кояштан табигать уттай кызды.
Кызда бар күк бу якларның җиләк тәме,
Аллы-гөлле чәчкәләрнең сихри яме.
Шушымы әллә яшьлектәге хозур ләззәт,
Кешеләргә гыйззәт биргән чын мәхәббәт?

VII

Сөйләп бирде егеткә кыз аяк хәлен,
Йөгергәндә шартлап сынган юньсез мәлен.
Юк, сынмаган. Тайган гына. Мәгәр — авыр.
Алып китсә, табылыр бит берәр авыл.
Дәвам итә янә иманлы сәяхәт,
Егет кочагында кызга бик рәхәт.
Авыл бәләкәй. Салам түбәле йортлар.
Каршы алды юлчыларны яшьләр, картлар.
Бер ак әби артык шатлана, сөенә,
Алып китте "кунакларны" үз өенә.
Әби өе бәп-бәләкәй, кетәккә тиң,
Әмма әбинең күңеле дөньядай киң.
Киң күңелле кешеләр күп икән монда,
Намус, шәфкать, шәфәгать һәркем уенда.

Кызның исеме дә матур — Шәфкать икән,
Алла тәгълиматы өчен башын игән.
Әби тәвәккәл керәште изге эшенә,
Алып кайтты болыннардан бик күп чәчкә.
Нык кайнаткач, була чәчкә тәмле ширбәт,
Кызның йөрәгенә ята баллы ләззәт.
Яфраклары тайган урынга ябыла.
Кыз йөзендә шатлык нурлары чагыла.
Мунча яга. Миңлек белән чаба чат-чат,
Түзеп тора эсселектән кызыкай чак-чак.
Янә таба әллә нинди яңа им-том,
Аңламассың ак, әбинең сихри холкын.
Авыл теле кызның эчүен бу ил суын,
Җир күкрәгенә иман белән басуын.

VIII

Чәчкәләрнең яңа төрен егет таба,
Аягына дару ясап назлап яба.
Бу шәфәгать кызның үзәккәен өзә,
Анда мәхәббәт шифасы барын сизә.
Егетнең күз карашында сөю хисе,
Бу бит йөрәктә кайнаган әрнү ише.
Бу караш, гүя, язгы җылы агым,
Эретерлек боз йөрәккәйнең дә җанын.
Назда чагыла егеткә хас батырлык,
Батырлыкка канат куйган чын матурлык.
Кызның да мөлаем карашында аклык,
Оҗмахтагы Кәүсәр чишмәседәй сафлык.
Кыз елмая. Елмаюда җан-зөбәрҗәт,
Зөбәрҗәттә егет өчен баллы рәхмәт.
Аягына басты бермәл чибәр Шәфкать,
И, шатлана алар өчен зур мәхәббәт.

IX

Ак әби бик мәрхәмәтле, эшчән булды,
Тик бервакыт мәңгелеккә күзен йомды.
Ул калдырды иманлы юл фанилыкта,
Аның җаны илаһи хак хөр оҗмахта.
Гөнаһсызларның бәхете җир күзендә,
Нәселендә, шәҗәрәдә, ил йөзендә.
Ак әбинең дөньясында калган Илеш
Бу авыл халкына булды иманлы иш.
Кешеләрне йөрәк белән ул яратты,
Яхшылык ак савап тай үзенә кайтты.

Йорт салды ул матур итеп Шәфкать белән,
Яшәү өчен парлы аккошлардай гелән.
Аккошларның мәхәббәте изге булды
Өйнең эче бала-чага белән тулды.
Ак каендай күркәм буй җиткерде кызлар,
Малайлары күплеккә шатлана кырлар.
Авылга "Илеш" дигән исем кушылды,
Моның өчен Тәңре үзе дә хуш булды.

X

Гөлләргә куна сандугач: гөлләр матур,
Ирләргә ышана Алла: ирләр — батыр.
Ир-егетләр һәйкәл туган-үскән илгә,
Ата-баба рухы сеңгән изге җиргә.
И, мөкатдәс рухи байлык, син бит хозур,
Тәгълиматың һәмәләрдән өстен һәм зур.
Бу тагълимат кояш нурыдай тарала,
Тамыр җәя авылларда һәм калада.
Илеш бабай тәгълиматы шулай булды,
Ул иманлы илгә асыл кошлар кунды.
Таралдылар асыл кошлар канат кагып,
Шатландылар янә яңа урын табып.
Кошлар аны да атады "Илеш" диеп.
Һәм әйттеләр: даны торсын күккә тиеп.
Илеш халкы җиң сызганып чумды эшкә,
Калкып чыкты аннан инде зур көрәштә.
Халык тире һәм җир тире нык дуслашты,
Хезмәт белән хөрмәт чынлап култыклашты.
Хезмәтле ил — хөрмәтле ил җир шарында.
Дөнья яшәр андый илләр бар чагында.
Илеш иле хәзер инде күркәм мәктәп,
Өйрәнергә килә аны чит мәмләкәт.
Монда Илеш бабайдан килгән шанлы кан,
Канда кайный илтифатлы, иманлы җан.
Монда шәүкәт, монда намус, монда шәфкать,
Монда аклык, монда хаклык, күр шәфәгать.
Илеш моңы, гүя, шигъри, милли сәнгать,
Аң-акыл, хис-тойгы, ямь бирүче җәннәт.
Әгәр диңгездә коенса су кондызы,
Илеш халкы нур сибүче җир йолдызы.

XI

Оҗмах итә ак каеннар Илеш җирен,
Оҗмах гөле булып үсә монда иген.

Доньядай киң Илеш халкының күңеле,
Йөз яктысы әйтерсең лә кояш йөзе.
Бәхет капкасыдай ачык Илеш йөрәге.
Киләчәк кунак өчен, гүя, саулык терәге.
Илеш жырлары моңы — сандугачныкы,
Ярсу биючеләр чаңы — карлугачныкы.
Чит ил өчен Илеш даны, гүя, тумыштан,
Бер француз баласына "Илеш" дип кушкан.
Хезмәттә чарланган кеше — тәңре ише.
Аң-акылы булган кеше — хак җимеше.
Ил бавырын ныгытырга бу биленңне,
Чуендай ит йомшак сөяк җилегеңне.
Күркәм күңел кирәк илне матурларга,
Ходай бирә гыйззәтле көч батырларга.
Яшәү өчен буш сүз узгынчы җил фәкать,
Ялкаулыктан ми чиләнә, корый тәкать.
Иманлыны бәхет үзе эзләп таба,
Имансыз җан шайтан авызына каба.

XII

Ак каеннар урап алды Илеш җирен,
Бу бит минем җандай күргән туган илем!
Ак каеннар — ак күңелле Илеш халкы,
Бу халыкның йөзе нурлы һәм дә якты.
Ак каенлы Илешем — яшәү җимешем,
Матур була монда йөрсәм күргән төшем.
Бу сүзләрне язам 90 яшьтә зурлап,
Алла рухы белән уйлап һәм хозурлап.
Булсак иде ак каендай ак күңелле,
Ап-ак итсәк иде газиз бу гомерне.
Теләк туры килсен гадел сафларына,
Фәрештәнең "Амин" дигән чакларына!!!

Солдат йөрәге

Таң.
Җирнең аһ-зар, сыкрау өнен йоткан
Кара-кучкыл болыт яшь сыга.
Минем белен ята янәшәдә
Украин егете — дустым Самиго.
Таң. Аңкый дары исе.
Үлем исе килә борынга.
Дустым минем, авыр уйга чумып,

Ялкын сулап, миңа борыла.
Ул, ашкынып, алга таба карый,
Чекрәп яна уттай пар күзе;
Уртын чәйни, тешен шыгырдата,
Өзелеп чыга, әрнеп һәр сүзе:
— Дустым, Фәйзел!.. Алда безнең авыл...
Дошман таптый туган туфракны...
Кайгы күргәч, дөрләп, йөрәгемнең
Янганы юк иде бу чаклы.
Анда атам-анам, сөйгән ярым...
Менә тиздән давыл — атака.
Дошман йөрәгенә аткан укның
Тиюе бар газиз атама.
Нәфрәт белән кысты автоматын,
Моңсу итеп миңа карады.
Җир тетрәтеп, кара болыт ярып,
Гайрәт чәчеп "катюша" уйнады.
Атты туплар, атты минометлар...
Ут чолгады, төтен дөньяны;
Чыдамады, гүя, табигать тә
Бу дәһшәттән әрнеп елады.
Тынды туплар, тынды минометлар...
"Ил"юшалар очты һавада.
— "Алга!.. Ил өчен! Изге җир өчен!.."
Яңгырады көчле команда.
Өермә күк алга ташландык без:
Күргәнем юк андый давылны.
Кеше каны акты дәрья булып,
Эңгер кичтә алдык авылны...

* * *

Менә бер өй. Янып, авып төшкән,
Минем дустым шунда борыла.
Барып туктый утта янып, көеп,
Күмерләнгән гәүдә турына.
Баздан чыкты күрше карчык Рима,
Куенына алды Самиго:
— Я, әйт, әби... Әйт, син чын дөресен...
Кем гәүдәсе ята?.. Кем. монда?
Кырык карта кебек әби йөзе:
Мең газапның анда эзләре.
Күпме дәһшәт, газап, мыскыл күргән
Эчкә баткан аның күзләре.

Тетрәп төште әби. Сыны катты.
Уттай кайнар яшькә төелде.
Канлы еллар утын йоткан йөрәк:,
Нәрсә әйтер —
Куркып тордым алмый тынымны.
— Атаң китте партизаннар белән...
Җанын аямады көрәштә...
Әниеңне утка... — Әби бөгелеп төште
Сүзе шушы урынга җиткәч тә.
— Вера кайда?.. — Солдат, өмет баглап,
Әби күзенә өзелеп карады.
— Кудылар... Германиягә... —
Шуннан башка
Карчык бер сүз әйтә алмады,
Самиго бакты бакча капкасына:
Алмагачлар чатнап янганнар.
Ул үстергән чия, грушалар
Күмер булып көеп калганнар.
Йөрәгендә солдат чыдамлыгы,
Көнбатышка ярсып карады;
Дошман тубы гөрселдәгән якка
Утлы караш чәнчеп кадады.
Шыкырдатып кысты автоматын,
Тоткан җирдән, гүя, өзелде.
Бу — солдатта., изге көрәш өчен,
Тагын бер кат биргән ант иде.

* * *

Мең атака, мең газаплар аша,
Украинаны азат иттек без.
Кара елан оялаган җиргә —
Германиягә килеп җиттек без.
Авыл. Бер өй. Солдат, ярсый-ярсый,
Кесәсеннән алды шырпысын:
— Ул яндырды минем авылымны,
Мин дә төртәм, янсын, ут булсын...
Кул калтырый, шыбыр тиргә батты,
Үзе еш-еш миңа карады.
Кысып изге кулда шырпы кабын,
Юк, ул утны төртә алмады.
Эчкә кердек. Җирән бер карт немец
Кызны буа, яньчи, изрәтә.

Җанындагы соңгы көчен җыйнап,
Кыз көрәшә, каршылык күрсәтә.
— Атам, җирән!..
— Немец сыгылып төште.
Йөрәгенә Самиго төбәде.
Косты фашист эчкән кеше канын,
Гомере белән барын түләде.
— Вера!.. Сөйлә... Нинди явыз җилләр
Сине китереп монда ташлады?
Йөрәк өзгеч сулкып, авыр сулап,
Солдат кызы сүзен башлады:
— Өч ел буе аңа хезмәт иттем,
Шушы җирән эчте канымны.
Бар гөнаһын инде җуяр өчен,
Ул теләгән минем җанымны...
Һуштан язды Вера, күзен йомды.
Оһ, мәңгегә була күрмәсен!..
Кара болыт үтте, кояш чыкты,
Чәчкә гомер, шиңмә, шиңмә син!
Бер минутка ачты күзен Вера,
Язгы кояш, гүя, елмайды.
Тагын йомды. Ярып йөрәгеңне
Шушы кызга биреп булса иде!
Һәрбер күргән сугыш дәһшәтләре
Йөрәккә ук булып тиделәр.
Күпме гөлләр фашист учагында
Чәчәк атмас борын көйделәр.

* * *

Канлы еллар инде күптән үтте.
Илләр гөл-чәчкәгә күмелә.
Сугыш сөремнәре очмасыннар
Дөньякайның аяз күгендә!
Болай әйтү, беләм, кардай йомшак,
Атом белән уйный патшалар.
Җир йөрәге шартлап ярылыр кебек,
Бу патшалар һаман шашсалар.
Без бит — халык. Түгел аңгыра сарык.
Алла хозурында — ак күңел.
Яшәмик без куркып, кан калтырап.
Горур булсын иманлы гомер.
Бомба, фәхеш, алдау, нәфсе колын

Изеп, күмеп бетерсәк барын,
Бәхет килер ямьле яздай балкып,
Оҗмах итсәк изге Җир шарын!

Гөрлә, тракторым

Зәңгәр күктә соңгы йолдыз сүнә,
Алсу төскә офык манылган;
Таңгы нурлар назлый басу өстен, —
"Сөреп киләм урман яныннан.

Гөрлә, НАТИ, кырлар күкрәгендә
Тасма буразналар сузылсын.
Тыныч таңның төренеп нурларына,
Ямьле яшьлек юлым узылсын.

Гөрлә, НАТИ, актар җир күкрәген,
Кара ефәк булып күперсен.
Үссен иген кагып дулкыннарын,
— Безнең хезмәт данга күмелсен.

Карт коммунист

Менә билет. Кырык елдан артык
Йөрәгемнең тора янында.
Партия исеме, мәгърур бер көч булып,
Сеңгән минем йөрәк канына.

Булды көннәр: уты, давылы да...
Октябрьда ялкын суладык.
Патша өнен көл күк күккә чөеп,
Якты тормыш, ирек яуладык.
Без көрәштек: ачы, кара язмыш
Мәңгелеккә бетсен, куылсын
Кайгы йөген кеше күтәрмәсен,
Сабый кебек гел-гел шат булсын.

Кеше йоткан черек Сивашны да
Ярып үттек, ай-һай димәдек.
Мең газаплар чиктек вакыты белән,
Әмма башны түбән имәдек.

Хасан күле мәңге шаһит булыр:
Самурайга сабак укыттык.
Күз акайтып, ачу чәчеп килгән
Акфиннәрне бозга утырттык.

Менә билет. Үттем аның белән
Бозлы сулар, утлар, давыллар.
Аның белән таулар күчерерлек,
Котып эретерлек көчем бар.

Әнә шулай-авыр юллар аша,
Без аттырдык илдә гөл чәчәк.
Айдан якты, кояштан да нурлы
Булсын өчен Сезнең киләчәк.

Еллар үтте. Куам сигез унны,
Җыерылды, маңгай, яңаклар.
Илгә әле биреп бетермәгән
Йөрәгемдә кайнар ялкын бар.

Бәхет

Комбайным гүя зур корабль
Штурвалга горур менәмен.
Дулкынлана арыш, гүя диңгез.
Шул диңгездә һәр көн йөзәмен.

Гөрли басу. Кайный данлы хезмәт.
Тирә-якны чорный моңлы шау,
Кызыл башлык киеп сулда тора
Күккә күтәрелгән очлы тау.

Күзем белән күреп байлыгыңны,
Йөрәк белән тоям, Туган ил.
Күз карасы бик. кадерле нәрсә,
Син дә шулай миңа, туган җир.

Мин — комбайнчы. Иген диңгезендә
Таңнан алып һәр көн йөзәмен.
Изге хезмәт аша ил алдында.
Бәхетемне күбрәк күрәмен.

Безнең еллар якты булсын өчен

Агыйделнең карап дулкынына,
Салмак кына атлап киләбез.
Яр башында ялгыз бер кабергә
Дулкынланып башны иябез.

Чал сакалын бабам сыйпады да
Сөйләп китте аның турында:
Егет гомере, көзге яфрак төсле.
Өзелеп калды шушы урында.

Бер яшь егет кышын вузда укып.
Кайткан иде жәен авылга.
Үткен теле белән тукмап йөрде
Кулакларны ул һәр адымда.

Кулак ана канлы хәнжәр сузган,
Егет йөрәгенән кан тамган.
Туган жирнен күкрәгенә сеңеп.
Жуелмаслык изге дан калган.

Тал-тирәккә күмелеп калган инде
Батыр комсомолец кабере.
Безнен еллар якты булсын өчен,
Жир куенына яшьли череп яткан.
Бер кешенең алтын Гомере.

Солдат анты

Без әткәйне сагынып сөйләп яттык.
Йокламадык. Сызылып таң атты.
Сугыш тынар, әткәң кайтыр, диеп
Төннәр буе анам юатты.

Тәрәзәдә январь, көн яктысы.
Жил әрнеде тышта, үкерде.
Хәбәр килде: әткәй һәлак булган —
Кайгы, ярып йөрәккә керде.

Ул чагында мин бер сабый идем,
Дошманымны юньләп белмәдем.

Тик шулай да нәни бармаклардан
Алар өчен йодрык төйнәдем.

* * *

Еллар үтте. Үсеп буйга җиттем.
Погон тактым ике иңсәмә.
Байрак үбеп, солдат анты бирдем,
Хезмәт итәм Совет иленә.

Мин ант иттем: безнең сыман шулай
Бер сабый да ятим калмасын.
Сугыш чыгып, тагын гөл бакчалар,
Авыл, шәһәр, утта янмасын.

Комсомол йөрәге

Сугыш кайный. Кызарып, уелып төшкән
Кан шәүләсе күкнең читенә.
Яраланып ауды солдат Таһир
Җир-ананың дымсу битенә.

Аңга килсә, үләт исе тулган
Землянкада ята сулыгып.
Ач яңаклы, чандыр җирән немец
Мәет төсле тора сузылып.

Бүре кебек комсыз, чәнчеп карый,
Кан суырган нурсыз күзләре.
Сары юшкын сеңгән теш очыннан
Сөзелеп чыга агу сүзләре.

— Сөйлә солдат... Күпме рус көче?...
Юмарт булсаң сугыш серенә,
Яшәү вәгъдә итәм, саран булсаң,
Канлы хәнҗәр йөрәк түренә.

Авыр сулый Таһир. Тын кысыла
Караланып көйгән ирене.
Җавап кыска: рус әрчер кердән
Елан оялаган жиреңне.

— Комсомол син... фриц үкерә, шаша,

Бер күгәрә йөзе, агара.
Инә белән тәнен тунадылар,
Тоз сиптеләр әрнү ярага.

Түзде солдат. Кучкыл канга баты,
Землянканың тынчу идәне.
Килде үлем. Шәфкать сорамады,
Сер ачмады, сыкрап баш имәде
Комсомолның мәгърур йөрәге.

* * *

Дүрт кыз — дүрт гөл

(Франция хөкүмәт суды Алжир патриоткалары Җәмилә, Жаклин, Байа, Джохорны үлем җәзасына хөкем итте.)

Дүрт кыз —
Дүрт гөл
Шомырт кара күзләр.
Мамык бүрек кебек бөдрә чәч.
Туган җирне ятлар таптаганга,
Ачу ташып, җаннар өзелгәч,
Чыккан алар көрәш мәйданына,
Бәхет яулап, ирек, яктылык,
Шиңмәсен, дип, яшьлек, корымасын,
Дошман тырнагында буылып.
Дүрт кыз —
Дүрт гөл
Үз илләрен
Кайнар сөю белән сөйгәннәр.
Шуңамы соң нәфис кулларына
Тимер богау алар кигәннәр?
Дүрт кыз —
Дүрт гөл!
Суд залында
Үлем җәзасына тартылды.
— Рәхмәт сезгә, "изге" әфәнделәр... —
Үтергеч бер көчле ирония
Кызлар йөрәгеннән атылды.
Дүрт кыз —
Дүрт гөл
Таш капчыкта

Үлем күтеп таңнар аттыра.
Алар жырлый көрәш, яшәү жырын,
Җилләр туктый, исми, тын тора.
Дүрт кыз каны әгәр жиргә акса,
Дүрт гөл үсеп чыгар Дөньяга.
Миллион йөрәкләрдән палачларга
Сүнмәс ачу, нәфрәт, үч ява.
Дүрт кыз —
Дүрт гөл,
Көрәш жыры жырлап,
Төн уздыра, таңнар аттыра.
Күз алдында шыксыз үлем шаша,
Ләкин —
Яшәү дәрте һаман яктыра.

Иман

Аллаһ биргән бәндәләргә иҗтиһадлык,
Кодрәт, шөһрәт, намус, гамь, рухи ныклык.
Атам-анам иман шартын салды жанга,
Әйтте алар: "Хак бел — кол булма алтынга".
"Гөнаһ белән басма", — диде газиз жирем, —
Түкмә гадел күкрәгемә харам тирең".
Киңәш бирде нәфис, зәңгәр, изге күгем:
"Һич уйнатма саф йөземдә керле күзең".
"Кара уең белән бакма, — диде Кояш. —
Харам булыр тамагыңа ризык һәм аш".
Син — Кояштан. Аңла шуны, мәгърур кеше —
Жир белән Күк мәхәббәтенең жимеше!
Тормыш — тәмуг, яшәү — зиндан яман затка:
Ил каргышы юләр итә аны хәтта.
Утлар кичтем иман шартын укый-укый,
Илләр гиздем "Ходай" сүзен тукый-тукый.
Тар-мар иттек без имансыз фашист йотын.
Саклап калдык иман белән дөнья котын!
Бу иманга яный хәзер атом-бомба,
Әйтерсең лә Жир сусаган пычрак канга,
Һич килешми бу ахмаклык акыл-аңга,
"Кеше" дигән бөек, шөһрәт, алтын жанга.
Шөкер, иман кайта заман заңы белән,
Җәяр кебек юлыбызга яшел келәм.
Яшеллектә газиз Аллаһ рухы булса,

Аңа Тәңредән зикер, гыйззәт тә кунса,
И, бәндәләр, ясасак хак иман-бомба,
Гаделсезлек йөрәгенә атсак аны,
Наданлыкны күмсәк әгәр кара җиргә,
Атар безгә хозур, нәфис, бәхет таңы!

Мөселман мәдхиясе

Мөселман күңеле айдай ап-ак,
Ак нур — Хак Тәгалә гыйззәте.
И бәндәләр, карайтмасак акны,
Бәхетле итәр Алла кодрәте.

Динебез Ислам — хаклык тәгълиматы,
Иманлы яшәүнең алтыны.
Җир йөзенә кара һич яктырмас
Аның шифалы ак ялкыны.

Мөселман Кояшы һәр кавемнең
Йөрәгенә гамь, кан, ямь салсын.
Җиһан киңлегендә мәңгелекнең
Якты йолдызлары балкысын!
2013.

Ләйлә

Төн.
Сугыш уттан кызу.
Порох исе дала чөмергән
Язгы җирнең дымсу күкрәгенә,
Яралангач, каным түгелгән.
Йөрәк тала. Гәүдә кискә кебек
Гер ташына гүя бәйләнгән.
Богаз киереп, үлем кара төндә
Мең мәртәбә мине әйләнгән.
Ят җирләрдә җәсәд черер диеп,
Җан өшеде, күңел әрнеде.
Курчак кебек матур, сабый йөзле
Сестра миңа яшәү, наз бирде.
Җәһәт кенә яраны бәйләде ул,
Аркасына җайлап яткызды.
Алып чыкты уттан,

Мәңге онытмам
Яз гөле күк чибәр яшь кызны.
Су эчерде. Кара күзләреннән
Шәфкать нуры тора тамарга.
Кояш кебек назлы елмаюын
Шифа итеп япты ярама.
Сорап белдем Ләйлә икәнен дә,
Сөйләр сүзем дөнья иде дә, —
Китеп барды, Калды кыз образы
Бөреләнеп мәңге күңелдә.
1999.

Хезмәт һәм моң

Хезмәткә хөрмәтең, Илшат, бәләкәйдән,
Аның алтын тамыры әткәң, әнкәңнән.
Ул тамырны иман шарты итә белдең,
Тормышыңда гыйззәтлеген бик күп күрдең.

Моң чыгардың эреткәндә салкын тимер,
Үзе бер моң булып үтә синең гомер.
Суыртасың җир астыннан "кара алтын",
Күтәрелә өскә гүя, моңлы ялкын.

Кара эшне акыл белән агартасың,
Авырлыкларны җиңәргә яратасың.
Синең өчен намус — яшәүнең яме,
Зур хезмәттә генә фәкать икмәк тәме.

Син күрсәттең кул көчеңнең гаделлеген
Туган җирнең ана кебек газизлеген.
Йөрәгеңдә хакыбызның нуры тулы,
Җырга күчте син яраткан хезмәт моңы.
2012.

Мәхәббәт уты

Күбәләк гөлләргә куна
Былбыл сайрый тирәктә.
Кояш булдың син, Гөлүзә
Ут кабыздың йөрәктә.

Мәхәббәт уты икән ул,
Янмасам ярар иде.
Мин барына да түзәрмен,
Сөюең булса изге.

Син чибәрсең, син гүзәлсең,
Телкәңнән бал тама.
Таңда бер җырлап җибәрсәң,
Сандугачлар уяна.

Яшик без фани дөньяда
Сайрашып сандугачтай.
Беребез булсын кайнар Кояш,
Икенчебез — якты Ай.
2013.

Агыйделкәй алкын

Агыйдекәй җыр-моң иҗат итеп ага,
Чал дулкыны азан әйтеп ярга кага.
Сукайлары оҗмахтагы Кәүсәрдәй ак,
Яшь ананың кайнар сөтедәй саф һәм пакъ.

Тау астыннан чыкса әгәр шашып елга,
Агыйделнең ак йөзенә гашыйк була.
Бер үбәргә мең газаплар чигә-чигә
Мәхәббәтен ярсый-ярсый эзләп килә.

Тик үпкәндә керле була иренкәе,
Нык кителә Агыйделнең күңелкәе.
Кыен икән саклау аклык бу дөньяда —
Кешегә, урманга, күлгә, елгага да.

Керсез кәгазьгә языла ак әсәрләр,
Анда төшә йөрәктәге сүз-гәүһәрләр.
И, "Агыйдел!" Ак җаныңа кертмә кара,
Каралардан арын да син акка кара.

Лилиянең туган көнен котлап

Син матурсың, бик гүзәлсең, Лилия,
Сине халык, дус-иш кардәш мактый, сөя.

Атлап китсәң назлы җилләр чәчең үбә
Гөлләр зурлап син чибәргә башын ия.

Тулган айдай балкый һәрчак нурлы йөзең,
Галибәнә сөеп карый ике күзең.
Әйткән сүзең гүя ширбәт, балдай татлы,
Кыяфәтең фәрештәләрдәй сыйфатлы.

Яңа пешкән тал чыбыктай буең нечкә,
Күңелкәең тулы, нык бай изге хискә.
Йөрәгеңдә рәйхан гөле хозурлыгы,
Алла биргән шәфкатьлелекнең зурлыгы.

Син намуслы, син эчкерсез, син гыйззәтле,
Ходай биргән сиңа бар илаһ кирәкне.
Шуңа күрә син бәхетле, и Лилия,
Синең алда авырлыклар гел баш ия.

Өйләнү фәлсәфәсе...
(Тукайга ияреп)

Утырганда уйга чумып бер көн ялгыз,
Килеп керде айдай балкып дустым Яндыз.

Әй тотынды ярсый-ярсый такылдарга,
Шатлануы түгел, имеш, юкка-барга.

Еллар үтеп, житеп килгәндә утызга,
Гашыйк булган җиләктәй бер чибәр кызга.

Әйттем менә: — син бит аттың күп кызга күз
Сөйгән ярың булгандыр бит инде бер йөз.

Җавап әзер: — Дөрес дускай, күп сайландым,
Ләкин матурлык алдында гел алдандым.

Шулай да мин хәзер инде һич кырыкмам,
Гарьлек булыр үтсәм өйләнми кырыктан.

Ул чагында кала безгә фәкать карт кыз,
Бит карт кызның йөзе — нурсыз, куены — боз,

— Алай булгач, ник сузасың, өйлән тизрәк,
Бит тимерне кызу чакта сугу кирәк.

Үтә дә күп йөрмә алтыннан тап эзләп,
Үтеп бара яшь гомерең кызлар күзләп.

— Анысы шулай: сиңа бит ул әйтү җиңел,
Әллә нигә шикләнә лә күя күңел.

Яшь булса да әллә нигә саргайган теше,
Үбешкәндә аңкып торды тәмәке исе.

Үзе болай эчкерсез ул: сөйли барысын да,
Эчә икән сырасын да, аракысын да.

Төзәтмәсә ул мәңгегә шушы хатасын,
Тыңламаса мине түгел, хәтта атасын.

Мин нишләрмен ул чагында әйтче, классташ,
Була калса бер вакытта ул чын алкаш.

Туса алкаштан әгәр дә гарип бала,
Шуннан нәселдә мәңгелек бер чир кала.

Ул алкашың әгәр күз атса башкага,
Менә шунда зур фаҗига да башлана.

Яратмыйм богаз чәйнәшеп яшәргә,
Җитмәс кебек көчем озак көрәшергә.

Шуны уйласам рухым төшә, дөнья ямьсез,
Була кайчак эчкән суларым да тәмсез.
— Бу сүзләрең белән мине күп ялкыттың,
Әле килеп тагы да шуны калкыттың.

Курыксаң өйләнмә, сөйләнмә һич тә,
Йокла чибәр кызлар күрә-күрә төштә.

Илеш һәм Баймак каймагы

Мин күп йөрдем яшенташтай яшьрәк чакта,
Изге Илештә, бай рухлы Баймакта.

Аларда да сызылып алсу таңнар ата,
Сугыш газабыннан җирләр сыкрап ята.
Авырлыкка үч иткәндәй даһи халык,
Тәңре-көчтән бөек илһам, иман алып.
Дару тапты Җир-Ананың ярасына,
"Гайрәт" дигән бу дарудан афәт сына.
Һәр җиңүгә дога кыла Урал бабай.
Ялгышсаң, бармак кага: "ярамый алай".
Дога-шифа. Аңлы җирләр юмартлана.
Әйтерсең лә, тәмле сөтле күркәм ана.
Дәрман бирә Баймакка, Илешкә Ходай,
Булсын өчен икесе дә нәкъ тулган Ай.
Кысыштырды ерак булса да юлларын,
Якынайтты йөрәк, күңел, хак юлларын.
Йөри-йөри аялкын дуслар арасында,
Мин күп күрдем яшәүнең ак, карасын да.
Бу илләрдәге халыкның йөзе якты,
Хәтерләтә Күк-кабак ачылган чакны.
Алар өчен хезмәт, намус, вөждан даны —
Хөр яшәүнең илтифатлы тәм каймагы.

Ватандашлар!

Бу сүз кайный йөрәгемдә — Ватан каны,
Авыр көрәшләрдә җиңгән иман заңы.
Язмышларда Ходай гыйззәт хозурлыгы,
Халкыбызның айбарлы, кәр горурлыгы.

Тар-мар иттек комсыз, ерткыч фашист явын,
Чәнчелдердек Җиргә корган гөнаһ тавын.
Ватан өчен дип ташландык мең-мең утка,
Гайрәт гамен күрсәттек алман алйотка.

Сугыш тынды. Җиңүчеләр җиң сызганып,
Ватан яралары өчен нык сызланып.
Тотындылар изге, гадел, күркәм эшкә —
Бизәргә илне гөл, чәчкәгә, җимешкә.

"Фронтовик" дигән сүз — җиңү символы.
Ватан даны. Шөһрәт чаңы. Гөзере олы.
Бу сүз нәзакәте белән Ватан тыныч,
Читләр өчен атом-бомбадай куркыныч.

Җир шары ул үзе — мәхәббәт йомгагы,
Һәр кавемнең үз мөлкәте, хакы, даны.
Әмма Ватан бер генә. Сөекле ата!
Без — баласы. Бала атаны ярата.

Яратыйк без Ватанны җан, кан белән.
Кордаш, юлдаш булсын зур мәхәббәт гелән!
Ватандашлар! Нәзакать — Алла гыйззәте.
Халык тәгълиматы — шуның бер сәнгате.
Гыйззәт, тәгълимат, сәнгать — яшәү ләззәте
Шунда инде бу гомернең мәхәббәте.

Тукай моңы

Изге халкың корыч һәйкәл салды сиңа,
Анда гасырларның рухы, моңы сеңә.
Анда инсаннарның олы мәхәббәте,
Ә шагыйрьнең мәңге сүнмәс зур бәхете.

Март җилләре һәр ел салкын карны ашый,
Апрель җиле канатында язлар ташый.
Рухың йөри язгы моңсу җилләр булып,
Сине мактап сайрый кошлар гөлгә кунып.

Зур шигъриятькә салдың алтын нигез ташы,
Син һаман да милләтеңнең йөзек кашы.
Булып калдың пәйгамбәре һәр гасырның,
Ачып бирдең гәүһәрдәй сүзләр асылын.

Карт йөрәк белән сөйләшү

Йөрәк әйтә: "Гел борчылдым синең өчен,
Аңламадың бит дөньяда яшәү көчен.
Ташлар ярдың, тирес чаптың, сабан сөрдең,
Ятылыкның кара ягын күпме күрдең.

Бер егылдың ачлыктан алҗып син, хуҗам,
Мин торгыздым үлмәсен дип мескен җан.
Кырык ямаулы бишмәт, иске чабата
Киеп йөрдең гарьләнмичә син яшь чакта.

Чибәрлегең һәм акылың торды ташып,
Сөйде шуңа күрә сине кызлар шашып.
Акыллы кыз карамый ертык бишмәткә,
Аңа кирәк ут егет мәңге иптәшкә.

Купты сугыш, йөрттем сине саклап кына,
Кадерен белми яхшылыкның ахмак кына.
Нык сугыштың, кайттың илгә Герой булып,
Чайкалдылар алларыңда кызлар тулып.

Һич белмим: әллә сөясең, әллә юк,
Шуңа күрә бирмим сиңа кайнар ут.
— Дөрес әйтәсең, йөрәк, янып сөймәдем,
Үтте гомер искән җилдәй — һич сизмәдем.

Булмагандыр миндә, бәлки, хак мәхәббәт —
Әллә язмыш, әллә ялгыш: бу ни хикмәт?
Әмма йөрәк, картаймыйсың, мин шуңа шат,
Килә яшисем хәзер гел сиңа охшап.

Сөясем килә, сөеләсем ханымнардан,
Дәртемдә ут, сүнмәгәндәй һаман дәрман.
Аңла йөрәк: син кал шулай мәңге яшь-яшь,
Акыл биреп яшә миңа, бул киңәштәш!

90 яшьтә уйланулар

Газиз туфракка тәпи басып китү —
Яшәү өчен Алла алдында ант итү.
Тормыш диңгезендә Акуладай йөзү —
Кайгы, хәсрәт, ялган, гайбәтләргә түзү.

Егермедә булдыммы мин Өлкәр йолдыз?
Дөрләттеме йөрәгемне утлы утыз?
Кырыкта кылны кырыкка шәп ярдыммы?
Илле җилен югәнләп Хажга бардыммы?

Ялкау җандай мышнамадыммы алтмышта?
Йөзгән җилдәй җебемәдемме җитмештә?
Сиксәндә сикереп, туксанда тупылдап,
Бәхет кудым, аумадым җиргә уфылдап.

Туксан! Зур сан!! Алдында тотам имтихан!!!
Я отылам, я котылам, и газиз Хан!
Аңла, Туксан: шагыйрь күңеле — тулган ай.
Тик шулай да кылдан нечкә бит безнең җан.
Имтиханда хаклык, гыйззәт бирсен Ходай,
Пычратма Айны надан укытучыдай
Имтиханны бирү дә, алу да авыр,
Нык күнеккән безнең моңа эчәк-бавыр.
Ал имтихан, Хызыр-Илъястай бул гадел,
Бәхет чәчкән Сәмруг коштай безнең кадер.

Авыр хезмәттә йончып, ял итеп алганда, бер строфа шигырь язып куя торган гадәтем бар. Алар бик күп. Шуларның берничәсе.

Ник корылган фани дөнья күп ялганга? —
Сугышалар каннар түгеп юкка-барга.
Уйламыйлар фәрештәләрнең иманын, —
Киләчәктә күрербезме бәхет таңын?

* * *

Карынымны ярып чыктың балам-гөлем,
И күз нурым, йөрәк-бәгырем, якты көнем;
Үс сөелеп иман белән булып матур,
Сынма җилдә, давылларда нык каты тор!

* * *

И газизем, аяк бастың киң дөньяга,
Юлдаш булсын зур бәхетләр — атла алга;
Гөлләр сипсен фәрештәләр юлларыңа;
Авыр булса, син сыкранма — түз барына!

* * *

Син хәзергә йокла, ял ит, и газиз җан,
Шифа булсын — җыр-моңнарым белән назлан.
Син тугачтын сихәт булыр кайнар сөтем,
Оҗмах кошым, җәннәт гөлем, и өметем!

* * *

Тормыш түгел бит ул шома көзге —
Көрәшәләр анда яман белән изге;
Йөргән җирең булмас һәрчак чәчкә дә гөл,
Аяк асты тулы бәла — син шуны бел.

* * *

Дәрья төбе энже-мәрҗән белән тулы,
Аны чүпли оста ир-егетләр кулы;
Чүплә, улым, тормыш диңгезеннән энже,
Син шатландыр хаклык-иман белән безне.

* * *

Сабах җиле исеп тора илләр буйлап,
Исә төрле язмыш белән уйнап-уйнап;
Син яшә язмышлардан узмыш юк дип,
Чын яшәүнең мәгънәсе узмышта бит.

* * *

Алда әле башланган олы юллар —
Һәрберсендә күпме бәхет-сәгадәт бар?
Юллар илтә бәндәләрне киң дөньяга,
Шунда гына ул Үзенә гәүһәр таба.

* * *

Килә шатлык булып бу дөньяга бала,
Бөтен җиһан аны сөенеп каршы ала;
Ярты гомерен бирә һәр балага ана,
Нигә аны кайгыларга сала бала?

* * *

Купты җилләр, тайфун-давыл, дөнья кайный,
Котыра заман, бар дөньяны ялкын ялмый.
Илләр буйлап шашып йөри җәнҗал ташы,
Ниләр күрер бәндәләрнең газиз башы?

* * *

Бу дөньяга күзен ачкан мәлдә
Әверелер агу язмышка.
Ни ул шөһрәт — адәм үтерүчеме?
Я үлүме? Ни дип кан куша?

* * *

Әллә тәкъдир, әллә язмыш, әллә ялгыш,
Ни корыта адәм баласын?
Алда томан, михнәт, кылыч күпер, җәнҗал —
Беләме ул кая барасын?

* * *

Зәңгәр чишмәкәйнең суын эчтем,
Суын эчтем йөрәк янганга:
Кайгырмагыз, дуслар, кайгырмагыз,
Гомеркәйләр бик аз калганга.

* * *

Иң тәүдә пакълау кирәк эчнең керен,
Эчтә тулып ятмасын кара эрен.
Аһ, дуслар! Эч тазарсын, эч тазарсын —
Булмаса, файда бирмәс коры белем.

* * *

Таң, таң ата, Чулпан калка,
Чулпан — таңның көзгесе.
Шәфәкъларда нык балкысын
Гомеркәйнең изгесе.

* * *

Таң таң ата,Чулпан калка,
Чулпан таңны уята.
Таңда теләгән бәхеттә
Алсу чәчәкләр ата.

* * *

Юллар илтә безне усал язмышларга, —
Алданмагыз сез бәндәләр юкка-барга.
Чәчсәң бәхет орлыклары үсми калмас,
Канатларың авырлыктан бер дә талмас.

* * *

Урал батыр болай дигән:
Дөньяны матур төзегән —
Ул да булса яхшылык.
Күккә дә очар яхшылык.

Суда да батмас яхшылык,
Утта да янмас яхшылык.
Бар эшкә дә баш булыр,
Үзеңә дә, кешегә дә
Мәңге яшәр эш булыр.
Нур өстенә нур булсын, дигәндәй, аларга сүз энҗеләре өсти-өсти,

“жир уллары”, “яхшылык яу кайтара”, “яхшылык заяга китмәс”, “яхшылык иткән саулык урыр” кебек мәкаль-әйтемнәре дә ижат итә. Тик илаһилык алдында һәркем саждәгә китә алмый. Шуңа күрә дөнья тузына. Шаша. Котырына. Кеше белән язмыш көрәшә. Язмыш бәгъзе бер вакыт бәндәне уч төбенә утыртып, ул мескенне уңлы-суллы чапакларга тотына. Аннан җилгә әверелеп, аны әллә кайларга алып китеп олактыра.

* * *

Тормыш усал, бик аяусыз, авыр да ул,
Гөл утыртмый фәрештәләр юл чатына.
Калмый артыңнан кара сакал һич тә,
Менсәң хәтта күкнең җиденче катына.

* * *

Күзләремнең нуры бетсә,
Алырмын алсу таңнан.
Кояштан эссе сорармын,
Җылылар китсә җаннан.

Күктә дисәләр бәхетне,
Анда да менәр идем.
Хәлдән килсә юлларыңа
Таҗ гөлләр тезәр идем.

Йокла улым! Йөрәк хисен
Мин юрган итеп ябам.
Төннәр буе керфек какмый
Җырлар җырлармын һаман.

* * *

Фаҗига-шайтан олып йөри илләр буйлап:
Ник котыра, нигә шаша — ниләр уйлап?
Ул сусаган кешедәге җанга-канга, —
И, бәндәләр, бирмик язмышны шайтанга!

* * *

Бозыклыктан сынса илнең корыч биле,
Иссә гөнаһлардан елап кырыс җиле.
Булса явыз, канлы куллы патша-тәхет,
Алла бирми андый илгә иң зур бәхет.

* * *

Яши пәйгамбәрләр җаны күк катында,
Кан коеша инсаният юл чатында;
Бер-берсенә тими хәтта ерткыч-җанвар,
Нишләп кешенең кешедә нык үче бар?

* * *

Тормыш матур зур мәхәббәт, сөю белән,
Ләкин бәхет килми сөю белән гелән.
Ачы язмыш көлә адәм баласыннан.
Кан сораган, явыз, үчле шайтан сыман.

* * *

Табигать ул үзе оҗмах, сөю һәм гөл,
Аның эче зур мәхәббәт, син шуны бел.
Гыйшык уты күчкән кеше йөрәгенә,
Син — бәхетсез, янмасаң ул утта бер дә.

* * *

Патша азса, бөтен илгә килә афәт,
Халык азса, патша башы була харап.
Иле нинди булса, патшасы да шундый,
Надан патша белән бәхет корып булмый.

* * *

Исә җилләр. Ага сулар. Әйләнә җир.
Хәрәкәттә йолдыз, кояш, бөтен галәм.
Рух оча, югары аң, хис-тойгылар, —
Шул давылда хәрәкәттә даһи адәм.

* * *

Күктә — йолдыз. Суда — кондыз. Җирдә — дәһшәт.
Язмышларга кара яга нигә вәхшәт?
Кайда безнең гаршедәге югары аң?
Кайчан атар бәндәләргә бәхетле таң?

* * *

Җир әйләнә. Җирдән кан-яшь тама,
Тирән Җир йөрәгендәге яра.
Кан-яшьләрдә кеше язмышы бар,
Ә җир өчен иркен галәм дә тар.

* * *

Алла сыный бәндәләрне төрле яклап,
Кайгылардан очар кебек бу җир шартлап;
Юк, Җир сабыр, түзә барсына, чыдый,
Нык булырга аңа кушкан үзе Ходай.

* * *

Җир һаман да нык борчыла, кан-яшь түгә,
Гөнаһ колы булганнарны әрли, сүгә:
Ник юалар каннар белән аның йөзен,
Пычраталар шакшы җаннар дөнья күген?

* * *

Мәхәббәтне канга буйый кеше үзе,
Һәр гаделгә сукыр икән күңел күзе;
Бу сукырлык патшаларны талаштыра,
Яхшылыкны яман белән алыштыра.

* * *

Әйләнә Җир Кояш тирәсендә һаман,
Картая Җир, йончый, эштән чыга тәмам.
Гөнаһлылар күбәйгәнгә ул кайгылы,
Әрни, бозылганга җирдә хаклык юлы.

* * *

Җир шарында — аң, моң, мәхәббәт, хиссият,
И, Кеше! Бел: яшәү — гөл. Алйотлык — оят.

"Ил!" дия-дия, түксә тир, кан, кылынса эше,
Шунда гына була ала ул кәр кеше!

Яшь шагыйрь хыялы

Кайда качты мәргән сүзләр,
Ник тончыкты тел-келәт?
Чукынып китсен шигыре... —
Берлеккә керү кирәк.

Яшь драматург зары

Конфликт эзли-эзли,
Күзләрем чыкты минем.

Әгәр тапсам шул дуңгызны,
Шекспир булыр идем.

Яшь прозаик гаме

Проза бакчасы бик киң,
Кыпчак даласы кебек.
Кемнәр йөри икән анда:
Әллә мал, әллә киек.

300 җыр язган шагыйрьгә

Җыр капчыгы ертылган.
Бер җырыңны белә идем

Җырла дисең, җырла дисең,
Анысы да онтылган.

* * *

Язарга өйрәтә безне
Оста Рәхмәтулла.
Аңламаслар бит барыбер
Булыйк лучше мулла.

* * *

Сүзләр күп, мең вагон, диләр,
Ник алдыма түгелми?
Яшьли янса шигырь уты,
Картайгач та сүрелми.

* * *

Поэзия борып алды
Картайган көннәремдә.
Шигырь эзләп ыза чигәм
Йокысыз төннәремдә.

Фәрештә кыз

Нәфис атлап йөрүләрең — аккошныкы,
Тел тәмең, җыр-моңнарың — сандугачныкы.
Бөгелеп-сыгылып торган сының — яшь талныкы,
Зәңгәр күзләрең нурлары — тулган айныкы.

Керфек каксаң, күктә йолдызлар атыла,
Алар синең изге җаныңа тартыла.
Чын фәрештә булсаң бу дөньяда әгәр,
Ник мин түгел сиңа лаеклы пәйгамбәр.

Син гыйффәтле, син гыйззәтле, кешелекле,
Ходай биргән зур бәхетең мәңгелекле.
Чибәр кызга намус саклау — каһарманлык,
Алла хозурына бөек рухи аклык.

Сине сөям, Айсылукай, давылланып,
Сөйгән кебек Адәм үзенең Һавасын.
Нык яралы мәхәббәттән йөрәк,
Синдә күрәм аның илаһи дәвасын.

Яраларда гөлләр үсә, чәчкә ата,
Гөлләрем дә сине өзелеп ярата.
Бул сандугач, кун гөлемә, сайра, сайра,
Матур яшик мәхәббәтле бу дөньяда!
2008.

Кышкы кич

Кар өстендә кичке куксел нурлар уйный.
Йолдыз белән бизәкләнә зәңгәр һава.
Буран тынган. Җил дә исми. Табигать тә
Тынын, гүя, бик сакланып кына ала.

Тәрәзәдә моңсу булып утлар балкый.
Күтәрелә морҗалардан зәңгәр төтен.
Ак каеннар оеп утыра, селкенми.
Көмеш бәстән юрган яба аларга төн.

Чыңлады бер заман гармонь, тирбәнде моң.
Бозды яшьләр бу тынлыкны тора-бара.
Хис бөркегән кайнар җырлар ташкыныннан
Дулкынланды салкын йоткан кышкы һава.

Ай күз кыса шул вакытта тау артыннан.
Ай авылны алтын нурлар белән төрә,
Туган илнең чатнап торган суыгы да

Җанга ләззәт, күңелгә ямь, илһам бирә.

Их, Агыйдел, нинди ямьле син!

Яз!
Таллар бөгелеп төшкән
Агыйделнең ап-ак суына;
Акчарлаклар сөенеп балык чүпли,
Рәхәтләнеп казлар юына.
Көтү көтәм.
Комсомолның
Путевкасы йөрәк янында.
Кояш үрелеп тирәк очларыннан
Болыннарны үпкән чагында,
Монда булам.
Сыерларым
Керт-керт утлый бәрхәт үләнне.
Сауган чакта ап-ак сөтләр белән
Тулып ашсын кызлар чиләге.
Су коенам.
Агыйделнең
Дулкынында йөзәм, шаярам.
Балык төсле чумып югалам да
Су тибеннән чуер таш алам.
Көтү көтәм.
Сыерларым
Үләннәрнең чүпли тәмлесен.
Яз сулышы тулы яшел болын,
Су өстендә уйный бөдрә Дулкын,
Их, Агыйдел, нинди ямьле син!

Май!

Дөнья нурга чумган.
Бар табигать гөлгә төренде.
Бәйрәм бүген.
Йортка, капкаларга
Кызыл байрак таңнан эленде.
Май!
Калкып дымсу җирдән,
Күккә йотыла язгы йомшак пар.
Нурга чумган колхоз кырларында

Иген чәчәм — үкерә трактор.
Иген чәчәм.
Кояш җирне назлый.
Бит очымны үбә искән җил.
Кара балчык күперә бәрхет төсле.
Бәйрәм хөрмәтенә
Ике норма — бүген исәбем...
Иген чәчәм.
Илдә байлык булсын.
Ишелеп уңсын кырда игеннәр.
Май ае күк мәңге назлы, гөлле.
Күркәм булсын безнең гомерләр!

Тыпый ул гөлләр иле!

Авылым Тыпый! Кайттым сиңа бер карт бабай;
Халкың йөзе һаман шулай — тулган айдай.
Һәр тарафың йөрәк ачып каршы ала,
Әйтерсең лә, мин һаман да яп-яшь бала.

Мине котлап амин тота алсу таңнар,
Сәлам бирә Кәсәй таулар, очлы таулар.
Яшь кызлардай кул болгыйлар Маткай елга,
Җәмәк елга, Гүрде елга, Нәҗә елга.

Азан әйтә сәҗдә китеп Җирекле Карай,
Иман кайта бит авылга — и, котлы заман!
Түгәрәк күлдә туй ясый кошлар гаскәре,
Собханәлла, канат җәя бер Ходасы әзһәре.

Әйләндерелгән каберлек ак нур белән,
Анда җәелгән хуш исле чәчкә-келәм.
Күз алдыма килә җәннәт, оҗмах, бар җиһан,
Күтәрелде әткәй, әнкәй сиреннәр арасыннан.

Балкый алар ап-ак булып — оҗмах кошлары,
Апаларым, һәр туганым җыелды бары.
Юк булдылар күп тә үтми, күбәләк булып,
Китеп бардым авылым буйлап, күңелем тулып.

Исеп куйды мине назлап авылым җиле,
Чәчәкләрдән хуш-ис аңкый, Тыпый ул гөлләр иле.

Кайттым, авылым, сагнып-жирсеп, мин мәңгелеккә,
Тәнем калсын, җаным очсын көрси-җәннәткә!

Кызым Фәридәгә

И кызым, алмам, хөрмәм, бәбкәм Фәридәм!
Илле яшьтә хур кызыдай чибәр иркәм!
Җитезлегең тигез иде Өлкәр йолдызга,
Диләр иде: "Ай нуры бар бу кызда".

Гүзәл идең, эчке рухың тышка чыкты,
Ул балкыды йөзкәеңдә нәкъ кояш булып.
Шомырт кара күзләреңнең төпләрендә
Һәрвакытта торды тормыш яме тулып.

Шат идең, елмайдың изге, фәрештәдәй,
Кешеләрне сөйдең ихлас күңел белән.
Каушамадың авырлыклар алдында һич,
Илаһият юлдаш булды сиңа гелән.

Нишләп гомерең өзелде соң иртә шулай?
Әллә уйладымы синең хакта Ходай?
"Каралганчы ак күңеле бу баланың,
Үз яныма алыйм Инде аның җанын..."

Аерылышу кайгысыннан күңел тула,
Гәүһәр төсле күз яшьләрем шаһит моңа.
Ул яшьләрдә әтиеңнең мәхәббәте,
Олы сөю, кайнар тойгы хакыйкате.

Никах иманы

Никах мәхәббәт гөле ул,
Гөлнең чәчкәсе була.
Әгәр наз, гыйззәт җитмәсә,
Чәчкәгә кырау куна.
Мәхәббәт Алла рухы,
Рухта яшәү яме.
Пәйгамбәрнең иманы,
Тормышның күркәм тәме.

Никах ул Алла алдында

Хозур имтихан бирү.
Гөнаһлардан аерылып,
Иманлы юлга керү.

Юллар була ташлы, утлы,
Курыкмагыз утлардан.
Җиңеп яшәү генә матур,
Эзләмәгез ялган дан.

Өмет итсәгез җиңеллек,
Тел очрар авырлык.
Дуслашсагыз ялган белән
Кыйнар сезне явызлык.

Керсез булса күңелегез,
Гадел булса мәхәббәт.
Алладан алырсыз шәфкать,
Халык әйтер: "Рәхмәт!"

Алмаз — "асылташ" дигән сүз,
Наилә — "бүләк" була.
Асылташка алтын бүләк,
Бүләк Алмаз кулында.

Кулларыгыз ныклы булсын,
Йөрәкләр парлап типсен.
Кайда гына барсагыз да,
Сезне зур бәхет көтсен!

Рәхмәт, илем

Кем сындырган ап-ак ботакларын,
Ялгыз каен нигә корыган?
Ничә еллар мескен, яраланып,
Моң-зар Йотып гомер уздырган.

Әти-әни үлгәч, шул каенга
Башны терәп, үксеп еладым.
Каен кебек мин дә мәңге ялгыз,
Моңсу булырмын дип уйладым.

Каен кебек ялгыз мин булмадым,

Саргаймадым, шиңеп, көймәдем.
Илем мине корыч кеше итте,
Кайгы күреп, башым имәдем.

Нәрсә әйтим: ямьле яшәү биргән,
Күз карамдай Ватан — анама?
Рәхмәт, илем!
Минут, секунд саен
Мәхәббәтем сиңа яңара.

Исмә, әй җил, чиртмә тәрәзәсен...

Әкрен генә кичке шәфәкъ сүнә,
Зәңгәр күктә йолдыз кабына.
Тәрәзәңә карап туктап калдым,
Килгән чакта, иркәм, яныңа.

Ике күзең китап битләрендә:
Пәрдә аша күрәм шәүләңне, —
Гөлләр сузган алсу чәчәкләрен,
Якты нурлар кочкан гәүдәңне.

Бакчаң аша үтеп, мин дә сиңа
Сузар идем сирень гөлләрен;
Я булмаеа җырлап бирер идем
Син яраткан Сәйдәш көйләрен;

Сөйләр идем йөрәк, серләремне,
Уйларыңны килми бүләсәм.
Яп тәрәзәң — дулкын чәчләреңне
Язгы җилләр үбә күрмәсен.

Мин ышанам, дустым, син иртәгә
Имтиханын "биш"кә бирерсең:
ВУЗ залында, нәфис күбәләктәй,
Җилфер-җилфер балкып йөрерсең.

Ә хәзер моңсу карап үтәм
Якты төшкән койма буйларын.
Исмә, әй җил, чиртмә тэзәрәсен,
Бүлә күрмә аның уйларын.

Урманчылар җыры

Ап-ак бәсләр тармак ботакларга
Көмеш сырга булып үрелгән.
Җемелдәшә карлар,
Әйтерсең лә
Җиргә саф энҗеләр түгелгән.
Ә урманда көн-төн хезмәт кайный
Без кар дулкыннарын ерабыз.
Сөңге кебек төп-төз, озын, юан
Чыршы агачларын егабыз.
Балта чаңы, пычкы моңнарына
Бер кушылып җырлап аласың.
Их, күңелле эшләү сулый-сулый
Шул урманның таза һавасын!

Җәймә, әнкәй, мамык түшәгеңне

Җәймә, әнкәй, мамык түшәгеңне,
Тынып ята аталмам барыбер.
Мин авырмыйм инде. Өч көнгә ял
Врач белми генә биргәндер.

Минутлары еллар кебек озын,
Күңел сызлый болай ятудан.
Ач, булмаса, әнкәй, тәрәзәңне
Иген исе керсен басудан.

Иптәшләрем анда, ярыш башлап,
Җырлый-җырлый иген урадыр.
Бодай басуларын иңләп-буйлап,
Комбайннар гөрләп узадыр.

Аерылган ятим кыр казыдай,
Авыр мина ялгыз калуы.
Сагындырды инде бер көндә ук.
Дусларымның шаян шау-шуы.

Мин дә барам, әнкәй,
Эшләмәсәм,
Чәй кайнатып шунда ятармын.
Сәламәтлек тизрәк кайтсын өчен

Игеннәрнең исен татырмын.

Җәймә, әнкәй, мамык түшәгеңне.
Монда ятып мин ямь табалмам.
Китим кырга, шунда, ял итәрмен,
Түшәк ясап йомшак саламнан.

Хушыгыз, кырлар!

Кырлар! кырлар!
Сау булыгыз инде, —
Күзләремне тутырып, сезнең якка
Соңгы тапкыр карыйм каерылып,
ВУЗга китәм.
Әй, сез, тук башаклар.
Моңсуланып башыгыз имәгез:
Безне назлап, сөеп үстерде дә.
Ташлап китте үзе, димәгез.
Сез тагын ла туграк булсын өчен,
Белгеч булып бире кайтырмын;
Төннәр буе, чумып арагызга.
Серләремне сөйләп ятармын.
Әллә инде сабый чагымнан ук
Күкрәгеңдә аунап үскәнгә.
Әллә инде салкын чишмәләрнең
Гашыйк булып, суын эчкәнгә, —
Сез якынсыз туган анам кебек.
Ләкин аерылабыз без бүген.
Китсәм дә мин ерак-еракларга,
Саклар сезне минем күңелем.

Тәүге карлар

Карлар ява.
Мамык төсле карлар.
Ә мин кайтып киләм урамнан.
Әйтерсең, лә авыл
Ак кар түгел.
Ак чәчәкләр белән уралган.
Бер бөртеген тотып алдым карның:
Күбәләктәй менә монысы!
Сезнең беләп, карлар, көннәр буе

Әй уйныйсы килә, уйныйсы.
Әллә сезне артык сагынганга.
Урамнардан килми керәсем
Бодай кырларында мамык юрган
Түшәлүне килә күрәсем.
Карлар ява. Күктән әйтерсең лә
Саф энжеләр жиргә коела.
Яшькелт ужымнарга карлар түгел,
Бәхет яуган кебек тоела.

Иш булсын

Таңгы ямьне тоеп йөрәк белән,
Участокка сөенеп барам мин.
Шыгрым халык. Көчле дулкынланып,
Бюллетеньны кулга алам мин.

Ташып торган бәхет биргән илгә
Изге теләк тулы уемда.
Мең рәхмәт әйтсәм Партиягә,
Аз булыр күк һаман тоела.

Бюллетеньне салам. Минем тавыш
Миллионнарныкына кушылсын,
Туган илне гөлгә бизәү өчен,
Ямьгә күмү өчен иш булсын.

Тавышымны илнең улларына,
Батыр кызларына бирәм мин.
Киләчәкнең бүгеннән дә якты,
Бәхетле буласын беләм мин.
1958.

Агрономның башы шуңа күккә тигән

Агроном килә ялгызы
Басу буйлап.
Басу буйлап, тәмле иген
Җирен сулап.
Бер башакны өзә дә ул
Уып карый.
Уч төбендә гәрәбә кебек

Бөртек саный.
Игеннәргә карый да ул
Уйга тала.
Бит очында сүнмәс шатлык
Эзе кала.
Быел арыш башакларын
Түбән игән.
Агрономның башы шуңа
Күккә тигән.

Зөһрә йолдыз

Зөһрә Рәхмәтуллинага багышлана

Гаделсез бәндәләрне Аллаһ нык суга,
Түзә алмый Аллаһ гөнаһлы ярсуга.
Син кагылдың, Зөһрә, шакшы, шул кулларда,
Йөрттеләр сине утлы, канлы юлларда.

Син саф идең. Түздең. Көттең ак чынлыкны,
Күрсәттең: мөселман кызындагы ныклыкны,
Тик шулай да басты кара һөҗүм гелән,
Күп көрәштең шайтан, иблис, Хаин белән.

Эчең тулы энҗе, мәрҗән, иман иде,
Синең алда алсу гөлләр башын иде.
Илтеп куйды фәрештәләр ай янына,
Тынгы булсын өчен изге, хөр җаныңа.

Анда, Зөһрә, син йолдыз булып кабындың,
Ходайга аң, акыл, хис белән табындың.
Ай янында моң, нур чәчә Зөһрә йолдыз,
Яктырта дөньяны кыш, яз, җәй һәм дә көз.

Сагына Зөһрә җан, кан биргән җиркәен,
Давылларда чыныктырган хак илкәен.
Аллаһ йолдыз итте бит аны мәңгегә,
Иман нуры коеп торырга изгегә.

Батыр Зөһрә! Сиңа Ислам дине юлдаш,
Амин тота һәр изгеңә кайнар кояш.
Һаман шулай мөселманча нык бул, түзем,
Хәерхаһ нур белән назла илләр йөзен!

Картайгач уйланулар

Ярсып-шашып шигырь яздым яшь чагымда,
Утлар чәчри иде шигъри учагымда.
Ул утларда кара тормыш яна, гүя,
Минем алда илаһият башын ия.

Яшь акылым оча, йолдызларны гизә,
Пычрак күрсә, вата, җимерә, яньчи, изә.
Әллә ниләр уйлап хыялланам тәмам, —
Юньсез патшаларга бомба булып явам.

Баз казыймын яман, надан юлбашчыга,
Ялагайга, гайбәтчегә, алдакчыга...
Кырып бетергәч дөньяда шакшы җанны,
Мин балкытам кешеләргә алсу таңны.

Төзим Җир шарында оҗмах, рәхәт тормыш,
Була төп-төз хәзер инде кыек язмыш.
Яздым шулай өем-өем шигырь тәмләп.
Булмый икән шигырь белән дөнья ямьләп.

Каләмемне яктым утка нык ачудан,
Һәм котылдым шигырь язып мин ярсудан.
Картайгач язарга булдым тагын да бер,
Аңлашылсын дип кешегә безнең гомер.

Авырлыкларны үлчәсәң — миллион тонна,
Ип каралары пычраткан безнең җанны.
Әйтәләр бит: узган гомер — сүнмәс күмер,
Үтәсе бар кылдан нечкә изге күпер.
Нык картайдым, күп уйларга вакыт бик тар
Мәңгелеккә ак, пакь килеш китәсем бар!

Яңа оя

Капка түбәсенә Марат
Бер оя ясап куйды.
Кара, аңа нинди матур
Сыерчык килеп кунды.

Сайрый сыерчык, куана:

— Нинди яп-яңа оя?!
Марат читтән генә моңа
Елмаеп карап куя.

Киң кырлар буйлап очар ул,
Чыгарыр тагын бала.
Ул бүген оя башында
Шатлыктан канат кага.

Менә шулай шат яшәр ул,
Сайрый-сайрый, сыерчык.
Чөнки бездә иркен тормыш,
Безнең илдә тынычлык.
1954.

Кечкенә Гали

Капка төпләрен Гали
Бик тырышып көрәде.
Очты читкә җемелдәп
Йомшак кар бөртекләре.

Кайберәүләр әйтәләр
“Гали ул эш ярата.
Өелеп торган карны
Төрле җиргә тарата”.

Беренче дулкынлану

Хисләремне көчкә тыеп тордым.
Алган чакта класс журналын,
Шатлыктанмы, әллә борчылудан
Калтыранып куйды кулларым.

Хезмәтемне аклый алырмынмы
Ышанычын туган илемнең, —
Шуны уйлап йөрәк дулкынлана",
Борчылуы шуңа күңелнең.

Звонок та булды, зал шаулады,
Ачып керәм класс ишеген.
Шат балалар басып каршы ала,

Дулкынланмый шул чак нишлим мин?

Дулкынлану... каушау... борчылулар
Түгел бер дә куркып калудан;
Миңа ышанган балаларның
Язмышлары өчен янудан.

Кеше һәм аракы

Әйткән бер көн аракыга әрнеп кеше:
— Юктыр бу дөньяда яман синең ише.

Бөтен бозыклыкның килә синнән башы,
Иң җирәнгеч эшләрнең дә син юлдашы.

Сине эчеп азмы йомшый батыр ирләр,
Күпме ястык була аңа пычрак җирләр.

Син кашыйсың кесәдәге соңгы тинне,
Күпме кешеләрне ярлы иттең инде.

Берәү менә акрын-акрын гына өскә,
Гомер буе күтәрелә көчкә-көчкә.

Һәм була ул мәртәбәле бөек кеше,
Гасырларда калыр иде кылган эше.

Дуслаша да шундый зур зат синең белән,
Килеп төшә баткаклыкка ул йөзтүбән.

Сине эчеп харап булды күп начальник,
Бу эшләрең, и аракы, бик начар бит.

Күп тыңлагач әйткән кешегә аракы:
— И бәндәкәй, юк бит бер сүзең яраклы.

Бу дөньяда юк акыллы минем кебек,
Куйган җирдә тора алам мең ел түзеп.

Соң, үзең бит кузгатасың урынымнан,
Киләсең дә син аласың муенымнан.

Һәм саласың стаканга вылт-вылт итеп,
Эчеп җибәрәсең, комсыз, голт-голт итеп.

Шуңа күрә сиңа минем ачуым яман,
Һич жәлләми баткаклыкка сузып салам.

Син атасың аунап шунда чучка кебек,
Ләгънәт укып китә сине күпләр күреп.

Бармы минем аунап яткан чагым җирдә
Башым һәрчак нык кадерле, урыным түрдә.

Шулай булгач, кем соң боза бу дөньяны,
И бәндәкәй, бик нык кына уйла аны!

Тамаша

Яна йөрәк, шаша күңел вакыт-вакыт,
Нигә шулай? Һич булмый сәбәбен табып.
Нейронда тамаша кыла ак, кара уй,
Аларга бул, гүя, кызык бер сабантуй.

Яман давыл куптара кара тамаша,
Ак тамаша изге ул — күңелне ача.
Шулай булды гәзиз ак журнал "Тамаша",
Донъяны танып-беләбез аның аша.

Анда иман, анда илаһ, анда сәнгать,
Хис-тойгыга акыл бирүче шәфәгать.
Ул өйрәтә белергә ак һәм караны,
Төзәтергә йөрәктәге күп яраны.

Дөньяга килдең син балкып, ак "Тамаша",
Әллә күпме авыр, кара юллар аша.
Инде сәхифәңдә булсын күркәм сәнгать,
Нур таратсың сәнгатьтәге асыл шәфкать.

Ләлә
(поэма)

Саф аяз кич.
Юлдан син киләсең.

Моңсу нурлар борчу йөзеңдә;
Салкын карның көмеш тавышлары
Чыңлап кала баскан эзеңдә.
Син киләсең, Ләлә,
Мамык шәл читләрең
Ап-ак, бәсләр белән бизәлгән.
Кем соң сине салды кайгыларга,
Нигә шулай
Моңсу башың түбән иелгән?
Ник көлмисең.
Нигә элеккечә
Көләч түгел синең йөзләрең?
Керфекләрең түбән иелгәннәр?
Керфекләргә
Күмелгәннәр зәңгәр күзләрең.
Нигә элеккечә
Сокланып бер карамыйсың.
Йолдыз белән
Бизәкләнгән зәңгәр һавага?
Яшь күңелең синең сулкып сызлый.
Син уйлыйсың һаман, һаман да:
“Сөйдем аны,
Сүнмәс, сүрелмәслек
Кайнар сөю белән, сөйдем мин;
Аның өчен типте яшь йөрәгем,
Аның өчен яндым, көйдем мин.
Сөйдем аны,
Чишмә суы кебек
Саф күңелем белән сөйдем мин;
Бу сөюнең көчле ялкынынннан
Көзге гөлләр кебек көйдем мин.
Нигә сөйдем. Нигә давыл төсле
Ут кабыздым тыныч йөрәккә...
Оһ, ул утлар мәңге, сүнмәсләр...
Шушы уйлар борчый бигрәк тә!
Яшьли сөйгән Яшьлек өметеңне
Онытып булмый, диләр, гомергә;
Онытыр идем дә.
Мәхәббәт язгы гөлләр төсле
Йөрәгемдә чәчәк атмаса:
Шул чәчәкне өзеп усал җилгә
Туздырырлык миндә көч булса.

Туздырырсың...
Әгәр башка берәү
Күңелеңне били алмаса...
Гомер буе шулай ялгыз калсаң.
Икенчене сөеп булмаса.
Уйлар...
Оһ, бу шомлы тирән уйлар
Күңелемне талый бигрәк тә.
Нигә сөйдем,
Нигә давыл төсле
Ут кабыздым тыныч йөрәккә.

* * *

Язгы яшен төсле берәү килә.
Аңа таба берәү ашыга:
— Ләлә!.. Бер минутка... тукта инде...
Килеп баса аның каршына.
— Ләлә! Тагын килдем... ни дисәң дә
Вәгъдәм минем сиңа бирелгән.
Минем бәхетем синең кулларыңда,
Син чыкмассың мәңге күңелдән.
Биш ел буе сине сөю хисе,
Сагыну хисе белән яндым мин;
Синең белән бергә постта тордым.
Давылларга каршы бардым мин.
Ләлә!..
Кара миңа...
Я, бер генә
Зәңгәр күзләреңне текә дә
Кара миңа...я дим...
Я дим инде...
Карамыйсың:
Оһ, йөрәгем яна, үртәлә.
Ләлә!
Аңла мине...
Әйдә китик...
Матур шәһәрләрдә торырбыз.
Менә диген тормыш корырбыз.
Ни дисәң дә шәһәр шәһәр инде.
Анда танцы, парк, кинолар...
Ә авылда?
Әйтче, я ни бар?

Син беләсең:
Мин бит моряк кеше. —
Мин өйрәнгән җилгә, давылга;
Шулай, Ләлә, шашкын күңелләрем
Сыя алмас инде авылга.
Без барасы шәһәр шундый ямьле.
Урамнары аның таш кына.
Ник яшәргә безгә, я әйт... нигә...
Артта калган шушы колхозда.
Син дип кайттым,
Сине генә сөям,
Синең өчен
Таш ватармын, илләр гизәрмен:
Эшләмәссең дә
Нәфис чәчәк төсле
Алсу ефәкләргә бизәрмен.
Мин яшәрмен синең бәхетең өчен,
Теләмисең, шуны аңларга.
Ни җитмәгән сиңа шул фермада
Сарык арасында аунарга.
Ун ел укын.
Урта белемеңне
Сарык карар өчен алдыңмы;
Яшьлек акылыңа буйсындың да
Үз бәхетеңә аяк чалдыңмы?
Ләлә!..
Ник дәшмисең,
Нигә шулай
Башларыңны түбән иясең
Күзләрең ук әнә әйтеп тора:
Син бит мине, беләм: сөясең.
Ләлә!
Я бер генә,
Тутырып кара миңа
Элеккечә көләч йөз белән:
Назла минем боек күңелемне
Яз нурыдай җылы сүз белән.
— Нәрсә дим, Наил!
Биш ел буе зарыгып көтүемне
Тагын бер кат сөйләп чыгыйммы:
Эчләремдә дөрләп утлар яна,
Шул януга һаман чыдыйммы.

Кайтуыңа тиздән өч ай тула,
Өч ай буе
Китәбез дип тидең жаныма.
Нигә һаман булмас сүзләр сөйләп,
Тоз саласың инде каныма.
Кая китик?
Нигә?
Нәрсә өчен?..
Жиңел кәсеп эзләп чабыйкмы;
Вөжданыбызны салып су төбенә,
Карт анабызны ташлап качыйкмы?
Безнең колхоз һаман артта бара,
Икмәкне дә, дисең, аз бүлә.
Егетнеңме көчле ихтыяры
Алырлык алдында бөгелә.
Ачуланма, Наил,
Жаным әрнегәнгә
Бәреп әйтәм бүген күзеңә.
Оч ай буе һаман жил куасың:
Бөтен авыл халкы
Нәфрәт белән карый үзеңә.
Син бит шушы жирнең суын эчеп,
Туфрагында аунап үскәнсең.
Ничек соң ул сиңа бүген генә
Ят, күңелсез булып киткән соң?!
Ярый, Наил...
Минем сүзләремнең
Кирәген дә инде тапмассың.
Я, хуш!..
Беләм:
Күпме тырышсам да
Фикереңнән кире кайтмассың.
— Ләлә!
Тукта...
Соңгы тапкыр
Я, әйт әле миңа нишләргә?
— Наил!
Туган жирең,
Туган колхоз өчен
Жан кызганмый тырышып эшләргә.
Ә мин...
Минем барлык уем, хисем,

Күңелем минем туган авылда;
Моннан мине көчле өермә дә,
Куптаралмас җил дә, давыл да
Болар минем соңгы сүзем, Наил,
Әйдә китәбез, дип,
Килмә бүтән, килмә яныма.
Сөйлисең дә эч пошыргыч сүзләр,
Тоз саласың минем каныма.
Ләлә китте.
Наил калды ялгыз,
Хисләреннән көчкә тыелып;
Әйтерсең лә очты күңел кошы,
Очты бәхете исәр җил булып.
Учлап алды кулга салкын карны,
Басар өчен йөрәк ялкынын.
Ул ялкыннар... оһ, ул ялкыннар
Сизәме соң аның салкынын.
Ничек соң бу?!
Нигә мәхәббәтнең
Ялкыннары көчле була икән?
Нигә кеше аның ялкыныннан
Көзге гөлләр кебек сула икән?
Диңгез дулкыннары шауласалар.
Бер басыла — мәңге түгелләр.
Мәхәббәттән әгәр дулкынланса,
Һич басылмый икән күңелләр.
— Әллә калыргамы...
Яшьлек дустым,
Мәхәббәтем, бәхетем янында?
Юк, юк...
Һаман мин-минлеге
Җиңеп кала аны тагын да.
—Әйткән икән, беткән...
Егет сүзе
Ике булмас — бары бер булыр.
Бу ялкында мәңге янмам әле,
Берәр вакыт сүнәр, онытылыр.

* * *

Кичке тынлык.
Ләлә ут янында
Ялгыз гына альбом актара.

Актара да тирән уйга тала.
Үткәннәрен уйлап уфтана.
Менә Наил.
Моряк киемендә
Шундый матур-карап туймассың,
Өзелеп-өзелеп күпме карасам да
Инде син минеке булмассың.
Моңсу күзен Ләлә теки аңа,
Кысылып кала кинәт сулышы.
Их, син, Наил,
Иркәм, көт, диюең,
Яратуың инде шушымы?
Нигә сөйдем, нигә давыл төсле
Ут кабыздым тыныч йөрәккә.
Оһ, ул утлар һаман сүнмәсәләр,
Шушы уйлар борчый йөрәктә.
Әкрен генә барды тәрәзәгә.
Тышта бүген
Ак чәчәктәй матур кар ява.
Ә Ләләнең гөлдәй керфегеннән
Тамчы-тамчы кайнар яшь тама.
Тышка карый Ләлә.
Өй янында
Сирень тора ялгыз моңаеп.
Аңа хәзер бераз күңелсездер,
Сагынып көтәдер ул май аен,
Яз җиттеме — сирень куаклары
Язны ямьләп, яфрак ярырлар.
Ә Ләләнең өмет гөлләре
Чәчәк атмый шиңеп калырлар.
Яз җиттисә — сирень куаклары
Яшел яфрак белән төренә.
Ә Ләләнең килер язлары
Бик ямансу булып күренә.
Төне буе яуган ап-ак карлар
Таң алдыннан гына туктады.
Карлар яуган ферма юлы буйлап,
Әкрен генә Ләлә атлады.
Төне буе сызлап янган йөрәк
Таң алдыннан бераз басылган,
Давылдан соң бераз вакытлыча
Тынын калган көчле җил сыман.

Ачып керә Ләлә зур капканы.
Каршы ала аны сарыклар.
Онытылды әрнү, пошынулар,
Басылгандай булды кайгылар.
— Әй, сез минем йөнтәч пәриләрем;
Анагыз бит килгән, күрмисез,
Туктагызчы, зинһар, сарылмагыз
Атларга да ирек бирмисез.
Абау, бигрәк матур монавысы,
Туя алмассың карап, сокланып.
Ике күзен текәп йөнтәчләргә
Озак торды Ләлә тукталып.
Озак торды, тагып борчу утлар
Телгәләде кызның йөрәген.
Нигә менә өзелеп сөйгән яры
Аңлап житми аның йөрәген.
Сарык, арасында аунаучы дип,
Күңелемә нигә кагыла.
Чобалган уй башта, дулкынланып,
Шашкын елга кебек агыла.
Белемем белән,
Яшьлек дәртем белән,
Комсомолның
Путевкасы белән килдем фермага.
Ни кирәк соң миңа...
Ә ни житә
Үз эшеңне сөеп эшләүгә
Хезмәт кенә, фәкать хезмәт кенә
Ямь, матурлык бирә кешеләргә.
Кайчагында кинәт шулай була:
Кайгы артыннан килә кайгысы:
Биш көн инде менә печән житми:
Ләлә бүген
Сарыкларга сала соңгысын.
Ә житмәсә жиле чыгып тора,
Купса әгәр салкын бураны;
Йөнтәчләрем печәнсез дә калса...
Төрле уйлар аны урады.
Төрле уйлар аны урап алды,
Озак торды Ләлә тукталып;
Яшьлегенең моңсу хәтирәсен,
Йөрәк өзгеч ялгыз киләчәкнең,

Барын, барын уйлап, уфтанып.

* * *

Урам уртасында гына
Трактор тора.
Өч көн инде бер яшь егет
Суккалый, бора.
Тракторның эше начар —
Туңган бозланып;
Язсыз, бәлки, еремәс тә,
Китмәс кузгалып.
Тирәсенә җыелганнар
Егетләр, кызлар.
Өметләнеп көтеп тора
Унлаган күзләр.
Урам буйлап Наил килә,
Горур адымы.
Сүзсез генә, салкын каршы
Алдылар аны.
Кызлар арасыннан ике —
Ачы теллеләр
Чәнечкеле сүзләр белән
Аны күмделәр.
Кайткан берсе армиядән
Борын күтәрә.
Күкрәк киереп йөрүенә
Җаным үртәлә.
Шәһәр урамына әллә
Тозлы су сипкән;
Әллә бәхет анда гына
Явамы күктән.
Тракторны ничек оста
Йөртәдер иде.
Бөтен авыл сагнып аны
Көтәдер иде.
Китканче бөтен авылны
Ипи ашатты.
Армиядән нигә шулай
Очынып кайтты.
Берсе әйтә: — Егет булса,
Кабызып бирсен;
Пускай, аннан кесәсенә

Кул тыгып йөрсен.
Икенчесе: — Бу эш аның
Кулыннан килмәс;
Килсә дә ул безнең белән
Вакланып йөрмәс.
Кулыннан килмәс дию
Каты ишетелде.
Ачу кабарды Наилдә,
Күңеле кителде.
— Кулдан килмәсә, дөньяда
Яшәмим — диде.
Кайтты да өйгә тиз генә
Комбинезон киде.
Киде дә тәрәз янына
Килеп баш иде,
— Менә дурак... я ни өчен
Котырдым инде.
Нәрсә калган миңа анда
Кул пычратырга.
Бәлки, "җан" да кертеп булмас
Ул тракторга.
Ә, юк, кеше куркып калган
Икән димәсен.
Җебегән дип уйламасын,
Миннән көлмәсен.
Күрсеннәр әйдә Наилнең
Кем икәнлеген;
Калсын сагнып сөйләр өчен
Бер истәлегең.
Ачу иткәндәй боларга
Буран котырды.
Җил дөньясын яңгыратып,
Сызгырып торды.
Сызгырма син, җил, сызгырма,
Котырма, буран;
Кар давылына күмелмә,
Күмелмә урам.
Шауласаң шаула син, буран,
Котырсаң, котыр.
Гөрләтте авыл буйларын
Безнең трактор.
Буран дулый, буран дулый,

Мотор котыра.
Мамык карлардан трактор
Алга омтыла.
Җыелдылар, шатландылар —
Кызлар, егетләр.
Бит очлары янып тора,
Роза кебекләр.
Җыелдылар, уйнадылар,
Шаулап көлделәр;
Җырлый-җырлый киң чанага
Бар да менделәр.
Ә Наилне җылы назлы
Сүзгә күмделәр:
— Әйдә, Наил, гөрләт моторны
Калсын безгә сагынып сөйләргә;
Ой, Наил дус, Наил, колак сал
Безнең җырга, безнең көйләргә.
Сибелә чәчем, сибелә җилферди
Таңда искән җиләс җилләргә;
Гөлләр күкрәп чәчәк аталар
Безнең туып үскән җирләрдә.
Иртүк торып, алсу таң белән
Сулар сибәм зәйтүн гөлемә,
Яшьли сөйгән гүзәл ярларны
Онытып булмый, диләр, гомергә.
Әйдә, Наил, гөрләт моторны,
Калсын безгә сагынып сөйләргә,
Их, күңелле яшәү бергәләп
Туып үскән матур җирләрдә.
Җыр агыла зәңгәр һавада,
Мотор гөрли, мотор котыра.
Ә трактор иркен кырлардан
Карлар ярып алга омтыла.
Җыр яңгырый зәңгәр һавада,
Уйлар йөзә Наил күңелендә;
Йөзә дә ул очып югала,
Тотып булмый ләкин берен дә.
Күз алдыннан йөгереп үттеләр
Сабый чаклар, мәктәп еллары
Ул чагында шушы машинага
Утыру өчен күпме янмады.
Ә ул хисләр моряк күңелендә

Тора-бара сүнде, сүрелде.
Әллә еллар аны җуйдылармы,
Әллә диңгездәге
Дулкыннарга чумды, күмелде;
Ләкин алар менә бу минутта.
Кабат янды, кабат терелде.
— Әллә калыргамы
Яшьлек дустым
Мәхәббәтем, бәхетем янында;
Төннәр буе сабан сөрер идем
Җырлый-җырлый кырда тагын да.
Кал син, Наил,
Тиздән яз да килер,
Яз көннәре
Их ямьле дә була кырларда;
Яз һавасы шундый җиңел була —
Күкрәкләрне тутырып суларга.
Кал син, Наил!
Ямьле яз көнендә
Җырлый-җырлый сабан сөрерсең;
Яшьли сөйгән гүзәл ярың белән,
Ләләң белән парлап йөрерсең.
Әйтмә алай:
Ташкын күңелләрем
Сыя алмас, диеп авылга.
Син чыгарсың кырга
Алсуланып,
Язгы таңнар аткан чагында.
Һәм суларсың язгы җиңел парны,
Чәчәкләрнең исен суларсың;
Салкын чишмәләрдән су эчәрсең,
Хәтфә болыннарны буйларсың.
Табигатьнең серле матурлыгы
Күңелеңне назлар, иркәләр.
Их,
Күпме шатлык,
Күпме җылы хисләр
Алып килә язгы иртәләр!

* * *

Кич.
Көндез котырынган.

Буран тынган, буран туктаган;
Җил дә исми,
Әллә ул да инде
Берәр җиргә кереп йоклаган.
Кич.
Ферма.
Тирә яклар
Яшьләр шавы белән күмелде.
Салкын һаваларны ярып үтте
Матур итеп кызлар көлүе.
Кич.
Ләлә ялгыз гына
Өй янына килеп сөялде.
Ирексездән сулган гөл чугыдай,
Керфекләре түбән иелде.
Зәңгәр күктән нидер эзләгәндәй,
Йолдызларга таба карады.
— Уф!..
Мәхәббәткә дучар булган йөрәк
Һаман шулай әрнеп янармы?!
Куш каеннар аерылса да
Аерылмам дигән идем;
Ай белән кояшка тиңләп,
Өзелеп сөйгән идем.
Аның өчен гомер буе
Йөрәгем янар инде;
Кайгылары басылса да,
Моңнары калыр инде.
Кинәт көчле мотор тавышына
Яңгырады ферма буйлары.
Мотор тавышына күмелеп калды,
Бүленеп калды аның уйлары.
— Трактор!..
— Печән!..
Кызлар шатлыгыннан
Кул чаптылар, шаулап көлделәр.

* * *

— Әйдә бушатышыйк...
— Әйдә!.. Кызлар
— Печән... печән... печән... —диделәр.
Тракторга каршы йөгерделәр,

Ә трактор
Кырлар ярып алга омтыла
Ә рульдә...
Тукта.
Ничек соң бу...
Наил утыра?
Ышанмады Ләлә
Әллә башка берәү
Наил булып шулай күренә,
Юк — ул.
Сәйлән бөртегедәй
Шатлык яше килде күзенә.
— Наил!
Кызлар барысы да:
— Наил бит бу, Наил! — диделәр.
— Шатлан, Ләлә!
Кызлар Ләләне
Тоттылар да күккә чөйделәр:
Күп тә үтмәде,
Менә трактор да
Килеп туктады.
— Иптәшләр!..
Берәү кул күтәрде
Бер минутка бар да тындылар.
Тындылар да
Нәрсә әйтәчәген
Тын да алмый көтеп тордылар.
— Иптәшләр!
Ягез әле,
Яхшылыгы өчен
Күккә чөйик хәзер без аны.
Кечкенәдән бергә уйнап үскән
Дустыбызны, Наилне.
— Әйдә, әйдә...
Шунда ук Наилне
Урап алды кызлар, егетләр;
Бит очлары янып тора
Мәк чәчәге кебекләр.
Бар да уңган, бар да җитезләр,
Бар да җитез, бар да ут кебек
— Раз... два...әйдә...взяли...
Очты Наил күккә туп кебек.

Бу минутта, әйе бу минутта
Төрле уйлар йөзде күңелендә:
— Калыргамы әллә дуслар белән
Авылымда, туган җиремдә,
Кал син, Наил!
Ямьле яз көнендә
Җырлый-җырлый сабан сөрерсең,
Яшьли сөйгән
Яшьлек дустың белән,
Ләләң белән парлап йөрерсең.
Болыннарның серле матурлыгы
Күңелеңне назлар, иркәләр.
Их,
Күпме шатлык,
Күпме җылы хисләр
Алып килә язгы иртәләр!
Кичке тынлык.
Әй түгел лә,
Ничек инде
Шаулы дөнья кинәт тынсын ди;
Ник табигать, кайгы йоткан төсле,
Тын да алмый тып-тын торсын ди.
Әнә бераү
Өзеп-өзеп тальян гармонь уйный, —
Моң агыла авыл өстендә.
Клуб тирәсендә яшьләр шаулый.
Кичә бара аның эчендә.
Тирәсендә бәсле каеннарның
Тәлгәшләре түбән иелгән,
Тәрәзәсеннән Ильич утларының
Якты нуры ерак сибелгән.
Шул нурларга карап, акрын гына,
Ләлә, Наил ферма юлыннан
Парлап килә, Наил элеккечә
Сөйгәненең йомшак кулыннан
Алмаган да. Алса әллә ничек
Ярамас күк хәзер тоела,
Сөям сине, бәгърем, һәм сөярмен
Гомеремнең гомер буена,
Дигән сүзләр, яшьлек вәгъдәләре
Тузан булып күккә очтымы;
Яшьли сөйгән, яшьлек өметенең

Югалуы инде шушымы?
Үткән көннәр моңсу ядькар булып
Томаннарга төрелеп калдылар.
Алар шулай акрын,
Салмак кына
Сөйләшмичә озак бардылар.
Эчтә кемдер бераү,
Өзеп-өзеп бер көй уйнады.
— Вальс!.. Кем бу? Шундый матур уйный,
Үтеп керә хәтта йөрәккә,
— Әйе, — диде Ләлә, —
Яңа укытучы
Күптән безгә танцы өйрәтә.
Танцы! — Ник торабыз... Әйдә керик...
Ә, юк,
Эш киеме икән өстемдә.
— Булсын, Наил, синең комбинезоның
Шундый матур, шундый килешә.
Алар керде.
Баян вальс уйный.
Яшьләр әйләнәләр — күңелле.
— Менә, Наил... — Ләлә сүз башлады.
Бездә дә бар танцы күрдеңме?
— Әйе, — диде.
Башка сүз дәшмәде.
— Әйдә без дә...
— Әйдә...
Назлап йомшак кына
Алды Наил аның биленнән.
Кайгы түгел,
Ләләнең
Шатлык, бәхет нуры
Бөрки иде алсу йөзеннән.

* * *

Кичә бетте.
Яшьләр төркем булып,
Урам буйлап җырлап уздылар.
Ләлә, Наил
Артта моңсу гына,
Сүзсез генә атлап бардылар,
Гармонь тынды,

Тынды жыр ташкыны.
Авыл талды тирән йокыга.
Ләләләрнең өе
Өй янында
Сирень куагы оеп утыра,
Ләлә, Наил килеп туктадылар.
Наил Ләләнең
Зәңгәр күзләренә карады:
— Сөйлә, Ләлә, синең йөрәгең
Минекедәй көчле янамы?
Янса әгәр...
— Наил, ташла зинһар...
Бер дә юкка
Януларның нигә кирәге.
Бушка түгел,
Берәр файдалыга
Яна икән синең йөрәгең.
Син беләсең:
Агым сулар үргә акмыйлар",
Күпме янсаң, күпме үкенсәң дә
Үткән эшләр кире кайтмыйлар.
Булсын өйдә бар да синекечә,
Ак чәчәкләр атсын юлыңда.
Юк, кирәкми, Наил...
Бакма шулай минем күземә.
Я, хуш.
Бүгенге яхшылыгың өчен
Мең рәхмәт яусын үзеңә.
— Тукта, Ләлә. Нигә ашыгырга?..
Бер сүз сөйлим —
Тыңла сүземне.
— Әйт дөресен, Наил,
Китү турында — түгелме?
— Түгел, Ләлә.
Наил Ләләнең
Бәсләр кунган маңгай чәчләренә,
Зәңгәр күзләренә карады.
Ул күзләрдә күпме саф гүзәллек!
Ул чәчләрне
Талгын искән җилләр тарады.
Ә аннары
Наил алды йомшак кулларыннан:

— Ләлә!
Котылдым мин борчу уйларыннан,
Өстән, гүя, авыр таш төште;
Күңелдәге кара томаннарны,
Куа-куа гүя минем өчен
Шундый рәхәт изге җил иcте.
Ләлә!
Аңладым мин бүген барын да:
Безнең кебек көчләр
Бик күп кирәк икән авылга.
Юк, ул гына түгел.
Беләсеңме?..
Сабый чакта янып сүнгән хисләр
Йөрәгемдә кабат кабынды.
Хәтерләдем бүген ләззәт белән
Иң беренче хезмәт таңымны.
Тракторга тәүге утырганда,
Их, ул чакта күпме шатландым.
Бүген менә сагыну һәм дәрт белән
Шул чакларны кабат искә алдым.
Аның белән — язгы алсу таңның
Нурларында күпме йөзмәдем,
Аның белән туган кырларымны
Җырлый-җырлый күпме сөрмәдем,
Тракторда бардым.
Мотор гөрли.
Яшьләр
Җырлар белән күмде үземне.
Һәрбер агач сәлам бирә кебек,
Шундый рәхәт, шундый күңелле.
Урман аша уздым,
Һәрбер зифа каен
Мине котлап, гүя, баш иде.
Китмә, Наил,
Китмә,
Кал, диде.
— Оһ, син, Наил!..
Шундый матур сүзләр сөйлисең.
Ник сузасың?
Нигә өзеп кенә
Синең белән калам димисең,
— Калам, Ләлә,

Калам мәңгелеккә
Туып үскән жирдә, авылда;
Минем өчен иң кадерле булган,
Өзелеп сөйгән ярым янында.
Сүзсез торды Ләлә дулкынланып,
Ни әйтергә башта белмәде,
Ә аннары...
Түзмәде,
Наилнең
Кочагына кереп йомылды.
Дөньядагы барлык нәрсәдән дә
Бу минутлар,
Oh, бу минутлар
Иң кадерле булып тоелды.
Ләлә!..
Уйларымны минем белмисең,
Бик күп сүзләр килә сөйлисем.
— Юк, кирәкми, Наил, сөйләмә,
Нәрсә әйтереңне
Мин болай да инде беләм лә.
— Ләлә!..
Их син минем Ләләм, Ләлүшкәм.
Я, әле...
Бер туйганчы карыйм...
Тулган айдай нурлы йөзеңә,
Мин яраткан зәңгәр күзеңә.
— Кара, Наил...
Зәңгәр күзләремдә
Сиңа булган кайнар саф сөюнең
Ялкыннары әле сүнмәгән;
Йөрәктәге вәгъдә гөлләренә
Кар яумаган, кырау тимәгән.
Наил алды йомшак кулларыннан,
Моңсу йөзләренә карады.
Ә Ләләнең бәсләр кунган чәчен.
Талгын искән жилләр тарады.
— Ләлә!.. Исеңдәме?.. Кара әнә.
Бакчадагы сирень куагын.
Без таныштык шунда, син хәтерлә
Шау чәчәкле ямьле май аен.
— Әйе, Наил...
Алар икесе дә

Сирень куагына бактылар.
Яшьлек вәгъдәләре бу минутта
Өр яңадан
Терелделәр, чәчәк аттылар.
— Исеңдәме, Ләлә, иң тәүге кат
Тартынмыйча назлап сөйдем мин.
Бул минеке мәңге, дидем мин.
Ә син, Ләлә, булам, булам, дидең,
Вәгъдәм өчен әнә шаһит булсын
Каршымдагы сирень гөлләре.
Синнән башка бүтән ярлар сөю
Күңелемә минем килмәде.
Ул көннән соң биш ел гомер үтте,
Ә ул еллар
Шундый озын булып тоелды;
Ничә тапкыр сирень чәчәк атты,
Ничә тапкыр җиргә коелды.
Сирень
Энҗе бәсләр белән төренгән дә
Ялгыз гына тора моңаеп;
Аңа хәзер бераз күңелсездер
Сагынып көтәдер ул май аен.
Язлар житәр,
Сирень куаклары
Бакчаларны гөлгә бизәрләр.
Назлы кызлар күксел чәчәкләрен
Букет ясар өчен өзәрләр.
Яз житдисә — сирень куаклары
Яшел яфрак белән төренә.
Ләләнең дә килер язлары
Бик бәхетле булып күренә.

Табындагы уйлар

Кичке тынлык.
Бүлмә якты, жылы.
Аш-су белән өстәл күмелгән.
Бүген синең туган көнең Гөлсөя,
Котлыйм сине бөтен күңелдән!
Табын – күркәм.
Күңел – күтәренке.
Без канәгать шушы байлыкка,

Бокалларда мөлдерәп тора шәраб,
Әйдә, иркәм,
Тост күтәрик синең саулыкка.
Кырыс заман безне күп күрсәтте,
Телгә алу кыен кайсысын.
Син, Гөлсөя, ирләр белән бергә
Уртаклаштың дөнья кайгысын.
Син ирләрчә көчле ихтыярлы,
Хатын-кызча нечкә күңелле;
Җил-давылда — имән кебек ныкча,
Кайгы килсә — таш күк түземле.
Синең белән кулга-кул тотынып,
Ничә еллар гомер сөрелгән;
Сугышларда икәү парлап йөрдек,
Гомеркәйләр данга күмелгән.
Усал, икәсең дә,
Шаянлык та синдә җитәрлек;
Чая күзең
Чибәр йөзең ләкин
Бер күрүдә гашыйк итәрлек.
Мин шуларга кыздым.
Тышкы. матурлыгың
Явын алды ике күземнең.
Ул чагында карап-карамадым
Эчке дөньяңны бер үзеңнең.
Синең белән башлап җибәрергә
Уйладым мин тормыш юл башын.
Авыр, диләр, аны,
Шуңа күрә
Яхшы булсын гомер юлдашың.
Тормыш, диләр, төпсез диңгез кебек
Йөзә белгән
Матур итеп колач сала, ди;
Ә белмәсә, черек агач төсле,
Дулкыннарга күмелеп кала, ди.
Кайберәүләр биек кыя итеп,
Күз алдына аны китергән;
Кемдә көч бар,
Кемнәр кыю була,
Түбәсенә фәкать шул менгән.
Моны, бәлки, шулай бик күпертеп,
Куркак җаннар гына әйтәдер;

Алай дисәң...
Һәм, чыннан да,
Тормыш шулай таләп итә бит.

* * *

Ул чаганда әллә яшь булганга,
Мин боларны юньләп белмәдем;
Бер карауда гашыйк иттең мине,
Һәм тоттым да тизрәк өйләндем.
Мамык төсле йомшак кулың синең
Авырлыкка, белмим, чыдармы?
Кош тәпие кебек аякларың
Киртәләрне атлап чыгармы?
Тал кебек бөгелеп нечкә нәфис билең
Җил-давылда сынып калмасмы?
Тормыш юлы авыр булгач шулай,
Барган чакта хәлең талмасмы?
Мин бу турда озак уйланмадым,
Әллә яшь булганга,
Аны юньләп уйлый белмәдем;
Бер карауда гашыйк иттең мине
Һәм тоттым да тизрәк өйләндем.

* * *

Үткән гомер искән җил шикелле -
Бер-бер артлы көннәр авышты.
Без яшәдек тату һәм дус кына,
Шалтыратмый табак-савытны.
Бүген менә
Туган көнең, Гөлсөя,
Бокалларга шәраб салынган.
Бу мул тормыш синең белән минем
Зур көрәштә яулап алынган.
Дөнья матур хәзер.
Аш-су белән тулган табыннар.
Ләкин менә сугыш куркынычы...
Ул бетмәгән әле, тагын бар.
Эфир дулкыннары океан аша
Ташып тора шомлы хәбәрне.
Вакыт-вакыт гүя кисәтеп куя:
Алда көрәш...
Ә син

Әзерме?
Ул хәбәрләр тыныч күңелләрне
Ярсыта да кат-кат уйлата.
Нәрсә дисең?
Безнең йодрык әле
Нык төйнәлгән утка карата.
Бу сүзләрне сөйләп торуның да
Кирәге юк, беләм, табында.
Һәм, чыннан да,
Аны беркайчан да
Искә алмас иде тагын да.
Безнең хыял — түгел буш өмет.
Безнең өмет — түгел буш өмет.
Бу тормышны кабат беркемнән дә
Җимерттермәс өчен төзедек.
Дөнья һаман авыр сулап тормас,
Бер йомшарыр, шиксез, бу хәлләр.
Сугыш түгел,
Яшәү, матур тормыш
Сөйләр фәкать соңгы хәбәрләр.

Карт бабай киңәше

Көчем булса икән бинихая –
Әкияттәге алып батырдай,
Юлымдагы тимер киртәләрне
Тешем белән умрып ыргытырдай –
Ажгырып килгән бер мең авырлыкны
Кырып салсам әгәр камчылап, –
Егет көче шулай дияр идем,
Җыймас идем бәхет тамчылап.

* * *

Авызың белән йолдыз чүпләп йөрсәң,
Син йотарсың дөнья тузанын.
Тормыш – усал. Тормыш, аһ, яратмый
Юка жилкәләрне,туганым!
Уттан качкан шәрә шайтан кебек,
Чапсаң әгәр күреп авырны,
Аяз көннәр фәкать өмет итсәң, –
Каршы алыр тормыш давылы.

* * *

Атаң кисте мәчет манарасын
Һәм әйтте ул: "Дөнья яңарсын,
Дин буяган кара сөремнәредәй
Кеше куңеллләре тазарсын.
Син йөрисең мәчет салам диеп,
Ярый ла ул җайлап утырса
Кисмәссеңме манарасын ярсып
Бер дуңгызы әгәр котыртса?

* * *

Тормыш бит ул усал ата кебек,
Тыңламасаң тотып камчылый.
Утлы чукмар белән тукмаса да,
Кеше мескен түзә, ык,чыдый.
Була хәтта шундый вакытларың –
Кайгыларга күңел яраша;
Һич төзәлмәс яра кала әмма
Якын дустың әгәр алдаса.

* * *

Бу тормышта син бит ялгыз түгел,
Ике иңендә ике фәрештә.
"Ак", "караны" алар язып бара,
Сынап карый сине һәр эштә.
Син уйлама кылган гөнаһыңны
Күрми диеп дөнья инсаны.
Фәрештәнең гадел бизмәнендә
Җыелып бара аның һәр саны.

* * *

Син эзләмә, дускай, ялган бәхет,
Ялган бәхет – шома чуртан ул.
Өмет итмә хозур оҗмах түрен
Тәмугларга илтә ялган юл.
Кеше кояшында сырт кызартып,
Йоклап яшәү егет эшеме?
Зур бәхетләр әгәр кирәк икән
Ит бәхетле башта кешене!

* * *

Ялган өчен елый кабер ташы,

Ялган күреп кире чигә тауның башы.
Нигә ялган йөртә икән кеше?
Ник сөйләргә яраклашкан канлы теше?
Гомер буе кеше хурлап йөрдең,
Кер эзләдең тырнак астыннан.
Ахыр чиктә тормыш җәза бирде –
Мәхрүм калдың соңгы дустыңнан.
И дускаем, нигә болай булдың –
Чүп эзләдең алтын базыннан?
Син бит хәзер шундый мескен кеше –
Тирес корты чүптә казынган.

* * *

Күңелләргә керле шом салынып,
Җан өшесә кара уйлардан,
Өзгәләнсәм эзләп яшәү ямен,
Алыйм дисәм аны кайлардан, –
Кылган гөнаһларга йөрәк әрнеп.
Мин эзләсәм әгәр инсафлык,
Күңел йөгрә, тәүге мәхәббәткә:
Тәүге мәхәббәттә – зур сафлык.

* * *

Авыр заман килде дип сыкранма,
Түкмә әле, шагыйрь, куз яше.
Дөнья хәлен ничек кабул итү
Һәркемнең бит, туган, үз эше.
Ник ваклыйсың яшьле сүзләр белән
Кеше күңелендәге байлыкны?
Кыен булса үкер син бикләнеп,
Тик елатма, зинһар, халыкны!

* * *

Күбәләк
Оча, уйный,
Болында.
Чәчәкләрнең үбә ул
Алын да,
кызылын да.
Мин күбәләк булмам,
Күп чәчкәгә кунмам,
Берне генә үбәрмен,

Шуны гына сөярмен.

* * *

Җил чыкты,
дулкыннар
уйнады, уйнады.
Сине күңел өзелеп
Уйлады, уйлады.
Җил тынды,
дулкыннар
Басылды, басылды.
Сине сагынып йөрәк
Ярсыды, ярсыды.

* * *

Көз.
Шәрә агач
моңсуланып
Уйга талган.
Ботагында
тик бер генә
Яфрак калган.
Төшәр-төшмәс дерелдәп тора,
Торыйм дигән кебек азрак.
Аерылуның кыенлыгын
Сизә әллә
сары яфрак?

* * *

Мин, диде,
Таулар үтәрмен,
Барасы җиремә
барып җитәрмен.
Очрады юлда зәңгәр кыя.
Ул менә-менә дә
аска карап куя.
Кулы талды,
Ташка тире тамды.
Җитәр, диде, барган кадәресе;
Менеп булмас:
Көч түгүнең юк мәгънәсе.
Төште кире,

Ирешә алмый максатына.
Көчсез кеше куркып тау үтүдән
Барыр юлын шулай кыскарта.

* * *

Тормыш гизгән чакта очрап куйса
Киртә, чокыр, юлның бозыгы.
Үт син аны, кыю егет булып, –
Яшәүнең бит шунда кызыгы.

* * *

Күл.
Пар үрдәкне
Озак күзләдем.
Аннан
Мылтыкны
Җайлап төзәдем.
Берсе үлсә, берсе калыр, –
Шундый уй
　　　　мине биләде.
Атмадым:
Аларны
Аерасым килмәде.

* * *

Көз.
Җил исте.
Салкын бәгырьне кисте.
Без таныштык.
Көз кебек булмасын
Безнең күңел.
Бер суынса
　　　　җылыту кыен.
Ул бит тимер
Мич түгел.

* * *

Зәңгәр күзе,
Кара кашы
Алды һушымны.
Язгы күкрәү кебек килгән
Сөю шушымы?

Зәңгәр күзем,
Кара кашым,
Барыннан бигрәк:
Миңа синең
чишмәдәй саф
Йөрәгең кирәк!

Яз

Язгы таңның хушбуй исле
Җиле өрде.
Йомшак һава тәрәзәмнән
Бөркеп керде.
Тышка карыйм: Күк йөзендә
Чулпан йөзә.
Бакчамдагы бадьян гөлен
Былбыл үбә.
Ефәк кебек томан төшкән
Су буена.
Бөдрә урман алсу-кызгылт
Нур коена.
Болыннарда шытып чыккан
Яшел үлән.
Һәр тарафта мин тормышның
Ямен күрәм.

Сөембикәнең акыл таҗы

Акыл алтын таҗ кебек ул, Сөембикә, –
Ул кешене мәңгелек һәм бөек итә.

Тарих дулкыннары күмде сине берчак, –
Изге җанга ябырылды күп пычрак.

Юк дөньяда кара үлем иманчыга, -
Үлән дә бит ташны тишеп өскә чыга.

Син калыктың кабат дөньяга йолдыздай,
Һәм балкыйсың җир йөзендә тулган айдай.

Синдә мәллә чал тарихның гәүһәр ташы,
Матурлык һәм батырлыкның йөзек кашы.

Көч-куәт һәм гаярлекнең иң сафлыгы,
Татар хатын-кызларының инсафлыгы?
Син күтәргән авырлыкны җиңү өчен
Кирәк булган туплау ул чак миң ир көчен.

Дан күтәреп исемең бүген түргә менде,
Акыл-таҗың хатын-кызга Байрак элде!

Исмә, җил!

Рәшит Җиһанов музыкасы
Суфиян Поварисов сүзләре.

Әкрен генә кичке шәфәкь сүнә,
Зәңгәр күктә йолдыз кабына,
Тәрәзәңә карап туктап калдым,
Килгән чакта, иркәм, яныңа.

Ике күзең китап битләреңгә:
Пәрдә аша күрәм шәүләңне,
Гөлләр сузган алсу чәчәкләрен,
Якты нурлар кочкан гәүдәңне.

Мин хәзергә моңсу карам үтәм
Якты төшкән койма буйларын
Исмә, әй, җил, чиртмә тәрәзәсен,
Бүлә күрмә аның уйларын.

Истәлекләр

Рәшит Җиһанов музыкасы
Суфиян Поварисов сүзләре.

Һава җирнең йомшак парын сулый,
Игеннәрдә сәйлән чык уйный.
Күл буена аксыл томан төшкән,
Без аерылдык әнә шул төштән.

Көт, кайтырмын, озакламам, диден.
Чыклы үлән җилдә чайкалды.
Мәхәббәттән минем йөрәгемдә

Җуелмаслык тирән эз калды.

Югалсаң да сүнгән йолдыз төсле,
Син күңелдә һаман тулган ай.
Бик сагынсаң бер кайтырсың әле,
Вәгъдәм чиста зәңгәр һавадай.

Илеш каеннары

Илеш җирен урап алган ак каеннар,
Каеннарда Алла рухы, ак илаһ бар.
Илеш халкы йөзе каендай ак,
Илеш күңеле каен суыдай саф һәм пакь.

Бу төбәктә булган Нух пәйгамбәр туфаны,
Төбәккә сеңгән скиф, шумер, кыпчак каны.
Чал Иш-тау бар горур Илеш күкрәгендә,
Һич селкенми утлы күкләр күкрәгәндә.

Каен орлыкларын Алла үзе чәчкән,
Ак, каеннар ярыша-ярыша шаулап үскән.
И каеннар! Без җирдәш, кардәш, сердәшбез,
Олы Ватанда аерылмас илдәшбез.

Ак илкәй төзек җирдә оҗмахтай,
Нурлы булсын тормыш гүя тулган айдай,
Теләк туры килсен Ходай хакларына,
Фәрештәнең "амин" дигән чакларына.

Язам әле

Язма, дисең, язма дисең,
Язма картайдың инде.
Язсаң күңел күтәрелә,
Шуны белмисең, тиле!

Язам әле, язам әле,
Каләмем сынмас, түзәр;
Язсаң яшьлек кире кайта,
Шуны белмисең җүләр!

Язам караңгы төннәрдә,

Күңелем эзли аклык.
Мин язамын, син йоклыйсың,
Язма дию ахмаклык.

Язам көзге яңгырларда,
Язам кышкы буранда.
Мин язамын, син йөрисең,
Аракы эчеп урамда.

Яшь мәхәббәт узгынчы җил,
Карт мәхәббәт таш яра.
Алтын базларын актара
Карт шагыйрь тора-бара.

Язам кичке шәфәкъларда,
Сызылып таңнар атканчы.
Картайсам да һаман язам,
Каләмем оҗмах тапканчы.

Ана һәм бала

Тугыз айлар кайнар карынында
Аналар бит йөртә баланы.
Бала бит ул газиз илкәй каны,
Аналарның иманлы таңы.

Бер авырлык бала күрмәсен дип,
Мең кайгыга ана түзәлә.
Балаларның боек йөзен күрсә,
Ана йөрәккәе өзелә.

Балаларга бәхет бирәм диеп
Үтеп китә ана гомере.
Аналарның олы йөрәк хисен
Белсә икән бала күңеле.

Мәхәббәткә ант

Зөлфия һәм Рөстәм никахына мәдхия

Мәхәббәт башлана илаһи никахтан,
Дога кылып сора бәхет Аллаһ-Хактан.
Никах ант ул зур һәм изге мәхәббәткә,

Шулай ди пәйгамбәр-кадир Мөхәммәт тә.

Никах – очкын-ялкын, мәхәббәт – кайнар ут,
Мәхәббәткә тиңләрдәй кодрәт-шөһрәт юк.
Бөтен галәм-җиһан тора мәхәббәттән,
Бөтен коръән торган кебек күп аяттән.

Мәхәббәткә карыйк, мөэмин, зур ант белән
Ант яшәсен иман булып эчтә гелән.
Зур гөнаһ ул мәхәббәткә кер тидерү,
Һич кирәкми аңа ялган баш идерү.

Үтә-үтә бозлы таулар, утлы юллар,
Адәм, Һава эзләгәннәр мәхәббәтне.
Табышкачтан, кавышкачтан, кочаклашып,
Таратканнар Җир йөзенә бар бәхетне.

Мондый бәхет килде сиңа да, Зөлфия,
Алларыңда Ходай рухы башын ия.
Бик сирәк ул Рөстәмдәй уңган егет
Гәүдәкәе коеп куйган корыч кебек.

Йөрәкләрне берләштерә никах туе
Зур мәхәббәткә нигез ул гомер буе.
Бәхет торсын юлыгызда иман булып,
Сез яшәгез зур бәхеткә дога кылып!

Илһам

Әгәр сызланса күңелем кайгы күреп,
Ул вакытта булмас булса һичбер түзеп,
Берөзлексез янып торса бу йөрәгем,
Һич белмәсәм ул йөрәккә ни кирәген, —
Калсам уртасында шәһәр тузаның.
Баса алмасам яраларын бу җанымның.
Гайбәтләргә телгәләнсә йөрәк итем,
Булса миңа яшәү әгәр бик тә читен, —
Андый чакта мин кайтамын Илешемә,
Тап буламын бәхетемнең көмешенә.
Монда мине каршы ала ак каеннар,
Ак каенда туган якның хозуры бар, —
Җилләр исә сыйпап-сыйпап чәчләремне,

Алар бәйли туган җиргә хисләремне.
Монда күреп бай күңелле Илеш халкын,
Тиз онытмам бу тормышның һәр ваклыгын;
Кайта кебек бала чагым – садә чагым,
Бәхет тулы якты, матур, алсу таңым,
Мин бу җирдә җанга рухи азык табам,
Яшәү өчен бетмәс-сүнмәс илһам алам!

Беренче мәхәббәт

Кич.
Зәңгәр күктә кара-кучкыл болыт,
Шәһәр халкы агыла ярсый-ярсый.
Син киләсең тып-тып кына басып,
Бер тотам да минем арттан калмый.

Тигезләнде безнең ара бик тиз,
Алга чыгып бүлдең син юлымны.
Уттай кайнар йөрәк белән шашып,
Кысып тоттың нык салкын кулымны.

Тын ялкының әллә күчте җанга,
Күп кирәкми икән яшьлек канга.
Мин бит әле белмим сөю хисен,
Татымаган мәхәббәтнең көчен.

Озатып куйдың. Карышмадым һич.
Әллә язмыш, әллә ялгыш бу кич?
Башка хәтта урын да тапмадым,
Төне буе керфек тә какмадым.

Күңел кошым

Җыр

Күңелемдә бөек өмет булып,
Син яшәдең, иркәм, яшәдең.
Йөргән юлларыма нурлар сибеп,
Матур яшьлек булып яшьнәдем.

Юлларыма мәңге юлдаш бул син,
Зур бәхетләр безне чолгасын.
Ярсып типкән яшьлек йөрәкләре

Кайнар сөю булып чыңласын.

Балкып үтсен сөю белән гомер,
Бәхет бөркеп атсын ал таңнар.
Син бит, иркәм, күңел кошым минем,
Синең белән матур дөньялар.

Студентлар җыры

Биш ел буе без казыдык
Энә белән коены.
Бер вагон китап укыдык,
Ул да бик аз тоелды.

Их, студент еллары шул,
Кала сагынып сөйләргә.
Матур яшьлек вакытлары
Үтте бит синдә генә.

Авыр булса да биш еллар,
Сизелми үтеп китте.
Сау бул инде, институт,
Китәр вакытлар житте.

Каршыла, зур тормыш, безне
Якты йөзләрең белән.
Башым тулы белемем бар,
Сиңа ашкынып киләм!

Вакыт җиле

Исә вакыт җиле һәрчак галәм буйлап,
Төрле сыйфатларга керә уйнап-уйнап.
Бер була ул нечкә билле фәрештә,
Шифалы нур бөркеп китә һәрбер төшкә.

Чәчләреңне назлы кыздай сыйпап үтә,
Куеннарга тулып йөрәкне җилкетә.
Ташый безгә сихри хәбәр алла сыман
Җиде кат күк – югары аң дөньясыннан.

Кайчагында җирдә бик күп вәхшәт күреп,

Елап йөри ач баладай гел үкереп.
Ачулана җен-пәридәй нык котыра,
Өй җимерә, зур ташларны алып ора.

И, җилкәем, сына көчең янә бер кат,
Бу дөньяны каралаучы затны син тап.
Тау астында булса ул зат – куркак куян,
Тауга менсә зур арыслан – бу да зыян.
Ул үкерсә, ачу чәчә, комсыз шайтан,
Ач Диюгә әверелә иң азактан.

Төшер аны тау башыннан – булсын куян,
Меңгереп куй тау башына чын зат-инсан!
Булса иманлы бәндәләр тау башында,
Тотарбыз хак имтихан Тәңре каршында.

Фронтовиктар васыяте

Ут эчендә янмый чыккан фронтовиклар —
Ил намусына алтын терәк булганнар...
Сызласа да авыр яралары һаман,
Сынатмаска каты басып атлый алар.

Рухи каеш беләң будыгыз сез билне,
Күтәрдегез сугыштан соң баткан илне.
Корыч кулларда Прометей уты янды,
Җир йөзенә уттан кайнар тамчы тамды.

Ут-ялкыннан оешты "фронтовик" сүзе,
Аңа борылды күп кыйтгаларның йөзе.
"Фронтовик" сүзе хәзер көч символы ул,
Юк җир йөзендә аңа җиткән чукмар кул.

Чукмар йодрык хәзер шаша, каты уйный:
Җирдә башка болай яман яшәп булмый.
Күбәйде уйнашчы, ялкау, ялган, алкаш,
Ә таләпләр зур — асыл кием, тәмле аш.

Без сугыштык изге, сөйгән Ватан өчен,
Нык күрсәттек илебезнең күәт-көчен.
Алтмыш биш ел, шөкер, күркәм хезмәт иттек,
Караңгыдан яктылыкка ил күтәрдек.

Ак-кара һаман икесе дә нык көчле,
Сөзешәләр котырынган үгез төсле.
Безнең васыять: җиңсен җирдә гел аклык,
Әдәп, иман, шәфкать, хезмәт һәм инсафлык!

Йөрәк һәм мин

Йөрәгең начар, карт, тузган, ди бер табиб,
Булмас, ди, аңа көчле дәва табып.
Ни булса да Алла биргәне хактыр,
Алладан түгел, диюләр нахактыр.

Мәгәр һич булмады начар минем йөрәк
Табибка аңларга аны бик нык кирәк.
Ак йөрәккә минем йөрәк ак нур чәчә,
Кара йөрәк куркып карашымнан кача.

Саф йөрәгем барлык пычракларга кояш
Аңа хас түгел бозыклык һәм уйнаш.
Ул сугышта бомба булды дошман өчен,
Һәм күрсәтте ир-егетнең гайрәт көчен.

Яндырмады аны тәмуг утлы юллар,
Куркытмады каһәр төшкән авыр еллар.
Ул бит канатлы, ялкынлы хисләр оясы,
Ә зәррәләр фанилыкның зур дөньясы.

Анда матурлык, мәхәббәт, җиһан уты,
Кайгы, шатлык, михнәт, шаңдау, яшәү суты.
Баеп барса да гомерем кояшы, табиб,
Яшим әле мин дөньяда зур ямь табып.

Әйтмә, зинһар, “йөрәгең начар”, “тузган”, “карт” дип,
Әйт: “Аңа житешми нибары бер шарт”, — дип.
Кызлар күрсә, яшәрә бит бу карт йөрәк,
Димәк, аңа һаман саф мәхәббәт кирәк.

Сөясем һәм сөеләсең килә һаман,
Такса да мең ташын бу авыр заман.
Бәддога кылмый бу матур, фани җиргә,
Китәрмен мәхәббәт белән гөнаһсыз илгә.

Йөрәк белән сөйләшү

Акрын гына атлап тормыш баскычларын,
Кулга алдым туксан яшьнең ачкычларын.
Күпме ишек ачармын карт ачкыч белән, -
Ярсый күңел шуны уйлап, шашам гелән.

Йөрәк әйтә: "Гел борчылдым синең өчен,
Аңламадың бит тормышның яшәү көчен.
Ташлар ярдың, тирес чаптың, сабан сөрдең,
Ачы кайгысын дөньяның күпме күрдең.

Бер егылдың ачлыктан алҗып син, хуҗам,
Мин торгыздым үлмәсен дип бу мескен җан.
Кырык ямаулы бишмәт, иске чабата,
Киеп йөрдең оялмыйча син яшь чакта.

Чибәрлегең һәм акылың торды ташып,
Сөйде шуңа күрә сине кызлар шашып.
Акыллы кыз карамый ертык бишмәткә,
Аңа кирәк чос егет мәңге иптәшкә.

Купты сугыш, йөрттем сине саклап кына –
Яхшылыкның белми кадерен ахмак кына.
Нык сугыштың, кайттың илгә герой булып,
Чайкалдылар алларыңда кызлар тулып.

Берни белмим: әллә сөясең, әллә юк,
Шуңа күрә бирмим сиңа һич кайнар ут.
– Дөрес әйтәсең, йөрәк янып сөйләдем,
Үтте гомер искән җилдәй, һич сизмәдем.

Булмагандыр чын мәхәббәт, бәлки, миндә,
Үкенәмен, шуның өчен картлык көндә.
Әмма, йөрәк, картаймыйсың, мин шуңа шат,
Килә яшисем хәзер гел сиңа охшап.

Сөясем килә, сөеләсем ханымнардан,
Дәртемдә ут, сүнмәгәндәй һаман дәрман.
Аңла, йөрәк, син кал шулай гомер яп-яшь,
Акыл биреп яшә миңа, бул киңәштәш!

Күңел кошы

Җыр

Күңелемдә бөек өмет булып,
Син яшәдең, иркәм, яшәдең;
Йөргән юлларыма нурлар сибеп,
Матур яшьлек булып яшьнәдең.

Юлларыма мәңге юлдаш бул син,
Зур бәхетләр безне чолгасын;
Ярсып типкән яшьлек йөрәкләре
Кайнар сөю булып чыңласын.

Балкып үтсен сөю белән гомер,
Бәхет бөркеп атсын ал таңнар;
Син бит, иркәм, күңел кошым минем,
Синең белән матур дөньялар.

Авылымның айлы кичләре

Җыр

Язгы моңнар чишмә булып агыла,
Шаулап тора басу эшләре.
Нурлар балкып кырдан каршы ала
Авылымның айлы кичләре.

Урамнарда тәмле булып аңкый
Яңа пешкән икмәк исләре.
Иркәләнә гармун моңнарында
Авылымның айлы кичләре.

Синдә күңлем, уем, тойгыларым,
Йөрәгемнең кайнар хисләре.
Чатнап торган салкында да матур
Авылымның айлы кичләре.

Авылымның алсу таңнары

Иркәләнә акрын искән җилдә
Агыйделнең бөдрә таллары.
Тирә-якка нурлар бөркеп ата
Авылымның алсу таңнары.

Сандугачлар моңы белән тула
Чылтырап аккан чишмә буйлары.
Күңелләрдә илһам, дәрт уята
Авылымның алсу таңнары.

Уяналар гөлләр күккә карап
Чыңлап тора талъян моңнары.
Бәхет теләп эшкә озатып кала
Авылымның алсу таңнары.

Таң нурлары яткан киң кырларда
Канатлана гомерем язлары.
Яшьлегемдәй матур булып балкый
Авылымның алсу таңнары.

Кеше һәм күз нуры

Бар Уфада бер күзхана,
Шунда картлар җыела.
Сүнеп барган күз нурлары
Балкыр кебек тоела.

Күпне күргән бит ул күзләр,
Күктән йолдыз чүпләде.
Картайган көннәрдә нигә
Күз нурлары чүпләнде.

Күз нурлары белән бергә
Уйлар сәяхәт итте.
Күз нуры калды якында,
Уйлар еракка китте.

Бар, имеш, кайдадыр шунда
Гөнаһсыз изге илләр.
Анда һич тә исми икән
Бездәге чүпле җилләр.

И, Ходаем, сакла зинһар,
Керләнмәсен керфегем.
Кучер мине саф илләргә,
Алмам чүпнең бөртеген.

* * *

Кайтам әле Илешемә
Сабантуй көннәрендә:
Күпме истәлекләр калган
Яшьлек гомерләремдә.

Тапкан идем сабантуйда
Бәхет-мәхәббәтемне.
Ташлап китсәм дә еракка,
Өзәлмим өметемне.

Сабантуйлар ямьле була,
Шатландыра һәркемне.
Ә мин бөек. Һаман эзлим
Югалган бәхетемне.

* * *

Без таныштык сабантуйда,
Бәйләнде чәчләр чәчкә.
Сабантуйдагы мәхәббәт,
Булмады үкенечкә.

Ел да кайтам сабантуйга,
Кошлар кебек кагынып.
Авылымны, кырларымны,
Яшьлегемне сагынып.

Мәңге яшәр йөрәкләрдә
Сабантуйдагы моңнар.
Ул моңнарда яшьлегемнең
Кайнар мәхәббәте бар.

Дөнья оҗмахы

Җыр

Урал таулары бизәге
Ассы шифаханәсе.
Урманнары бал, моң коя,
Шифа йомшак һавасы.

Монда җәннәт, монда иман,
Фани дөнья оҗмахы.

Бер килсәң дә озайтыла
Гомеркәйләрнең таңы.
Урманнар иркен тын ала,
Елгалар моңсу ага.
Бар табигать сиңа карый,
Шатланып күзен бага.

Шифаханә күңелләргә
Мәңгелек илһам сала.
Киткән чакта һәр матурлык
Зурлап озатып кала.

Мәхәббәт

Гашыйк булдым сиксән яшьтә бер чибәргә,
Мәхәббәтем уттан кайнар – ничек түзәргә?
Гыйшкым ялкынында дөрләп янам, көям,
Газиз Аллам! Мин бит аны шашып сөям.

Ожмахтагы былбылныкы – аның тавышы,
Буй-сынкае, гүя, Кәүсәр күле камышы.
Нур агыла шомырт-кара күзләреннән,
Баллар тама тәмле-татлы сүзләреннән.

Бер атласа каршысында гөлләр баш ия,
Бу ни гаҗәп – ул да мине өзелеп сөя.
Кырыккача пар тапмаган сылуның җаны,
Иш итмәгән берәүне дә мәхәббәт каны.

Әнкәйгә мәдхия

Рәхмәт, әнкәй, мине өйрәткәнсең:
Еламаска – килсә авырлык.
Әйтә идең: “Имән кебек көчле
Алтыннан да кыйммәт сабырлык.

Алты бала – алты коры кашык:
Әткәй үлгәч – сиңа сыендык.
Ашамаган үлән калмагандыр,
Кәлҗемәләр чәйнәп туендык.

Алсу йөзләреңә сары төште,

Яңакларың эчкә баттылар.
Бар авырлык кара чәчләреңә
Ап-ак кырау булып яттылар.

Алты кашыкка җим ташый-ташый,
Үзең берчак ачтан шешендең.
Аналарның бөек икәнлеген
Сабый чакта ук мин төшендем.

Кайгы йөге таудай басканда да
Мәрхәмәтле карашың сүнмәде.
Дөнья йөзенә үпкә ташламадың,
Зарлану сүзен телең белмәде.

Алты бала тетрәп үсеп җиткәч,
Мәңгелеккә киттең арадан.
Үлгән чакта соңгы елмаюыңны
Бер күрергә иде яңадан.

Елап түгел көлеп үлү үзе
Кеше өчен иң зур дан икән.
Синдә булган барлык уңай сыйфат
Мине дә бит көчле зат иткән.

Мин тырыштым синең кебек әнкәй,
Кайгыларга көлеп карарга.
Чын яшәргә дигән бөек антым
Сине уйласам кат-кат яңара.

Без төзедек бөек гигантларны,
Ватан язмышы дип яшәдек.
Ил чакырса җитди көрәшләргә,
Яшен уты булып яшьнәдек.

Сугыш утларында янмый чыгып,
Дәваладык илнең ярасын.
Кайгы артыннан кайгы килә торды,
Кабул иттек көлеп яңасын.

Васыятеңнең барын үтәдек күк,
Биш кашыгың алдың чиратлап.
Иң төпчегең миңа да бит туксан,

Барыр вакыт житә иң арттан.

Адәм балалары нидер даулап,
Елап туа икән анадан.
Синең сымак ныклы яшәп, әнкәй,
Көлеп китсәм иде дөньядан.

И телкәем!

Күбәләк кунса куана — бакчада гөл,
Энже-мәржән сүзләр булса — сафлана тел.
Кун кешегә күбәләктәй, и телкәем,
Яралама берәүнең дә күңелкәен.

Син бит минем рухи көзгем, саф иманым.
Шәфкать-мәрхәмәтлек тулы олы жаным.
Дәвала син явызны да, куштанны да,
Житсен көчең дус итәргә дошманны да.

Кирәк икән, уктай кадал хаиннарга,
Әмма булма үткен кылыч юкка-барга.
Тот һәрвакыт милләтеңнең бөек данын,
Тик онытма газапланып түккән канын.

Күп чаптылар балта белән тамырыңа,
Курпыладың тагын үч итеп барына.
Инде тамыр жибәр жирнең йөрәгенә,
Какшатмасын жил-давыллар сине бер дә.

Синдә яши чал тарихның рухи йөзе,
Бүген төбәлгән дөньяның сынау күзе.
Һич каушама усал күзләр чая бакса,
Бөек халык беркайчан да калмый аста.

Син хаклыкта күңелемне ак кыл һәрчак,
Һәм яктырма саф йөземә кара пычрак.
Нык бул, туган телем, көрәшләрдә һаман,
Яула жиңү килсә кат-кат усал заман..

Сайра, сандугачым!

Син сайрыйсың сандугачым, чүт-чүт итеп,

Тыңлап торам: илһамланып, исем китеп.

Чыгып тора бер яңа көй минут саен,
Кайдан алдың бу моңнарны табу җаен?

Кечкенә җан иясеннән зур моң ага,
Ни әйтерең бар, кошчыгым, бу дөньяга?

Рәнҗисеңме без кырганга урман өчен,
Хәсрәт чигәсеңме шуңа иртә-кичен?

Сызланасың мәллә безнең яманлыкка,
Ызгышалар алар диеп барга-юкка?

Әйтәсеңме: бу дөньяның каны каты,
Ник аңламый икән шуны адәм заты?

Дисең бугай:кеше боза матурлыкны,
Челпәрәмә итә алла биргән котны;

Язып бара иманыннан бөтен галәм,
Мин гаҗизмен бу кайгыдан инде тәмам.

И кошчыгым, бу хакта мин ник уйланып,
Үзем дә бит урман кисеп дача салам.

Табигатьне балта белән без кырабыз,
Бу дөньяны юк-бар белән без бозабыз.

Әле дә менә балта уйный уң кулымда,
Мең төрле уй кайный һаман бу уемда.

Без дә синең кебек җырлап моңаябыз,
Рәхәт яшәү өчен диеп җай алабыз.

Әмма җырлап кына бармый икән тормыш,
Оһ, авыр бит, сандугачым, тормыш-кормыш.

Аның өчен кирәк акыл һәм зур хезмәт,
Аңламыйча шуны чигәбез күп михнәт.

Ә син, сандугачым, сайра, сайра, сайра,

Синең сайравыңнан безгә бик күп файда.

Ямь бирәсең урман, кырга, далаларга,
Сайрамыйсың безнең кебек юкка-барга.

Бу бит синең төп һөнәрең — изге эшең,
Төп һөнәргә көче житми күп кешенең.

Әгәр шул хис бик нык булса безнең уйда,
Яшәр идек бик бәхетле бу дөньяда!

Чуар тавык горурлыгы

Ихатада унбиш тавык, бер шәп әтәч,
Унбиш тавык кыла шәп әтәчкә ядәч.
Ядәч көрәшендә жиңә чуар тавык,
Шәп әтәчнең мәхәббәтенә нык зәвык.

Чуар тавык моң-чаң белән жырлый белә,
Бу чаң-моңкай шәп әтәчнең жанын телә.
Шәп әтәчтә тавис кошының матурлыгы.
Урал таулары бөркете батырлыгы.

Таңда кычкыргач шәп әтәч – Чулпан калка.
Чуар тавык шәп әтәчне нык ярата.
Тик "Чуар", кылтым кыздай, очынып йөри,
"Сөймим сине, Әтәч", дигән була юри.

Жиңелсенме данлы әтәч була торып,
Булмасмыни мәхәббәткә капкан корып?
Күп аңлаткач, горур тавык башын иде – ялт,
Әмма ул куйды әтәчкә бик зур бер шарт:

"Нәфес тели ярма-бөртек, әтәч-жаным,
Шуны тапсаң сиңа бүләк – сөю каным.
Данлы әтәч чүп өемен нык актарды,
Янды-пеште, тиргә батты, хәлдән тайды.

Тапкач Әтәч нык кычкырды, һава ярды,
Бу тавышка бөтен авыл хәйран калды.
Тик алданды шәп Әтәч менә нилектән:
Тапкан бөртек ярма түгел, гәүһәр икән.

Әйтте тавык: "И, Әтәчкәй, акылың кайда,
Бу түгел бит мин теләгән бөртек-ярма.
Мәхәббәтне алыштырмыйм алтынга да".
Кет-кет итте, и кылтайды, китте төкереп.
Катты әтәч, сынды канат, шиңде кикрик.
1953.

Саз бакасы хыялы

Саз бакасы
　　　　　　әллә көнләп,
Ачу тота кошларга:
Нигә һава пычраталар,
Файдасызга,
　　　　　　　　　　юк-барга?
Канат чыккач,
　　　　　　　　　　ул очачак
Галәм киңлеге буйлап.
Максат –
　　　　　　күк патшасы булу,
Ята шул хакта уйлап.
Патша булгач,
　　　　　　бар кошларны
Батырыр сасы сазга.
Үзе өчен
　　　　　　төзер
　　　　　　　　　　оҗмах,
Яшәр коенып назга.
Ил таҗына
　　　　　　чыннан да бит
Үрли сазның бакасы.
И, бәндәләр,
　　　　　　уйлыйк ныклап,
Бу соң кемнең хатасы?
1953.

* * *

Ак каенның сукайлары
Ана сөтедәй тәмле.
Ак каеннар үскән Илеш
Җир оҗмахыдай ямьле.

Ак каеннар үскән җирдә -

Ак бәхетләр доьясы.
Андадыр асыл шәфәгать –
Яшәүнең хөр оясы.

Ак каеннарда ак иман,
Иман – Ходай хозуры.
Хозурлыкта көч зурлыгы,
Яшәүнең ямьле нуры.

Монда халык Аллаһ алдында
Дөрес имтихан тота.
Шуңа күрә көрәшләрдә
Ак бәхетне күп ота.
1953.

* * *

Сайрый
    сандугач,
        моң чәчә;
Телә,
  өзә
    үзәкне.
И, кошчык,
    надан шагыйрьдәй,
Була күрмә
    бозлы йөрәкле!

Урманчылар жыры

Ап-ак бәсләр тармак ботакларга
Көмеш сырга булып үрелгән.
Җемелдәшә карлар,
Әйтерсең лә
Җиргә саф энҗеләр түгелгән...

Ә урманда көн-төн хезмәт кайный,
Без кар дулкынын ерабыз.
Сөңге кебек төп-төз,
        озын, юан
Чыршы агачларын егабыз.

Балта чаңы, пычкы моңнарына
Бер кушылып җырлап аласың.

Их, күңелле эшләү сулый-сулый
Шул урманның таза һавасын!
1966.

Тракторчы жыры

Матурлыгың белән чорнап безне,
Әй, тыныч яз, тизрәк кил инде.
Хезмәт дәрте ярсып типкән
Йөрәк ашкынуын бел инде.

Тракторым минем күптән әзер,
Гүя ул да түзми, эш көтә.
Жәйге таңда басу гөрләтүләр
Искә төшеп мине жилкетә.

Жылы нурларыңны, кояш, чәч тә
Эрет инде тизрәк карларны,
Әллә нигә күңел түзми һич тә
Бик сагындым иркен кырларны.

Матур итеп, кызлар тасмасыдай,
Буразналар килә сызасы.
Очар кошлар кебек талпынамын
Кырга тизрәк килә чыгасы.
1960.

Тамчы хисләре

Минем йөрәгемдә дулкынланып,
Кайнап торган хезмәт дәрте бар.
Биек итеп матур йорт салганда
Эчкә сыймый кайчак шатлыклар.

Һәр кирпечне кулга алган чакта
Бер генә хис яна күңелдә:
Тамчы гына түгел, яңа тормыш
Төзүче мин туган илемдә.
1957.

Чын мәхәббәт

Күзләреңнән сөю ялкыннарың
Кирәк булган өчен эзләдем.
Карашыңда күргән керсез нурлар...
Әйтми, дустым, сиңа түзмәдем.

Бик күп күзләр миңа һаман әле
Сөю карашлары ташлыйлар.
Ләкин алар минем күңелемдә
Синекедәй урын тапмыйлар.

Тик бирәүгә, сиңа, яшьлегемнең
Кайнар мәхәббәтен бирәмен.
Чын мәхәббәт аша тормышымның
Яктылыгын күбрәк күрәмен.
1954.

Яңа елга бүләк

Мамык төсле ап-ак карлар ява.
Ләлә кайтып килә урамнан.
Әйтерсең ул карлар белән түгел,
Ак бәхетләр белән уралган.

Кар бөртеген тотып алды Ләлә:
— Күбәләктәй менә монысы!
Үзе салкын сыман, ә үзендә
Яңа елның шатлык җылысы.

Йомшак карлар, һаман уйный-уйный,
Сумкасына кызның куналар.
Кайберләре, сoклангандай булып,
Читтән генә очып узалар.

Ләлә бик шат. Тәти сумкасында
Яңа елга аның бүләге.
Дөнья мактап язган шигырендә
Чәчәк ата аның теләге.

Мәхәббәтең өчен

Басуда, юл буендагы
Ялгыз каен янында,
Язгы таң тыныч нурларын
Илгә сипкән чагында.
Озатты кыз армиягә
Сөйгәнен үбеп кенә:
— Исән йөреп кайт, Фәйзием,
Батыр бул, — диеп кенә.
Мәхәббәтең өчен, Мәрьям,
Постта уяу булырмын,
Туган илгә дошманнардан
Кул суздырмам, күз нурым!
1954.

Тимерче егет

Гашыйк булган димә гаҗәпләнеп
Синең янга мин еш килгәнгә.
Мин киләмен тик шул син эшләгән
Алачыкның үзен сөйгәнгә.

Сокланамын күреп күзләреңдә
Мәхәббәтнең көчле алкынын.
Күзәтәмен көләч йөзләреңдә
Тормыш матурлыгы балкуын.

Чүмеч тавышлары яңгыравын
Охшатамын моңлы җырларга.
Шул җырларың мине җилкендерә,
Яратамын дәртне тыңларга.

Гашыйк булган димә гаҗәпләнеп
Сөяр өчен һич тә килмимен.
Дуслык җебем сиңа шундый көчле
Нәрсә өчен? Үзем белмимен.
1954.

Икенче бүлек

Күп әдип (шагыйрь, прозаик, драматург) иҗатын шигырь язудан башлый.Ә менә нигә аны ташлый? Үземнекенең сәбәбен кереш сүздә әйттем инде. Аны кабатламыйм. Башкаларныкын санап торуның да кирәге юктыр. Бөтенләй ташлау поэзиянең җаны, каны, бавыры, арка сөяге булган сүз-сурәт, сүз-фикер, сүз-тойгы кардәшлелеген илаһилаштыра алмаудандыр, бәлки. Мин дә шундыйлар сафындамы әллә? Алай дисәң, шигърият башка жанрларыма да (публицистика, драма, проза) эстетик зәвык бирергә ярдәм итте бит. Шигырь һәм поэмалар да язылып торды. Илгә иш булган, кешелеклелек өчен күпне кылган, каһарманнарча яши белгән Илеш бабаебыз турында роман язу теләгем дә бар иде. Вакыт җитмәде. Шулай да 90 яшемне "Ак каенлы Илешем" дигән поэма (мәдхия-эссе) иҗат итеп каршылавыма бик шатмын. Мәгәр шигырьләр җыентыгы нәшер итү уе миндә бөтенләй юк иде. Вагы-төяге белән болай да 60тан артык китабым дөнья күрде бит инде. Кимендә 50 томлык язма хәзинәм бар. Дөнья әдәбиятында (шул исәптән төркиләрдә дә) шигъриятькә яңача караш башланды. Моны замана заңы таләп итә. Бу заң башкорт, татар милләтеннән булган сүз сәнгате осталарын да җилкетә. Шигъриятнең йөрәгенә бәреп керү тырышлыгы сизелә. Бирсен Ходай!

Миңа, бәлки, шигъриятькә башка жанрларга караганда ныграк игътибар итәргә кирәк булгандыр. Бу хакта каләмдәш дусларым да әйтә. Китап та алар киңәше белән бастырыла. 2014 елда Татарстан китап нәшриятында дөнья күргән романым ("Утлы дуга кыңгыравы") Бөек Җиңүнең 70 еллыгына багышлана. Уфада нәшер ителгән пьесалар җыентыгым (Авылымның алсу таңнары") — 90 яшемне каршылау мәдхиясе. "Агыйдел" журналында басылып яткан романым ("Гәүһәр күгәрченнәре") 90 яшь тулган көннәргә туры килде. Шөкер! "Бәхет" дигән беренче шигырем әдәбият мәйданында бәхетле шәхес итте мине. Поэзия шөһрәтендә алай итә алмавы бәхәссез. Керештә әйтелгәнчә хыянәт итем шигъриятькә. Бу хыянәт минем өчен әллә үзе бер михнәтме? Җыентыкны әзерләү шактый авырга туры килде. Теләсә кайда аунап яткан шигырьләрем. Тотындым җыярга. Гөнаһым өчен үч иткәндәй, табылмый алар тиз генә. Тапкан кадәресен тәкъдим итәм Сезгә, хөрмәтле укучыларым!

Биредә шуны әйтү дә урынсыз булмас кебек. "Поэма" дигән сүз шигъриятьтә генә түгел, башка жанрларда да кулланыла. Сезгә Макаренконың "Педагогик поэма"сы булу мәгълүм. Башкорт язучысы Тайфур Сәгыйтов "Аманат" дигән романын "поэма" дип атый. Яхшы язылган очеркларны да "поэма кебек" дип әйтүчәннәр. "Ак каенлы Илешем" җыентыгымда проза белән язылган поэмаларым да бар.

“Кешелеклелек” дигән төшенчә аларда да авыр бирелә. Авырлыкны җиңгән — уңа, авырлыктан курыккан — туңа. Имансыз бәхет — бер көнлек, иманлы бәхет — мәңгелек. Илеш бабай шушы илаһи гыйззәтлелекне яшәү кануны итә белү белән откан. Проза белән гамәлләштерелгән поэмаларда да Илеш бабайда булган күркәм сыйфатлар чагылдырыла. Менә аларның кайсыберләре.

Таң балкышы

Ул яза һаман яза. Көндәлек яза.

— Юк, көндәлек кенә түгел бу. Повесть, роман. Ул елларга ярты гасыр үткән. Әмма аларның һәр минуты, сәгате, көне — күңел дәфтәрендә. Әнә шул күңел дәфтәрендәсен кәгазьгә төшерә Мәхмүзә. Язганнары хәзер бер өем. Ул повесть, роман итеп бастырыр өчен дә түгел. Үткән авыр һәм романтикага бай тормышны кәгазь битләренә теркәп калдырасы килә. Аны, бәлки, бүгенге, киләчәк яшьләр укыр, менә ничек яшәгәннәр икән, дип кемдер искә алыр. Шуны уйлап яза ул. Беренче әтәч тә кычкырды әнә. Ә ул яза. Һаман яза. Инде роман калынлыгы булып өелгән язмаларын бер якка куеп, Мәхмүзә үткән көннәр хатирәсенә бирелде.

...Күзгә караңгы төн. Бәләкәй генә тәрәзә тишекләреннән җил өрә. Уйлар дулкынына чумып, һич йокыга китә алмады Мәхмүзә. Авылда колхоз оешты. Җирне агач сука белән ергалап, муенга тубал асып, яз көне ирләр ашлык чәчте. Унжиде яшьлек Мәхмүзә, ай-урагын уйнатып, башка хатын-кызлар белән бергә урды. Күмәк эш нинди күңелле! Дөнья яңара, матурлык туа, искелек чигенә. Көнне-төнгә, зәңгәр таңны кичке эңгергә ялгап эшлиләр. Ару-талуны белү юк. Мәхмүзә комсомолга керде. Яңа тормыш эчендә йөзеп йөри. Спектакльләрдә уйный. Сәхнәләрдән кулакларның тетмәсен тетә. Ә эштә — ут инде менә! Мондый ир йөрәкле, өлгер, батыр кыз җир йөзендә юктыр, дип сөйли халык.

Шуннан ул төскә үзе кебек чибәр, озын буйлы, кап-кара чәчле Суфиянга гашыйк булды. Егет тә комсомолга керде. Тормышка караш, хыял, теләкләр бер. Озакламый аларның чәчләре чәчкә “бәйләнде”.

Көннәрдән бер көнне, җил-давылдай дулкынланып, халык колхоз амбарына ташланды. Ишекне ватып-җимереп керделәр дә, бөтен ашлыкны алып чыгып та киттеләр. Колхоз таралды. Кайберәүләр төшенкелеккә бирелде. Ләкин Мәхмүзә артка чигенмәде. Тешен кысты, йодрыгын төйнәп, көрәш утына чумды. Колхоз яңадан төзелде. 1932 елда Мәхмүзә партиягә керде. Суфиян да гариза биргән иде, аны алмадылар, чөнки кулакларның йөз граммына алданып, алар тегермәненә су коя башлады. Алыптай гәүдәле ирнең авыр чакта шулай җебеп төшүенә аптырады Мәхмүзә. Мең төрле киңәш, үгет-нәсихәт, акыл бирү дә ярдәм

итмәде, аракы күрсәтүчеләр артыннан чапты ире. Җитмәсә, исереп кайтып, Мәхмүзәне җәберли башлады, партиядән чыгарга өндәде. Аның белән бергә яши алмау хәзер көн кебек ачык иде.

Ирен исерек хәлдә күрергә теләмичә Мәхмүзә каенанасы янында кунарга калды. Көзге әче җил тәрәзә кага. Мәхмүзә йоклый алмый ята.

Кинәт ишек шакыдылар.

Мәхмүзә, курка-курка, ут кабызды. Каенанасы ишек ачарга китте. Бераздан ул авыл Советы председателе Шәйдуллин һәм комсомол оешмасы секретаре Закиров беләи килеп керде.

— Әйдә, киен әле, Мәхмүзә, үз өеңә кайт, нигә болай куркып яшисең, — диде председатель.

— Юк, юк. Мин анда кайтмаячакмын.

— Әйдә әле, әйдә, эш бар, бик җитди.

— Нинди эш? Җиде төн уртасында? — дип борчылды каенанасы.

Әбигә Закиров җавап бирде:

— Безнең өчен көн-төн юк. Заманы шулай.

Алар урамга чыктылар. Күзгә төртсәң күренмәслек караңгы төн, Җиргә сеңгән салам түбәле өй кыекларына, читән буйларына, абзар каралтыларына сугыла-сугыла, ачлыктан икмәк сораган баладай, үкереп җил елый. Җил, өермә булып, тегеләргә ябырылды. Алар бер-берсенә тотындылар.

— Менә шулай бер-беребезгә нык тотынсак, ташкын өскә ыргыса да, егылмабыз, — дип сөйләнде председатель.

Авыл изрәп йоклый. Тәрәзәләрдә утлар күптән сүнгән. Өч коммунист! Өч бөркет. Тубыкка җиткән пычракны ерып, караңгылык пәрдәсен ертып, алга атлый.

Бәләкәй генә өй янына килеп җиттеләр. Мәхмүзә, бишмәт кесәсеннән ачкыч алып, ишекне ачты. Өйгә кергәч, Закиров сукыр лампаны кабызды.

Шәйдуллин белән Закиров урындыкка барып утырдылар. Сүзне Шәйдуллин башлады:

— Мәхмүзә сеңелкәш, сүзне озакка сузмыйча, коммунистларча ачыктан-ачык сөйләшик.

— Уратмагыз, агай, турысын гына әйтегез! Әллә берәр күңелсез хәл бармы?

— Бик күңелсез. Колхозны бер яктан төзибез, икенче яктан тарала. Габдерәүфне колхоз председателе итеп куйган булдык. Файдасы юк.

— Соң бу хакта көн буе баш ваттык бит инде, — диде Мәхмүзә.

— Баш ватып кына калабыз шул.

— Соң?.. Авылда колхоз председателе итеп куярдай кеше юк бит инде?

— Бар!

— Кем?

— Син!

— Мин?!

— Әйе! Менә шушы минуттан ук үзеңне колхоз председателе итеп исәплә! Әле, дөресен генә әйткәндә, авылда председатель булмады диярлек. Син — беренче колхоз председателе.

Өй эчендә бераз тынлык урнашты. Мәхмүзә бер агарды, бер кызарды, ни дип әйтергә белмичә, аптырап тик торды. Ап-ак йөзенә кан йөгерде. Юка иреннәре дерелдәп куйды. Авылның бер ярлы кызы. Унҗиде яшьлек чакта комсомолга кергәч, кырыкмыштай дип көлделәр. Кулакларның битләренә бәреп сөйләшә башлагач, көн-төн пычак белән янадылар. Тирә-якта председательләрне үтерәләр, комсомолецларны тере килеш бәкегә салалар. Билгеле, боларның берсе дә куркытмады Мәхмүзәне. Яңалык көрәшсез килми. Көрәш корбансыз булмый. Кесәңә комсомол билеты салгансың икән, битараф булып яшәргә хакың юк. Ә инде партиягә кергәч, халык алдында, ил алдындагы җаваплылык мең мәртәбә артты. Тик ул җаваплылыкның эчтәлеген аңлап бетерми иде Мәхмүзә. Йөрәк ярсый, күңел шаша һәм яңалыкка пычак белән кизәнүче кулакларны чәйнәп ыргытасы килә. Дөядәй алтының булганчы, төймәдәй акылың булсын, ди. Анавы Габдерәүф ише дөя гәүдәле кешенең гомер уздырып, чабата туздырып йөрүендә ни файда? "Их, үзем нигә ир-егет булып тумаганмын!" — дип үрсәләнгән чаклары күп була иде Мәхмүзәнең. Менә!.. Әллә аңлаганнармы аның ярсу йөрәген? Хыялын, уй-хисләрен, эчке көчен аңлаганнармы? Бу хата түгелме? Ул бит әле нибары егерме дүрт яшьтә генә. Үзе юка, бәләкәй генә. Шундый авыр чакта колхоз председателе булырга?! Һич башка сыйдыра торган эш түгел бу.

— Мин бит хатын кеше, Шәйдуллин агай!

— Ә нигә коммунист икәнлегеңне әйтмисең?!

— Ирем моңа теше-тырнагы белән каршы киләчәк.

— Анысын без дә бик яхшы аңлыйбыз. Аны боргычларлык кына көч бар бездә.

...Бу вакытта исерек Суфиян алпан-толпан кайтып килә иде. Өйдәге ут яктысын күреп, аптырап торды. Капканы ачып керде дә тәрәзәгә капланды. Бәй, чынмы бу, түгелме? Күз алдында кинәт ут уйнагандай булды. Җиде төн уртасында аның хатыны ят ирләр белән "типтереп" утыра, Йодрыгы белән тәрәзәне челпәрәмә китерде дә ямьсез тавыш белән сүгенергә тотынды.

Аны каршыларга берәү дә чыкмады. Ул үзе керде. Авыл Советы председателе белән комсомол оешмасы секретарен күргәч, бераз каушап калды.

— Синең алда шакшы хатын түгел. "Ишкар" колхозының

председателе басып тора! — диде Закиров.

Суфиян, авызын ерып, көләргә тотынды:

— Колхоз председателе?.. Минем хатын!.. Ха-ха-ха...

* * *

...Мәхмүзә арып-талып кайтып керде. Соңгы көннәрдә тагы да ябыгып, бит очлары чокыраеп калды, күзләре эчкә батты.

— Ташла, сеңелкәш, бу эшеңне, үзеңне харап итәсең бит, — дип каршылады аны Мәфтуха апасы.

— Мин коммунист, ич апа! Коммунист артка чигенмәскә тиеш!

Бу сүзләрне, билгеле, әйтүе генә җиңел. Мәхмүзә кабул итеп алганда колхозның нибары өч баш сыеры, утыз биш аты, берничә агач тырмасы гына бар иде. Котсыз, пычрак, караңгы көз, буранлы, салкын кыш үтеп китте. Елмаеп яз килде. Карлар эреп акты. Елгалар ташты. Кешеләр күңеленә дәрт керде. Атлар, сбруйлар язгы чәчүгә әзерләнеп куелды. Иртә алсу таңнан басуга!

Мәхмүзә, хәлсезләнеп, өстәл башына барып утырды да стенага сөялде. Апасы чәй әзерләгән арада йокыга да китте. Ире ташлап чыгып киткәч, Мәфтуха апасы белән бергә тора башлады. Апасы сеңелесенең шулай ныклы, көчле ихтыярлы, ир йөрәкле булуына эчтән шатланып бетә алмый. Тик... бигрәк үзен аямый эшләве генә күңелне сызлата. Көн-тен чаба бит. Әле менә шундый хәлсезләнеп кайтып кергән, кыл өзәрлек көче дә калмаган.

— Мәхмүзә!.. Мәхмүзә!.. Кая, чәй эчеп алыйк, аннан ятып йокларсың.

— Ә?! — Мәхмүзә сискәнеп уянды. — Озак йокладыммы, апа?

— Нинди озак... черем генә иттең...

Алар чәй табынына утырырга да өлгермәделәр, ишектән ат караучы Фәрвәз килеп керде.

— Харап булдык, Мәхмүзә сеңелем, кулаклар сбруйларны тураклаганнар, иртәгә чәчүгә чыга алмыйбыз.

Мәхмүзә байтак кына сүзсез торды. Кемдер зур күсәк белән башына китереп суккандай булды. Аннан яшен тизлегендә атылып, ишеккә ташланды:

— Әйдә, Фәрвәз агай!

Урамга чыктылар. Караңгы төшеп килә. Дымлы җир исе, яз исе аңкый. Мәхмүзә, соңгы көчен җыеп, колхозның ат абзарына чапты. Фәрвәз агай аннан калышмаска тырышты.

Бераздан бөтен авыл аякка бастырылды. Җыелыш җыелды. Анда Шәйдуллин белән Закиров та бар иде. Алар ярсып-ярсып сөйләделәр. Мәхмүзәнең чыгышы кайсы берәүләрнең күзенә яшь китерде, йөрәген сызлатты, күңелен тетрәтте.

— Карагыз... күпме сабый бер телем икмәккә тилмереп утыра. Күпме аналар бүген ач баласы өчен зар елый. Тавык кетәгедәй җимерек өйләрне күреп азрак җаныгыз телгәләнмимени сезнең? Ачлык-хәерчелектән котылу өчен төзибез без бу яңа тормышны!

Кыш буе колхозга нибары унҗиде хуҗалык язылган иде. Әлеге Мәхмүзәнең чыгышыннан соң янә берничә кеше гариза бирде. Төне буе эш кайнады, авыл гөж килде, һәркем үз сәләтен, булдыклылыгын күрсәтергә тырышты, һәм... сызылып таң атып килгәндә, кызыл байраклар күтәреп, җыр, шатлык белән авылны гөж китереп, колхозчылар басуга киттеләр.

Менә тәүге буразна сызылды. Кара тасмадай сузылып ята. Тәүге буразна! Аннан биш пар ат бер-бер артлы тезелеп китте. Җир өсте кара бәрхет кебек күпереп калды.

— Тукта, тукта, Гәрәй туган! Син сабаныңны тирәнгәрәккә көйлә әле! Беренче көнне үк җир мыскыл итеп йөрмик.

— Һәй, Мәхмүзә, бөтенесен дә белеп тугансың.

Кичкә чаклы сабанчылар янында булды Мәхмүзә. Аннан соң авылга кайтты. Анда район милиция бүлегеннән килгән иделәр. Әлеге сбруйларны тураклаучы кулак калдыгы да табылды.

Әле Мәхмүзә аскы урамнан кайтып килә. Янә бер тәүлек үтте. Йокланмаган төн, мең мәшәкатьле язгы озын көн. Ул нык арыган. Көчкә-көчкә атлый. Авыл өстенә акрын гына язгы төннең кара пәрдәсе ябыла. Тыкрык башында, һич көтмәгәндә, каршыга исерек Суфиян килеп чыкты. Бу юлы матурлап сөйләшергә тырышты ул.

— Мәхмүзә! Мин синсез яши алмыйм. Онытырга да тырышам, ә менә... булмый...

Аерым торсалар да, ара өзелмәгән иде әле. Ахыр килеп, хатасын аңлагандыр, бәлки. Мәхмүзә үзе дә ярата ләбаса аны.

— Мин дә яратам сине, Суфиян! Бу авырлыкларны икәү бергәләп күтәрсәк, нинди җиңел булыр иде.

Суфиян йомшап китте:

— Ярый, үткән эшкә салават. Оныт бу хакта. Эчүемне ташлыйм. Колхозга җанымны биреп эшләрмен. Кушылабызмы?

— Чын йөрәктәнме, Суфиян?

— Чын йөрәктән. Тик бер шарт белән.

— Нинди?

— Председательлегеңне ташлыйсың. Миңа председатель түгел, ә хатын кирәк. Соң, ахмак, аңла, бу бит вакытлыча... Бүгенме, иртәгәме сине барыбер куачаклар. Я килештекме?

Мәхмүзә иренең алдына килеп басты:

— Юк, Суфиян, председательлекне ташламаячакмын!

— Бу соңгы сүзеңме?

— Соңгы сүзем.

Суфиян Мәхмүзәнең үзсүзле, чигенмәс икәнлеген яхшы белә. Шулай да бу юлы соңгы көчен салырга булды. Җайлап сөйләшү файда бирмәгәч, куркыту юлына басты. Кесәсеннән нидер алды да:

— Менә моның белән мин сине теге дөньяга озатам, — дип ярсыды.

Сугар дип уйламаган иде Мәхмүзә. Ә шулай да сукты. Пәке сабы белән булса кирәк. Мәхмүзәнең башыннан гөжләп кан китте. Ул, күз аллары караңгыланып, читән буена ауды.

Тавышка кемнәрдер йөгереп килде. Мәхмүзәне өенә илтеп куйдылар, һушына килгәч, аның беренче соравы шул булды:

— Суфиян кайда?

— Качкан, — диделәр.

Мәхмүзә эсселе-суыклы булып китте. Эчкече, көнчел булу өстенә куркак та икән әле үзе.

Зәңгәр күктә табактай ай йөзә. Авыл башындагы ак каеннар моңга талганнар. Җирән кашкасын акрын гына атлатып, шул каенлык аша узды Мәхмүзә. Аннан сукмаклар, чокыр-чакырлар аша олы юлга чыкты. — Менә шушы җирәнчәккә атланып күпме җир үтепгәндер инде. Бер караганда юрта, икенче караганда коштай оча, бөтен басуны беләп йөри. Суфиян мәңгелеккә юк булды. Ул әйткәнчә, Мәхмүзәне вакытлыча гына куймаганнар. Күпме еллар үтте инде. Иң кыены халык белән эшләү булды. Караны ак, акны кара диюче наданнар күп, белемлеләр бик аз. Хәер, белем Мәхмүзәнең үзендә дә бик чамалы иде. Парта арасында да утырып укырга бик күп туры килмәде шул. Әмма ул бөтен нәрсәне үзлегеннән өйрәнә, һәр яңа газетаны, һәр яңа китапны йотлыгып укый. Алган белемен шунда ук халыкка өләшә. Бу яктан күңеле тыныч инде. Аңа хәзер яшь кызга карагандай ышанычсыз күз белән карамыйлар. Усал телле, ут бөрчәседәй җитез генә түгел, эчке дөньясының да матур, миһырбанлы, шәфкатьле булуын бөтен авыл халкы аңлады хәзер. Икмәк ашатам дип күкрәк сугып сөйләште, тәки ашатты. Беренче елда ук халык колхозның өстенлеген күрде. Картлар белән картларча, балалар белән балаларча, егетләр белән егетләрчә сөйләшә белде ул. Һәркемнең йөрәгенә ярашлы ачкыч тапты. Кешеләрне җирнең кадерен белергә, аны яратырга өйрәтте. Звенолар төзеп, җирне аларга бүлеп бирде. Башта кош тизәге ташытты, тирес түктерде.

1934 елда, Илеш районы төзелгәч, "Ишкар" колхозы аның составына керде. Бу вакытта инде авылда коммунистлар да күбәйде. Партия оешмасы секретаре Галимҗан агай Мәхмүзәнең уң канатына әйләнде.

Ләкин һәр адымда — киртә, һәр адымда — каршылык. 1936 елның язында ук эссе көннәр башланды. Авыл, урман, басулар буйлап коры җил

исте. Үләннәр, ужымнар, яңа шытып чыккан бәрәңге сабакларына кадәр көйде. Инде аякка басам дигәндә, корылык, ачлык килде. Халыкның рухы янә төште. Йомшак җаннар тагы да колхозга тел тидерә башлады. Кешеләргә калаклап өләшерлек тә ашлык булмады. Бервакыт, буранлы кышкы төндә, идарәдән кайтып килгәндә, Мәхмүзәнең юлына әзмәвердәй өч ир каршы чыкты:

— Балаларыбыз ачтан үлә, киттек амбарга, — дип пычак белән кизәнделәр аңа.

Мәхмүзә куркып артка чигенмәде. Пычакка күкрәген куйды да:

— Үтерегез мине! Я, нигә каушап калдыгыз, их, сез, ирләр!.. — диде. — Амбардагы орлык чәчүгә дә җитмәячәк. Киләсе елда балаларыгызның ачтан үлүен теләсәгез, барыгыз, алыгыз!

Тегеләр, башларын түбән иеп, буран эченә кереп югалдылар. Мәхмүзә китеп барды.

Шуннан соң аның гомеренә пычак белән кизәнүче булмады. Авыр утыз алтынчы елны да халыкның күңелен таба белде ул, киләчәк матурлык белән кызыксындырды, түземле булырга өндәде. Ә утыз җиденче елда инде иген басуга сыймастай булып уңды. Аны карарга бөтен тирә-яктан килделәр. Тик кешеләрне бу игеннең нәкъ шул яшь хатын җитәкчелегендә үстерелүенә ышандыру бик кыен иде.

* * *

Бервакыт, утыз сигезенче елның көзендә, Мәхмүзәне райкомга чакырттылар. Кыска гына буйлы, ачык йөзле райком секретаре Вәлиев аны бик җылы каршылады. Утырырга урын тәкъдим итте. Колхоз хәлләре, үзенең шәхси тормыш-көнкүреше хакында озак кына сораштырып утырды. Аннан соң:

— Менә нәрсә, Мәхмүзә сеңелем, сиңа колхозың белән вакытлыча хушлашып торырга туры киләчәк, — диде. Мәхмүзә кинәт сискәнеп китте:

— Нигә хушлашырга? Алдыралмый башладыммы?

— Син алай тиз генә төшенкелеккә бирелмә әле. Аюдай ирләрнең борынына чирттең бит! Гектарыннан унсигезәр центнер...

— Ә киләчәктә егерме... егерме биш...

— Соң шулай булгач, нигә председательлектән аласыз?

— Алмыйбыз, сине партия мәктәбенә укырга җибәрәбез. Яшьләр укый, халык белем ала. Ә председатель ни эшләргә тиеш?

— Аңлыйм, Вәлиев агай! Җир белемле кешеләр сорый. Җир сулышын аңлавы бик кыен. Минемчә, колхоз председателе югары белемле булырга тиеш! Шундый чаклар булыр бит?

— Булыр, Мәхмүзә сеңелем, булыр.

* * *

Хыяллар! Яшьлек! Үткән гомер! Партия мәктәбендә уку... Аннан сугыш... Райком аппаратында эшләү... XXII партсъезд исемендәге колхозда партком секретаре булу... Хәзер лаеклы ял... Әмма көрәш утында чыныккан ярсу йөрәк тынгы беләме? Ул әле һаман җәмәгать эшләрендә катнаша, яшьләр арасында була, аларга үткәннәр хакында сөйли. Иң шатлыклысы — аның хыяллары тормышка ашты. Илештә 1978 елда һәр гектардан 32 центнердан күбрәк ашлык алынды. Кайбер колхоз җире урыны белән гектарыннан иллешәр центнер бирде.

...Тышта — таң әтәчләре симфониясе. Ул, язмаларыннан аерылып, тәрәзәгә барды. Таң балкышы!..

Җир батыры

Салиха апа кунак егетенә урын салып бирде дә үзе мич башына менеп ятты. "Кунак" дигәч тә, чын кунак түгел ул. Идарәдәге дежур апа китереп китте. Председатель әйткән имеш: шушы егетне Салиха апага алып бар, өстәлендә нәрсәсе бар, шуның белән хөрмәт итсен, дигән. Колхозга бер-бер кеше килеп төшсә, тоталар да аңа җибәрәләр. Ул, имеш, ялгыз, киң күңелле, ачык йөзле.

Киң күңелгә бернинди байлык тиң түгел, тип әйтәләр дә бит, шушы кышкы салкында туңып килеп кергән кешенең эченә җылы сүз генә түгел, җылы аш та кирәк иде. Бәрхет кебек кабарып торган чем-кара чәчле, зәңгәр күзле шушы чибәр егетне калдык-постык аш белән сыйлачы... Әй, бу сугышны!

Төнлә бервакыт уянып китсә, теге егет шатыр-шотыр килә, идәндә арлы-бирле йөри. Мич башыннан ай нуры төшкән идәнгә үрелеп караса, чыбагач белән ашлык суккан кебек, кул болгап маташа егетең.

— Нишлисең, дустым?

— Физзарядка ясыйм, апа, өегез бик суынып китте лә...

— Җил үтә суга шул...

Апа, төшеп, сукыр лампага ут яндырды да мич алдындагы вак-төяк чыбык-чабыкны җыештырды, тимер мич ягып җибәрде. Егет, солдат шинеленә төренеп өстәл янына барып утырды. Аңа Салиха апа да игътибар итми калмады:

— Кара... Әллә нинди туфрак... балчык... Нигә кирәк болар?..

— Анысын үзем дә белмим, апа. Көз көне авылларда йөргәндә төрле басулардан җыям.

— Ә-ә-ә... Агрономмыни?

— Агроном да түгелмен, укып булмады бит, сугыш аяк чалды. Болай... үзем кызыксынып кына җыям. Җире шәп бит, апа, кара әле: күмер төсле кап-кара! Һәр бөртеге икмәк бит моның! Ап-ак икмәк шушы

кара җирдән була бит.

— Әйе. Җир җанлы икәнсең, дустым! Монда нинди эшләр белән килдең соң? Исемеңне дә сораган юк?

— Иртәгә клубта җир, икмәк турында доклад сөйләячәкмен. Мин партия райкомының агитация-пропаганда бүлегеннән бит, апа. Тәлгать Рахманов булам.

Егетең кичтән сүзгә бик саран күренә иде. Әле менә икмәк, җир турында сүз чыккач, ихлас күңелдән сөйләште ул. Бераздан:

— Я, ярый, иртәгә бәйрәм түгел, — дип, Салиха апа кире мич башына менеп китте. Тәлгать, солдат шинеленә төренеп, почмактагы урынына ятты.

Яңадан тиз генә йокыга китә алмады Тәлгать. Уйлар, җепкә тезелгән кебек, башка бер-бер артлы килде дә торды. Ә нигә офицерлыкны ташлап кайтты соң әле ул? Әйттеләр бит: — Анда ачлыкның күзенә барып керәсең, — диделәр.

Туган җир, туган кыр, балдай татлы сулар, ялан, изге төяк тартты күңелен. Бәләкәй чакта да бакчадагы матур-матур түтәлләргә, киң кырлар буйлап тасмадай сызылып киткән буразналарга карап торырга ярата иде. Шул чакта ук ул үзенең җиргә гашыйк икәнлеген аңлады. Ләкин менә җирне үзең яратудан ни фәтвә? Ул да сине яратырга тиеш. Яратмаганга серне сөйләмиләр. Сине яратмаса, җир мәңге серен ачмаячак. Яраттыру өчен җир галиме булырга кирәк.

Армиядән кайтып, егетлеген җир эшендә дә күрсәтә алмый бит әле. Кеше эшләгәнне күзәтеп кенә йөри. Кайда кушсалар, шунда чаба. Барган җирдә үзенчә тәртип тә булдырып китә кебек. Ләкин бу чын игенче булу түгел инде.

Уйлар давылында адашып йөри торгач, бервакыт йоклап китте ул. Яңадан уянганда өй яктырып беткән иде. Өй тагы да нык суынган. Апа кайдадыр чыгып киткән. Ул торып, физзарядка ясап алды да, юынып-киенеп, тәрәзәгә карады. Кыш бабай пыялага кардан әллә нинди тук башаклар ясап бетергән. Менә шундый эре башакларны басуда үстерәсе иде дә бит, дип уйлады ул.

Озакламый Салиха апа да кайтып керде.

— Нәрсә белән сыйлыйм икән үзеңне? Коры чәй булса да... Үлән чәе генә...

— Юк, юк, апа, чәйне аны эчәрбез әле, — дип, шинель өстеннән каешын кысып буды да, соңрак кайтырга вәгъдә биреп, чыгып та китте Тәлгать.

* * *

Райкомның беренче секретаре Әхмәтовның кабинетында төнге сәгать унберләрдә дә ут бар иде әле. Тәлгать керергә дә уйлады, кермәскә дә. Аннан соң тәвәккәлләде.

— Сезнең чакыруыгыз буенча кайттым. “Кызыл маяк” колхозына".

— Яхшы. “Биш партизан”га барырга кирәк иде бит әле. Анда өзеклек. Икмәк тапшыруны сузалар. Син инде ышанычлы кеше...

— Барырмын... — Бу сүзне салкын, тормышка битараф кеше кебегрәк әйтте.

Арыган егет, ялыккан, артык күп эшләгән ахырысы, дип уйлады секретарь. Күндәм, тырыш кеше шулай инде: биш ялкауның эшен берүзе башкара.

Юк, Тәлгать бу минутта ару хакында тамчы да уйламый иде. Иң артта калган колхозларның җирен, ачуым килмәгәе, маңгае белән сөреп, тешләре белән ергалап эшкәртер иде ул. Ләкин андый дуамаллык белән җирне җиңеп булмый. Ә шулай да Илеш җире башкаларныкыннан начар түгел бит. Ә нигә иң артта сөйрәлә Илеш районы? Берәр җиргә барсаң, үзеңнең Илештән икәнлегеңне әйтергә ояласың. Илеш басуларын чүп баскан. Илеш кешеләре, төркем-төркем булып, башка районнарга, производствога китә. Нинди кодрәт кирәк бу Илеш халкы күңеленә ямь өрергә? Бармы ул кодрәт? Кайда ул?

— Әллә авырыйсыңмы, Тәлгать? — дип сорады секретарь, егетнең уйчан, боек йөзенә игътибар итеп.

— Юк, авырмыйм, таң белән “Биш партизан”га китәм, — дип саубуллашып чыгып китте ул.

Урамга чыккач, ком юл уртасында тукталып, ике катлы райком йортына озак кына карап торды Тәлгать. Бөтен халык изрәп йоклый. Ә секретарь утыра. Әнә, тәрәзәсендә ут ничек балкып яна. Ул шушы районны алга алып чыгу мөмкинлекләрен эзлидер, бәлки. Төнге тынлыктагы уйлар тирәнрәк була, диләр бит. Шундый уйлар белән алга атлады Тәлгать. Секретарьның: “Әллә авырыйсыңмы?” — дип соравы гына күңелгә бик охшап бетмәде. Авырырга вакыт бөтенләй юк. Ул — солдат хезмәтендә нык чыныккан кеше. Ерак Көнчыгыштагы заставада хезмәт итте. Заставаның парторгы булды. Тәрбия эше белән нык шөгыльләнергә туры илде. Димәк, физик һәм рухи яктан көчле булуы бар. Ул чыныгу уты мондый авыр елларда аеруча кирәк. Тәлгать аны сүндермәскә тырыша. Егерме-утыз чакрым өчен колхоздан ат-фәлән сорап тормый (ул вакытта машиналар юк иде), билне каеш белән кысып бәйләп, башны югары тотып, солдатча атлый бирә. Авырлыкка, ачлыкка үч итеп дигәндәй, вакыты белән унар чакрымны йөгереп тә үтә. Тормыш йомшакларны яратмый. Киләчәк өчен үзеңне чын кеше, чын коммунист итеп тәрбияләргә кирәк.

* * *

Җир! Галимнәр, ниһаять, радиоактив методлар буенча, синең яшеңне дә билгеләделәр. Дүрт миллиард ярым елга тиң икәнсең син. Ләкин үзең бик карт булсаң да, син әле һаман сабый бала хөкемендәсең.

Синә әле сабый балага караганда да күбрәк тәрбия кирәк. Син, аннан соң, артык көйсезсең. Көеңне табып булмый. Син, ахырысы, шуңа үпкәләдең сугыш вакытында күкрәгеңне сабанга үгез җигеп тә, сыер җигеп тә телгәләделәр, кыскасы, боздылар сине!.. Сырхау баланы аякка бастыру кыен булган кебек, бозылган җирне ипкә китерү дә бик җиңел түгел икән.

Җиргә карап, шундый уйлар кичергән чаклары күп Тәлгатьнең.

Юк, җир, кеше, үгез мөгезенә кунып очкан чебен кебек, синең сыртыңа гына кунып очучы түгел. Ул синнән көчлерәк. Сине эшкә ныклап җигәргә тиеш.

...Райкомга икенче секретарь булып Әхмәт Әминев килде. Ул, кирза итек киеп, колхоз басуларын бер аркыры-бер буй җәяүләп атлады, пычрак фермаларда бата-чума йөреп, көне-төне халык арасында булды. Ул беренче секретарь итеп үрләтелгәч, Тәлгать райсовет председателе итеп сайланды. Әминев киткәч, беренче секретарьлык Тәлгатькә йөкләтелде.

Илеш районының артталыгына теш сызлагандай сыкранып йөрде, әмма мондый җаваплы, зур эшне үз җилкәсенә алу турында беркайчан да уйламаган иде әле ул.

Трактор, киң кырларны гөрләтеп, сөреп китте, сабаннары кәсләрне җай гына каплатып бара. Җир өстендә кап-кара туфрак мамыктай күпереп кала. Шул кап-кара дымлы җирне учына алды Тәлгать Лотфуллович:

— Яхшы бит, җирне әйтәм, тик менә таралып торган кап-кара туфракта күзгә күренми торган чүп үләне орлыклары бар, ничек бетерергә шуны? Ә?! — Секретарь колхоз председательләренә. агроном, инженерларга шундый сорау бирде. КПССның Илеш райкомы секретаре, Социалистик Хезмәт Герое Т. Л. Рахманов.

— Гербицидны күбрәк сибәргә кирәк, Тәлгать Лотфуллович, — диештеләр тегеләр.

— Дөрес, ул чүп үләнен бетерә, ә бит иген уңышын киметә түгелме? Хәтта умартачылыкка да зарар китерә. Яшь үсентеләргә дә зыяны зур.

— Ә ничек котылырга соң бу чүп үләненнән? Секретарь трактор сөреп киткән дымлы кәсләрне ике кулы белән актарырга тотынды.

— Карагыз әле: аста — буразна төбендәге кәсләр арасында ун-унбиш сантиметр чамасы җир сөрелми кала, димәк, чүп үләннәренең тамыры киселеп бетми. Җир яхшы эшкәртелсә, гербицидың бер якта торсын. Менә нәрсә турында уйларга кирәк, егетләр! Иртәгә үк районның бөтен механизаторларын җыеп киңәшләшик әле.

...Җиде төн уртасы. Секретарь уйлана. Өстәл өстендә кәгазь, каләм, сызмалар. Ул яңалык эзли. Ә яңалык тиз генә табылмый. Яңалык ул искелек белән каты көрәш нәтиҗәсендә барлыкка килә. Бу — диалектика законы. Ә законнар тормыш, яшәеш, чынбарлыкны кешеләрнең практик

танып-белүе нәтиҗәсендә барлыкка килә. Дөреслек ялгышуларны җиңә-җиңә өскә чыга. Шулай да җир хаталануны бик авыр кичерә. Озак эзләнү вакытлары үткән. Тәлгать Рахмановның секретарь булып эшли башлавы КПСС Үзәк Комитетеның 1965 елгы март Пленумы вакытына туры килде. Ә Пленум авыл хуҗалыгын күтәрү мәсьәләсен куйды. Димәк, шундый зур эшнең башы ил эчендәге борылышка туры килүдә үзенчә бер символик мәгънә бар кебек. Җитәкчелеккә, партия эшенә чын күңелдән бирелгән, аң-даирәсе киң булган, кешелекле, уңган, откыр кадрлар сайлана башлады. Тәлгать — әнә шундыйларның берсе. Бөтен ил буенча зур икмәк өчен көрәш ялкыны кабынды. Бу көрәшкә Илеш игенчеләре зур дәрт, кайнар теләк, бөек хис-тойгы белән кушылды. Дәрт булса — дарман табыла, ди. 1965 елның көзе үк илешлеләр өчен шатлык белән килде. Һәр гектардан уртача унсигезәр центнер иген алынды. Бу зур җиңү иде ул вакытта. 1967 елда инде Илеш җире һәр гектардан 25әр центнер иген бирде. Илеш хәзер, аргымак ат кебек алга сикереп, республикада беренче урынга чыкты. Секретарьның түшенә Алтын Йолдыз кададылар. Ул хәзер хезмәт батыры! Социалистик Хезмәт Герое! Җир һәм халык батыр итте аны!

Ләкин бу эшнең башы гына. Батырлар җиңелүне белмиләр! Алар фәкать җиңеп яшәргә тиеш!

Шундый уйлар белән кайткан иде ул бүген өенә. Кайтты да язу өстәле артына утырды.

— Син үзең гел кәгазь колы булып яшәүче җитәкчеләрне сүгә торган идең, Тәлгать, — дип, тормыш иптәше аның янына килде. — Ә үзең?.. Тукта, тукта!.. Нинди сызмалар бу?.. Трактор... Сабан... Җир... Син бөтен эшкә дә үзең җигеләсең, ахырысы... Инженерларың, агрономнарың юкмыни?

— Алар югары белемне институтта укып алганнар, ә мин менә — шушы өстәл артында, Илеш басуларында... Беләсеңме... Терентий Мальцев бер җирдә дә укымаган, җир буйлап ялап аяк йөргән, җирнең сулышын, йөрәк тибешен, ай-һай, оста сиземләгән ул!..

— Аңладым... Я, я, ят!.. Сәгать бер...

— Хәзер... хәзер...

...Сызмадан аерылганда таң атып килә иде. Бик арыган булса да, һаман йокысы килми иде аның. Менә хәзер, Мальцев кебек ялан аяк йөгереп, үзенең табышын бөтен игенчеләргә әйтеп шатландырасы иде!

* * *

Тәлгать Лотфулловичның күзләре чалт аяз зәңгәр күккә төбәлгән. Яздан бирле бер тапкыр да рәхәтләнеп яңгыр яуганы юк бит. Сирәк-саяк күренгән бияли зурлык болытлар да Илеш җирен урап үтә. Ә тирә-якта, башка районнарда ява.

...Райком бинасын үтеп, сул яктагы ком юлга борылгач, каршысына бер апа килеп чыкты. Алар бер-берсенә карашып алдылар. Тукта, тукта!.. Кайда күргән иде соң әле бу мөлаем йөзле апаны секретарь? Ә-ә... Әйе... Әйе...

— Саумысыз, Салиха апа?

— Бик... бик... әйбәт әле! Теге... Ой... Тфү... хәтере... Тәлгать бит... Теге вакытта үзеңне кысыр тукмач белән сыйлап җибәргән идем...

— Ул вакытта кысырын да табу авыр иде бит, апа!

— Хурланып үлә яздым инде шунда...

— Үзеңнең хәлләр ничек соң, Салиха апа?

— Районга йомыш белән килгән идем дә... Сезнең якка барасы да бар иде...

— Әйдә, Салиха апа, "Волга" белән генә алып барыйм әле үзеңне.

— Һаман шул кешелекле кеше булып калгансың икән. Халык үзеңне белми мактамый икән.

Секретарь Салиха апаның бу сүзләренә ни әйтергә дә белмәде. Райком секретаре нинди булырга тиеш? Бу хакта күп уйлаганы бар аның. Җирне, агротехниканы, машинаны, икътисадны райондагы теләсә нинди белгечтән ким белми ул. Болай уйлау да дөрес үк түгелдер әле. "Кем белми" түгел, күп белергә, өйрәтергә тиеш. Шунсыз таләпчән, принципиаль җитәкче булып булмый. Ә кеше? Кеше йөрәгенә шифа булып ятарлык җылы, ягымлы сүзләрең бармы, секретарь? Менә... Салиха апа кебекләрнең дә күңелен эретерлек? Бар, анысы да бар. Авыр сүз әйтеп, кеше күңелен кырып куюдан саклана ул. Ә инде җиргә, кешеләргә гамьсез караучыларга аның кулы каты. Шуңа күрә: "Нечкә күңелле, каты куллы җитәкче", — диләр аны.

Әкрен генә җил исә. Бодай башаклары кыштырдашып куялар. Аларның кыштырдавында игенченең моңа кадәр җырланмаган ниндидер дәртле лә, шаулы да җыры бар кебек. Шул тук башакларны әллә кайлардан, хәтта Пензадан килеп карап киттеләр. Әле Куйбышевтан килеп төштеләр. Менә алар басуда. Юл буенда әллә иллеләп машина тезелгән. Төркем-төркем игенчеләр диңгездәй дулкынланып торган игеннәргә карап хәйран кала. Сөйлә, секретарь, уңышның серен, диләр.

— Нәрсә сөйлисең? Рахманов күп сүзле түгел. Күп эшләгәннең сөйләр сүзе кыска була бит аның. Җир кадерен белергә кирәк, дип кыска гына әйтә дә куя ул.

Алар җир куенына тагы да тирәнрәк төштеләр: утыз-утыз биш сантиметрга тирән төшкәч, аның дымы да озакка җитә, чүп үләннәре дә баш калкыта алмый. Басуда бер чүп күренүне ап-ак күлмәгенә кара тап таму кебек күрә хәзер Илеш халкы. Хәтта телефон баганалары тирәсе, юл буйлары мамыктай эшкәртелә — чүп булмасын. Басу йөзен ямьсезләп тормасын.

Игеннең дә үзенең матурлыгы, сәнгате, культурасы бар лабаса! Ә инде җирне ашламалар белән сыйлау хакында күпме генә сөйләсәң дә аз булыр кебек. Кыскасы, җир һәм кеше проблемасы күптәнән килә. Бу хакта бөтен дөнья игенчеләре баш вата. Илештә әнә шуны аңлап эш итә башладылар. Зур хөрмәт күргән җир кояшның эссе нурларына да бирелми. Калын стена булып күтәрелгән игеннәр корылыкны батырларча кичерә. Илеш игенен карарга хәзер ерак-ераклардан киләләр.

...Әкрен генә җил исә. Тук башаклар кыштырдашып куялар.

Рахмановның кулын киң җилкәле, таза гәүдәле бер кеше килеп кысты:

— Хәтерегездәме, Мәскәүдә сез үзегезне "игенче" дип таныштырган идегез? Ә сез Герой-секретарь икәнсез! Бу тыйнаклык саклаудыр инде?

Тәлгать Лотфуллович җиңелчә генә елмаеп куйды. Киң күкрәкле кешегә озак кына карап торды ул.

— Әйе, әйткән идем шул. Мин аны хәзер дә әйтәм. "Секретарь" сүзенә караганда "игенче" көчлерәк түгелме? Миңа бит Герой исемен секретарь булганым өчен түгел, иген үстергәнем өчен биргәннәр! Икмәк — бөтен дөньяның нигезе!

— Менә шулай киләләр дә карыйлар. Без дә кеше бит, шундый бер чүбе булмаган, басуга сыймаслык игеннәрне без дә үстерергә тиешбез, дип сокланалар. Куйбышевтан килгән делегатлар да шундый уй-тойгы белән кайтып китте.

Кеше күңеле — тирән диңгез

"Башкортстан" колхозы дәфтәрен ачам. Укыйым. Дәфтәр таушалып беткән. Чөнки мин аны бөкләп-бөкләп кесәдә дә, портфельдә дә, кулга тотып та йөрткәнмен. Ул дәфтәргә райкомда да, колхоз идарәсендә дә, кырда да, урамда да язылган. Ашыгып-ашыгып язылган. Кайбер сүзләр язылып та бетмәгән. Бер яки ике иҗектән нокта кую белән генә канәгатьләнгәнмен. Башка кеше бу язмаларны танымый, әлбәттә. "Кыр", "сыер", "бодай", "борчак", "процент", "сөт" кебек сүзләрне күреп кенә нәрсә турында сүз барганлыкны чамалар ул. Ә мин аларны таныйм. Әллә кайчан, моннан ун-унбиш ел элек язылганнарын да, бик яхшы укыйм. Юл дәфтәремнең бер як читенә "Кылны кырыкка яручылар" дип язганмын. Дәфтәрнең исемен шулай атарга булдым. ... "Башкортстан" колхозына Илеш районының үзәге булып исәпләгән Үрге Яркәй. Түбән Яркәй. Йонны, Ирмәш ауыллары керә. Үрге Яркәй белән Түбән Яркәй хәзер тоташып бетте. Йонны авылы — Яркәйдән биш чакрым ераклыкта. Ирмәш — Йоннидан 3-4 чакрым чамасы сул якта. Урман эчендә — табигать кочагында. Колхоз председателе Габдрахман Сираев — минем авылдашым. Бер чишмә суы эчеп, бер авыл сукмакларын тапап, бер

мәктәптә укып үскән кешеләр. Габдрахман үзен тиз арада оста җитәкче, колхоз икътисадын якты белүче итеп танытты. Бер тиенне икегә бүлә, кылны кырыкка яра белә, тип тә сөйлиләр аның хакында. Булыр да. Колхозны авыр елларда миллионер итте дә куйды. Авылдашымның бу сыйфатын — тиннәр кәдерен белүен, экономиканы тирән аңлап, сакчыл эш итүен мин зурлыйм. Шуңа күрә бу дәфтәрдә күбрәк икътисад мәсьәләсенең тәрбиягә әверелүе хакында сүз барачак.

Габдрахманның нинди авырлыклар аша колхозны алга алып чыгуы миңа нык билгеле. Ул кешеләр белән эшләүгә бәйләнгән. Бу яктан отышлар да, ялгышулар да булгандыр. Чөнки ул — кеше күңеленә бәйле мәсьәлә. Авылдашым Габдрахман белән 1981 елның августында колхоз эше турында тагы да бер ныклап сөйләшеп утырдык идарәдә. "Башкортстан" колхозы икътисадын мин нык өйрәндем. Әмма башта колхоз председателенең беренче көннәрдән үк булган эшчәнлеге хакында язасым килә.

Кышкы ачы җил, әллә нинди куркыныч килерен хәбәр иткәндәй, иртәдән бирле котырып-котырып исә. Ул, тәгаен шуңа хаслашкан кебек, абзар түбәсендәге саламнарны актарып-актарып ташлый. Оһ, бу абзарлар!.. Менә-менә авып китәр шикелле. Әллә ничә җирдән кыйшаеп төшкән. Зур-зур тишекләрдән шәфкатьсез җил өрә. Җил котыра, тилерә, шаша...

Председатель, бит очларын усал җил чеметеп-чеметеп алуга бөтенләй игътибар итмичә, җимерелеп барган ферма каралтыларына әрнеп карап торды. Аннан, акрын гына атлап, ат абзарына керде. Өелеп-өелеп торган туң тиресләргә карап катты да:

— Нигә моны түкмисез? — дип сорады ат караучылардан.

— Ат җигәргә камыт-дуга юк.

Аннан сарык, сыер азбарзарына китте, салкында бөршеп торган ач малларга карап, йөрәге өзгәләнеп-өзгәләнеп сыкранды аның. Бу сыерлар былтыр нибары 400 килограмм сөт биргән иделәр. Оят, валлаһи!.. Кәзә сөте хәлендә генә бит. Җигәргә сбруй да булмагач, ничек җитәкләмәк кирәк бу колхозны?!

Моның өчен кемне битәрләргә дә белмәде председатель. Сугыштан соңгы авырлыкны белә ул. Озак еллар җаваплы эштә эшләде. МТС директорының урынбасары да булды. Гамсез председательләрне "кызган табага" бастырырга да аптырамый иде. Көннәрнең бер көнендә үзенең кулына колхоз дилбегәсе тоттырдылар. Илеш районы иң арттагыларның-арттагысы, алга сикерү өчен каты куллы, рухи һәм физик яктан да көчле җитәкчеләр кирәк, янәсе, эш председательлеккә корыч йөрәкле уңган егетләр сайлаудан башлана; бу шаукымның уртасында син дә булырга тиешсен, Габдрахман Сираев иптәш!

Бу колхозны элек-электән яхшы белә ул. Иң арттагы районның иң

арттагы колхозы. Башка авылда, ачмы-тукмы, халык үз җирендә ята. Ә бу колхоз — район үзәгендә. Берәү сельпога китә, икенчесе — заготскотка, ә өченчесе базар юлын тапый...

Булдыксыз җитәкче эшнең бармавына мең сәбәпләр табып аклана. Колхозның артта калыуында объектив сәбәптәр дөнья тулы. Ләкин аңа сылтану егетлек түгел; алдыра алмасаң, әйтерләр: өйрәтергә телең шәп иде, сүз сөйләүне теләсә нинди буш куык та булдыра, ә менә хәзер телең белән түгел, кулың белән, акылың белән эшләп кара! Ә нисек?

* * *

Юл чатында аңа Мәрһәм Насретдинов очрады. Уртача буйлы, ябык йөзле бу кеше озак еллар шушы район үзәгендәге колхозда председатель булып эшләде. Хәзер — сельпода.

— Сау гынамы, Мәрһәм туган! — дип җылы гына күреште аның белән Сираев.

— Саулык чамалы инде ул, Габдрахман Хөсәенович, үзегез беләсез, тере мәет булып йөрибез шунда...

— Авырыйсызмы?

— Йөрәк сызлый. Ни өченме? Анау салам түбәле өйләрне күрче... Район үзәге бит бу... Гарьлегеңнән егылып үләрсең!..

— Әйе, әйе, сез хаклы, Мәрһәм Таҗиевич, сыкраныр урыннар күп, ләкин бу йортларны озакламый утынга тураклаячакбыз. Шыңгырдап торган карагайдан салырбыз әле без йортларны! Әнә тегендә парк булачак! Шәһәр халкын көнләштерерлек мәдәният йорты салып җибәрербез! Тынлы оркестр!

Мәрһәм яңа председательгә башын кыйшайтыбырак карады:

— Ә ничек?

— Менә монысы авыр сорау, Мәрһәм Таҗиевич! Бәлки, колхозга кире кайтырсың, бергәләп уйлашырбыз, ә?

Төне буе йокламады Мәрһәм. Шушы колхоз өчен ярты гомерен бирде ул. Башын ташка бәрердәй булып тырышты. Юк, булмады, колхоз бер урында һаман мүкләнгән таш кебек сеңеп утырды. Ул әле халыкка туйганчы икмәк бирү хакында хыяллана иде, шул хыялын тормышка ашыра алмыйча китте колхоздан. Ә бу тирәнрәк уйлый, карашын еракка ташлап, дөньяны ал да гөл итеп, кешеләрне бик тиз генә бәхет диңгезендә йөздермәкче.

Тукта!.. Нигә аның колхозга кире кайтуын тели ул? Төшерелгән председательләрне аның урынына килгәннәр, гомумән, яратмыйлар бит, чөнки искелек гел яңалыкның киртәсе дә ул, юк-юк та, иске председатель яңаның тырнак астыннан кер эзләп маташа. Мәрһәм алай булмаячак, билгеле, ул эчкерле кеше түгел, аның өчен председательлеккә әллә кемне куймасыннар, тик колхозны гына алып барсын, халыкка икмәк бирсен,

икмәк! Сираев, бәлки, аның шушы эчкерсез уйларын сизәдер. Ни дисәң дә, озак еллар партия эшендә эшләгән кеше. Мәрһәм Таҗиев дип олылап эндәшүче дә беренче ул булды. Әллә кеше кадерен белүчеме? Шулай булса — шәп!

Сираев исә Мәрһәм ханында белеп-ишетеп йөри иде. Сельпода урын җылырак булса да, үзенең колхозын, анын басуларын сагына. Бүгенге сөйләшүдә дә аңлашылды бу. Авыл ямьсезләп, җиргә сеңеп утыручы өйләр өчен дә, артталыкка да ачына кеше, колхозны аякка бастыра алмаганга үкенә, болай бер максатсыз яшәвенә борчыла. Дөрес, бер уч бодай чәчеп, бер келәт иген ала алмаган кебек, болай эчтән корыга көеп йөрү белән колхозны алга алып китеп булмый. Ә шулай да колхоз язмышы өчен тирән борчылу бар кешедә.

Янган йөрәк гамьсез булмаска тиеш ул! Кил, Мәрһәм туган, кил, кулга-кул тотышып эшләрбез! Кара инде: колхозның исеме дә "Башкортстан" бит. Артта калып, койрыкта сөйрәлеп барырга ни хакы бар аның? Исеменә генә караганда да, бөтен Башкортстан данын тотарга тиеш ул!

Икенче көндә таң сарысыннан килде Мәрһәм идарәгә. Аның тузып беткән күтәрмәләреннән атлап менгәндә дә күңелен ниндидер җылылык биләп алды. Көн дә ачып керә торган ишекләргә кадәр сагындырган. Рәхмәт, яңа председатель, ояга кире кайтырга ярдәм иттең! Мең-мең төрле авырлклары, газаплары булсын, Мәрһәм өчен барыбер җылы оя ул!

Керсә, председатель күптән монда икән.

— Мин килдем, — диде Мәрһәм, исәнләшеп, саулык сорашкач. — Сельпога барганчы, кичә сөйләшкәннең азагын белеп китим...

— Бригадир итеп куябыз сине, Мәрһәм, шушы беренче бригадага.

Мәрһәм уйланып калды. Бригада дигәне шул элек үзе җитәкчелек иткән колхоз инде. Тирәнтен уйлаганда, шул ук колхоз председателе, шул ук авыл, шул ук кешеләр! Халык нисек каршы алыр аны? Мәрһәм инде иске калай, күп кагылган, димәсләрме? Әгәр әйтмәсәләр, яңы председательнең шундый зур ышанычын аңлап, тоташ төннәр йокламыйча эшләр иде ул.

— Мин риза! — диде ул азак килеп.

...Сагынган кырларны, киң-киң болыннарны урап, ал-ял белмичә эшләп йөрде Мәрһәм. Ары чапты, бире чапты, яңа председатель алдында бер басасы урынга биш басып торды. Кешене сыныйм дисәң, аны җитәкче итеп куй. Кайсы берәүләр икенче көндә үк дусын да, туганын да оныта, урын, әйтерсең, шәхси мәнфәгате өчен тоттырыла аның кулына. Мәрһәмнең властьтан файдалана белмәвен аңлады председатель. Халык күңеле тузган чәркә түгел, гел китеп торуга чыдамый, акырып-бакырып куркытудан ялыккан инде ул, аңа җылы сүз кирәк. Мәрһәм тагы да халык күңеле белән шаяра башлады. Чакырып алды да председатель:

— Йодрык заманы үтте, Мәрһәм Тажиевич, акыл белән эш итү заманы килде, — диде. — Шуны да онытма: икмәк, мал үзе үсми, аны кеше үстерә!

Үзе хакында озак кына уйлады бригадир. Димәк, ул тагы да булдыксыз жан булып чыкты. Халык көннән-көн үзгәрә, культурасы күтәрелә, аңлылана бара шул, аның белән житәчелелек тә үзгәрергә тиештер инде.

— Гафу итегез, Габдрахман Хөсәенович, — дине Мәрһәм, — моннан соң уйлабрак эш итәрмен.

Председательнең җавабын озак-озак көтте бригадир, ләкин жылы сүз ишетмәде. Димәк, китүемне тели, урынга тагы да икенчене куялар, әйдә, шулай булсын, дип уйлады да, башын түбән иеп, чыгып китте.

Аңа авыр иде. Үзен-үзе, шул ук председательне, кешеләрне аңламый иде ул. Башта председатель хакында озак уйланды. Үзе дә каты куллы кешеләр рәтенә керә ул. Гомумән, Сираев районда корырак холыклы, эрерәк табигатьле, аз сүзле кеше буларак танылган. Дөресен генә әйткәндә, беренче көннәрдә халык аны кырын күз беләнрәк каршы алды. "Башкортстан" колхозы өчен тансыклап көтелгән кунак түгел иде ул. Алай дисәң, әнә теге көндә ничек йөрәген ачып сөйләште. Ул, бәлки, эре дә, коры да түгелдер, тышкы кыяфәте, йөзендәге кырыслыгы гына якын килергә куркытадыр. Синең йөрәгеңә ачкыч тапты бит, башкаларга да табадыр. Халык шуңа якын күрә башлагандыр аны.

Усаллыгы бар барын. Әнә, ферма мөдире Шәмсетдиновны ничек тиз җилпеде. Малларга гамьсез караган өчен очырды үзен. Күп сөйләшеп тормый бу. Гамьсезләргә гамьне бирә белә. Шулай кирәктер, бәлки: кемгә баллы тел, кемгә каты сүз кирәктер. Ә менә синең үзеңне шул кырыс холыклы председатель баллы-татлы сүзе белән эретте бит, бер сөйләшүдә йөрәгеңнең нечкә кылларын тибрәлдерде. Ә син үзең кем йөрәгенә шулай сары май булып керә аласың, бригадир иптәш?

Юк, алай ук та кирәкми. Сары майны теләсә кемнең авызына учлап тутырырга да ашыкмаска кирәк. Әнә, Шәмсетдинов авызына салган сары майны да йота алмады. Председатель әйткән ди бит: ике-өч елда колхозны аякка бастырмасам, башымдагы фуражкамны кимим, дигән ди. Моның өчен иң беренче бөтен кешеләрне нечкә иләктән үткәрәм, колхозның бер тинен әрәм-шәрәм иттермим, кылны кырыкка бүләм, "Башкортстан" колхозының җирендә бер генә бөртек бодай да әрәм булып аунап ятарга тиеш түгел, дип әйтә ди.

Әйткән сүзен җилгә җибәрмәгәнлеге дә күренә. Диңгез тамчылардан җыелган кебек, мең-миллион сумнар да тиннәрдән җыела бит. Маллар гел югары көрлеккә җиткәнче симертелә. Һәр килограмм итнең, һәр килограмм игеннең исәбе председательнең уч төбендә.

Тракторы ватылып ята икән, кабыза алмый ызалана икән, аның

өчен түләү юк, һәр эшләгән секундына, минутына хезмәт хакы ала кеше. Башта председательне вакчыл кешегә, сыкканны ялаучыга санап көләләр иде. Шул вакланудан җыелган тиннәр колхозчылар кесәсенә сумнар булып тама башлаган иде, менә, җәмәгать, муллык шул вакчыллыкка да бәйләнгән икән әле, председателебезнең вакчыллыгы тормышыбызны эрелэтә дә лабаса, дип сөйли башладылар.

Менә ни өчен ярата хәзер халык председательне! Шундый уйлар кичерде Мәрһәм. Икенче көнне иртүк тагы да идарәгә килде ул. "Мин үзем шушы колхозныкымын. Шулай да кешеләрне сезнең кебек якыннан белә алмыйм. Үз авылым! Аның язмышы өчен сызланам. Ә шулай да берни эшли алмыйм. Сез бөтенләй башка авылдан, ят кеше булып килдегез. Шулай да халык сезне бик тиз үз итте. Сез башка авыл кешеләре өчен тир түгәсез". Тагы да әллә ниләр әйтмәкче булган иде бригадир председательгә, ләкин... теле көрмәлде, сүзе чыкмады.

— Мин... мин... эшләргә телим! — диде дә тотлыкты. Председатель аңлады аның кичерешен, ләкин бик эреп тә төшмәде.

— Эшләгез! — диде коры гына.

Менә шулай, бригадир иптәш, дип үзенә-үзе эндәшеп атлады ул юлда, җан азыгы кебек яхшы сүз сиңа ярамады, хәзер баш казыгы кебек яман сүз ишетәсең, шулай кирәк сиңә. Шулай!..

* * *

Кояш таулар артына китеп яшеренде. Үзе китсә дә аның алсу нурлары әле җир өстендә сүнеп бетмәгән. Дөнья кичке матурлык эчендә балкый. Иген исе, басу исе, яңа пешкән икмәк исе, яңа сауган сөт исе таралган авылга.

Председатель урам буйлап атлый. Идарәгә житәрәк, бригадир килеп чыкты. Ул нык арыган. Йөзен басу җиле, кояш нуры чуен кебек карайтып, елкылдатып җибәргән. Бу кыяфәт аңа бик килешә. Шулай: игенчедән иген исе, кыр исе килеп тору яхшы. Мәрһәмдә игенче үрнәк итеп алырлык уңай сыйфатлар күп хәзер. Җирне ярата, җир белән эш итүче кешеләр белән уртак тел табарга өйрәнде, тик... күбрәк үзе чаба... Әле бригадирның йончу йөзенә карап шуны әйтте председатель.

— Күбрәк үзегез чабасыз шикелле, Мәрһәм Таҗиевич, болай булса, ике-өч елда шыгырдык арба хәлендә калырсыз.

— Үзе чапкан — күбрәк тапкан, диләр бит.

— Бу — иске мәкаль. Сез үзегез чабып, башкаларның эшкә инициативасын каплап калдырасыз. Җитәкче оештыра белергә тиеш. Бригада советы оештырып җибәрәбезме әллә биш-алты кешедән?.. Алар бөтен җиргә сезнең күз белән карый белә торган кешеләр булырга тиеш.

Икенче көндә үк төзелде совет. Җитәкченең күңел күзе һәр көн һәр тармакны күреп торырга тиеш. Чөнки һәр урынга йөгереп җитешеп

булмый. Ә инде әнә шул һәр урында бригада өчен җан атып йөрүче ярдәмчең булу шәп икән. Алар үзләре тирәсенә янә коллектив туплый. Шулай итеп, бригада бер-берсен аңлап яшәүче, гомум эш өчен янучы зур бер коллективка әверелә. Акыллы кешенең бер киңәше мең акылсызның мең уеннан көчлерәк, диләр иде, дөрес икән. Председатель үзе дә, кайда барып бәрелергә белмичә бушка чабып йөрүчеләрдән түгел. Мәсьәләнең асылына минуты-сәгате белән төшенеп ала. Менә тотты да малчылыкка ябышты. Әллә нинди тәмле үләннәр чәчтерә малга. Урындагы материаллардан менә дигән ферма эшләтеп бирде. Ике-өч ел эчендә аякка басты колхоз. Колхозчыларның кесәсе ярыйсы гына калыная башлагач, акчаның кайдан килүенә гаҗәпләнде халык. Менә бит, агай, күпме байлыктан файдалана белмәгәнбез, килде егет, чокчына, эзләнә, таба, ничә күңел, ничә күз күрмәгәндә күрә, диештеләр.

* * *

Соңгы сүзенә ноктә куйгач, башын аз гына кыйшайтып, ниндидер тавышка колак салды председатель:

— Ачыгыз әле, иптәшләр, тәрәзәне!

Тәрәзә ачылгач, көзге салкын һава белән бергә, идарәгә музыка тавышы яңгырап керде. Әле генә председательнең йөзе кырыс, усал иде. Уңышларны, колхозның киләчәген әйткәч, берәүнең дә күзе төшмәгән, ләкин аяк арасында һәр көн уралып йөргән әллә никадәр вак-төяк кимчелекләрне чокып чыгарды, аларны бетерү юлларын ярыйсы гына ачып салды. Музыка тавышы аның кырыс йөзенә, гүя, нур бөркеде. Аның йөзе, яңа атып килгән таң кебек, һаман яктыра, елмая барды. Колхозның тынлы оркестры булсын да, ул авылга кала яме биреп торсын да, нигә яктырмасын ди председательнең йөзе! Аңа аеруча Мәрһәм игътибар итте. Председательгә рәхмәте тау зурлыгы аның. Кеше итте аны бригадир гына түгел, укытучы итте. Халык белән эш итү өчен укытучы-педагог булырга кирәк икән шул, педагог итте аны Сираев, үткерләде, чарлады... Андый чарланганнар колхозда бер Мәрһәм генәме? Күпләр алар. Бөтенесе дә председательгә рәхмәт әйтәләр.

Монысы бер хәл. Кеше күңеле — җиде кат күк, җиде кат җир, ди бит. Ай-һай, катлаулы кеше күңеле. Аскы иренен тешләп, уртын чәйнәп, көннәрне төнгә ялгап, икмәк дип чапканда, әлеге теге “коры кеше” дигән сүз озак сыланып йөрде председательгә. Келәтең буш, кесәң сай булгач, кеше ачуы китереп, тыштан ялтырап йөрүдә ни файда? Тыштан ялтырап, эчтән калтырай башласаң, синнән нинди җитәкче чыксын, ди. Илештә, гомумән, андый сыйфатлы кешене яратмыйлар. Колхозның матди байлыгын, икътисадын ныгытып алган иде, күкрәк тутырып иркен итеп бер сулап куйды да:

— Егетләр!.. Давай, музыка!.. Тынлы оркестр!.. Музыка мәктәбе!..

— диде председатель.

Әлеге теге җиде катның бер каты ачылды: председатель җыр-моң, музыка яратучы, хисле, тойгылы кеше икән лабаса!

Җырны, музыканы, оркестрны үтә бер мөләемлек белән бирелеп тыңлый ул.

Тагы да бераз тын алган иде:

— Егетләр!.. Давай, яшеллек!.. Бакча!.. Парк!.. — диде. Председательдәге күңел күгенең тагы да бер каты ачылды: ул яшеллекне бик-бик яратучы кеше икән лабаса!..

Районның нәкъ үзәгенә зур мәдәният сарае салдырды ул. Әйдә, үз колхозы гына түгел, бөтен район яшьләре күрсен изгелеген. Тагы да нәрсә? Базы суын будырып, буа ясатты. Елга буйлап агачлар утыртылды. Соңгы вакытта табигатьтән күпне алу, әмма аңа бирмәү турында сөйлибез бит. Агач, урман — җир бизәге. Уфа ягыннан килгән кешеләрне Яркәйгә якынлашканда ап-ак каеннар каршы ала. Каенлыкны чыгу белән ярлары җимерелеп беткән котсыз Базы буе сәламләп тормасын. Базы буйлары да яшеллеккә күмелсен. Кешегә табигать күпме матурлык бүләк итә. Ә кеше шулардан дөрес файдалана белми. Тәбигатьне корыта.

Моның өчен кешеләрне киләчәк буын гафу итмәячәк. Киләчәк бер хәл. Хәзерге яшьләрне табигатьне ярата торган итеп тәрбияләргә кирәк. Киләчәк алар кулында. Янә пляж дигәнен дә эшләтте. Әлеге шәһәрдәгечә эшләпәле баганалар да утыртылды. Әлбәттә, уттай эш вакытында председатель кеше халыкның комда сыртын кояшта яндырып ятканын яратмый. Ләкин тормышны төрле яклы, кызык, мәгънәле итеп тезергә кирәк. Колхозда да эш җайланыр. Шәһәрдәге кебек сәгатьләп эшләнер. Эш ял белән аралашып барганда гына күңелле. Билгеле, болар — көне-сәгате белән хәл ителә торган проблемалар түгел. Әмма акрынлап бөтенесен дә җайга сала барырга кирәк. Авылда шәһәрчә яшәү мәсьәләсе куелган икән, моны якын елларда хәл итәргә кирәк. Кемнең колхозчылары йортны күп төзи? "Башкортстан" колхозы колхозчылары. Һай, күрәлми дә инде председатель авыл котын җибәреп торучы ямьсез йортларны. Матурлык өчен көрәште Сираев. Элек район интеллигентлары сала иде матуррак йортларны. Бәй, баксалар, берничә елдан соң колхозчылар салган йорт янында тегеләрнеке бәләкәй генә булып күренә башлады.

* * *

Бераздан алар урамга чыктылар. Көзге чалт аяз күк йолдызлар белән чигелгән. Мәңге сулап туймаслык салкынча саф һава. Салкынча саф һавада әлеге тынлы оркестрның моңы еракларга тарала. Уйныйлар. Бәйрәмгә әзерләнәләр...

Бераздан председатель ялгызы гына калды. Бик акрын атлады ул өенә табан. Анау оркестр тавышын тыңлап әсирләнде. Менә нинди заман

килде: музыка мәктәбендә ел саен егермеләп колхозчы баласы музыка буенча белем алып чыга. Быел унбер кеше санаторийга, ун кеше ял йортында, сигез кеше туристик походта булып кайтты. Колхозчыларның уртача айлык хезмәт хакы йөз сумнан арта. 150-180не алалар. 200-250 сумга житкәннәре дә бар. Кара, кайсы яклап кына исәпләмә, шәһәр белән тигезләшеп киленә икән лабаса! Житмәһә, кассада миллион ярым сумга якын акча бар. Монысын кайда куярга? Булмаса, шәһәр тибында йортлар сала башларга кирәк!.. Ике катлы итеп. Бөтенесе дә үзендә булсын: ванна, туалет, газ... Тагы да уйлар... Хезмәтле кеше — хөрмәтле, ди. Мәскәүдәге Халык хужалыгы казанышлары күргәзмәсендә өч ел рәттән катнашып, икенче дәрәжәле диплом алды колхоз.

Уйлады-уйлады да үзеннән-үзе көлеп куйды Габдрахман. Соң, иптәш председатель, шулардан башка уең юкмы синең? Клубта да, ашаганда да һаман шул бер үк уйлар.

Үзе һаман акрын гына атлады. Һава саф. Дөнья саф. Акрын гына ай күтәрелеп килә. Аның көмеш нурлары авыл өстенә җәелгән. Уйлата, әллә ниләр уйлата торган көзге матур кич! Габдулла Тукай "Көзге җилләр" дигән шигырендә әнә ничек язган: "Көзге төн. Мин йоклый алмыйм. Өй түрендә җил елый; Җил еламый, ач үлемнән куркуыннан ил елый".

Тукай яшәгән заманда гына түгел, сугыштан соңгы елларда күпме кайгылы кара көзләр килде. Көзге байлыкта келәтләр буп-буш була торган иде. Язын орлык пристаннән күтәреп ташылды. Ярый, безнең халык җегәрле, көчле ихтыярлы, чыдам, авырлыкларны җиңә белә торган булып сыкты. Шулай уйлады председатель.

* * *

Уйлар! Уйлар! Аларның офыклары һаман киңәя бара. Техник прогресс чоры. Автоматлаштыру. Механикалаштыру. Кешеләр психологик яктан үзгәрә. Фикерләр горизонты шуңа бәйле рәвештә катлаулана. Элек авыр иде, хәзер җиңел ул, дибез. Бу чагыштырмача фикер йөртүнең нигезе нәрсәгә кайтып кала? Объектив чынбарлыкны бөтен тулылыгында чагалдырамы ул? Бүгенге яшьләр, картайгач, балаларына шул ук фикерне әйтмәсме? Без әнә нисек эшләдек, ә сез кнопкага гына басып утырасыз, димәсләрме? Кешеләр бер кайчан да тормыш белән канәгать булмаган. Бу дөрес тә. Канәгатьләнү — яшәүгә нокта куюдыр ул. Үз-үзеңнән канәгатьләнү — үсешне тоткарлау, гамьсезлеккә бирелү, киләчәккә перспективаны күрмәү, белмәү, аңламау дигән сүз. Габдрахман Хөсәенович Сираев үз-үзеннән канәгатьме? Илеш районында сугышка чаклы ук урыны белән гектарыннан 40ар центнер уңыш алган колхозлар булган. Күкрәкләренә Ленин ордены, Хезмәт Кызыл Байрагы ордены алып таккан колхоз председательләренең булуы мәгълүм. Ә бу колхоз? Илле икенче елда да әле, кешеләр җиңү белән

күкрәк какканда, "Башкортстан" җире гектарыннан нибары 5 центнер икмәк бирде. Ә хәзер кайсыбер бригада җирләре гектарыннан 40ар центнер бирә. Председательнең түшен ике Ленин ордены, Октябрь революциясе ордены, Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, "Почет билгесе" ордены бизи. Чын мәгънәсендә хезмәт батыры ул!

Бер журналист Сираев иптәш хакында характерлы сүз әйтте. "Без, берничә журналист, — диде ул, — "Башкортстан" колхозының мәдәният сараенда булачак җыелышка киттек. Ниятебез иң алдагы эскәмиягә утыру иде. Әмма Сираев, бик ягымлы гына итеп, алдагы өч рәтнең хезмәт алдынгылары өчен булуын әйтте.

Бу, бер караганда, артык искитәрлек деталь түгел кебек. Әмма, төптән уйлаганда, ул бик характерлы, үзенчәлекле деталь. Без күп вакыт кешеләргә, яше-картына карамыйча, җитәкче булуын искә алып, хөрмәтнең иң зурысын күрсәтәбез. Гади хезмәт кешесе, әйдә, көтеп торсын, соңрак җайлашыр, янәсе. Ә менә Сираевта ул гадәт юк. Хәер, гади хезмәт кешесен зурлай белү кебек күркәм сыйфатлар бөтен район җитәкчеләрендә тәрбияләнә. Әлегә бу четерекле мәсьәлә һаман әле авырлык белән хәл ителә. Яңа кеше тәрбияләүнең төрле формалары кулланылса да, нәтиҗәсе һәрвакыт уңышлы да булмый кебек. Матди байлыкка бәйле рәвештә кешеләрнең яшәү сферасы үзгәрә. Тиз үзгәрә. Менә шуны аңлап бетерү'кыен. Диңгез төбен үлчәп була, ә кеше күңелен — юк. Кыскасы, матди байлыкны барлыкка китерүче, хезмәт җитештерүчәнлеген, икътисадны үстерүче кеше белән нык эшләргә кирәк! Халык хәзер укый, кино, телевизор карый, белемле, укышымлы кешеләр белән аралаша, ул үз өстендә даими эшли, дөньяга башка күз белән карый. Җитәкче боларның бөтенесен дә искә алырга тиеш!

Васыять

Тимерханны председатель итеп куйдылар.

1947 елның язы иде бу. Сугыш беткәнгә ике ел тулып килә. Әмма дөньяның иркен тын алалганы юк әле. Меңнәрчә урыннан туплар, бомбалар белән күкрәге яраланган Җир-ана һаман сыкрый. Җимерелгән авыл һәм шәһәрләр акрынлап аякка баса. Туйганчы бер чара икмәк ашарга тилмерүчеләр дөнья тулы. Әмма, тамагы ач булса да халыкның рухы көр. Ул моңача тарих белмәгән шәфкатьсез сугышта җиңүче булып чыкты. Хәзер үзен теләсә нинди тәмуг утларында янмаслык көчле итеп сизә. Аягы яраланган җир өстендә булса, күңеле йолдызлар илендә. Безнең ил йөрәгенә бөтен дөнья юксылларының киләчәккә өмет тулы күзе төбәлгән. Аңа корычтай нык булырга кирәк. Бөтендөнья кайгысы белән сулыш алган кешегә шунсыз ярамый.

Күп яралардан тәне иләкләнеп, сугыштан гарипләнеп кайткан

Тимерхан да шулай уйладымы икән? Уйлагандыр, әлбәттә. Фронт кырында, ут эчендә батырлыклар күрсәтмәде түгел. Офицер буларак, солдатларны атакага күтәрде, "ура" кычкырып, дошманга иң алда үзе ташланды. Вак-төяк яраларның күбесен чебен тешләве кебек кенә хис итәргә тырышты. Томырылып, ярсып, дошманны чәйнәп ыргытырдай булып барганда тирә-ягында дөнья тетрәтеп шартлаган туплар гына аны аяктан екты, Сафлар алга үткән. Аңын югалткан Тимерхан үз тирәсендә күпме туплар ярылганын белми, әлбәттә. Артык рәхимсез бер ярчык кулын бөтенләй өзеп ташлый язган, һавага күтәрелеп, җиргә кире яуган балчык-туфрак аны күмеп ташлаган диярлек. Госпитальдә, аңына килгәч, аның үлем белән яшәү арасында озак көрәшкәнен әйттеләр. Ә инде яшәүгә өмет уты яңадан ныклап кабынгач, кылдан нечкә, кылычтан үткер сират күперен оста үткәнмен, болай булгач, яшәргә мөмкин икән әле, дип көлде Тимерхан үзенчә. Беркөнне аның койкасы янына ак халатлы врач килеп утырды:

— Я, батыр, хәлләр ничек?

— Мин нинди батыр булыйм ди.

— Ә син үлемне җиңдең.

— Ничек?

— Эчке көчең белән. Менә сине Салават токымы дисәң дә ярый.

— Ә Салаватны кайдан беләсез? Врач татарча сөйләшүгә күчте. Ул үзе Казаннан икән. Кырык яшьләрдә. Уртача буйлы. Мөлаем карашлы, сабыр холыклы кеше.

— Исемең дә җисемеңә туры килә бит, — диде бераз сөйләшеп утыргач, Тимерхан... Тимер кебек ныксың... Әнә шул ныклыгың белән җиңдең үлемне... Авыр чакта сыкрана да белмисең бит... тешеңне кысып түзәсең... Андый кешеләр яшәүгә нык хаклы...

Тимерханга әти-әнисе бу исемне, чыннан да, тимердәй нык булсын дип кушкан. Әмма ныклык та төрлечә бит әле. Табигать кайберәүгә тимердәй ныклыкны бик юмарт бирә. Ләкин тимер сыйфаты бервакыт аны трагедия сазлыгына китереп батыра. Ул, көченә масаеп алны-артны, уңны-сулны карамый, борынын йолдызларгача күтәрә, беләген хезмәт өчен түгел, кешеләр җилкәсен чамалау өчен сызгана. Сугышыр өчен уч төбе дә кычытып кына тора башлый. Андыйлар үзеннән түбәнне рәнҗетергә һич тә күп сорамый. Бу инде аның көчсезлек билгесе. Тимер, шулай итеп, тутыга. Тышкы яктан тутыга башладымы, тимер эчтән дә чери. Эчке көче булмаган кеше дә шулай. Беләге бар — берне, белеме бар меңне җиңәр, дип халык белми әйтмәгән. Белемне бу очракта акыл дип алыйк. Әлеге тимер көчне авызлыклап тота торган акыл — башлык кирәк. Акыл синең физик һәм рухи көчеңә, холык-фигылеңә, кешелеклелек, кечелеклелек, гаделлеккә — кыскасы, бөтен сыйфатларыңа, рухыңа, хосусиятеңә хан булсын. Менә ни өчен бирелгән Тимерханга андый исем.

Шәкерт абыйсы бервакыт шулайрак аңлаткан иде.

Тимер ныклыгыңа, тәнеңдә бер басасы урынга биш бастырып кайнап торган эссе каныңа, йөгәнсез яшьлек хисләреңә акыл-ханны башлык итеп куя белү дә бәрәңге ашау кебек җиңел түгел икән шул. Тимерханга бу хакыйкатьнең чынлыгын кешедән сорыйсы юк. Гамьсез балачакта да, сөлектәй буй җиткезеп, фырт егет булып өлгергәч тә, авыл картларыннан каргыш алган, дуамаллыгы аркасында әти-әнисен бик күп төннәрдә тәмле йокыдан мәхрүм иткән чаклары аз булмады. Әлбәттә, Тимерханның күңелендә кешеләргә карата кара күләгә бөтенләй юк иде. "Яхшыдан яман туган" дигән сүзләр дә йөрәген телгәләмәде түгел. Ә яманлык кайдан килә? Нигә яхшылык белән яманлык аерылмас юлдашлар? Бөтен яманлыкны чокыр казып күмәсе иде дә, җир йөзендә, ап-ак канатын җәеп, яхшылык кына очып йөрсен иде. Алай итү дә мөмкин түгел шул. Чөнки яхшылык белән яманлык бер-берсенең эчендә яшиләр икән. Бар, яшьлек тилелегеңә акылыңны хан итәлмәгән башың белән аерып кара син аларны? Аш биреп, таш алган кебек, вакыты белән яхшылыгың да яманлык булып кайта. Бу, бәлки, тормыштагы аерым очраккынадыр. Очраклы яманлыкларга япсарынып, яхшылык дигән бөек, изге, мөкатдәс төшенчәгә кара ягу турында уйлау гына да гөнаһтыр. Әмма бу кырыс тормышта күпләр объектив чынбарлыкка нәтиҗәне аерым очракларга таянып чыгара бит. Ничек кенә булмасын, яхшылык өчен яманлык алудан авыр хәл юктыр бу дөньяда. Бу хакта да Тимерханның кешедән ишетәсе юк. Ул шуның авырлыгын күп кичергән кеше. Әллә ничәсеннән берсен искә алу да җитә.

Тимерханнар авылы Ябалак янында Ямәлкә тавы бар. Анда Емельян Пугачев гаскәре оборонасы булган. Бу тау тирәсендә әби патша гаскәре белән кискен алышлар була. Боларны Тимерханга шәкерт абыйсы сөйләгән иде. Тимерхан күңелендә бәләкәй чакта ук ниндидер сихри көчкә ия булырга теләү хисе кабынды. Малайлар арасында үзен атаман дип атарга да җөрьәт итте ул. Ямәлкә тавы буенда үзенчә сугыш уеннары оештырды. Көрәш, алыш каты була торган иде. Бервакыт, салкын көзге көннәрнең берсендә, тирләп-пешеп, хәлдән таеп беткәч, атаман Сөн елгасына йөгерде. Билгеле, малайлар аннан калмаска тиеш. Коштай очып шулай барган җирдән Тимерхан, чишенми-нитми, салкын Сөн суына кереп китте. Малайларга аннан калырга, куркаклык галәмәтен аз гына да сиздерергә ярамый. Малайлар елгага суга сусап килгән үрдәк балалары урынына сикерештеләр. Беркемнең дә сынатасы килми.

Тимерхан моңа шат. Әмма күпләр бизгәк тоткандай калтырарга керешә, тешләре-тешкә тими. Тимерхан тагын торып чаба. Малайлар да аннан калмый. Тагын тирләү. Ләкин бу шома гына үтми. Кайта да егыла. Ул хәзер уттай яна. Салкын тигән...

Малайлар моны сер итеп тота, билгеле. Әмма без капчыкта ятмый.

Усал булсаң — асарлар, юаш булсаң — басарлар, ди. Бу усаллык өчен Тимерханга тал чыбыгы ашарга туры килә.

Ничек кенә булмасын, атаманлыкны ташламады ул. Күңелендә үзе өчен фәкать бер изге, мөкатдәс уй саклап йөрде: үсеп армиягә алынгач, командир булырга! Теләгән таш ярган, дигәндәй, бу максатка да иреште ул. Сугыш чыккач, хәрби училище тәмамлап, ике кулбашына офицер погоннары такты. Аны взвод командиры итеп куйдылар. Аның взводы бервакыт ПТР белән дошманның җиде танкын тончыктырды. 1943 елда иде бу. Ржев янында. Бу батырлык өчен Тимерханның күкрәгенә икенче дәрәҗә Ватан сугышы ордены тактылар. Орденнар белән, бәлки, күкрәк тулыр иде. Хәер, мәсьәлә анда түгел. Көрәшәсе, алышасы, алга барасы, сугыш беткән көнне фронт кырында каршылыйсы килә иде Тимерханның. Әйе, булмады. 1944 елның мартында инвалидка чутлап кайтарып җибәрделәр.

Физик ныклыгы, үлемне эчке көч белән җиңүе хакында әйттеләр лә ул. Ләкин врачлар синең йөрәгеңдә нинди яшерен ут янганлыкны белмиләр шул. Йөрәк кавын түгел, ярып күрсәтеп булмый. Күпләр кебек ул да Берлинга барып җиткән булыр иде, бәлки. Ут эчендә үзен-үзе саклый белмәде. Янып калды. Гәүдә бөтен, билгеле. Әлеге сафта бару хыялы янды, ә кисәве йөрәктә калды. Ул яңадан дөрләргә кереште, Тимерхан күбесенә үзе гаепле. Өлкән командирлар кисәтә килде: юкка батырлык күрсәтергә тырышу ахмаклык ул, сакла үзеңне, диделәр. Билгеле, менә мин нинди атаман, күрегез, дип, дан казаныр өчен утка ташланмады Тимерхан. Аның йөрәге түземсез иде. Ул, бәлки, балачактагы атаманлыктан киләдер. Хәтта взводны вакытыннан алда атакага күтәргән чаклары да булды. Ә инде; “ура” кычкырып, иң алдан үзе йөгерми чарасы юк. Көч-куәтнең чамасызлыгын сиздереп торган озын буй. Эчке бер ныклыкның барлыгын балкытып торган караш. Сабырсызлык галәмәте катыш кырыс йөз. Ул үзен взводтагыларның барсыннан да көчлерәк сизә. Көчле күбрәк күтәрмәсә, көчсезгә көч килә, ди бит. Кыскасы, авырлыкны үзенә алырга тырышу гадәте анда балачактан килә.

Бу кеше өчен яхшы сыйфаттыр, бәлки. Әмма Тимерхан аны һич тә үзен яхшы күрсәтергә теләү нияте белән эшләми, болар бөтенесе аның егетлек дәрманлыгыннан килә. Егетлек данын югары тоту тойгысы көчле анда. Әмма тимер ныклыкка акыл һаман хан була алмый. Алда туплар ярыла. Ә ул туплар ярылганда ятмый. Солдатлар куркакка санамасын, янәсе. Әйтерсең, үзен чыннан да утта янмый торган тимер дип хис итә. Туплар күпләп ярылды Тимер бөгелеп төште...

...Кайткач, мәктәптә физкультура укытучысы булып эшли башлады ул. Бер ел үтте. Ике...

Көннәрдән беркөнне аны шәкерт абыйсы чакыртты. Чакыра килгән

сары малайның теше сирәк иде, күрәсең, сер йомгагын шундук сүтеп тә ташлады: шәкерт абыйсының васыяте бар, имеш...

— Нинди васыять? — дип гаҗәпләнде Тимерхан.

— Ул сезне председательлеккә... — малай, белмичә суган сатмыйммы дигәндәй башлаган сүзен дә очламады.

— Нинди председательлек?..

— Ни... мин кеше әйткәнне генә...

— Кем әйтте?..

— Әни дә... башкалар да...

Малай ничек җилдәй килеп кергән булса, әйттем исә кайттым дигән төс белдереп, җилдәй чыгып та сыпырды.

Тимерхан уйга калды. Ул моны көткән иде. Ачыктан-ачык әйтмәсә дә, шәкерт абыйсы тел төбе белән акрынлап сиздерә килде: колхоз дилбегәсен киләчәктә Тимерхан тимер кулларына урап тотарга тиеш. Тик васыять дигәне генә шикләндерә. Нинди васыять? Председательлеккә ул васыятьнең ни кысылышы бар икән тагы?.. Янә бер сорау күңелне тырный: нигә төн заманымда чакырта ул? Иртәгә башланмаган өр-яңа көн бар лабаса? Васыять дигәне әллә?..

* * *

Тимерхан урамга чыкты. Өч тәүлек буена котырынган март бураны тынып калган. Әле кичке сәгать уннар булыр. Әмма бик сирәк тәрәзәләрдә генә утлар күренә инде. Халык йоклый. Юк, болай уйлау дөрес булмас. Күпләрнең сукыр лампалык та керосиннары юк бит. Кайберәүләр чыра яндырып та азрак утыра. Өй эче исләнеп, төтенләнеп бетә. Шуңа күрә кышкы озын төннәр. өчен сәкегә урын иртәрәк җәелә шул. Әмма аларны бу вакытта тирән йокыга талган дип уйларга һич тә ярамый. Тол хатыннар фронт кырларында ятып калган ирләрен сагынып мендәр чылатадыр. Балаларының кайтуын көтеп тилмергән аналарның колаклары сакта торадыр. Әнә капка шыгырдады. Аяк тавышы. Тәрәзә чиртелеп, ишек шакылды. Ана сикереп тора. Ишеккә бара. Юк, юк. Тавыш тына. Ул тавыш, гомумән, булмаган. Шуны өмет итеп ятканга колакка шул тавышлар ишетеләдер. Ана янә үз урынында. Аның хәзер керфекләре чыланмый.. Чыгасы яше чыгып беткән инде. Кипкән. Хәзер йөрәге елый. Монысы бигрәк тә авыр. Туйганчы бер еласаң, күңел бушап кала. Эчтәге хәсрәт уты күз яше белән тышка түгелә. Ә инде сугыш вакытында, аннан соң да зурларның авыр йөген үз җилкәләренә алган юеш борынлы нарасый малайлар, эштән арып кайтып, киң сәкене тар итеп дигәндәй, бер аркылы, бер буй килеп изрәп йоклап яталардыр. Аларның кайберләренең әнә шул юеш борыннары астында, сизелер-сизелмәс, бала йон урынына мыек төртеп чыга башлаган. Алар йокыга әвәс түгел. Ару-талуны белми. Белсә дә, сынатмый. Карынга бүген икмәк

эләкмәгән икән, икмәк сорап кычкырып, кеше арасында хур итмәсен өчен, әче чыкмаслык итеп, әчне каеш белән алагаем кысып буа да куя ул. Кызлар күзен кызыктырырлык итеп чәче чыгып торсын өчен бүрекне я кырын кия, я маңгайдан арт чүмеченә таба ераккарак шудырып куя. Фырт-фырт басып урамга чыгып китә. Клубка, уку өенә бара. Аннан мөмкин булган урынның тәрәзәсен чиртеп карый. Я булмаса, күмәкләп, ниндидер көтелмәгән яңа бәхет табарга өмет иткәндәй, урам әйләнәләр. Тальян телгә кинә. Җыр-моң яңгырый. Нишлисең, яшьлек үзенекен итә-

Шуларны уйлап атлады Тимерхан. Әйтерсең, аның уйларын җөпләп, безнең хакта ялгыш фикер йөртмисең Тимерхан абзыкай, дигәндәй, тын һаваны дулкынландырып, аргы якта тальян чыңлады. Тальян моңы егетләрнең җыры белән аралашты. Авылга ямь, яшәү дәрте кергәндәй булды. Дөрес, бу моң чын егетләр моңы түгел иде әле. Тавышны бик чәрелдек дип тә, чын егетләрнекечә кызлар йөрәген җилкендерерлек дип тә булмый. Гадиләштереп әйткәндә, ул әле көзге әтәч кычкыруын хәтерләтә. Бар иде Тимерханнарның тар урамны киң итеп җырлап үткән чаклары. Ул калын тавышлы егетләрнең күбесе сугыш яланында ят җирләрдә ятып калды шул. Тимерхан җырда да атаман иде. Тавыш көр, моңлы, йөрәккә үтеп керә торган. Башлап ул җырлады. Аңа кушыла торганнар иде. Фронттан кайткач, ул вакытларны да сагынып күп ямансулады Тимерхан. Җәйге төндә рәхәтләнеп, күкрәк киереп, туйганчы бер җырлап үткән чаклары аз булмады. Ләкин аның моңында элекке йөрәк ялкыны, тормыш симфониясенең кайнар сулышы, яшьлек дәрге белән тулып кайнаган хис-тойгы юк иде инде. Шәкерт абыйсы бер көн аны җиңелчә генә шелтәләп тә алды:

— Син әллә тол хатыннарны, балаларын көткән аналарны елатыйм әле дип җиң сызганып кайттыңмы? — диде.

Тимерхан авырга алмады.

— Йөрәк ярсый, шәкерт абый! — диде.

— Әнә клуб. Сәхнә. Тик кара анны — елатма халыкны. Халыкка рухи көч кирәк.

Илеш бабакайны хәтерлә!

Тимерхан клубка күчте. Чыннан да, бала заманына карап туа, дигәндәй, җыр-моң да заманча булсын икән. Күңелен патриотик хисләр белән тәрбиялим дип, халыкка әхлак принципларына корылган җыр җырлап кына торып булмый бит инде. Ул артык нечкәреп, балланып-кәнфитләнеп китүне дә яратмый икән. Үз йөрәгендәге моңны кешеләр йөрәгендәге моң белән ялгарга, тоташтырырга, берләштерергә кирәк иде аңа. Бу максатка иреште ул. Хәтта үзе җыр язып, үзе көй чыгару осталыгы да аннан читтә калмады. Ул җырлагач, идәнгә аякларны тибә-

тибә, гөр килеп, кул чаба торган булып китте халык. Аннан пьесалар кую башланды. Тимерхан хәзер — режиссер. Пьеса сайлау да җиңел эш түгел икән. Ул да җыр кебек. Әсәрнең эчтәлеге дә, андагы геройлар да, артистларның уйнавы да халыкның рухи дөньясына тәңгәл килерлек булсын. Үтә нечкә хисләргә, сызлануларга, кәнфитле мәхәббәтләргә корылган, идеясе өрсәң мамык кебек очып китәргә торган пьесаларны халык яратмый. Идея артыннан куып, кызыл сүзләрне борчак урынына чәчкән, лозунгтагыдай фразаларга корылган пьесаны да халыкның рухи хосусияте кабул итми. Халык андый пьесаларны көйләнмәгән скрипкадан чыккан моңны ихтыярсыз кабул иткән кебек кенә кабул итә. Кешеләрнең күңеленә рухи азык бирү, ул күңелне якты нур белән баету дигән нәрсәнең дә серләре ифрат четерекле икән.

Әлеге сугыш чорында үзләрен иртә олы сизгән, тол хатыннарның йөрәк әрнүләрен үз йөрәкләренә кабул итеп, балаларын көткән аналарның күз яшьләрен күреп үскән көзге әтәчләренең моңы әллә нинди уйларга чумдырды Тимерханны. Ул акрын гына атлады, һава саф. Зәңгәр күктә бихисап йолдызлар чекрәеп яна. Күңелдә мең төрле уйлар: яшьлек, сугыш, яшәү, шәкерт абыйсы, председательлек, васыять.

Илеш карт васыяте

Бүген әллә нигә күңеле күтәренке түгел иде аның. Шәкерт абыйсы янына ул бу дөньяда яңадан табылмаслык нидер югалтып, балтасы суга төшкән кеше кебегрәк барып керде.

Керә керешкә, билгеле, кикриге шиңгән әтәч кебек йөрү галәмәтен яшен тизлегендә үзгәртергә туры килде. Борын салындырып, ник туганына үкенеп йөрүчеләрне шәкерт абыйсының җене сөйми. Аның янында үзеңне булдыклы солдат кебек тотарга кирәк. Бу — бер. Икенчедән, соңгы вакытта аның сәламәтлеге нык какшады. Шулай булмаса, ул тынгысыз җан бу вакытта юрган астына керергә ашыкмас иде. Җитмәсә, өенә кеше чакырганда. Кәефен күтәрер өчен аның алдында якты йөзле булырга кирәк.

— Исәнмесез, шәкерт абый! Хәлләрегез ничек? — дип, аның койкасы янына барып утырды Тимерхан. — Чакырткансыз икән?

Шәкерт абыйсы сүз башларга ашыкмады. Эчкә баткан хәлсез күзләре белән Тимерханга озак кына карап торды.

— Хәлләр шәптән түгел, Тимерхан,— диде ул бераздан соң. — Койка магнит белән бер бит менә, үзенә тарта, яткан идем, җибәрми, җитәр сиңа, карт сөяк, дөнья ямьсезләп, кот җибәреп, кеше күзенә күренеп йөрмә, ди.

Аның кипкән иреннәре көзге яфракны хәтерләтеп дерелдәде. Ул, үзенчә, елмаерга тырышты. Ләкин елмая алмады. Моны сизде Тимерхан.

Шәкерт абыйсы сынатырга, жәлләтергә, мескенләнергә теләми... Алай йомшап калма, йөрәкнең соңгы тапкыр тибүенә кадәр бу дөньяда Кеше икәнлегебезне ихтыяр көчебез белән күрсәтергә тиешбез, ди инде, янәсе.

Илеш шулай булган бит!

Ничек кенә булмасын, шәкерт абый күз алдында сүнеп бара. Өстәл өстендә җиделе лампа. Аның яктысында шәкертнең кипкән йөзе күм-күк булып күренә. Хәл белергә Тимерхан үзе килергә тиеш иде бит. Нигә инде чакырганны көтәргә? Әй, бу башсызлыкны!..

Шәкерт, талган күзләрен әйләндереп, Тимерханга бер карады да, күкрәге белән авыр тын алып, ютәлли башлады.

— Васыятем бар! — диде, ютәле басылгач. Үзенең күзләре һаман Тимерханда булды. Нуры сүнеп барган ул күзләр күпне сөйли иде. “Минем васыятемне үтәрсеңме, егетлегең җитәрме, каешың ничек, бик йомшак буылмаганмы?” — ди иде ул караш.

Тимерхан исә эсселе-суыклы булып китте. “Васыять” дигән сүз аның зиһенен алды. Шәкерт абыйсы бу якты дөнья белән бәхилләшергә уйлыймы? Андый кешенең үлемгә хокукы бармы? Васыять хакында уйлау дәрәҗәсенә җиткәч, ул үзенең хәлен үзе беләдер инде. Йолдыз булып балкыды бит. Тирә-якка нур чәчеп яшәде. Андый йолдызларның үзе сүнсә дә нуры кала, билгеле. Ләкин... аның сүнүенә һич тә ышанасы килми.

— Васыятем шул: колхоз дилбегәсен кулыңа тот!..

— Председатель бар бит инде, шәкерт абый!

— Хановны әйтәсеңме? Колхоз өчен туган кеше түгел ул.

— Халык ни әйтер бит?

— Халык минем сүздән чыкмас...

Тимерхан уйланып калды. Озак кына сүзсез утырды ул. Үзе дә сизмәстән, кулындагы солдат бүреген йомарлады, кул аркасы белән маңгаена бәреп чыккан салкын тирен сөртеп алды. Сизгер күңелле шәкерткә аның икеләнгәнен аңлау кыен түгел иде.

— Күрәм: куркасың...

Тимерханның йөрәге “жу” итеп китте. Шәкерт абыйсы аны куркакка чутлыймы? Менә монысын ишетү кыен, әлбәттә.

— Болай бит ул, шәкерт абый!.. — дип сүз башламакчы булган иде Тимерхан, шәкерт сөяккә генә калган көчсез кулларын селкеп куйды: кирәкми, акланма, тыңламыйм, янәсе.

Аннан ул дәвам итте:

— Кирәк икән, синнән сорап тормаслар. Минем үз уеңны беләсем килә. Колхозны мин Ханов кулына калдырып китә алмыйм...

Тимерхан аны юатырга тырышты:

— Шәкерт абый!.. Сез әле яшәячәк...

Шәкерт, артык сүз кирәкми дигәнне аңлатып, тагын кулын селекте.

— Ризамы? Син шуны гына әйт!

— Иртәгәге чаклы уйлыйм әле, шәкерт абый!

— Иртәгә чаклы, имеш... Хәтереңдәдер, Тимерхан, моннан ике ай элек җыелышта колхозның киләчәген сөйләгән идем... Авыр булырмы? Күтәр! Васыятем шул... Карт коммунист васыяте! Әмма минеке генә түгел ул, ата-бабайларныкы!.. Буыннарныкы Илнеке! Партия васыяте! Син коммунист! Мин моны иртәгә үк бөтен халыкка, райкомга җиткерәм!

Тимерхан икеләнеп утыруына үкенеп куйды. Шәкерт абыйсының бер сүзле, тоткан җирдән өзә торган гадәтле икәнлеген белә бит инде. Нигә аның күңелен күтәреп, җанына тынычлык биреп, "була ул, шәкерт абый" дип кенә әйтмәскә?

Шәкерт аңа әлеге хәлсез кулын үзе сузды:

— Ышанам!.. Көчеңә, халыкка, җиреңә таян!

Илеш җирендә яшисең

— Рәхмәт!.. — диде Тимерхан, саубуллашып чыгып китте.

Тышта салкынча иде. Тынлык хөкем сөрә. Теге көзге әтәчләрнең дә тавышы ишетелми. Кунаклаганнар, күрәсең. Тимерхан, үз уйларына күмелеп, акрын гына атлады. Чыпчыкның да бизмәне бар дигәндәй, аның үзенчә яңа планнары бар иде. Ул укытучы булып китте. Дөресен генә әйткәндә, яратты ул бу һөнәрне. Мәктәптә аңа физкультурадан тыш расем, жыр, сызым дәресләре дә бирә башладылар. Тарихны бик ярата иде ул. Үзлегеннән хәзерләнеп, башта унынчы класс өчен имтихан тотмакчы иде. Аннан институт ишеген шакырга була. Анда инде фән дөньясы. Боларны шәкерт абыйсына әйтмәде. Чөнки аларның барсы да әле чыкмаган кояш. Аның белән шәкертнең күңелен җылытып булмый. Гомумән, ул васыятьтән баш тарту бернинди әхлак принциплары, язылган һәм язылмаган законнар белән сыешмый. Ул васыятьтән баш тарту коммунистлык, ир-егетлек, кешелек намусыңны хөрмәт итмәү булыр иде. Алардан башка тормышта яшисе дә калмый.

Әйе, Ханов ашка таш белән атты. Халык күзенә көл сибә башлады. Аңа ышандылар. Колхоз председателе итеп куйдылар. Ә ул халык ышанычын рәхимсез рәвештә аяк астына салып таптады. Беркөн эчкән килеш колхоз председателенең өч рәхәте булуы турында сөйләп борчак чәчкәнен Тимерхан үз колагы белән ишетте. Аныңча, өч рәхәтнең берсе — айгыр җигеп йөрү, икенчесе — аракы, өченчесе — хатын-кыз. Ә бит председатель булганчы алай түгел иде. Кеше өстәл артында сынала шул. Өстәл арты бирәүне бик тиз эгоист ясый, икенчене дусларыннан, туганнарыннан аера Өстәл арты кайсы кешене кеше итә. Әйтик, эндәшми-

тынмый, сабыр гына, күрер күзгә өметле, булдыклы, егәрле булмаган берәүне өстәл артына утырттылар. Ул — җитәкче. Менә шунда ачылып китә кеше. Буаны ерып җибәргән кебек. Әгәр су буага аның тыеп тора торган көченнән артык җыелмаса, ул китмәс иде. Әлеге сабыр кешенең эчендә һичкем игътибар итмәгән, күрмәгән, буа суы кебек җыелып торган көч булган. Аны кая куярга да белми йөргәндер ул, бәлки. Җитәкче булып алгач, бу акыллы баш, җиң сызганып, бөтенхалык мәнфәгате өчен изге эшкә керешә. Өстәл артының кадерен белә ул. Ханов, кызганычка каршы, алай булмады шул. Йомшак җан булып чыкты. Солдаткаларның күңеле белән уйный. Сыйлаганда су эч, дигән принцип белән яши. Йөз граммга алдана. Айгыр җигеп, күрше авылларга күңел ачарга чыгып китә. Ә без шуңа түзеп яшибез, җитмәсә, үзебезне коммунистка чутлап йөрибез, фронтовик, җиңүче булу белән мактанабыз, дип борчылды Тимерхан.

...Үч иткәндәй, чатка борылганда аның каршысына Ханов килеп чыкты. Ул кызмача иде. Алар кара-каршы килеп бастылар.

— Ә-ә-ә... Синме бу... Тимерхан?.. — дип мыгырданды теге.

— Мин әле бу, Ханов агай, — диде Тимерхан, "Ханов агай" сүзенә басым ясап.

Ул бу басымны аңлады шикелле.

— Каты сөйләшмәкче буласыңмы?

— Ә нигә безгә йомшарга?

— Oho!..

Тимерхан узып китмәкче булды. Председатель аның беләгеннән тотты.

— Тукта әле, сөйләшәсе бар, күптән тел кычытып йөри.

Тимерханның кәефе юк иде.

— Бәлки, иртәгә калдырырбыз, сез эчкәнсез.

Ханов йомшак сөйләшүгә күчте.

— Әй, туган, безнең эштә син дә эчәр идең...

Тимерхан эндәшмәде. Аңа нотык укуның стенага борчак белән бәрү кебек икәнлекне ул яхшы белә. Шәкертне тыңламаганны, башкалар сүзенә колак та салмый инде ул. Шулай да аннан бераз шөрле иде әле. Ә инде ул түшәккә яткач, бөтенләй чыгырыннан чыкты.

— Әйе, эчәр идең, — дип сүзен дәвам итте Ханов. Шулай диде дә янә Тимерханның җиңеннән тотты. — И... мин әйтәм... эчәчәксең дә. Васыять алырга бардыңмы? Ха-ха... Сине... председатель итепме?.. Ха-ха... Шәкерт синең яклы ул... Ярый, аның күләгәсендә яшәрсең, ә ул үлгәч...

Тимерханның ачуы табан астына төште, бугазын буды; бөтен тәне бизгәк тоткан кебек калтырый иде аның.

— Җитте! Оятсыз! — дип кычкырды ул. — Шәкерт абыйга тел тидерәсе булсаң! Мин сине!..

— Колхоз печәте кирәкме, мә!.. — дип йодрыгын Тимерханның борын астына куйды ул.

Тимерхан аның якасыннан бөтереп алды. Менә хәзер салып изәсе иде үзен. Әмма тыелып калды. Ярамый. Атаманлык еллары үткән.

— Шәкерт яшәячәк! Ә син?.. — Әйтәсе сүзен Тимерхан әйтеп бетермәде, Җил-җил атлап китеп барды. Бервакыт үзләренең капка баганасына килеп сөялде ул. Хәзер тәрәзәләрдәге утлар да сүнгән. Тын. Тып-тын. Тимерхан, үзе да сизмәстән, телогрейка төймәләрен ычкындырып җибәрде. Март салкыны аның тәненә сарылды. Ә төне матур!.. Тик ул артык серле кебек. Җиргә таян, диде шәкерт. Ә җирдә кемнәр генә юк. Нигә җир йотмый шундый кешеләрне? Җир-ана артык сабыр шул. Безнең кебек пырдымсыз түгел. Ул күккә карады. Әнә кайда сафлык! Күктә бөтен нәрсә сафтыр ул. йолдызлар саф кешенең карашын хәтерләтеп балкыйлар!

Фронттагы кебек бу. Бервакыт бары да тына. Ә ул тынлык күңелгә шом сала. Дошман нindидер этлек уйлый. Шуңа күрә атмый әле. Андый тынлык синең йөрәгеңне ярсыта гына. Ул тынлыктан соң давыл өермә, ут булмый калмый. Биредә дә шундый. Бүген әле тынлык. Иртәгә шушы Ханов һәм аның кебекләр белән кискен көрәш башланачак.

Бераздан Тимерхан өйгә керде. Хатыны Мәгъдәния ятмаган иде әле. Сукыр лампа яктысында бәйләм бәйләп утыра иде.

— Шәкерт абыйның хәле ничек? Нигә чакырткан? Нинди васыять?.. — Мәгъдәния, түземсезләнеп, Тимерханны төрле сораулар белән күмеп ташлады. Әмма иренең борчулы йөзен күреп, җавап алырга ашыкмады.

Тимерхан телогрейкасын, бүреген салып чөйгә элгәч, гимнастерка изүен ычкындырып җибәрде дә:

— Хәзер... барын да сөйлим, — дип Мәгъдәниясе янына барып утырды.

* * *

Ябалак авылы, дөнья күзеннән яшеренергә теләгәндәй, Сөн елгасы буендагы бер ышыграк урында посып утыра. Ул Илеш районына керә. Тәмам өстенә килеп чыкмый күренмәгән бу авыл белән ил картасында ул каен яфрагын хәтерләтеп торган Башкортстан чикләнә. Ябалак. Сөн. Аның көнбатыш ягында Татарстан башлана. Ябалак яныннан бормаланып-бормаланып аккан Сөн Агыйделгә коя. Агыйдел — Камага. Кама — Россия елгаларының анасы Идел белән барып кавыша. Сөн елгасы, әйтерсең, чокыр урында, тау ышыгында посып утырган шушы Ябалак халкының кайгы-хәсрәтен дә, шатлыгын да, тын алышын да җанлы бер сын кебек сизеп, аңлап ага; аны яшерен, серле бер тарихи ядкарь итеп саклап, бөтен ил йөрәгенә җыелып бара торган истәлекләр хәзинәсенә илтеп сала. Икенче төрле әйтсәк, Ябалак авылы йөрәге бөтен

ил йөрәге белән бәйләнгән. Ил йөрәгендә башланган революция дулкыннары монда да бик тиз килеп җитә. Октябрь кояшының якты нуры бирегә дә бик тиз килеп төшә. 1928 елда егерме сигез хуҗалык берләшә. Аның җиде сабаны, берничә сыеры, берничә аты була. Утызынчы елда ул "Искра" колхозы булып китә. Беренче бураздны коммунист Габдрахман Басыйров сыза. Ул буразна салам түбәле өйләре җиргә сеңеп утырган шушы караңгы авылның олы, якты тормышка чыгуын символлаштыра иде. Кешеләр күңеленә иң беренче яктылык буразнасы сызучы да Басыйров булды. Парта арасында аңа башлангыч белем алырга гына туры килгән. Үзлегеннән укый ул. Искесен дә, яңасын да, гарәпчәсен дә, латинчасын да — барсын да су кебек эчә. Шуңа күрә авыл халкы аны башта "шәкерт" дип атады. Әмма теге унбишәр ел мәдрәсәдә ятып катып калган шәкерт дип уйларга ярамый. Элек, халык надан булганда, шәкертләрне бик белемлегә санаган. Авылга кайтса, алардан барын да сорашканнар. Әйтерсең, ул әүлия, барын да белә. Басыйровны халык барлык белемнәрнең шәкерте дип исәпли. "Шәкерт" исеме әнә шуннан кала. Соңга таба, халык мәдәниләшә башлагач, аны "аяклы тарих", "энциклопедист" дип тә атыйлар. Әмма "шәкерт абый" дигәне халыклашып китә. Бу сүз эчке бер җылылык белән, аны зурлап, хөрмәт итеп әйтелә.

Кемнең кем икәнен халык аңлый шул. Беренче буразнаны ул сызып, күп вакыт буразнада йоклады, авырлык төбенә башта үзе җигелеп, эшләү үрнәген, яшәү мәгънәсен үзе күрсәтте. Сугышка китәргә дә йөрәксенгән иде — алмадылар. Рәхимсез авыр еллар сәламәтлеген нык какшаткан. Син монда да бик кирәк, диделәр. Бу сүзне райком да, военкомат та әйтте.

Сугыш елларында ул уку йорты мөдире булды. Аннаң гел партия оешмасы секретаре эшен алып барды. "Шәкерт абый" әйтте дип кенә сөйләшә халык. Ул әйтсә — закон. Димәк, уйлап, үлчәп, акыл белән әйтелгән. Ул беркайчан да коры үгет-нәсыйхәт, матур сүзләрне чикләвек урынына яру белән шөгыльләнмәде, ваклашып, кешеләр җанын ашамады. Олы йөрәкле кеше иде ул. Эшнең эчендә кайнады. Аның йөрәгендә бөтен халык, ил кайгысы иде. Ил үзен зурлаган улларын зурламый калмый, әлбәттә. Сугыш беткән елда аның күкрәгенә Хезмәт Кызыл Байрагы ордены тактылар. "Искра" сугышка чаклы да очкыннан ялкынга әйләнгән иде инде. Икмәк үстерде ул.

Икмәкне күп үстерде. Икенче дәрәҗәле диплом белән бүләкләделәр колхозны. Кемне генә председатель итеп куймасыннар, колхозны барыбер Басыйров җитәкләде. Эз белән, акыл белән.

Кешеләр күңелендә якты нур булып яшәгән шәкерт юк инде. Март бураннары котырган көндә ул мәңгелек йокыга талды. Ә васыяте калды. Ул райкомга да яшен тизлегендә барып җитте. Райкомның агитация һәм

пропаганда бүлеге мөдире Тәлгать Рахманов килде да клубка бөтен авыл халкын җыйды. Башта колхозның озак еллар дан тоткан кодрәте хакында әйтте, Хановның кешеләр күңеле белән шаяруы, җирне аңламавы, үз корсагы мәнфәгате өчен генә яшәве турында сөйләде.

Җыелыш давыллы булды. Хановның да коерыклары аз түгел икән. Мактап-мактыйлар тегене. Алар хәтта халыкны гаепләү кебек оятсызлыкка барып җиттеләр. "Салып бирүче булмаса, Ханов аракыны иснәп тә карамас иде, алдында "ихахай да михахай" килеп, кәнтәйләнеп тормаса, хатын-кызга да бармас иде ул, гаеп үзебездә, халыкта, җәмәгать, начар егет түгел иде бит ул", — диде берсе. Халык шаулап көлеп алды, үзара сөйләшү китте. "Давай, Ханов калсын, ул эшләр, Нәҗмиев сәхнәдә җыр җырлар, җырчы да кирәк бу дөньяда, ач кешенең ачуын кабартырга", — дип шаулаштылар.

Авыл халкы җор телле була. Мондый тарткалашның таңгача сузылуы мөмкин иде. Рахманов кыска тотты.

— Киләчәк хакында нык уйлагыз, иптәшләр! — диде. — Икмәк кирәк! Дәүләткә кирәк! Илгә кирәк! Халыкка кирәк. Һәрберегезнең туйганчы бер икмәк ашыйсы килә! Җир кадерен белүче, кешеләр күңелен аңлаучы, кешелекле, кечелекле җитәкче кирәк!

Тимерхан әнә шул сыйфатларны үзендә чагылдыручы кеше булып чыкты. Күп куллар аны яклап күтәрелде. Каршы чыгучылар да булмады түгел, әлбәттә. Ничек кенә булмасын, ул кадәр теләп куймадылар шикелле аны. Тимерхан моны сизде. Ләкин халыкка үпкәләмәде ул. Халык әйтсә — хак әйтә. Халык күңеле — ил күңеле. Ил күңелендә кара тап булып талпынып тору мөмкин түгел.

Болай итеп уйлавы гына җиңел. Кырык җиденче елның мартында аны председатель итеп куйдылар. Егерме дүрт яшь иде аңа бу вакытта. Икенче көнне иртүк идарәгә килде. Эш көне кырык ямаулы күлмәк кигән бер апаның ярты гына кило булса да он бирүләрен сорап килүе белән башланды. Өч балам ачтан үлә, дип елады ул. Аңа кушылып, Нәҗмиевның да йөрәге елады. Ул колхоз малларын карарга чыгып китте. Алар да ачтан тилмерә. Каралтылар да сугыш кайгысын аз кичермәгән. Анда терәү, монда терәү.

Мартның соңгы, көннәре иде. Кояш кыздыра. Кыйгаеп беткән мал абзарларына озак кына сыкрап карап торды Тимерхан. Шунда бер карга абзар түбәсендәге бер колгага килеп кунды да: "кар-кар-кар" дип каргылдарга керешге. Тимерхан бу тавышны яратмады. Карга, әйтерсең, "кар-кар-кар, карашың тар-тар-тар" дип, Нәҗмиевтан көлә иде. Әле мин сине дип, Тимерхан янда гына яткан бер туң ат тизәге алды да, озак төзәп торды, бәреп төшерү теләге белән, каргага томырды. Бәләкәй чакта бик төз ыргыта торган иде. Юк икән, һәр нәрсә үз вакыты белән...

Әйе, карашлар тар иде ул вакытта. Бөтен нәрсәнең нигезе икмәк

шул. Сугыш бетте. Бер ел үтте. Икенче елда аякка басуда иде исәп. Кырык җиденче елда табигать кешеләрнең күңелен аңламады. Күк ул елны кешеләрдән бер тамчы яңгырын да күпсенде. Үләннәр көйде. Ашлыклар көйде. Менә шул елны эчтән генә, йөрәге белән ант итте Тимерхан: табигатьтән рәхимлекләр көтмәскә, табигатьнең рәхимсезлекләрен җиңеп яшәргә! Җирнең серен, сулышын, тын алышын аңларга! Шул җир белән эш итүче кешене бөтенесеннән дә өстен куярга! Моның өчен ул вакытта карашлар тар булгандыр, әлбәттә. Ул карашлар икмәккә бәйле рәвештә киңәя бара шул.

Очу сәнгате

Ил бәхете! Кешенең үз бәхете! Болар арасында нинди аерма бар? Юктыр, бәлки. Бөтен ил кара кайгы кичерсә, нишләп аерым шәхес бәхетле була алсын, ди. Ил белән килгән уртак авырлык та ул кадәр какшатмый адәм баласын. Димәк, ил һәм кеше бәхете бер-берсе белән кәрәзләнеп китә.

Ике тапкыр Советлар Союзы Герое полковник Муса Гәрәев бәхетлеме? Бәхетле! Аны иле бәхетле итә. Дуслары. Полкташлары. Командирлары. Ә үзе илен бәхетле иттеме? Итте. Ике тапкыр Советлар Союзы Герое Башкортстанда берәү генә — Муса Гайса улы Гәрәев кенә. Аны “Урал бөркете” дип тә йөртәләр. Урал! Батырлык һәм матурлык символы ул! Күпме җыр, легенда, риваят иҗат ителгән аның хакында. Аның батырлары санап беткесез. Шуларга Муса батыр килеп өстәлде. Урал данын, Башкортстан данын янә күтәреп җибәрде бу батыр.

Батыр туса — ил бәхете, яңгыр яуса — җир бәхете, дигән мәкальне халык әллә кайчан ук иҗат иткән. Сугыш, көрәш, кан коеш һәрвакыт булып торган. Батырлы ил җиңеп чыккан көчле алышта.

Батыр егет телгә кыюсыз булыр, дип тә әйтәләр. Бәләкәй чакта кыюсыз, йомшак табигатьле, аз сүзле була Муса. Әтисе вакыт-вакыт әйтеп тә куя: “Юаш булсаң, басалар, усал булсаң, асалар”, — ди. Әтисе улының басылып яшәвеннән курка. Муса эндәшми. Әмма ул сүзләр күңелне кыра, йөрәкне әрнетә, нык уйланырга мәҗбүр итә.

Муса 1922 елда туа. Илеш районының Иләкшиде авылында. Колхозчы гаиләсендә. Утызынчы елларда мәктәптә “Кем булырга?” — дигән сорауга җавап эзли торган иде. Укытучылар укучыларны очучы, инженер, табиб кебек һөнәрләр белән кызыксындыра иде. Заманы өчен шулай кирәк булгандыр да. Чөнки ил һөнәр осталарына мохтаҗ. Мусаның күңеле шул һөнәрләрнең берсен сайлау теләге белән ярсыды. Тик... дәрт бар, дәрман юк, дигәндәй, алар турында уйларга да курка иде хәтта. Һм, врач бул, имеш. Кешеләрнең чирен тап. Моның өчен әүлия булырга кирәктер ул. Инженер, әнә, зур заводларны эшләтә белә икән. Авылга

беренче тракторлар килде. Тракторчылар, ай-һай, күкрәкләрен генералныкыдай киереп, үзләрен әллә кемгә санап, масаеп йөриләр. Ә инде "летчик" дигәне һавада оча. Бу сүзне телгә алырга ла курка Муса. "Җаны теләгән елан ите ашаган", — диләр лә ул. Елан ите ашавың белән генә һава корабын йөртеп булмыйдыр шул. Айга сикергән ахмактай кыланганчы, үз чамаңны бел дә, үз чанаңа утыр. Җиде еллык белем алгач, Уфа тимер юл техникумына укырга китә ул. Күктәге тормыш аңа тәтемәс. Очу бәхетенә барыбер ирешә алмаячак. Җирдә "очар". Их! Машинист булып алса! Тимер юлдан җиләсең генә бит. Аның әллә кайларга, еракларга яңгыраган моңлы тавышы гына ни тора. Әкияттәге толпар белән бер бит ул. Ә инде артта сузылып-сузылып калган күксел төтене шул толпарның ялын хәтерләтә.

Янә бер бәхет ишеге ачылды Муса өчен. Уфада аэроклуб эшли икән лабаса. Тимер юл техникумында да укыды ул, бер үк вакытта шул клубка да йөреде. Дөрес, урыс телен яхшы белмәү бәласе аркасында күп авырлыклар кичерергә туры килә. Вата-җимерә сөйли башласаң — көләләр. Андый чакта чөгендердәй кызара Муса. Шулай за артка чигенми. Вакыт-вакыт ул бөтен биргән эшне ятлап килә хәтта. Аңласа-аңламаса да сөйли бирә. Сүзләрне пулемет угы урынына чәчә. Аның бу гадәтеннән көлә башладылар. Урыс телен ул үзаллы да өйрәнергә кереште. Берүк һүзне унар-егермешәр тапкыр әйтә. Миенә тәмам сеңеп калырлык итеп, сүзлекләр белән дә эш итте. "Борының белән боз ярып булса да алга бар", — дигәнне ишеткәне бар аның. Алга! Алга!! Алга!!! Аэроклубны яхшы тәмамлагач, инструкторлар аңа очучылар әзерләүче хәрби училищега укырга барырга киңәш бирә. Димәк, ул аэроклубта вак бәрәңге булмаган. Аңлаганнар аның кайнар теләген. Унсигез яшьлек Муса Энгельс шәһәрендәге хәрби очучылар мәктәбенә укырга китә. Әмма анда да, әйткәндәй, кылдан нечкә, кылычтан үткер сират күперен үтәсе, ягъни имтихан бирәсе бар икән. Тапшыра ул имтиханны. Үтә сират күпереннән. Хәзер инде сөйләгәндә урыс шайтаны аның теленә тозак салмый. Фикер һәм сөйләм дә бер-берсе белән дуслашып алды. Хәрби училищеда ул үзенең чын мәгънәсендә күк батыры булачагын исбат итте...

Әйе, дөресен генә әйткәндә, сугышка ул куркыбрак барды. Юк, үлемнән түгел. Оятка калудан. Чөнки полкта үзен әкияттәге Алып батырдан да көчлерәк итеп күрсәтергә тырышучылар бар. Алар йодрык күрсәтә, фашисларны сүгә, "ә" дигәнче Берлинга барып җитмәкче була. Муса тын гына йөри. Андый ярсуларга катнашмый. Үзен шул "пәһлеваннәрдән" күпкә түбән куя. Беренче очыш вакытында ук беленә башлады кемнең-кем икәнлеге. "Пәһлеваннәр" алдыра алмай. Я дошман прожекторы яктылыгына эләгә. Шул яктылык буенча зенитка снарядлары очып килеп шартлый. Яна самолет. Бу якты дөнья белән мәңгегә

хушлаша мескен очучы. Бәгъзе берсенең моторы эшләми. Бомба ташлаганнан соң өскә күтәрелеп китә алмаучылар да була. Ярсу, алабарманлык, юкка әтәчләнү — очучының дошманы икән. Тәртип, игътибарлылык, курыкмау, авыр минутларда үзеңне кулга ала белү кебек уңай сыйфатлар кирәклекне беренче очышта ук аңлады Муса Гәрәев. Аларны иман шарты дәрәҗәсе итеп тойды. Шул иманга сугыш беткәнче тугры калды.

Сугышка кергәндә ул сержант кына иде әле. Штурм авиациясендә хезмәт итә. Ил-2 самолетында оча. Сталинград, Крым, Украина, Белоруссия, Балтик буе, Германия күгендә оча. Сугышны полк штурманы буларак тәмамлый. Димәк, полктагы барлык штурманнарның таҗы булу дәрәҗәсенә күтәрелә. Майор погоны тагып ала.

Белгәнен дә, белмәгәнен дә яшерми Муса. Оста очу серләрен ул һаман ныклап өйрәнә. Буш вакыттан файдаланып, очу техникасы турындагы китапларны укый. Оста очучыларның тәҗрибәсен өйрәнә. Крым егете Әхмәт-Хан Солтан аның иң якын остазы, укытучысы, соңыннан аерылмас дусы була.

Ул да Муса Гәрәев кебек, ике тапкыр Советлар Союзы Герое була.

Дөрес, Муса Әмәт-Хан алдында үзен көчсез очучы итеп тоя иде әле. Чөнки ул күккә күтәрелсә, фрицлар “күктә Әмәт-Хан Солтан”, “күктә Әмәт-Хан Солтан” дип тукый торган булганнар. Аны хәтта “күк шайтаны” дип атаганнар. Ул күктә чакта очарга да куркалар икән.

Әмәт-Хан Солтан Мусага биектән шәп тизлектә очу, дошманга көтмәгәндә көчле удар ясау серләрен сөйләде.

Сугышта бөтенесе дә бар. Хәтта мәхәббәт тә. Бу ике чибәр егеткә дә сугыш уты эчендә мәхәббәт уты татырга туры килә. Болар көндез оча, төнлә ял итә. Янә майор Бершанская төзегән хатын-кызлар полкы бар. Алар, киресенчә, төнлә очып, көндез ял итәләр. Ике очучылар полкы бер тирәдәрәк була. Ләкин бер-берсен һич тә күрә алмый. Шулай да бервакыт җай табылды. Өч-дүрт көн тегеләр дә очмады, болар да. Менә шунда Әмәт-Хан белән Муса әлеге очучы кызларны күзләп килмәкче булды. Кемнәр алар? Ниндирәк затлар? Ә бит бомбаны фашист өстенә төне буе борчак урынына коялар. Даннары бөтен фронтка таралды. Фашистар аларны “Төн пәриләре” дип атады. Әнә шул “пәриләрне” күрергә кирәк.

Төнлә очучы хатын-кызлар полкына урман аша барырга кирәк икән. Ни гаҗәп, адәм әйтеп, адәм ышанмас, шул “төн пәриләренең” берсе очрый боларга. “Пәри” бер каенга асылынырга маташа, Ни өчен? Ни кайгысы бар? Куркакмы әллә? Йөгереп барып, егетләр аның кулындагы җебен тартып ала. Ат кешнәшеп, сандугач сайрашып, кеше сөйләшеп таныша, ди. Сөйләшә торгач, шул ачыклана: бу “пәрине” — Ләйлә Санфированы — очудан мәхрүм иткәннәр. Кулак кызы булган өчен. Самолеты белән дошманга бирелүе бар, янәсе.

Егетләр кызны үлемнән саклап алып кала. Ләйлә яңадан оча башлый. Шулай да әлеге кулак корымы нык сылана Ләйләгә. Бервакыт аны утыртып куялар. Хәрби трибунага бирү өчен. Анда инде я үлем, я унбиш еллык таш капчык. Ташларга кирәк булганда, Ләйлә самолетының бомба салынган савыты ачылмаган, Бомбаларны ул кире алып кайта. Шуннан соң янә шау-шу китә. Имештер, кулак кызы Ләйлә үз аэродромын бомбага тотмак булган. Йозак кына ачылмаган.

Ләйлә белән бергә Мәгүбә Сыртланова да хезмәт итә. Егетләр полкка янә килә. Башта алар Мәгүбә белән киңәшләшә. Чөнки Мәгүбә Сыртланова полкта офицерлар намусы суды рәисе итеп тәгаенләнгән була. Аның белән гаплашеп алгач, егетләр полк командиры майор Бершанская янына бара.

— Менә нәрсә, егетләр, әдәпле генә килеп йөрергә мөмкин, әмма безнең эчке эшләребезгә тыгылырга хакыгыз юк, — ди полк командиры.

Сабыр табигатьле Муса бу юлы ярсып китә:

— Без кызның намусын, кешелеклелеген сакларга килдек; әгәр Ләйлә Санфировага очарга рөхсәт итмәсәгез, аны бүгән үк алып китәбез. Мин бу хакта полк командиры белән сөйләшеп килдем. Хатын-кызлар бездә дә җитәрлек. Әмма алтын базыннан чүп, тырнак арасынан кер эзләмибез. Алма кебек яшь кызны рәнҗетергә ирек бирмәбез.

Әхмәт-Хан Солтан бер сүз дә әйтмәде. Чөнки Мусаның усал сөйләшүенә нидер өстәргә кирәкми иде. Мәгүбә Сыртланова да тын гына тыңлап торды. Бу ике чибәр, батыр, сөйкемле егеткә карата булган кайнар тойгысы көчле иде аның. Муса — ак чибәр. Крым егете Әмәт-Хан — кара чибәр. Кеше язмышы өчен аларның шулкадәр янып йөрүләре охшады Мәгүбәгә. Соңыннан сорап та куйзы:

— Әллә сез сугышка чаклы икегез дә укытучы булдыгызмы, чибәр егетләр?

Муса менән Әмәт-Хан көлеп җибәрде. Шуннан аларга үзләренең кем икәнлекләрен бәйнә-бәйнә сөйләп бирергә туры килде. Баксаң, Мәгүбә үзе дә кулак кызы икән. Ике кулак кызы фронтка үз теләкләре белән килгән. Ә моңа ышанмыйлар. Мәктәптә Мәгүбәнең яраткан укытучысы булган. Ул да, болар кебек, кешенең кайгысын да, шатлыгын да уртаклашып яшәгән. Шул хакта сөйләп биргәч:

— Сугыштан соң сезгә укытучы булырга кирәк, энекәшләр, — дип елмайды ул.

Мәгүбә яше белән алардан олырак иде. "Энекәшләр" сүзен моның өчен әйтмәде ул. Кызлар берчә көлеп, берчә шаярып, берчә үзләрен эре бәрәңгегә санап очучы егетләрне "энекәшләр" тип йөртә башладылар.

Әмәт-Хан Солтан белән Ләйлә Санфирова йөрәгендә мәхәббәт уты дөрләп китте. Алар сугыш беткәнче үк, менә шушы ут эчендә, чәчләрен чәчкә бәйләргә тиеш иде. Вәгъдә бирешелде.

Аңлаштылар. Күктә мең үлемнән котылган Ләйлә җирдә минага абынып харап була. Аның үлемен авыр кичерә Әмәт-Хан, Муса исә полкларына килгән Таня исемле бер яшь кызга сала мәхәббәт тозагын. Бу вакытта аңа Советлар Союзы Герое дигән исем бирелгән була инде.

Ут эчендә туй ясала. Дөрес, Муса бу эшкә барыр дип берәү дә уйламый иде әле. Полк командиры каршы килергә дә уйлады. Ләкин Мусаның ялкынлы йөрәгенә су сибү мөмкин түгеллекне аңлады ул. "Батырның ярты һөнәре — тәвәккәллек", — дигәнне белә ул. Күктә дә тәвәккәл, җирдә дә. "Батырлык ярты бәхет", — дип тә әйтәләр. Әйдә, бәхетле булсын! Тик... сугыш берсен юк итеп, икенчесен бәхетсезгә әйләндермәсме? Шулай уйлады да полк командиры: "Батырны ук алмый", — дип куйды.

Сугыш бетәр алдыннан Муса Гәрәев батырлыкны аеруча нык күрсәтте. Полк штурманы булгач, иң җаваплы, куркынычлы очышларга ул башкаларны җибәрергә тиеш иде. Ләкин андый очракта үзе очарга тырышты.

Советлар Союзы Герое дигән исем дә бирелгәч, өйләнеп тә алгач, Мусаның гомерен сакларга тырышалар. Ләкин, авыр, куркыныч, җаваплы заданиеләрне барыбер үз намусына ала ул. Кешене түбәнсетүдән, аларга ышанмаудан да түгел. Ул очу "сәнгатен" башкаларга караганда ныграк үзләштерүен сизде, үлмәячәгенә нык ышанды. Бервакыт моторы эшләми башлады. Мондый очракта ул парашют белән сикерергә тиеш иде. Ләкин сикермәде. Чөнки ул әле дошман ягында. Җиргә борыны белән кадалырга биш-алты метр калгач эшләп китә самолет. Аны хәтта "Үлмәсбай" дип атадылар. Дошманның күпме ут-позицияләрен, танкларын, боеприпасларын, хәрби кораллар төягән эшелоннарын көл итте ул. Шуннан аңа Советлар Союзы Герое дигән исемне янә бер тапкыр бирделәр. Бу исемгә Ләйлә Санфирова да (үлгәнннән соң), Мәгүбә Сыртланова да (сугыш беткәч) лаек булды.

"Ефәк билбау — бил күрке, батыр егет — ил күрке", — ди. Сугыштан соң да ил күрке була Муса Гаиса улы Гәрәев. Ул Совет Армиясе сафында кала. 1951 елда Фрунзе исемендәге Хәрби академияне, аннан соң Генеральный штаб академиясен тәмамлый. Һаман шулай күп оча. Яңа самолетлар үзләштерүдә катнаша.

"Оясында — ни, очканында — шул", — диләр. Ул очучы һөнәрен Уфадагы аэроклубта үзләштерә башлаган иде. Муса Гәрәев моны беркайчан да онытмады. Уфага кайтып, үзенең дә яшьләрне шушы һөнәргә өйрәтү теләге белән яшәде. Һәм... кайтты да ул. Озак еллар Уфадагы Республика ДОСААФ комитеты председателе булып эшләде. Һаман шулай тыйнак, ачык йөзле, басалкы, аз сүзле, кешелекле була белде. Матурлык һәм батырлыкның гадилектә икәнлеген аңлатып яшәде.

Муса Гәрәев шактый авыр чирләр дә кичерә. Ләкин аны бирәүгә дә,

хәтта җәмәгатенә дә сиздермәскә тырыша. Ир кешегә зарлану килешми, янәсе. Дәваланса, бүген дә яшәр иде, бәлки. Җитмеш биш яше белән горурланып йөрер иде. Иртәрәк китте шул безнең арадан. Иртәрәк. Әмма якты истәлеге калды. Кешелеклелек сыйфатлары. Айбарлы гайрәте. Тарих сәхифәләренә язылган даны бизи!

Сандугач куна гөлләргә

Сандугач куна гөлләргә
Алар бит яшәү яме.
Гөл, сандугач мәхәббәте —
Күркәм тормыш гыйззәте.

Әдәпле, тәртипле, матур күңелле кеше “и гөлкәем!” дип сөйләшергә ярата. Бу сүз белән ул боз йөрәкленең бозын эретә, югары борынлының борынын төшерә. “Сандугач” дигәнебез шагыйрь булып чыкса, аның ләззәтлелек шәүкәтен “гөлкәем” дигән тәмле сүз генә канәгатьләндерми. Шуның мәгънәдәшләрен эзләп, тел диңгезенә чума ул. Аның дулкынында бер аркылы, бер буй йөзеп, төбенә үк төшеп янә сүзләр тапкач, янә өскә күтәрелә. Шатлана. Хозурлана. Ижтиһатлана. Хәзер сандугачтай сайрарга тиеш шагыйрь. Әгәр булдыра алса... Ә бит сандугач бер төрле моң белән генә сайрамый. Моңны ул даими үзгәртеп тора. Аның без белмәгән авазы, хәрефе, сүзләре бар. Шуларны үзгәрткәндә төрләнә аның моңы. Мондый үзгәртү сандугачка кешеләр һәм башка кошлар мәхәббәтен яулау өчен кирәк.

Сандугач кешеләр рухын чамалап сайрагандай, шагыйрь сүзләрне заман занына яраклаштырып куллана. Асыл сүз шагыйрьне адәм итә, гарип сүз — әрәм итә. “Сүз — йолдызлы күк”, “сүз — җан азыгы”, “сүз — рухи җимеш”... Бу хакта мин Татарстанның халык шагыйре, күренекле җәмәгать һәм дәүләт эшлеклесе Роберт Мөгаллим улы Миңнуллин турында язарга булгач, ныклап уйландым. Без — якташлар, бәрәкәтле Илеш иленнән. Илеш бабакаебыз бик уңган, мәрхәмәтле, сөйкемле, сабыр табигатьле, батыр йөрәкле, хезмәт ярата торган кеше булган. Фани дөньяны оҗмах итү хыялы белән яшәгән. Тамыры нинди — кәүсәсе шундый. Алтын тамырдан корычтай кәүсә хасил була. Корыч кәүсә тимердәй нык ботаклар җибәрә. Без — шул ботакларның баллы яфраклары. Шөкер, яфраклар дөнья ямьләү сәнгатен саклыйлар әле.

...Районташым, замандашым, каләмдәшем, фикердәшем, аркадашым Роберт Миңнуллин 1948 елның 1 августында бу якты дөнья оҗмахына елап түгел, җырлап килә. Әнисе Гөлжәүһәр аны Сөннән алып кайта. Сөн — Башкортстан белән Татарстан уртасыннан агучы иманлы елга. Мең бизәккә төренгән Салават күпере калыкса, аның бер очы — Башкортстан җирендә, икенчесе — Татарстанда. Уртада — Сөн. Кулга

шаһәдәтнамә алгач, Казан шәһәренә укырга китә Роберт. Мәктәптә чакта ук язган шигырьләре, җырлары Сөн сандугачы моңыдай шәфәгатьле була иде аның. Шулай итеп, Тукай әйткән дәртле Казанга, монлы Казанга Сөн моңы да килеп кәрәзләнде. Китап артыннан китап, майлы табадан төшкән коймактай, коелып тора. "Коймаклар" саны кырыкны кырлагач, бер ел эчендә (2007) җиде томлык сайланма әсәрләр бастырып, тизлек тәмен татытты, җитезлек җимешен жемелдәтте, батырлык балкышын балкытты, айбарлылык аен нурландырды, талант тантанасын танытты Башкортстан егете.

Моның сәбәпләре күп, әлбәттә. Беренчесе — Илеш бабакай рухыдыр, бәлки. Икенчесе — Салават иленнән булу шөһрәтедер, мөгаен. Бай, гүзәл, матур, нәфис табигатьле Башкортстан җире татар әдәбияты дөньясына Г. Ибраһимов, Ә. Еники, М. Әмир, Ф. Кәрим, Ә. Ерикәй, И. Юзеев, М. Фәттах һ.б. талантлар, сүз сәнгате осталарын бирде. Монысы — өченчесе булсын, ди. Дүртенчесе... Хәер, алар күп, санап тормыйк. Шулай да, халык әйтмешли, күптә бәрәкәт.

"Ни чыкса, Илештән чыга", дигән гыйззәтле сүзләр йөри. Май өстенә май ягылса — яна җай дигәндәй, Илеш сандугачының Татарстанда яңа моң белән сайравы барыбыз өчен дә уртак рухиятлелек. Бер ел эчендә — җиде том! Беренчесендә — шигырьләр, тәрҗемәләр; икенчесендә — җырлар, эпиграммалар; өченчесендә — балалар өчен шигырьләр, әкиятләр, хикәяләр, мәкаләләр; дүртенчесендә — балалар өчен шигырьләр, кечкенә әкиятләр, ирекле тәрҗемәләр, төрле язмалар; бишенчесендә — иҗади портретлар, мәкаләләр; алтынчысында — публицистика, истәлекләр; җиденчесендә — нотыклар, рецензияләр, әңгәмәләр. Бу җидене тау күкрәген бәреп чыккан җидегән чишмә белән дә чагыштырырга мөмкиндер. Җидегән йолдыз белән дә. Ул гел әйләнеп тора. "Бүген монда башкайларым, иртәгә әллә кайларда", — дигән кебек. Хәер, Роберт замандаш үзе дә шулай бит инде: бүген Башкортстанын сагынып кайтса, иртәгә Татарстанын сагынып китеп бара. Бу хакта ул күп яза. Җиде строфадан торган "Кайда да..." исемле шигыреннән икесе:

Тар ла миңа Казан гына
Үскәнгәдер иркендә.
Туган яклар тарта мине —
Түгел мин үз иркемдә.
Һәм кайтам мин Казаныма
Яктырып, канатланып!
Кайда да үзебезнең моң.
Кайда да безнең халык.

"Кайда да үзебезнең моң" дигәне күңел күбәләгеп ерак тарихка сәяхәт иттерә. Безнең эрага кадәр үк чиктәш яшәгән чиннар (борынгы кытайлар) белән һуннар (сөннәр-төркиләр) моңы уртак булган. Төрки

телләргә ерак кардәш булып исәпләнгән корея, япон моны да шуларга охшаш. Башкорт белән татар халкы арасындагы моңлылык мәхәббәте — кан, җан, заң, рух, иман кардәшлегеннән. Шулай булырга алла кушкан аларга! Бала заман заңына карап тугандай, кардәшлек каныңдагы зәррәләр дә үзгәрә бара. Соңгы елларда, рухи күперне тагын да ныграк алтынлау өчен, "Дуслык киштәсе" булдырылды. Башкорт язучыларының иң яхшы әсәрләре Татарстан китап нәшриятында дөнья күрә. Татар язучыларыныкы Башкортстан китап нәшриятында басыла.

Әлеге җиде томны Башкортстан халкы ябырылып укый. Халыкчанлык хас Роберт галиҗәнап өслүбе өчен. Сүз-сурәт, сүз-фикер, сүз-тойгы кардәшлеге көчле. Матурлыкның гадилектә икәнлеген аңлап яза. Үзенә генә тәгаенләнгән өслүбе бар. Өслүб (стиль) — киң төшенчә. Нәзариятчеләр (теоретиклар) аның йөздән артык билгеләмәсен бирә. Иң кыскасы: "стиль — әдип үзе". Холкы белән Роберт әфәнде уңган укытучыга охшаш: кешелекле, кечелекле, сабыр табигатьле, әдәпле, мәрхәмәтле, тәртипле, шәфкатьле, тырыш, рухиятле, иманлы, белемле, хисле, тойгылы, акыллы... Бу сыйфатларның алтынын ул поэзия ялкыны белән ялтырата алды. Читкә китәм, шикелле? Шулай да укытучы белән шагыйрь турында бер кәлимә. "Укытучысы нинди — иле шундый". Димәк, ил дәрәҗәсе укытучылар иманы белән бәйле. Аның киресе дә әйтелә: "иле нинди — укытучысы шундый". Димәк, надан, караңгы илдән яхшы укытучы чыкмый. "Кытайга барып булса да белем ал", дигәнне беләбез. Ломоносов белемне Алманиядә ала. Зыя Камали Гарәп илләрендә профессор дәрәҗәсенә күтәрелә. Русия халкы балаларын һаман әле чит илдә укытуны мәгъкуль күрә. Бу, бәлки, халык әйткәнчә, йонга ефәк кушып эрләүнең бер хикмәтедер. Шагыйрьдән укытучыга хас бизәкләрне эзләү кирәкме? Хәер, күпме генә төпченмә, ул бизәкләрнең саны — бик күп.

Зыялылар телендә "педагогик тактлылык" дигән термин бар. Икенче төрле, гадиләштереп, халыкча әйтсәк, үзеңне кайда да кешеләрчә тота белү. Бу сыйфат аң-акыл, хис-тойгы, рухи кыйммәт, иманлылык, әдәплелек белән бәйле. Мәгълум ки, әдәбиятның тамыры — әдәп. Әдәпле укытучы — иман ота, әдәпсезе — җил йота. Әдипләр дә (шагыйрь, прозаик, драматург) шулай. Башкортстан һәм Татарстан Язучылар берлегендә әгъза булып торучы әдипләрне бергә кушып санасак — биш йөз чамасы. Менә кайда рухи гаскәр! Исле гөл янында иссез гөл дә хуш исләнә. Бу гаскәрнең һәр солдаты исле гөл була алса, фани дөнья оҗмахыннан коммунизм төзер идек. Бу гаскәрнең рухи дулкынында кайнаган Роберт Миннуллинны мин исле гөл дип тә атыйм. Башкортстан җәмәгатьчелеге алдында чыгыш ясаса да, Татарстанда да шагыйрьнең әлеге яхшы укытучыга хас булган педагогик тактлылыгы исле гөлгә әверелә дә куя. Ул гына да түгел, һәр шигыре моң өрфиясе белән төренә

бит аның. һәр яз матур җәй өмет иткәндәй, һәр җыры моңлы көй сорап тора. Башкортстан әдипләре, халык, җәмәгатьчелек ярата шагыйрьне. Димәк, ике республика өчен дә "Исле гөл" була алды ул. Башкортстан халкы аның иҗат талантына да, кешелеклелек сыйфатына да югары бәя бирә.

"Сандугач куна гөлләргә", дидем. Сандугачы да, гөле дә шул бер Роберт булып чыга, ләбаса. Поэзия сандугачы ул! Димәк, сандугачтагы моң белән чәчәктәге бизәк мәхәббәте рухи илаһиятлелек хасил итә. Мондый илаһиятлелек шагыйрь йөрәгендә Ходай рухы булып нәкышләнгән.

Беләм, гомер буйларына
Миңа дога кылырлар.
Әнкәй кебек өянкеләр,
Әткәй кебек тупылдар,

— ди ул "Өянкеләр, тупыллар" дигән шигырендә. Сүз-сурәт, сүз-фикер, сүз-тойгы бердәмлегенең чынлыгына илаһи бер мисал бу. Яки:

Хатлар укыйм.
Кат-кат укыйм
Мин әнкәйнең хатларын —
Әнкәйнең, гади әнкәйнең
Даһи тәгълиматларын.

Мисалга алган дүрт строфада гына да, патриотик, эстетик тәрбия, хезмәт тәрбиясе, сүз тәрбиясе, педагогик тәрбия дигәнебезнең чаткылары сизелеп тора. Димәк, шагыйрь шигырьләре белән дә, кешелеклелек сыйфатлары белән дә тормыш-яшәеш укытучысы була ала.

Моң һәм мәхәббәт

Бу ике сүз, бер карасаң, гади, аңлаешлы, табигый. Ул кешенең аң-акылы, хис-тойгысы, йөрәге, күңеле, җаны, каны белән бәйле. Күчмә мәгънәдә әйтсәк, җир шарында, күктә, галәм-җиһан киңлекләрендә дә йөрәк бар. Җир шары — үзе бер мәхәббәт йомгагы. Моң аның эчендә дә, тышында да. Кеше — Җир һәм Күкнең мәхәббәте җимеше. Бу җимеш мәхәббәт һәм моң белән гыйззәтләнә. Адәм баласындагы моң һәм мәхәббәт Алла рухы белән бәһалана: "Моңлы кеше — уйлы кеше"; "Мәхәббәтле кеше — мәрхәмәтле кеше".

Бәгъзе балага моң ана "карынында ук бүләк ителә. Әгәр ана моң иясе булса, әлбәттә. Ә инде бишек моңында бала ананың ширбәтле сөте, назлы күз карашы, сөйкемле елмаюы, иманлы рухы белән ләззәтләнә. Тәпи басып, дөнья оҗмахы куенына кереп киткәч, ул алсу таңнар, кояш нурлары, шәфакъ балкышы, көмеш сулы чишмәләр, серле урманнар, мәгрүр таулар, чәчкәле болыннар белән очраша; сандугач сайравын,

күгәрчен гөрләвен, кәккүк моңын тыңлап әсәрләнә. Табигать матурлыгы нәфисли аның хис-тойгыларын. Назлы җилләр әллә кайлардан әллә нинди моңнар ташый. Бала үзенә кирәк моңны эләктереп ала. Табигать моңы бу. "Кайсы бер үзешчән яки профессиональ җырчылар, баш төзәтәм тип күз чыгаргандай, үзгәртә-үзгәртә, бозып та ташлый ул моңны. Ә менә җырчы Илшат Сибәгатуллин моңында андый "шаштырыу" сизелми. Шөкер!

Илшат Сибәгатуллин 1978 елның 4 августында Илеш районының Үрге Манчар авылында туа. Халык җырларындагы моңны аның йөрәгенә әле булса газиз әнисе Сафия сылу кәрәзләп тора. Әтисе Әнәс узаман, гармун уйнап, ул кәрәзгә дөнья яме өсти. Ата-ананың дәртле моң кушылмасы Илшат күңелендә күркәм дарман булып нагышлана. Илшат, авыл клубындагы концертларда катнашып, халык йөрәгенә бәләкәй чакта ук юл сала башлый. Үрге Манчар урта мәктәбендә тугыз ел белем алгач, Илеш район үзәге Үрге Яркәйдәге 86нчы һөнәрчелек училищесында слесарь булу өчен укый. Аны тәмамлагач, җаны сөйгән туган авылына кайтып, дүрт ел колхозда эшли. Тимерләрне эретеп ябыштырганда чәчрәгән ут чаткыларында да ниндидер моң бар кебек. Зур бәхетнең сызганып эшкә бирелгәндәй килүен аңлый. Хезмәттә мәхәббәт тә бар, моң да бар. Хезмәтнең агы да, карасы да аң-акыл, хис-тойгы таләп итә икән. Шуларның икесеннән дә моң йомгагы балкып килеп чыга. Аларның икесе дә иҗади эшчәнлеккә мохтаҗ. Икесе өчен дә имтиханны, зурлап әйтсәк, Алланың үзенә тапшырырга кирәк. "Моң" дигәнең сәнгать дөньясына илаһи мәхәббәт белән томырылуны сорый. Дүртөйле районындагы Җидегән (Семилетка) мәдәният йортына эшкә килә Илшат. Моңа кадәр оператор булып эшләгәндә дә, Үрге Манчар клубында да күп җырлаган иде инде ул. Клуб мөдире Фирдәвес Латыйпов сәхнәдә үзеңне ничек тотарга, каушамаска, бөгелү-сыгылу кыланышлары ясамаска, ялган матурлыклардан качарга, җырлаганда аерым сүзләргә генә түгел, һәр хәреф-авазга, аларның моң хосусиятенә, нәфислегенә, сәнгатьлелек дәрәҗәсенә игътибар итәргә өйрәтә. Беренче остазы Фирдәвес Латыйповка рәхмәте дөнья зурлык Илшат Әнәс улының. Шундый ук сәнгати таләпне Җидегәндә лә тоя ул.

1999 елда Башкортстан яшьләренең "Туган тел" конкурсы булган иде. Илшат Әнәс улы башкорт халык иҗаты энҗесе "Һандугас"ны җырлый. Җырчы моңыннан әсәрләнгән жюри рәисе Фәридә Кудашева Илшатка иҗади теләктәшлек белдерә. Фәридә апа белән аны моң дуслаштыргандыр инде. Казанга, районнарга бергә барган чактары да булды.

...Яшьләр концертында мин дә бар идем. Соңыннан моң турында Фәридә апа белән киңәшләшеп тә алдык. Дөресен генә әйткәндә, минем дә күңелләрне тетрәндерде ул чакта Илшат моңы. "Кайбер оста җырчылар, үрдә әйткәнчә, ясалмалыкка бирелеп, моң чамасын оныта.

Илшатта йөрәк белән кабул ителә торган саф самими моң!

Һәр милләтнең уз моңы. Бөек Ватан сугышыннан соң миңа Тянь-Шань таулары арасында яшәгән кыргыз моңын да, дала халкы казак моңын да, эссе табигатле үзбәк моңында, башка бик күпләрнекен дә тыңларга насыйп булды. Кыргыз белән башкортныкы нык охшаш. Ләкин аерма да бар. Моң — зур төшенчә. Бөек төшенчә. Ул чагыштырып карауга да мохтаҗ. Җырлый-җырлый шушы хәсиятне дә аңлый Илшат. 2002 елда аңа Илеш делегациясе белән бергә Баймакка бару бәхете елмая. Баймак — бай як, дип юкка гына әйтмиләр икән. Башта табигать әсәрләндерә яшь җырчы күңелен. Аннан бай күңелле башкорт халкының кунакчыллыгы шатландыра аны. 2003 елда Илшат, күңелендәге бу күчтәнәчне күтәреп, "Казанга Илһам Шакиров исемендәге татар җырларын башкару җыенына китә. Конкурста 200дән артык делегация катнаша. Монда да Илшат җыр яратучыларны әлеге саф, назлы, мәгънәви моңы белән шаккатыра. Илшат моңыннан Илһам Шакиров үзе дә гыйззәтләнә хәтта. Тантанага йомгак ясаганда ул Илшат йөрәгендә мәгърур Урал таулары арасында аккан елгалар кушылмасы моңы булуы турында әйтеп үтә. Илшат Казанда Татарстанның халык артисты Салават Фәтхетдиновның кайнар котлавы белән канатлана. Фәридә Кудашева, Илһам Шакиров, Рөстәм Маликов һ.б. талантлар даирәсе йогынтысы белән илһамлана. Репертуарын С. Садыкова, Р. Яхин, Р. Хәсәнов кебек күренекле композиторлар әсәрләре белән баета.

2004 елның 14 апрелендә Илшат Әнәс улы Сибәгәтуллинга Башкортстан Республикасының атказанган мәдәният эшлеклесе дигән мактаулы исем бирелә. Андый данлаулары күп аның. Оста җырчының шулай булуы тәбигый. Урын тарлыкка сылтанып, башкаларын язып тормыйк. Җырчы моңына гашыйк булганнар да бихисап. Илшат көндәлекләр язу белән дә мәшгуль. Аның хакында Фәридә Кудашева: "Беләсеңме, Илшат, сине шулкадәр дулкынланып тыңлыйм! Күңелемнең иң нечкә кылларын чиртәсең. Үземне гүзәл Агыйделкәй өстендә канат каккан коштай хис итәм. Рәхмәт сиңа, туганкай!" — дигәне үзе бер хөрмәт яшь җырсы өчен. Җыр бөркете Илһам Шакировның хисле чагыштыруын үз сүзләре белән бирик: "Тавышың Урал тауларынан ургылган саф сулы елга агышын хәтерләтә, дустым. Казанга консерваториягә укырга кил!

Фәридә белән Илһам моңы бөтен мөселман дөньясын, күп милләтләр күңелен яулады. Илшат моңына да киләчәктә шул насыйп булсын! Амин! Хәер, Илшат моңы да чит илләрдәге кан-кардәшләребезнең күңелен назлыйдыр хәзер. Аның районлашлары (илешлеләр) үткән гасырның икенче яртысында җир эшкәртү мәдәнияте шәфәгатьлелеге буенча Башкортстанда гына түгел, бөтен Русия Федерациясендә үрнәк күрсәтте. Алай гына да түгел әле. Иген-икмәк

өлкәсендә эшләгән җир галимнәре чит илләрдән дә килеп, кандидатлык, докторлык диссертациясе язу өчен материал җыеп киттеләр. Безнең халык: "Бер бөртек бодай эчендә игенченең бер пот тире бар", — ди. Әнә шул тирдә җир кешесенең моңы да бар. Бер чор илешлеләр ул моң белән чит ил халкының да күңелен тетрәндерде. Концерт белән Германия, Чехословакия, Венгрия, Польша, тагы да кайларда гына булмадылар. Сокланган тамашачылар алардан нинди сәнгать институтын тәмамлау турында сорыйлар икән. Берсе — савымчы, икенчесе — тракторчы, өченчесе — комбайнчы, дүртенчесе — хисапчы, бишенчесе — икътисадчы, алтынчысы мал караучы булулары турында әйткәч, ышанмый торганнар хәтта. Былтыр ноябрь аенда районлашларым көзге уңыш бәйрәменә чакырды. Кайттым. Бәй, атна үттеме-юкмы, Татарстанның Актаныш районыннан килеп алып киттеләр кунакка. Анда мәктәп директоры булып эшләгән идем (1955-1958 еллар). Икесендә дә хезмәткә бәйле концерт күрсәтелде. Хезмәт моңында кешегә, илгә, табигатькә, яшәешкә зур мәхәббәт бар! Тормыш авыр дип зарланабыз. Кайчан җиңел булган соң ул? Киләчәктә дә бәхетне, алтын арбага төяп, алдыбызга китереп түкмәячәкләр. Без фашизмны корал белән генә түгел, рухи ныклык белән дә җиңдек. Рухта моң да бар, мәхәббәт тә бар. Әлеге ике концерт та — җир оҗмахы матурлыгы. Бу матурлыкны балкытучылар — шул ук савымчы, тракторчы, машина йөртүче, мал караучы, хисапчы, икътисадчылар...

Ә менә үз моңы белән ил таҗы шәхесен, моң фәрештәсе Фәридә Кудашеваны, моң пәйгамбәре Илһам Шакировны (әгәр шулай әйтергә яраса) тетрәндергән Илшат Әнәс улының бүгенге төп хезмәтен беләсезме? Белмәсәгез — әйтәм: гади оператор ул. Чакмагыш нефть чыгару идарәлегендә эшли. "Мин — нефтьче" дигәнне зур горурлык белән әйтә. Үрге Манчар авылында яши. Үзе салган йортта. Мал асрый. Умарта үрчетә. Балык тота. Үзе кебек ак эшне дә, кара эшне дә яраткан, моң-хискә бай, мәхәббәтле хәләле Зирина белән дөнья көтүе бик күңелле аңа. Ике бала бу күңеллелеккә ямь өсти-өсти үсә. Профессиональ җырчы булып кына яшәргә кушкан моң фәрештәсенең дә, моң пәйгамбәренең дә киңәшләрен килештереп бетермәде ул. Шулай да, җырчы өчен дә белем кирәклеген аңлап, укыды да укыды. Сәнгать академиясен тәмамлады. Бу җәһәттән мин үзем дә Илшат яклы. Дөресен генә әйткәндә, бер җирдә дә эшләми, җырлап кына тамак туйдыручыны өнәп бетерми идем. Алла биргән талант белән генә масая, янәсе. Язучының бер бөртек таланты мең бөртек тир белән манчыла. Бу хакта хәбәрдарбыз. Җырчыныкы да шулай икән. Тамак төбе шартлап ярылу дәрәҗәсенә җиткәнче кычкырып җырлау талант түгел икән ул. Тупас итеп әйтсәк, аны ишәк тә булдыра ала. Тамашачы йөрәген дулкынландыру өчен ишәк тавышы түгел, сандугач моңы кирәк. Ә бит сандугач та гел бер моң белән сайрамый. Моңын

даими үзгәртеп тора. Димәк, иҗат итә...

Илшат Әнәс улы кассетасында әле 16 җыр: "Уел", "Яратам", "Сагынам, дуслар", "Су сибегез гөлләргә", "Әтием юкәләре", "Бөрлегән", "Хушлашырга ашыкма", "Бәхет", "Арча", "Сибай", "Китмә, сандугас", "Абага", "Очып кайтам", "Танго", "Хуш, авылым", "Өммегөлсем", һәрберсенә аерым моң кирәк. Менә кайда моң иҗаты. Хәзер аңладым моны. Бу аңлау — үзем өчен генә. Ә Илшатка аңлау — меңләгән тамашачы алдында имтихан тотканда кирәк. Җырчы Илшатны өч илаһилык зурлый: Алла иманына нык ышану, кешеләрне ярату, хезмәт сөю.

Ике максатым бар. Беренчесе — Илешебезне, илебезне иманлы моңы белән данласын. Икенчесе — илгә иш булган изге Илеш турында әзерләгән яңа китабымда моң кадерен белгән бер җырчы хакында бер кәлимә җылы сүз әйтү. Мин моң профессоры да, мәхәббәт мөгаллиме дә түгел. Язучының төп коралы — каләм. Җырчының төп хыялы — моң. Мәхәббәтле моң! Мәхәббәт һәм моң — яшәү илаһияте!

Тормыш укытучысы

Хәнәфи, кәгазьгә күмелеп, кабинетында уйланып утыра иде. Таң күзеннән кичке караңгыга кадәр, кырыкка ярылырдай булып, мең төрле эшнең артыннан чабасың. Төп хезмәте — мәктәптә. Директор. Мондагы карар күзгә күренеп тормаган вак-төяк эш тавык чүпләсә дә бетмәс. Бригадада партоешма секретаре. Бүген язгы чәчү башлана. Хәзер кырга ашыгырга кирәк...

Шулай, уйлар йомгагын сүтеп, күнлек эшкә җиң сызганып, йөрәксенеп утырганда, ишек шакыдылар. Хәнәфи “керегез” дияргә дә өлгермәде, ишек киерелеп ачылып китте, җиденче класс укучысы Мөхәммәт белән класс җитәкчесе Мәрьям Харисова килеп тә керде.

— Нәрсә булды?.. Мөхәммәт тагын да тәртип бозганмы?..

— Һәр дәресне өзә. Сугыша. Әле күз алдымда Мәхмүтнең борынына сукты. Минем көчем җитми хазер аңа. Сезнең карамакка тапшырам, Хәнәфи Сафуанович! — диде дә дәрескә керергә ашыгып чыгып китте укытучы.

— Директор аз гына уйланып торды. Аннан соң:

— Мәхмүткә нигә суктың? — дип сорады.

— Әләкләшә бит. Мин, имеш, кызларны тукмыйм...

Хәнәфи башта ни дип әйтергә дә белми торды. Көнбагыш чәчкәседәй сары чәчле, сипкелле бу тәртипсез малайның басып торышы ук әллә ничек кызык күренә. Итагатьлекнең әсәре дә юк үзендә. Күзләрен әйләндереп, иренен тешләп, ямьсез итеп карый. Эченнән нәрсә уйлый икән? Йөзендә аз гына курку, шүрләү галәмәте күрсәткән булса да,

эченнән көлә ул, сезнең сүзегез минем өчен стенага борчак сипкән кебек кенә, ди...

— Юк, сине сүгәргә телем кычытып тормый әле; аннан соң, иртәнге сәгать белән, гомумән, кәефне дә бозасы килми, дип уйлады директор.

— Менә нәрсә, Мөхәммәт!.. Вакыт юк... Кырга ашыгам... Соңыннан күзгә-күз карашып, иркенләп сөйләшербез. Хәзер дәресеңә бар! Укытучыларның һәр сүзен йотлыгып тыңла!..

Өйгә кайтып костюмын, ялтырап торган туфлиләрен салды да, аягына кирза итек, өстенә плащ киеп, басуга ашыкты Хәнәфи.

* * *

Бер карасаң, артык усал кебек тә түгел бу директор. Әмма матур гәүдәсен нык тотып, гаскәри кыяфәттә атлап килүендә үк әллә нинди сихри Көч бар. Әнә үзе!.. Кич булып беткәч, туп-туры килә боларга...

— Нихәл, Мөхәммәт! Әниең өйдәме?..

— Өйдә.

— Әйдә, керик әле!..

Маһира апа директорны якты йөз белән каршы алды. Утырырга кушты.

— Нишләптер, мәктәп юлын оныттыгыз, Маһира апа, — диде Хәнәфи, — ата-аналар җыелышына да килми башладыгыз..

— Бармыйм мин анда...

— Ни өчен?

— Укытучыларыгызны күрәсем дә килми...

— Нигә алай дисез?

— Тоталар да тиргиләр...

— Ә ни өчен?

— Бәй... менә шушы ристан малай аркасында... Карап торышын күр, юньсезнең...

Сүзнең кинәт болай башлануын көтмәгән иде директор. Мондый сөйләшүнең фәтвәсез булачагын аңлап, балага чыгып торырга кушты.

— Ә менә сезнең өзлексез аракы эчүегезгә ничек карый икән бала, бик еш төшерәсез шикелле, Маһира апа? Әле дә көчкә басып торасыз.

— Шушы бала кайгысыннан эчәм, туганкаем, шушы бала кайгысыннан... Мәгәр, җир тишегенә керер идем.

Директор авыр сулап куйды.

— Аракы эчсәң, бала төзәлерме?

— Белмим инде, белмим, эт белән песи кебек яшибез, туганкаем!..

Алар озак кына сөйләшеп утырдылар. Хәнәфи Мөхәммәтнең сәләтле, хәрәкәтчән, ләкин бер дә уйламыйча ахмаклык эшләп ташлый торган гадәте барлыгын әйтте. Аракы эчүне ташларга, малае белән

бөтенләй тиргәшмәскә кушты. Аннан соң... гомумән... ничек кенә хурламасыннар, Мөхәммәтне ярата иде Хәнәфи...

Ни өчен? Моңа үзе дә ачык җавап бирми. Мөхәммәт әләкләшүне яратмый. Чынлап та, сүз йөртүчеләрдән киләчәктә ялагай, түбән җанлы кеше килеп чыгуы мөмкин.

Мөхәммәт аннан соң хезмәт сөя. Хезмәттән тәм татучы кеше югалмый ул. Тик менә... баланың бөтен шушы уңай сыйфатларын аңларга, аңа холкына карап якын килә белергә кирәк. Шуны аңлатып бирде директор анага.

— Туганкаем! Яхшы сүз — җан азыгы, ди. Бөтенләй... Йөрәккә кереп барасың. Әле басуда көне буе арып йөреп тә, шушы ристан малай өчен вакытыңны әрәм итеп... минемише бер ахмак белән ихлас сөйләшеп утырасың.

— Мөхәммәтне чакыр әле, апа!

Әнисе эндәшү белән ялт итеп Мөхәммәт килеп керде.

— Әйдә, Мөхәммәт, башладык, — диде директор. — Башта математикадан.

Алар озак кына бер мәсьәлә өстендә утырдылар.

— Менә бит... менә бит... беләсең. Син берәүдән дә ким түгел, Мөхәммәт! — Директор малайның аркасыннан җиңелчә сөеп, дәртләндереп җибәрде дә кайтырга чыкты.

Мәһира апа аны капка төбенә кадәр озата килде.

— Кара инде, туганкаем, үз кулыңа ал, һич югында сигезенче классны бетерсен! Ә мин... Эчмәм моннан соң, авызыма да капмам.

Тышта күз бәйләнеп килә икән инде. Борынга дымлы җир исе килеп бәрелә. Кайдадыр кызлар көлүе ишетелә. Хәнәфи үз уйларына кумелеп акрын гына атлады.

* * *

Кырык тугызынчы елда унтугыз яшьлек Хәнәфине Илеш районындагы шушы Татыш авылы мәктәбенә физика-математика укытучысы итеп куйдылар. Бу елларда Илеш, ташбакадай, республикада иң артта сөйрәлеп килүчеләрнең берсе иде. Ә инде Татыш арттагыларның арттагысы иде. Беренче елда ук аны агитатор итеп куйдылар. Көн чапты, төн чапты, җылы сүзләр белән кешеләрнең күңелен таба белде. Читтән торып институтны да тәмамлап алгач, аны директор итеп куйдылар. Шуннан партоешма секретаре. Колхоз артта. Председатель ел да диярлек алышынып тора. Җан өзгәләнгән чакларда колхоз печатен үз кулына алырга йөрәксенгән вакытлар күп була иде. Тик... укыту эшенә дә бетен йөрәге белән бирелгән иде шул. Авыр фән булган математиканы да үзе бик яратып, җиңел укытты. Дәресләр бик җанлы була. Ул зур максатлар белән яшәде. Мәктәп тирәсен җиләк-җимешкә күмәргә. Мастерской

салдырып җибәрергә. Уку, хезмәт, күңелле яшәү! Бер генә бала да класста ике ел утырмасын! Колхоз иң алга чыксын. Менә шул!

Бервакыт Илеш ташбакадан — атка, аттан — самолетка күчте. Иген культурасы өчен ныклы көрәш башланды. Икмәк — бөтен нәрсәнең нигезе. Әмма Татыш, ни дисәң дә, иң ярлы авыл. Яз көне җирне су басканлыктан, чәчү соңга кала. Шуңа күрә иген уңмый. Андызлы җирдә ат үлми, дип, халык язмышка буйсынып, барына шөкер итеп яшәргә гадәтләнгән. Тавык кетәге кадәр салам түбәле өйләр, җимерек читән, ишелеп-ишелеп төшкән абзар-куралар күңелгә шом салып, табигатьнең ямен, котын җибәреп тора. Бервакыт Хәнәфине башка авылга да күчермәкче булган иделәр, тыңламады. Егет яуда беленер, ди фронттагылар. Аңа сугышта булырга туры килмәде. Тыныч тормышта ничек күрсәтергә егетлек көчен? Егет көче йөрәктә дә, беләктә дә дип яшәргәме? Физик көч, беләк, гайрәт, куәт бар, анысы. Ничек чалгы, балта, көрәк тотарга, хәтта матур итеп, шыңгырдатып ат җигәргә өйрәтте күпләрне. Тора-бара медицина, ветеринария фәненә кадәр үзләштерде. Кеше авырса да, мал чирләсә дә аңа килә башладылар.

Көннәрдән бер көнне аңа райком секретаре:

— Дәртең дә күп, Нәҗмиев, дәрманың да, ә менә колхозыгыз һаман койрыкта сөйрәлә, — диде. — Син, партоешма секретаре буларак, бу хакта ныклабрак баш ватсаң иде!

Еллар искән җил кебек тиз үтә. Бервакыт Татыш тирә-якка даны таралган "Искра" колхозына кушылды. Шушы колхозны оештыручы Габдрахман Басыйровка Хезмәт Кызыл байрагы ордены биргән иделәр. Колхоз печатен, Габдрахман агай үлгәч, Тимерхан Нәҗмиевка тоттырдылар. Нәҗмиевның күкрәгенә янә шундый ук орден тактылар. Батыр йөрәкле егетләр дан казана. Ә менә алар бригадасы һаман йокыга моң булып йөргән ялкау кеше кебек. Сөйләшкәндә бервакыт әйтте бригадирга Хәнәфи:

— Җитте, Раил дус! Нокта... Басуның су астында калуына сылтанып, мүкләнеп яшәү заманы түгел.

— Ә ни эшлибез?

— Басуны язгы ташкыннан саклыйк.

— Ничек?

— Канау казытырбыз... буа буарбыз... юллары күп...

...Татыш җире хәзер гектарыннан утызар центнер уңыш бирә.

Татыш олимпиадада катнаша икән, дигән хәбәр таралгач, бөтен район халкы көлде. Кит, кеше көлдереп, мәсхәрәгә калып, абруегызны төшереп йөрмәгез, диделәр Хәнәфигә. Әмма директорның авыл яшьләрен, мәктәп балаларын сәнгатьнең нинди нечкә, зәвыклы төрләренә акрынлап өйрәтә килүен белмәгәннәр икән шул. "Уңыш бәйрәме", "Ромашка", "Солдатлар биюе", "Колхоз яшьләре", "Йолдызлар төркеме"

дигән яңа биюләр иҗат иткәннәр икән алар. "Татышлар килгән икән", дигән хәбәр таралса, райүзәктә мәдәният йорты шыгрым тулы була. Тынлы оркестр алынды. Халык ансамбле оештырылды. Шул ансамбль белән хәтта Ленинградка барып дан казандылар. Опера театрындагы чыгышларын ленинградлылар да тәэсирләнеп карады.

Тәвәккәлләгән — таш ярган, диләр. Тәвәккәлләргә, хас итәргә, йөрәкләнергә генә кирәк икән. Ялгыз сандугач та яз китерми, ди, берүзе бернәрсә дә кыра алмас иде. Илештә җиң сызганып, күкрәк кагып, гайрәтләнеп эшләүче егетләр куп. Хәнәфи — шуларның берсе. Хәзер аның күкрәгендә Хезмәт Кызыл Байрагы ордены балкый. Нәкъ менә Габдрахман агасыныкы, Тимерхан агасыныкы кебек. Хәзер, җитмәсә, атказанган укытучы дигән даны да бар!

* * *

...Кар ява. Авыл, болын, кырлар ап-ак күлмәк кия. Тормыш нык хәзер. Культура да үсте. Әмма һәр адымда капма-каршылык. Ару гына яшәгән гаиләләр кинәт кенә бозылышып китә. Тоталар да Хәнәфигә киләләр. Көндез дә, төн заманында да. Аңа судья булырга, "суд" ясарга, кешеләрне кавыштырырга да туры килә. Нинди генә атамалар такмадылар аңа: укытучы, агроном, врач, судья... Хәер, чын халык укытучысына шулай кирәктер дә!

Мөхәммәт, Хәнәфи аның белән үзе шөгыльләнә башлагач, җайга килеп яхшы гына укып киткән иде. Ләкин әнисе белән сүзгә килгән дә, авылны ташлап кайдадыр чыгып киткән.

Укулар башлана. Гаеп булган малайны мәктәптә исемлектән сызып ук ташладылар. Кайбер укытучылар җиңел тын алып куйды.

Күз күне әнисенә хаты килде Мөхәммәтнең. Казахстанга барып чыккан малай. Адресын алып Хәнәфи аңа хат язды. Кеше тормышында андый кытыршылыклар була, Мөхәммәт, дүрт аяклы ат та абына, син дә абындың, инде кайт, аякка бас, үзем ярдәм итәрмен, әниең бик үкенә, елый, хәзер эчми, диде һәм тагын да күп үгетләр бирде.

Малай кайткач, директор аны мәктәпкә чакыртып карады. Ләкин тегесе килмәде. Күпләр аның парта артына кабат утыруына бөтенләй каршы булды. Инде бер чирек үтәп киткән. Болай да койрыкта сөйрәлеп барган Мөхәммәт хәзер алдыралмаячак. Әмма директор андый ялгыш карашларга кискен каршы төште. Бала язмышы, кеше язмышы хакында алай җиңел уйларга ярамый.

Кабинетта сөйләшүгә караганда, кешенең үз өендә, өстәле артында күзгә-күз карашып, чын йөрәктән аңлашуга җитми. Шуңа күрә директор Мөхәммәт кырына янә үзе барды.

— Нихәл, Мөхәммәт! Кайттыңмы? — дип исәнлек-саулык сорашып барып керде ул.

Малай, сөмсөре коелып, өстәл башында утыра иде. Мәһира апа — мич алдында.

— Әйдә, туганкаем, әйдә, түрдән уз. Һаман ташламыйсың безне, һай, бигрәк, кешелекле, изгелекле булдың да инде, — дип сөйләнде Мәһира апа.

— Менә... Мөхәммәт каршылык күрсәтеп маташа бит әле. Укырга бармый.

— Булмас инде хәзер, гөлкәем, булмас, эшкә йөрим, ди бит.

— Шулаймы, Мөхәммәт?

— Шулай, абый... Миннән бөтен мәктәп көләчәк. Ә минем көлкегә каласым килми,

— Юк, Мөхәммәт, берәү дә көлмәячәк... Менә күрерсең... математиканы бергә карарбыз. Иптәшләреңне куып та житәрсең, узып та китәртең. Мастер буласың киләме?

— Ә?! Мастер?! — Малайның соры күзләре очкынланып китте, йөзендәге сипкелләре балкыгандай булды.

— Матур-матур йортлар салу өчен кирпеч заводы төзиячәкбез бит. Сигезенче классны беткәннәрне курска жибәрәчәкбез. Давай, тәвәккәллә, Мөхәммәт! Көчемә ышанмасам, килеп тә йөрмәс идем... Теге вакытта директорның ни өчен аның артыннан шулкадәр янып йөрүен Мәһира апа да, Мөхәммәт үзе дә аңлап житкермәгән иде. Бала укымаса, мәктәпкә сүз килә. Шуңа ут үрсәләнеп йөриләр, янәсе. Юк, алай гына түгел икән әле. Менә бит... Мөхәммәт укымаса да була хәзер. Юк, һаман чарага куймый бу директор. Монысы инде кеше язмышы өчен чын-чыннан, ихлас күңелдән яну иде. Менә кем икән ул укытучы! Менә нинди икән аның күңеле!

Мәһира апа, капка баганасына сөялеп, уйларыннан һаман айный алмыйча, озак кына басып торды. Аннан соң яшен тизлегендә өйгә йөгереп кереп китте дә кроватька капланып, үксеп еларга тотынды.

— Әни! Әни! Нигә елыйсың?

— Балакаем! Бар!.. Иртәгә үк мәктәпкә бар!

* * *

...Ишек шакыдылар.

— Керегез, — диде директор.

Мөхәммәт килеп керде. Кара, нинди матур булып үсеп киткән.

— Бу бүлмәгә сезгә кайгы булып кына керә идем, шатлык булып та керим әле, Хәнәфи Сафуанович!

Алар кул кысыштылар.

— Я, Мөхәммәт, нинди шатлыклар алып кайттың Уфадан?

— Дипломлы мастер!

— Менә шәп!

— Иң башта мәктәпкә зур кирпеч йорт салып бирәм, Хәнәфи Сафуанович! Аннан...

Алар, бер-берсенә мөлаем карашып, озак кына сөйләшеп утырдылар. Мөхәммәт нык дулкынлана иде. Һаман бер үк сүзләрне кабатлады ул:

— Рәхмәт инде, Хәнәфи Сафуанович! Сез мине кеше иттегез!

Илеш галимнәренең канат киңлеге

Илеш-Бабайның нәсел-нәсәбе сабырлыгы, хезмәт сөючәнлеге белән генә түгел, гомер бакый һәр эшне төптән уйлап башлавы, зирәк акылы һәм куйган максатына барлык киртәләрне җимереп ирешә алуы белән дә дан тоткан. Илешнең уллары һәм кызлары һәрвакыт ил мәнфәгатьләре белән яшәгән, кайсы гына тармакта эшләмәсен, туган илнең чәчкә атуы, аның дан-шөһрәтен арттыру өчен талантын, көчен кызганмаган.

Ривнер Фазыл улы Ганиев — шундыйларның берсе. 1937нче елда Тәҗәй авылында туа ул. Башлангыч һәм җидееллык белемне Кужбахты вә Яңа Аю мәктәпләрендә ала. Урта мәктәпне Андреевкада тәмамлый. 1954-55 елларда Уфа авиация институтында укый. Мәскәүдә аспирантура тәмамлагач, кандидатлык (1966 ел), докторлык (1968) диссертациясе яклый. Ул хәзер Русия фәннәр академиясе академигы. 300дән артык фәнни хезмәт авторы. Хәзерге вакытта Русия фәннәр академиясе каршындагы Линиясез дулкын механикасы һәм технологиясе гыйльми үзәгенең фәнни җитәкчесе — директоры. Аның җитәкчелегендә 15 докторлык, 35 кандидатлык диссертациясе яклана. Аларның дулкын технологиясен производствога кертүләре бөтен ил икътисадына зур файда китерә. Бу яңалыкны чит илдә дә үзләштерә башладылар.

Мондый биеклеккә, минемчә, көчле ихтыярлы, акыллы, басынкы, тырыш, үз язмышына, зур бәхетенә ия булган шәхесләр генә ирешә ала. Ривнер Фазыл улының язмаларыннан бер өзек китерик әле: “Минем әтием Ганиев Фазыл сугышта һәлак булган, мин аны бөтенләй хәтерләмим диярлек. Аның бик яшь партия хезмәткәре (25 яшендә партия райкомы секретарьләреннән берсе) булуын беләм. Сеңлем белән мине әнием һәм картәнием тәрбияләделәр. Заман авырлыкларына карамастан, ач-ялангач итмәделәр. Әнием, картәнием, ә соңрак үги әтием безне, биш баланы, карап үстерде. Мин аларның хәстәрлеген һәм мәхәббәтен акларга тырыштым. Безне яхшы кешеләр итеп тәрбияләү һәм бишебезгә дә югары белем бирүгә көчләрен кызганмадылар алар. Башкортстанга кайткан саен аларның каберләренә барам. Мәктәп елларына килгәндә исә, алар күңелемдә якты хәтирә калдырды. Ул заманнарда белемле кешеләргә ихтирам зур иде. Хәзергечә әйткәндә, ул чорда белемнең абруе бик югары иде”.

Ривнер Фазыл улы туган авылына ел саен диярлек кайта. Гадилеге, кечелеклеге, садәлеге белән авылдашларын, райондашларын таң калдыра. Матурлыкның гадилектә икәнлеген чын мәгънәсендә исбат итә белә ул.

Ривнер әфәнденең дөньякүләм әһәмияте булган зур фәнни хезмәте җир асты байлыгына бәйләнгән булса, икенче райондашым — Башкортстан Фәннәр академиясенең әгъза-мөхбире, профессор Нәзиф Раян ул Бәхтизинныкы исә җир өсте хәзинәсе белән данлана. Болай чатнатып әйтү чынбарлыкка туры килеп тә бетмидер әле. Чөнки иген игү дә җирнең җылы куенына, аның асыл сыйфатына, кеше күңеле кебек серле якларына бәйле бит.

Күренекле галим, профессор Нәзиф Раян улы (хәзер аңа 70 яшь) Илеш районының Яңа Аташ авылында туа. Өлкән агалары фронтка киткәч (алар анда гүр иясе була), дөнья авырлыгы Нәзиф җилкәсенә төшә. Сабан сөрә, тырма тырмата, тирес түгә, колхоз хисапчысы булып эшли. Бер ук вакытта Иске-Дөмәй авылындагы урта мәктәпне тәмамлый. Авыл хуҗалыгы институтында укый. Агрономия факультеты аның ярсу хыялына ныклы канат куя. Бу канат, кулына кызыл диплом алгач, аны Куергазы районына очыра. “Мораптал” совхозында агроном булып эшләү дә аның күңеленә хуш килә. Аннан аспирантура. Кандидатлык, докторлык диссертацияләре яклау. 34 яшендә инде ул — Башкорт авыл хуҗалыгы институты ректоры. Озак еллар авыл хуҗалыгы буенча зур фәнни-тикшеренү институтының директоры вазифасын үти. Җирне тирәнгә сөрү, яхшы сыйфатлы орлык булдыру, иген игү культурасы серләрен өйрәнә. Бөтен хезмәттәшләре арасында СССР һәм Русия күләмендә җитди абруй казанган фән әһеленә әверелә. Социалистик Хезмәт Герое, даны чит илләргә таралган селекционер академик Сабирҗан Кунакбаев белән, кем әйтмешли, кулга-кул тотышып, йөрәкне-йөрәккә куешып, ихлас күңелдән, мөкиббән, фидакарь хезмәтнең ямен-тәмен татып эшләү һаман-һаман югары үрләр яулауга кызыксындыра. Алар икесе дә — шигъри йөрәкле шәхес. Нәзиф шигырьләр, пьесалар яза. “Качкыннар”, “Ярдәм” исемле драмалары сугыш елларында авыл сәхнәләрендә куела. Мәрхүм Сабирҗан әфәнде дә поэтик хис белән сугарылган шигъри шәлкемнәр калдырды. Бу поэтик ялкын алар уйлап тапкан яңа төр арыш орлыгына “Чулпан” исеме кушарга ярдәм итте. Чулпан! Таң йолдызы!! Таңны уята торган йолдыз!!! Ирешелгән кадәресе киләчәк зур уңышның таңы гынадыр әле, бәлки. Илеш игенчесе гектарыннан 50 центнер алу хыялы белән ялкынланып яшәде. Үсеш беркайчан да тоткарланмый. Тауның түбәсенә менә башлагач, аның сыртында гына туктап калырга ярамый. Ничек кенә булмасын, яңа төр “Чулпан” орлыгы тирә-якка таң йолдызы Чулпан булып балкыды. Табигать көйсезлекләренә, салкыннарга бирешми торган бу арыш куп уңыш бирә. Ул хәзер төрле урыннарда чәчелә. Академик Сабирҗан

Кунакбаев селекционер булу осталыгын, Академиянең әгъза-мөхбире Нәзиф Бәхтизин чәчү технологиясе маһирлыгын күрсәтте.

Гуманитар фәннәрнең Халыкара академиясе әгъзасы Әхияров Камил Шәехмурза улы турында да иң җылы, кыйммәтле, мәгънәле сүзләр әйтәсе килә. 1930 елның 19 февралендә Илеш районының Югары Манчар авылында туа ул. Башкорт дәүләт педагогия институтын тәмамлагач (1951), авыл укытучысы, Борай районындагы Чалкак урта мәктәбе директоры (1951-63) булып эшли. Аннан кандидатлык, докторлык диссертацияләре яклау. 1963-89 елларда Бөре дәүләт педагогия институты ректоры. Хәзер (1989 елдан бирле) Башкорт дәүләт педагогия институтындагы мәктәпләрне фәнни нигезгә кору кафедрасы мөдире. Профессор. Авыл мәктәпләрен политехник уку юнәлешенә коруда күп хезмәт салган узаман. 300дән артык фәнни хезмәт авторы.

Илештән чыккан фән әһелләре гомумән бик күп. Фән докторлары, академиклар, профессорлар гына да егермеләп. Аларның барысы да — тормышның төбеннән күтәрелеп, дөньяның ачысын-төчесен алагаем татыган, куп-күп михнәт чиккән кешеләр. Алыйк Югары Яркәйдә туган Сабир Закирҗан улы Локмановны (1906-67). Әти-әнисез калып, кеше ишек төбендә, типкелектә йөри ул. Шулай да, үсә төшкәч, Ходайга шөкер, язмышның ачы-усал җилләре аның белән шаярудан туктый. Укый Сабирҗан. Медицина фәннәре докторы, профессор булу дәрәҗәсенә күтәрелә. Озак еллар БАССР сәламәтлек саклау министры булып эшли, Башкорт дәүләт медицина институтында кафедра белән житәкчелек итә.

Рсай авылында туган (18 март, 1923 ел) Әнвәр Латыйп улы Латыйпов та медицина фәннәре докторы, профессор, Татарстан җөмһүриятенең атказанган фән эшлеклесе, күп ачышлар ясаган, фәнни хезмәтләр бастырган маһир.

Ә менә Буралы авылында туган (1924-91) Йосыпов Ислам Йосыф улы техник фәннәр докторы булып китте. Профессор Йосыпов Уфа авиация университетында тирән эчтәлекле, мавыктыргыч, техник фән тирәнлекләрен чагылдырган лекцияләр укыды. Аның да бик күп фәнни ачышлары, яңалыклары бар.

Янә бер техник фәннәр докторы. Ул — профессор Рафиков Махасим Юныс улы. Илеш районының Түбән Череккүл авылында туган (1927). Мәскәүдә яши. Хәрби һава академиясендә лекцияләр укый. Мәскәүдән искән шифалы җилләр аның хакында да туган якларына изге хәбәрләр алып килә.

Тагын да ике техник фәннәр докторы, ике профессор эшчәнлеге бизи Илештән чыккан зур галимнәр гаскәре сафын. Аларның берсе — Никифоров Иван Михайлович Юлдаш авылында (28 февраль, 1915), икенчесе — Әхмәтов Илүс Галим улы Югары Яркәйдә туган (5 ноябрь, 1933 ел). Ә менә Сеңрән авылында туган галим — тарих фәннәре

докторы, профессор, Татарстан җөмһүрияте фәннәр академиясенең әгъза-мөхбире, Казан дәүләт университетында кафедра мөдире булып эшләүче Әзһәр Гатаулла улы Мөхәмәдиев татар халкының борынгы тарихын өйрәнү белән мәшгуль.

Абдулла авылы егете Зифкат Ислам улы Сәетгалиев (1946) әле Мәскәүдә яши. Дәүләт җыелышы депутаты. Экономика фәннәре докторы. Язмыш җилләре аның холык-фигылен, ихтыяр көчен, кешелеклелек сыйфатын төрле-төрле урыннарга куеп сынады. Кандидатлыкны яклагач, Башкорт дәүләт авыл хуҗалыгы институтында укытты ул. Доцент. Бервакыт тотты да авылына колхоз рәисе булып кайтты. Аны аякка бастыру нияте белән. Тиеннәрнең кадерен белеп эш итте экономист. Ике елда колхоз күзгә күренеп үзгәрде. Аннан аны Әлшәй районының беренче секретаре итеп куйдылар. Һәм... тора-бара Уфага, Мәскәүгә үрләтелде. Иске Дөмәй егете Яппаров Хаҗгалинең дә язмышы шулайрак булды. Башкорт дәүләт авыл хуҗалыгы институтын тәмамлагач, авылга китә ул, икенче группа инвалид булуына карамастан, колхоз председателе камытын кия. Аннары фән дөньясына чума. Фәнни дәрәҗәгә ия булып, белем алган институтында лекцияләр укый, экономика белән шөгыльләнә. Авылдашым Тыпый кызы Фәнисә Галиева да Башкорт дәүләт университетында икътисад фәннәре буенча эчтәлекле лекцияләр укып шатландыра студентларны.

Бу исемлекне янә су буе сузарга мөмкин булыр иде әле. Санап чыгу өчен генә дә бик күп урын кирәк. Фән кандидатлары исемен алган йөзләгән илешлеләрнең һәркайсы зур мактауга лаек. Чибәрлеге, мөлаем йөзе, җылы карашы, тәмле теле, Казан дәүләт университетын тәмамлап, галим дәрәҗәсенә күтәрелүче Рәисә Тимергалина, аның тормыш иптәше Мөхәммәт Закиров турында да бик күп матур сүзләр әйтәсе килә. Ләкин урын кыска, кулны тота. Минем өчен куркынычлар да юк түгел. Исемнәрен телгә алмаучыларның рәнҗүләре дә мөмкин. Хәер, бер дә алай булмас кебек. Илеш халкы артык мактауны да яратмый. Аннан чыккан зур галимнәрдә дә шушы сыйфат әле һаман саклана. Гадилек, кешелеклелек, кечелеклелек, хезмәт сөючәнлек кебек күркәм сыйфатлар бизи аларны. Бу яктан алар бер-берсенә нык охшашлар. Карап торуга ул юаш кына кеше кебек. Эшкә керешсә инде, арттырып әйтсәк, кулында ут уйната. Райондашларымның эчке җегәрлеге көчле, күрәсең. Тышы — сүренке, эче — ут, диләр мондый кешеләр турында.

Бү гүзәл сыйфатлар, чыннан да, әллә Илеш-Бабайдан киләме? Булыр да. Илеш-Бабай турында әллә күпме риваятьләр йөри. Ул, имеш, үз улларына, оныкларына, кардәш-ыру, агай-эне, туган-тумачаларына нәсел-нәсәп данын нык сакларга васыять әйтеп калдырган. Ул нәсел-нәсәп тамыры шушы төштә ич. Бу тамырдан алтын кәүсә үсеп чыккан. Кәүсә ботаклар җибәргән. Ботаклар яфрак ярган.

Гаярьлек

Бүген ул ике хат алды. Берсе — Хәниф Әхияровтан, Икенчесе — Гәрәй Шәмсиевтан. Хәниф ихлас күңелдән, күтәренке рух, йөрәк җылысы белән язган. “Нургали абый! Сез мине кеше иттегез. Тормыш авырлыкларын җиңәргә өйрәттегез. Кешелеклелек сыйфатларыгыз һәрвакыт юлдаш була. Һаман әле сезне әтием, Маһибә апаны әнием кебек якын күрәм”, — дигән сүзләр аны нык дулкынландырды.

Икенче хат та Нургалигә дан җырлап язылган. Ләкин анда күңел төшенкелеге, нечкә тойгылар өстенлек ала: “Пенсиягә чыгарга тагын бер ел калды. Белмим, тартып булырмы, юкмы, бик йончыдым, инфаркт га үткәрдем, бавыр белән дә иза чигәм, күрмәгән чир катмады, исән-аман ялга чыксам, кыл да кыймылдатмас идем”, — дигән.

Нургали Әхмәтов — Корчагин токымы. Алтын — утта, кеше михнәттә сынала, ди. Бик күп уттан янмый чыкты ул. Күргән михнәтләренең авырлыгын бернинди бизмән күгәрерлек түгел. Ләкин Нургали сыкранып баш имәде, горур булырга тырышты, кайбер җебек җаннар кебек, үз кайгысын кеше җилкәсенә салмады.

Авырлык хакында сөйләргә дә яратмый иде ул. Шулай да серләрен Хәнифтән яшерә алмады. Ундүрт яшьлек малайга файдасы тиярме? Йөрәген генә ярсытып җибәрмәсме? Авыр бала белән эш иткәндә педагог-укытучы я ота, я отыла, Кеше язмышы вакыты белән кыл өстендә чак-чак тора. Дөрес чиртмәсәң, кыл өзелә дә китә, ә кеше упкынга тәгәри.

Ул вакытта, 1952 елда, Нургали Илеш районының Иске Күктау мәктәбендә директор булып эшли иде. Авылда балалар йорты да бар. Авыр язмышлы сабыйлар анда. Берсенең әти-әнисе фронтта үлгән. Икенчесен юлдан тапканнар. Өченчесе, йөри-йөри хәлдән таеп, үзе монда килеп егылган. Хәниф — шундыйларның берсе. Алар мәктәпкә укырга йөри.

Хәнифнең болай сәләте юк түгел кебек. Ләкин тырышмый. Өзлексез тәртип боза. Директор бүлмәсенә бер ел эчендә биш-ачты мәртәбә алып керделәр, Башта Әхмәтов аңың белән яхшы сөйләште. “Ни дисәң дә, ятим бала. Китек күңелле. Кайбер укытучы кебек ярсып, төкерекләр чәчә-чәчә, баланың борын төбеңдә йодрык уйнатмады.

Алай әдәпсез кылану директор кешегә килешми. Моңа Хәниф үзе дә юл куймый. Директор алдында, тын алырга куркып дигәндәй, инсафлы гына басып тик тора ул. Ә бит малайдан табигать матурлыкны кызганмаган. Шомырттай кара күзләр. Карлыгач канатыдай кара кашлар. Әдәпле генә елмаю. Әнә шул “әдәпле елмаю” артында мәкерлелек чаткылары бар икән шул. Укытучы дәрес биргәндә ул елмаеп кына бер кызыклы сүз әйтә. Ерык авызларга бу җитә кала. Тотыналар көләргә. Дәреснең кызыгы китә. Укытучы чыгырыннан чыга

Әхмәтов дәресендә андый хәл булмый, билгеле. Хәтта чебен очкан тавыш ишетелеп тора. Чөнки ул — директор. Бу — бер. Икенчедән, ул дәрескә ихлас күңелдән әзерләнә. Тарихи вакыйгаларны мавыгып, кызыклы итеп, вакыты белән легендага әйләндереп сөйли. Шулай булмаса, аның укыту кебек авыр, җаваплы эшкә тотынырга хакы да юк. Чөнки ул — беренче группа Ватан сугышы инвалиды. Нерв күзәнәкләре һәрвакыт кызган хәлдә. Бер саксыз сүз аларны ялкынга әйләндерергә тора. Шуңа күрә директор-укытучы, ярсып кеше көлдермәс өчен, түземлелек йөгәнен кулыннан ычкындырмаска тырыша. Ләкин көннәрдән бер көнне мәкерле елмаеп торган Хәнифнең якасыннан алып җилтерәткәнен сизми дә калды. Кулындагы таягы белән башына чак тондырмады. Егылып китүдән куркып, өстәл артына барып утырды. Малайга да утырырга кушты. Сүгү, җикеренү, кул күтәрүне теләсә нинди ахмак булдыра ала. Ә менә кеше күңелендәге асылташны күрә белү сәләтенә һәркем ия түгел. Бу хакта Нургалинең нык уйланган чаклары күп булды. Кеше йөрәгенә педагог күңеленнән карау кадәресе, әлбәттә, аз әле. Чөнки беренче ел эшләве. Ничек кенә булмасын, күп үлемнәрне җиңгән сугыш ветеранына укучы алдында җиңелеп калу оят.

Хәниф хәзер балалык бакчасыннан чыгып килә. Ундүрт яшьтә. Алтынчы класста укый. Нургали үзе дә әти-әнисез үсте. Унбер яшьтә колхоз көтүен көтә башлады. Әмма тәртип бозып, берәүгә дә авырлык китермәде. "Сукмак юлга алып барыр, юл халыкка алып барыр", — дигән борынгылар. Үз сукмагын үзе салды Нургали.

Ә бу ундүрт яшьлек мәкерле елмаючы ахмак, кеше ярган сукмактан да салулап китә. Директорны калач ашап үскән бер аксөяк дип уйлыйдыр әле, бәлки.

Нургали 1920 елда туа. 1921 елдагы ачлыкта әтисе үлеп китә. Әнисе тормышка чыга. Ул картәтисе тәрбиясендә кала. 1936 елда картәтисе вафат булгач, тормышның күзенә нык туры карап уйланырга туры килде аңа. Мең төрле уйлар кайнашты башында. Шулай каңгырып, әрнеп, эчтән өзгәләнеп йөргәндә, Ташкенттан кайткан бер кешене очратты ул. Дүртөйле районыннан икән. Рсайга кунакка килгән. Туганнарына. Кичен капка төбендә халыкка Урта Азиядәге байлык турында сөйләде. Ташкентны "икмәкле шәһәр" дип йөртәләр икән.

Абзый үзе бик купшы киенгән. Түш кесәсеннән сәгать чылбыры асылынып тора. Көлгәндә алтын тешләре елкылдап кала. Кешеләр алдында үзен бик җитди, горур тота.

— Абый, Ташкентка барыр өчен ничә сум акча кирәк? — дип сораган иде Нургали, теге, авызын ерып, көләргә тотынды:

— Бай дигәч тә... әллә анда акчаны юл буена өеп куйганнар дип беләсеңме... Башта син көлдән борчак чүпләргә өйрән әле, энем...

Нургалинең үлеп ачуы килде. Юл белмәгән юлда елар, дигәнне

ишеткәне бар аның. Ул еламаячак. Егет кешегә күз яше күрсәтү оят. Тәвәккәлгә бүре тимәс, дигән иде картәтисе бервакыт. Тәвәккәлләргә кирәк...

Ләкин олыларның: "Юл азабы. — гүр газабы", — дигәннәрен искә алмаган икән ул. Нинди поездга утырып китәргә? Билетны кайдан алырга? Нәрсә ашап барырга? Бер поездан төшеп, икенчесенә эләгеп китү... Вагон түбәләрендә җилдерү... Эч-эчкә ябышу... Ләмдә аунаган дуңгыз кебек пычранып бетү...

Урта Азиянең эссе кояшы астында башны кая куярга белми каңгырып йөрү... Ачлык... Барысын да татырга туры килде уналты яшьлек егеткә. Көннәрдән беркөнне Ташкент вокзалында ана бер абзый игътибар итте. Имән бармагын уйнатып, үз янына чакырды. Барса, үз күзләренә үзе ышанмый торды Нургали: бу бит теге вакытта Рсайда кешеләр арасында үзен әллә кемгә куеп сөйләшкән "Алтын теш". — Ташкентка барыр өчен күпме акча кирәк булу турында юкка сорамагансың син шул, энем, — диде ул, авыр сулап, киемнәре теткәләнеп беткән Нургалигә кызганып карап. — Күрәм: хәлең мөшкел...

Бу вакытта "Алтын теш" көлеп сөйләшми иде инде. Нургалинең кайгысын үз йөрәгенә тулы килеш алды шикелле. Өенә алып кайтып юындырды, киендерде, тамагын туйдырып, ике көн ял иттергәч, ФЗО мәктәбе директорының кулына алып барып тапшырды.

Бар икән яхшы кешеләр дөньяда! Бар икән!! Бар!!! Кем ул? Исемен дә сорамады хәтта. Нургали өчен ул "Алтын теш" булып калды. Теше генә түгел, акылы да алтын булып чыкты. Көлүдә дә хикмәт бар, күрәсең. Ул, бәлки, начарлыкка сыкранып көлгәндер. Бәлки, көлеп, башкаларның күңелен күтәрергә теләгәндер. Ничек кенә булмасын, кешеләргә карата зур ышаныч, матур хис-тойгы шул вакытта кабынды Нургали күңелендә. Шул бөек хис-тойгы аның вакытлыча сынган күңеленә корыч канатлар куйды. 1937 елда фабрика-завод һөнәрчелек мәктәбен бик яхшы тәмамлап, Ташкенттагы җиңел промышленность техникумына укырга керде ул. Отличнога укыды Нургали. Җәмәгать эшләрендә йөзеп йөрде. Комсомол оешмасы секретаре булды. 1939 елда халык исәбен алу эшендә катнашты. Урыс, үзбәк телләрен яхшы өйрәнде. Кыскасы, техникумның горурлыгына әйләнде.

Бервакыт, өченче курсны тәмамлагач, аларны стройга тезделәр. Егерме яшьлек Нургали, арттырып әйтсәк, егетләр солтаны булып җитешкән иде инде. Сөлектәй гәүдә. Чибәр йөз. Зифа буй. Елт-кара чәч. Үткер, горур караш. Аның гаярь егет икәнлеген саф алдындагы озын буйлы майор да тиз аңлады шикелле:

— Менә мондыйлар белән Ватанны сакларга була, — дип, Нургалинең аркасыннан сөеп куйды.

Аларны Алма-Атадагы хәрби училищега укырга җибәрделәр.

Менә... 1941 ел. 22 июнь. Сугыш... Август аенда аларга лейтенант званиесе бирелде. Нургали Әхмәтовны 385нче укчылар дивизиясенә җибәрделәр. Пулемет взводы командирры. Ноябрь аеңда Көнбатыш фронтында иде инде ул.

* * *

Нишләп болай килеп чыкты соң әле? Гомер кояшының батуы шушымы?! Карының белән кар ярып, борының белән боз ярып булса да юлыңны тап, диләр. Карын да яра, бозын да, ә менә юл — юк. Ике аяк та яраланганмы? Бөтен тән иләкләнеп беткәнме әллә? Кузгалып та булмый. Басып китү турында уйларга ярамый. Әмма карышлап кына булса да шуышырга тырышты ул. Ләкин әкияттәге көн китте, төн китте, энә буе җир китте, дигән кебек кенә. Җәй көне булса бер хәл. Март салкынына да бирешмәс иде. Әмма хәрәкәт итеп булмый. Карда кан коеп аунап ятуга өченче тәүлек китте булса кирәк. Авызга тәгам ризык та капкан юк. Кемдер килеп алганчы тәнне туңдырмаска иде. Монысына да тырышылыр иде, бәлки, һуштан язмаска кирәк. Бусы — яшәү белән үлемнең соңгы чиге. Бу чиккә әллә ничә мәртәбә килеп терәлде иңде ул. Тән ката. Күз йомыла! Бөтен дөньяның асты өскә килә. Шулай да вакыт-вакыт һуш керә. Кайда ята ул? Брянск — Ржев тимер юлы буендагы Киров шәһәреннән ерак түгел урында. Училищеда чакта ук хәрби хезмәтне яхшы үзләштергән иде. Ату, йөгерү, сикерү уставларны белү — төрле яктан үрнәк күрсәтте. Рәхмәт алмый калган көне бик сирәк була иде. Тылда өйрәнгәндә күп тирләсәң, сугышта канны аз түгәрсең, диләр. Сугышта да үзенең оста, жегәрле, кешелекле командир икәнлеген тиз күрсәтте ул. Кайда куркыныч урын бар, шунда аның взводын җибәрделәр. Лейтенант Әхмәтов взводы уттан — янмый, судан батмый чыга, имеш. Бу бәяләмәдә дә дөреслек бардыр. Кайбер командир һич кирәкмәгән чакта алып бара да тыга подразделениесен ут эченә. Күпме кеше һәлак була. Лейтенант Әхмәтов взводында исә өч ай эчендә нибары алты кеше сафтан чыкты. Моның өчен рота командиры лейтенант Крюков, рота командиры ярдәмчесе лейтенант — Газетдинов аңа күп мәртәбә рәхмәт әйттеләр. Бервакыт дивизия командиры полковник Савин үзе килде Әхмәтов взводына.

— Югалтуларыбыз аз түгел. Билгеле, сугыш корбансыз булмый, ә менә сине взвод солдатлары арысландай сугыша да белә, исән дә кала; бу яктан да, кеше өчен көрәшүегез буенча да, сез дивизиядә үрнәк булып торасыз, — диде. Дивизия командиры шелтәләп тә алды: — Пулеметтан күп вакыт үзең атасың, монысына рөхсәт юк, башкаларга ирек бир; урынсызга батырлык күрсәтү ахмаклык ул, безгә синең кебек оста командирларны саклау бурычы да бирелгән, аны намус бурычы дип әйтсәң дә ярый.

Шуннан аны партия сафына алдылар. Кызыл Йолдыз ордены белән

бүләкләнде. Тик дивизия командиры Савинның киңәшен генә үти алмады. Немецлар өскә ябырылып килгәндә, икенче отделениенең командиры да, беренче номеры да яраланды. Икенче номерга ышаныч юк иде. Әхмәтов пулеметтан үзе атарга булды. Дошманны якынга гына китереп, үтергеч ут ачты. Аның пулеметы алдында иллеләп немец гәүдәсе ятып калды.

Алыш ул көнне каты булды. Безнекеләр унга якын атаканы кире какты. Өстәмә көчләр килмәде. Солдатларга рухи көч бирергә кирәк иде. Кичкә таба кузгалган чираттагы атакага башлап үзе күтәрелде Әхмәтов. Сафлар, тимер ташкындай, алга ыргылды. Әхмәтов, көч-илһам биреп, һаман алдан йөгерде. Уң кулына, аягына, тагын кай төшенәдер пуля тигәнлекне, яраланганлыгын да сизде ул. Ләкин ятып калмаска тарышты, дошман оясын туздырырга ярсыды. Якында гына бер снаряд ярылгач кына, киселгән агачтай чайкалып, кар өстенә авып төште. Төнлә барысы да тынды. Димәк, дошман оясын туздырып, безнекеләр алга китте. Һушына килгәндә, кемнәрнеңдер сөйләшүен дә ишетте ул. Хәтта берсе якыннан гына үтеп китте. Госпитальгә җибәрү өчен санитарларның яралыларны эзләгәнлекләрен аңлады Әхмәтов. Кычкырып та карады. Тик ишетүче булмады. Юк, ул кычкыра алмагандыр. Тавышы чыкмагандыр. Үзенә генә кычкырган кебек тоелгандыр.

Соңгы мәртәбә аз гына һушына килгәндә, кар өстендә өченче тәүлек катып ятуын аңлады ул. Хәзер инде тән бөтенләй авыртмый кебек. Туңдырмый да. Киресенчә, кыза тән, ут кебек кыза. Туңып үләр алдыннан кешенең шул халәткә килүе хакында ишеткәне бар иде Нургалинең.

* * *

Кар өстендә җитмеш сәгать туңып ята яралы лейтенант Әхмәтов. Аны кыргыз егете — санвзвод командиры Астраханбеков килеп таба. Сугыш кырыннан күтәреп алып чыга.

Әхмәтовның исән калуына башта беркем дә ышанмый. Биш мәртәбә операция ясыйлар аңа. Җанын алырга килгән газраил белән биш тапкыр якалашырга туры килә. Беренчесен ул бик аз хәтерли. Аңына килгәч, уң аягының бот төбеннән бөтенләй кисеп алынуы турында әйттеләр. Чөнки аяк сөякләре чәрдәкләнеп, туңып беткән булган. Сул аягының бармакларын кисеп, үкчәсен генә калдырганнар. Тез капкачы алынган. Тәндәге кырыклап ярага ямау салганнар.

Тау белән тау гына очрашмый, кеше белән кеше очраша, дигәннәре дөрес икән. Беренче операция ясаучы әлеге Ташкенттагы "алтын теш" булып чыкты. Медицина капитаны Илһам Сабирович Хаков.

— Менә тагын да очраштык, — диде ул, Нургали операциядән соң беренче мәртәбә күзен ачкач. — Мин синең нык егет икәнлегеңне теге вакытта ук шәйләгән идем. Үлемне эчке гайрәтең белән җиңдең.

Гайрәттән яхшы дус юк, диләр. Хәзер инде шуңа ышанып яшәргә кирәк. Гайрәт-дус кешене беркайчан да алдамый.

Бу хәл Калуга өлкәсендәге Красин кыр госпиталендә булды. Аннан Серпейск госпитале... Камера... Тимирязев исемендәге Мәскәү институты... Владимир шәһәре... Стәрлетамак больницасы... Уфа Тимер юлы больницасы... һәм, ниһаять, Уфа шәһәренең Карл Маркс урамындагы гарнизон госпитале... Һәр операция вакытында ул Илһам Сабировичның: "Гайрәттән яхшы дус юк", — дигән кыйммәтле сүзләрен искә алды. Уфаның гарнизон госпиталендә аңа реампутация ясыйлар. Бу эшне яна гына медицина институтын тәмамлаган хирург Халидә Мостаева башкара. Килеп тикшергәч, Халидәне осталыгы, Нургалине рухи ныклыгы өчен мактадылар. Аерылышканда Халидә Нургалинең чәчләреннән сыйпап, аркасыннан сөеп куйды.

— Рәхмәт, Халидә Ильясовна, сез мине операция ясап кына түгел, җылы карашыгыз, ягымлы елмаюыгыз, кешелеклелегегез белән дә сәламәтләндердегез, — диде Нургали яшь хирургка ихлас күңелдән. Халидә Ильясовна да дулкынлана иде:

— Үзеңә рәхмәт, Нургали, корыч ныклыгың белән ярдәм иттең миңа, бу бит беренче операциям, аның уңышлы чыгуына бик шатмын; бер егетнең кыюлыгы мең кешегә дан китерә, икәүләп җиңдек! — диде ул.

* * *

Әйе, үлем җиңелде. Беренче группа Ватан сугышы инвалиды ясап, аны госпитальдән чыгарып җибәрделәр. Туган районы — Илешкә кайтып төште ул. Хәзер аның икенче якын дусты — таягы бар. Аны беркайда да кулыннан төшерми. Яхшы, нык басып йөрергә кеше күрмәгәндә өйрәнә. Елмаерга, горур булырга тырыша. Райкомга керде. Райсоветка. Кулына каты гына җаваплы эш бирүләрен таләп итте. Аны социаль тәэминат бүлегенә мөдир итеп куйдылар.

Туган авылы Рсайга ул гел кайтып йөрде. 1945 елның мартында Мәһибә исемле чибәр, уңган, алтын куллы авылдашына — укытучыга өйләнде. Район үзәгендә аларга коммуналь хуҗалык бер йорт бирде. Күгәрченләй гөрләшеп, шунда яши башладылар.

Мәһибә Югары Яркәй урта мәктәбендә укытты. Нургали мөдирлек эшенә чумды. Бервакыт сугыш уты да тынып калды. Дөнья иркен тын алды. Җиде ел эшләде Нургали мөдирлектә. Җиде ел эчендә партия оешмасы секретаре да булды ул. Комсомол оешмасының пропагандистлык эшен алып барды. Яшьләрне патриотик рухта тәрбияләде. Район комитетының ревизия комиссиясе әгъзасы булып та торды. Сайлау кампанияләрендә актив катнашты. Бер генә урып-җыю вакытында да колхозларга райком вәкиле итеп җибәрелми калмады. Күп укыды, үз өстендә даими эшләде. Урта мәктәп программасы буенча

үзлегеннән әзерләнеп, аттестат өчен имтиханнар тапшырды да 1949 елда Бөре укытучылар институтына китте. Бу вакытта ике бала атасы иде инде ул. Мәһибә укуына каршы килмәде. Киресенчә, шатланды гына. Өйләнешкәндә:

— Минем белән яшәве авыр булачак, Мәһибә, — дигән иде. Мәһибә җавапны бер сүз белән генә бирде:

— Сыкранмам!

Бөредәге ике еллык укытучылар институтың тәмамлап кайткач, аны Иске Күктау мәктәбе директоры итеп куйдылар.

...Шушыларны сөйләгәч, Хәниф күзгә күренеп үзгәрде. Уйчанланып калды. Тиздән директорны "Урожай" колхозының партия оешмасы секретаре итеп тә куйдылар. Димәк, муенына ике зур камыт киеп алды ул. Яңа мәктәп салу мәсьәләсен кузгатты директор. Башта аны Иске Күктау авылында "ярты Кеше" дип кабул иттеләр. Тиз арада үзенең ярты гына түгел, бер, ике, өч, бик күп кеше икәнлеген исбат итте. Мәһибә дә бөтен авырлыкны үз җилкәсенә алырга тырышты. Икешәр канат. Икешәр канат — дүртәр канат. Аңа башка укытучылар канаты өстәлә...

...Унсигез яшьтә детдомнан чыгып киткәндә шуны аңлады Хәниф.

* * *

Еллар үтеп торды. Сугыш яраларын төзәтү. Бөек төзелешләр. Чабатадан ботинкага күчү. Авылда салам түбәләрдән котылу. Күз явыңны алырдай матур-матур йортлар тезелеп китү. Шәһәрнең гөрләп үсүе... Тормыш дулкынында югалып калмады Нургали. Кайда каты куллы, белемле, педагогик осталыгы булган мәктәп директоры кирәк, Нургали Галиевичны шунда җибәрделәр. Яңа Аю урта мәктәбе директоры, Югары Йонны урта мәктәбе директоры, Үрмәт урта мәктәбе директоры. Кайда гына булмасын, мәктәпне яңартып китте, бер үк вакытта партия оешмасы секретаре вазифасын алып барды. Директорлык постында егерме өч ел буе тәртипле солдаттай нык торды ул. Дөнья үзгәрә. Халыкның аңы үсә. Белемлеләр һаман күбәя бара. Тормыштан артта калырга ярамый. Партия оешмасы секретаре, пропагандист булып эшләү, төрле түгәрәкләр белән җитәкчелек итү, Башкорт дәүләт университетының тарих факультетын тәмамлау — болар барысы да аны югары аң-белемле, культуралы, замабызның җитди таләпләренә җавап бирә торган кеше итте.

Бервакыт аларга район үзәгеннән бөтен уңайлыклары булган өч бүлмәле фатир тәкъдим иткәннәр иде. Нургали үзе дә, Мәһибә дә риза булмады моңа. Алар туган авыллары Рсайга кайттылар да, шыңгырдатып йорт салдылар. Нургали — тарих, Мәһибә туган телне укытты. Ихата тулы мал. Бакча. Умарталар. Чын крестьянча яшәүгә ни җитә! Тәрбияләп үстергән алты бала — алтын бәхетләре! 1946 елның җиңү көнендә туган иң олы уллары — югары белемле инженер Алигер — Көньяк Сахалинда

кошчылык фабрикасы директоры. Күптән түгел “Известия” гәзитендә язып чыктылар. Әлфирә индустриаль техникум тәмамлады. Мастер булып эшли. Әлбинә Башкорт дәүләт педагогия институтында югары белем алды. Хәзер урта мәктәптә укыта. Әлфия Уфа хисап-механизация техникумында укыды. Хәзер — Түбән Кама шәһәрендә технолог. Әлфинә Уфа медицина институтын тәмамлады. Әлеге вакытта Төньякта — Ямбургта стоматолог. Төпчек Даниф — югары белемле — географ. Илеш районының Аккүз урта мәктәбендә укыта.

Балаларның балалары да бик күп хәзер. Җәй көне, ял вакытында, төрлесе төрле яктан кайтып тула. Өй эче шат авазлардан гөрләп тора. Гөмбәгә баралар, җиләк җыялар. Су коеналар. Төнлә берсе — өйдә, икенчесе — чоланда, өченчесе — гаражда, дүртенчесе — бакчада, бишенчесе печәнлектә ятып йоклый. Авыл укытчысының башкалар өчен үрнәк булып торырлык матур тормышы бу.

Чөнки укыту, күп бала тәрбияләү, дөнья көтү, җәмәгать эшләрендә йөзү — төрле яклап авыл халкына өлге күрсәттеләр...

Беренче кыңгырау. Укытучы күңелен ул ярсыта да, моңландыра да, шомландыра да. Укытучы беренче дәрескә үк кулына журнал тотып керә. Ә журнал эчендә — күпме бала язмышы!

Быел да булды беренче кыңгырау. Нургали белән Мәһибәне ул тагын да моңландырып җибәрде. Ул моң шатлыклы хисләр белән аралашкан иде. Ата-ананың зур бәхете балаларында. Укытучының зур бәхете — үз балаларында гына түгел, укытып чыгарган йөзләгән-меңләгән кеше балаларында да. Шулар бәхете белән бәхетле укытучы. Нургали, Мәһибә укыткан балалар колхозда, районда, республикада, илебезнең төрле урыннарында эшли. Ә инде Хәниф алар белән беркайчан да бәйләнешне өзмәде. Институтта укыганда да, Себердә инженер булып эшләгәндә дә хат язып торды, ял вакытларында килеп, кунак булып китте. Ул инде дүрт бала атасы. Орденнар белән бүләкләнгән кеше. Новатор.

Тик Гәрәй хаты гына аларның икесен дә берникадәр борчып алды. Аның белән бергә Бөре институтында укыган иде Нургали. Яшь булуына карамастан, күп йокларга, күп ашарга ярата иде Гәрәй. Юк чирне бар итеп күрсәтә торган гадәте дә юк түгел иде. Хәзер пенсиягә чыгуны түземсезлек белән көтеп ята. Ә бит беренче группа инвалид Нургали Әхмәтовка хәзер 69 яшь. Ул һаман пропагандистлык эшен алып бара. Урып-җыю вакытында ындыр табагында селкенеп алырга да кыенсынмый. Быелгы халык исәбен алу вакытында тугыз авыл Советы буенча бүлек мөдире вазифасын үтәде. Зур пропаганда эше алып барды.

Ул һаман әле — көчле ихтыярлы, җегәрле, эшчән кешеләр атлаган корыч сафта. Йөзенә карасаң, житмеш яшь ишеген шакучы дип берәү дә әйтмәс. Ике мәртәбә инфаркт үткәрү дә жиңә алмады бу гаярь кешене.

Зур максатлар белән яшәү бөтен авырлыкларны җиңәргә ярдәм итә, күрәсең.

Яшьлек хатирәләре

Илеш районы үзәге (Югары Яркәй авылы) сугыштан соңгы елларда башкалардан аерылып тормый диярлек иде әле. Шул ук салам түбәле вак-вак йортлар, ишелеп төшәргә торган абзар-кура, тавык кетәкләре, кара мунча шул чордагы яшәү котын ямьсезләп тора. Акрынлап котсызлыктан котыла барды Илеш халкы. Райүзәктә дә, авылларда да Илеш халкы салган карап туйгысыз матур йортларны карарга башка районнардан да киләләр иде. Хәзерге Югары Яркәй җыйнак кына бәләкәй бер шәһәрне хәтерләтеп тора. Илеш җирен уратып алган ак каеннарда нindидер серле, сихри, иманлы көч бармы әллә?

Мин бу фикерне шуңа әйтәм. Мәгълүм ки, җиткән кызларыбыз, шәһәрдә укып югары белем алгач, авылга кире кайтырга кыенсына. Башка илләргә китеп, шунда кияүгә чыкса да шатлана. Ә менә шәһәрдә туып, шунда урта мәктәпне тәмамласа да, Илешкә килен булып килүче кызлар да бар. Илеш егетенең булдыклылыгымы бу? Шуны аңлыймы шәһәр кызы йөрәге? Илештә алар хәтсез. Менә шуларның берсе — Лилия Тимергазиеваныкы.

Мин бу фани дөньяга 1968 елда килгәнмен. Тау башында балкып торган Уфа шәһәрендә. Әнием Клара, әтием Марс Хәсәновлар — инженерлар. “Үзебез кебек булсын” диптер инде, 1985 елда Уфа шәһәренең 52нче урта мәктәбендә урта белем алгач, миңа авиация институтына керергә куштылар. Аны тәмамлагач, Илеш районының Югары Яркәй авылында яшәгән Әфкать Тимергазиевка тормышка чыктым. Илешнең финанс идарәлегендә инженерлык вазыйфасын башкардым. Янә икътисад институтын тәмамларга туры килде. Ирем майор дәрәҗәсенә күтәрелде. Йорт салдык. Зур улыбыз Алмаз — авиация институтында, кече улыбыз Булат нефть техникумында укый.

Шигырь язу белән урта мәктәптә үк шөгыльләнә идем. Әтием, әнием өйдә фәкать татар телендә сөйләшергә кушты. Илештә татар теленә ныклап гашыйк булдым. Тукайны, Гафурины, Бабичны, Такташны яратып укыдым. “Үткән хатирәләр”не туган телемдә язуымның сәбәбен шуның белән аңлатырга мөмкиндер. Искиткеч бай, матур, образлы икән ул татар теле!

I.

Уфа.
Миңа — унҗиде.
Яңа яшь йөрәк.
Урам, халык кайный.

Аларга ни кирәк?
Хатын-кызлар, ир-егетләр, бала-чага,
Гүя бәхет тотар өчен ярсып чаба.
Мин атлыймын.
Сизәм:
Кемдер килә арттан.
Уф-уф итә, гүя мәхәббәт югалткан.
Алга чыкты.
Бүлде юлны.
Тотты кулны.
Ошатмадым бу егетнең ахмаклыгын.
Тартып алдым кулны, дәвам иттем юлны —
Саклар өчен яшьлек сафлыгын.
Аңламассың: әллә нахал, әллә надан,
Аның өчен юкмы әллә заңлы заман?
Янә чыкты алга.
Юлны бүлде "карга".
И тотынды юньсез-гамьсез такылдарга.
Ул, янәсе, күргән мине магазинда,
Арттан калмый шуннан бирле бер адым да.
Гашыйк булган мәңгелеккә Таһирдай нык.
Арабыздан үтмәс кылыч, бернинди ук.
Сандугачтай сайрый, тезә баллы сүзләр,
Әллә ничек моңлы карый зәңгәр күзләр.
Тиз бирелә йомшак кызлар тел назына,
Тап төшерә уйламый яшьлек язына.
Авыр икән күп борчылу, яну, көю.
Давыл булып килде бугай тәүге сөю.

II.

Юк, ул ахмак, нахал,
Надан, карга түгел.
Аңламаганмын кешене —
Яшь бит күңел.
Мин — кала кызы.
Исним таш һәм газлы һава.
Тышка чыксам, өскә
Тузан, пычрак ява.
Егет авылчарак моңлы, күркәм сөйли.
Әллә нинди мин белмәгән көйләр көйли.
Мактап җырлый авылдагы ак таңнарны,
Саф һаваны, тук башаклы киң кырларны.

Илеш егете ул. Илгә зирәк кеше.
Торган җире, әйтүенчә, оҗмах ише.
Җирен сөйгән — бәхет сөзгән. Ул — бәхетле.
Авырлыклар булмый калмас: ул — тәхетле.
Мин дә сөям, хуп күрәм газлы каламны.
Туган җирдән кадерлерәк җай төш бармы?
Тик кайнатты канны бик нык гыйшык җиле,
Тормышка чыктым егеткә мин яшь тиле.
Илеш, диләр, Илеш, диләр...
Ерак — даны.
Бик-бик якын, үз җирендә — Изге җаны.
Хезмәт сөя Илеш халкы, матур яши.
Ләззәтләнеп, шатлык белән, горур эшли.
Башта кыен, авыр булды: мин чит чәүкә.
Үз итмиләр кебек алар мине һич тә.
Җитми икән бу йөрәккә ир бәхете,
Кирәк икән бик садә ил мәхәббәте.
Илеш илендә зур бәхет һәм мәхәббәт
Килә икән хезмәт итсәң генә йөкләп.
Илеш халкы киң күңелле, ачык йөзле,
Сайрап торган сандугачтай тәмле телле.
Нык ачылды безнең өчен колачлары,
Назлар бөрки сөйкемле күз карашлары.
Иркәләнәм ул назларда, гүя, бала,
Онытыла хәзер инде газлы кала.
Монда иман. Монда оҗмах. Монда хозур.
Мондый илдә намус та бар, бәхет тә зур.
Ирем белән йорт салдык без икәүләшеп,
Ярдәм итте Илеш халкы кумәкләшеп.
Бергәлектә икән дөнья рәхәте,
Кәүсәрдәй саф икән авыл мәхәббәте!
Илеш, диләр, Илеш, диләр...
Илеш кайларга китте?..
Илеш халкы мин шаянны
Акыллы ана итте.

Лилия ТИМЕРГАЗИЕВА

Өченче бүлек

Казан дәүләт педагогия институтының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә укыганда (1951-55 еллар) “Муса Җәлил поэзиясендә чагыштырулар һәм аларның әдәби әсәр эчтәлеген ачудагы роле” дигән фәнни мәкалә язган идем. “Совет мәктәбе” журналында басылып чыкты ул. Шуннан соң шагыйрьләрнең тел-стиле үзенчәлеген тикшерүне дәвам иттем. Алар төрле газит, журнал битләрендә, аерым китапларда да нәшер ителеп торды. Үземнең шигырь һәм поэмаларымда сүз-сурәт, сүз-фикер, сүз-тойгы кардәшлегенә игътибар итәргә тырыштым. Әдәби әсәрнең җанын, канын, йөрәк тибешен тәшкил итүче бу терминнар объектив карашлы булырга ярдәм итә. Дөрес, аларга карата төрле милләттә төрле карашлар да бар. “Чагыштыру – танып белүнең анасы”, – дип әйтү бәхәссез. Немецлар: “Һәр чагыштыру аксый”, – диләр. Французлар һәр чагыштыруның дәлилләү була алмавы турында әйтә. Аз сүз белән күп мәгънә белдерүе метафора, эпитет кебек сурәтләү-тасвирлау чараларының образлылыгы, идеялелеге, эмоциональлеге хакында да төрле карашлар яшәп килә. Традицион (халыкныкы), трансформацияләнгән (үзгәртелгән), индивидуаль (әдип үзе иҗат иткән) мәкаль-әйтем, фразеологик әйтелмәләрнең кулланылыш дәрәҗәсе турында да төрле карашлар бар. Болар хакында миңа күп язарга туры килде. Әле дә туктаганым юк.

Мәгълүм ки, беренче бүлектә туган оямның иманлы булу мәсьәләсе шигърият, икенче бүлектә хикәят-эссе ысулы белән яктыртылды. Өченче бүлектә башкарачак. Бер карасаң, аны аңлавы кыен сыман. Ныклабрак уйласаң, алай түгел. Әйтик, Кол Галинең “Кыйссаи-Йосыф” поэмасындагы Сабах җиле Илеш бабайның ата-бабасы булган Кыпчак җирендә исмәгәнмени? Искән. Илештә Кыпчак дигән авыл әле дә бар. Илештәге Кыргыз авылы да – Кыпчак-Бабай бүләге. “Салават Юлаев” дигән колхоз да бар Илештә. Бу якларда Салават җиле дә батырлык рухы булып исә әле. Бу бүлектә бирелгән шагыйрьнең поэтик җиле үзенчә бер матур, батыр яшәүнең символы булып исә.

Исә сабах җилләре
Кол Гали

Кулымда – каләм. Күңелем – чал тарихта. Ком сахралары. Күк йолдызлар белән чигелгән. Моңсу ай йөзә. Офык алга манылган. Таң ата. Сабах җилләре исә. Күктәге матурлык-шәфкатьлелекне җиргә таратучы җил бу. Ул матурлык фәрештәләр канатына төялеп тә килә, имеш. Җил аларны өлешләп-өлешләп тә тарата. Бик кирәк урыннарга. Җил, мәрхәмәтле-мөрәвәтле кеше сынына әверелеп, изге хәбәр ташучы сихри-

тылсымлы көчкә әйләнә. Җил йөрәге белән күк йөрәген бәйләп, йолдызлардан яктылык, кояштан эсселек, айдан моңсулык, таңнардан алсулык алып, Кәнган һәм Мисыр илләре бәндәләренә хәерхак биреп, бәхет-сәгадәт өләшеп, хозурлык балкытып исте ул бервакыт, галәм киңлекләрен айкап-байкап, канатына бик борынгылардан калган риваять-легенда, җыр-моң, яшәү рәвеше сыйфатлары төяп, борынгы ата-бабаларыбызның изге җиренә – Болгар иленә исеп килеп җитә ул. Анда Кол Галинең колагына өрә, йөрәгенә керә, күңеленә поэтик орлык ялкыннары сибә. Шагыйрьнең күңел сандыгында җил, шигъри символга әверелеп, каләм очыннан кәгазьгә тел гәүһәрләре булып түгелә. Улы кайгысыннан күңеле җәрәхәтләнеп, йөрәге әрнеп, күзләре сукрайган пәйгамбәр Якуп сабах җиленә мөрәҗәгать итә:

Акрын искел, сабах йиле, нә үтәрсән,
Хакыйкать Йосыфымнан ис дотар сән.
Җәрәхәтем уңалдырмага сән йитәрсән,
Сән искәли шат-хөррәм улдым имди.

Сабах җиле Якупка улы Йосыфның дөньяда барлыгы, кешелекле, кечелекле, шәфкатьле-мөрәвәтле булуы, ил, халык мәнфәгате белән яшәве турындагы изге хәбәрне алып килә. Җил Якупка шифалы җылы агым булып исә. Аның чәчләреннән, кайгыдан сукрайган күзләренннән сыйпый. Якупның җәрәхәт-яралары төзәлә, йөрәк сызлаулары басыла, күзләре күрә башлый. Шулай итеп, халык җырларында, риваятьләрдә, әкиятләрдә төрле сыйфатларда кулланылып килгән җил образы җанландырылып, яки кеше кыяфәтенә кереп, Кол Галинең “Кыйссаи Йосыф” поэмасында зур поэтик мәгънәгә, образ тудыручы көчле чарага, эстетик-эмоциональ хосусияткә әверелә.

Таңнар һаман ата, ата; сабах җилләре исә, исә, Кандалыйның да күңелен кытыклый: мәхәббәт тойгыларын, күркәм хисләрне, изге әманәтләрне үзе аша чагылдырырга куша. Анда да саба җиле сахраларда, чүлләрдә исә, кеше сыйфатына кереп, мәхәббәт кебек изге тойгыларны аңлатырга ярдәм итә:

“Ирәм багымдамы үстең, йөрәкәм бәгырене кистең, Саба йиле кеби исдең ки, сахраларда, чүлләрдә”.

Мәгълүм ки, егерменче йөз башында ак-кара, гаделлек-гаделсезлек, кешелеклелек-кешелексезлек көрәше сыйнфый характер ала. Кол Гали истергән поэтик җил хәзер илдәге хәерчелек, караңгы тормыш, милләт язмышы өчен ачынып, әрнеп, җылый-җылый исеп йөри: “Көзге төн. Мин йоклый алмыйм. Өй түрендә җил җылый; Җил җыламый, ач үлемнең куркусыннан ил җылый” (Г. Тукай). Такташта җил башта нан(икмәк) сорап йөри, аннан яңалык өчен көрәшүче символик көчкә әверелә, Г. Ибраһимовта исә карт агачны төбе-тамыры белән алып ыргыта. М. Җәлилнең “Ана бәйрәме” исемле шигырендә, Кол Галидәге кебек, хәбәр

ташучы сыйфатында йөри. Җил анага улларының сугыш кырында апмаз кылычларының кулларыннан төшмәве, соңгы тамчы каннары тамганчы көрәшүләре турындагы изге хәбәрне алып килә.

Кеше – табигать баласы. Аның йөрәге табигать йөрәге белән бәйле. Шуңадыр, бәлки, адәм баласы кайгы-хәсрәтен, шатлык-куанычын кояшка, айга, йолдызларга, алсу таңнарга сөйли. Аларга табынып бәхет тели. Ә инде шул табигать хозурлыкларына кагыла-кагыла, алардагы матурлыкларны тарата-тарата искән җилгә аның мәхәббәте аеруча зур. Ул аны кеше итеп, җаны итеп күрергә гадәтләнгән. Хәзерге вакытта кайбер шагыйрьләрнең җил образы аша кешенең галәмгә (космоска) булган мөнәсәбәтен күрсәтергә тырышулары да шуңа бәйләнгәндер (мәсәлән, М. Галинең "Кояш җиле" дигән поэмасы). Кабатлап булса да әйтик, Болгар чоры (XIII йөз) шагыйре Кол Галинең поэтик җиле һаман исә әле, ул яңадан-яңа эстетик-эмоциональ төс, мәгънә төрлелеге, сурәтләү-тасвирлау яңалыгы белән бөтәя бара. Теге яки бу чордагы шагыйрьнең поэтик телен тикшергәндә, гадәттә, үзенә чаклы булган нинди, кайсы каләм остасының традициясен дәвам итүенә басым ясала. Әгәр "Кыйссаи Йосыф" беренче язма әсәр, ата-бабаларыбыз калдырган беренче поэтик ядкарь, иң олуг мирас дип сөйләшәбез икән, бу мәсьәләнең тамырын юллап торасы да юк кебек. Кол Галинең нәфис сүз сәнгате остасы булуы бәхәссез. Поэзия тукымасында сүз гәүһәрләре, аш өстендәге өре кебек, үзен сиздереп-күрсәтеп тора. Ләкин шигърияткне гел генә күз явын алырдай "чатнап торган" матур бизәкләр белән нәкышлап тору да килешми. "Баллы сүз баш әйләндерә", – ди халык. Яки: "Кызыл сүзнең күчәре тиз сына".

Теоретиклар, әдәби әсәрнең тел-стиль үзенчәлеген тикшергәндә, каләм остасының халык тарафыннан иҗат ителгән традицион образлардан ни дәрәҗәдә уңышлы файдалануын ачыкларга тырышалар. Монысы, билгеле, кеше үстергән гөл-бакчага сокланып карап тору кебегрәк. Әгәр ул гөл-бакча үз кулыңа калып, син аны яңадан-яңа чәчәк-гөлләр белән балкытып җибәрсәң, менә шунда инде чын мәгънәсендә нәфис сүз сәнгате остасы була алуың. Кол Гали – шул маһирлыкны күрсәтүче шагыйрь. Аның җанландыру-сынландырулары, җансыз әйбер-предметларны илаһи бөек көчкә әверелдерә белүе, аларны матурлык-шәфкатьлелек фәрештәсе итә алуы гына түгел, шул әйберләрдәге төрле төсләрне, сыйфат билгеләрен ачыклаучы сүз бизәгечләре (эпитетлары) да гаҗәп үзенчәлекле. Халык, мәсәлән, бик борынгы заманнарда ук бәгъзе берәүнең каһарманлык сыйфатын күрсәтергә кирәк булса, аның өчен "йөрәкле" дигән эпитет кулланган: "йөрәкле кеше". Кол Галине бу гына канәгатьләндерми. Йосыфның физик һәм рухи көчен, бөеклеген, илаһилыгын күрсәтү өчен ул әкият-легенда, төрле риваятьләрдәге тылсымлы-сихри көчкә ия булган каһарманнарның асыл сыйфатларын

эзлй аларны гомумилэштереп, синтезлап, поэзия “җанында” классик өлге-үрнәк булып калырдай эпитет ясый: алып йөрәкле Йосыф. Аның кешелеклелек табигате, эчке дөньясындагы асыл сыйфаты, башка күркәм яклары “сәгадәтле”, “мөрәүвәтле”, “бар кешедән бик куәтле”, “һәйбәтле”, “кырык ирдән куәте артык” кебек эпитетлар, гиперболалар ярдәмендә тасвирлана. Менә бер өзек:

Дүртенче – сәгадәтле һәм мөрәүвәтле,
Бишенче – алып йөрәкле һәм һәйбәтле,
Алтынчы – бар кешедән бик куәтле.
Кырык ирдән куәте артык имди.

Сүзбизәгечләр шагыйрьгә аз сүз белән күп мәгънә аңлату, җанлы картина тудыру, образлылыкка ирешү, герой-каһарманның эчке һәм тышкы сыйфатын ачыклауга ярдәм итә. Әгәр ир-егет батырлыгы алып йөрәкле дигән сүзтезмә аша чагылдырылса, хатын-кыз матурлыгы Кол Галидә гәүһәр эпитеты белән тасвирлана. Гәүһәр яшь дигәндә бу сүз тышкы матурлыкны тасвирлау өчен генә кулланылмаган. Ул мәхәббәт утында янган йөрәкнең көчле, кайнар, ялкынлы хис-тойгыларын тышкы дөньяга алып чыккан.

Хәзерге вакытта әдәби әсәрнең телен тикшерүче телче-филологлар сүз сәнгате осталары тарафыннан кулланылган эпитетларның төрле “модель”ләрен күрсәтүчәннәр. Әгәр әйбер-предметтагы эчке һәм тышкы сыйфатларны бер генә үзенчәлек буенча ачыкларга кирәк булса, ялгыз эпитет та җитә; характерлы билгеләрне төрле яклап тасвирлаганда тиндәш кисәк формасында килгән берничә яки катлаулы эпитетлар ярдәм итә. Эпитетларның сыйфат, сыйфат-фигыль, исем һ.б. сүз төркемнәре белән ясалу күренешләре дә күз уңында тотыла. Бу төрләрнең һәммәсе дә Кол Галидә барлар. Алар шагыйрьнең поэтик канвасын бизәп торалар. Ялгыз эпитетлар: ачы су, зифа кыз, нечкә бил, якты йөз, нурлы йөз, татлы тәгам, ләззәтле шәраб; тиңдәш кисәк булып килгәннәре: сәгадәтле, мөрәүвәтле, һәйдәтле Йосыф; җәенке яки катлаулылары: яулак каты кайгылы кысынкылык, кызыл алтын беләзек, кызыл алтын кадәх (савыт), алып йөрәкле Йосыф һ.б.

Сүзбизәгеч энҗеләре белән татар шагыйрьләре поэзия түсен нурландырып торалар: ләззәтле хыяллар (Тукай), күркәм таң (Дәрдмәнд), сихерле җырлар (Г. Туташ), ачы яшьләр (З. Ярмәкәй), алтын җир (Ш. Бабич), гүзәл сукмак (А. Еникәй), шат яз (Г. Сөнгати), ямьле моң (Ш. Фидаи), алтын яшь (Н. Дәүли), алтын таңнар (В. Мифтахов) һ.б. Тиңдәш кисәкле, җәенке, логик һәм образлы (метафорик) эпитетларның матур үрнәкләрен прозада Г. Ибраһимов күрсәтте: зур буйлы, солтанат кыяфәтле, агара башлаган чәчле байбичә, мәхәббәт һәм кискенлек тулган матур кара күз, гади һавалы кыяфәт, һәртөрле чәчәкләр белән бизәлгән әгълә бакча һ.б.

Бик борынгы ата-бабаларыбыз: "Чагыштыру – танып белүнең анасы", – дигәннәр. Мең әйбердә мең төрле үзенчәлек. Аларның матурлыгы гүзәллеге, күркәмлеге, эчке һәм тышкы сыйфатлары, күзгә ташланып тормаган гаҗәп яшерен серләре бер-берсенә охшатып-чагыштырылып танып-беленә. Кол Гали чагыштыру объекты сыйфатында күбрәк якут ташы, гәүһәр, мәрҗән, энҗе кебек кыйммәтле, поэтик яңгырашлы матур эчтәлекле әйбер-предметлар сайлаучан. Шулар аша ул керфекләренә гәүһәр яшь кунган Зөләйханың кайнар мәхәббәтен, йөрәк ялкынын, күңел тетрәнүен чагылдыра, Йосыфның эчке һәм тышкы илаһилыгын, җан эретерлек күркәм сыйфатларын, асыл сынын гәүдәләндерә. Зөләйха әнә ничек зурлый Йосыфны:

Якутә биңзәр сәнең яңакларың,
Яшь алмадин ләтыйфьрак иякләрең.
Бал-шәкәрдин датлырак дудакларың,
Ике ләбең күңелем и өртер имди.
Яки:
Яңа бетмеш тал чыбык тик бармакларың,
Кяфурдан артыграк сөфракларың
Ләз-ләз энҗедин теделмиш тырнакларың,
Әлләрең хәрирдан йомшак имди.

Халык телгә үтә житди караган. Аның төзеклеге, сәнгатьлелеге,) мәгънәлелеге өчен даими рәвештә көрәшеп яшәгән. Борынгы ата-бабаларыбыз "тел ярышы" мәҗлесе үткәрә торган булганнар. Мәҗлестә тел бәйгесенә катнашучыларга нинди дә булса бер тема бирелә. Аларның сөйләме эчтәлекле дә, сәнгатьле дә булсын. Телнең фикер көзгесе икәнлеген кеше әнә шунда күрәсәтә ала. Аз сүз белән күп мәгънә аңлату, бер китаплык фикерне бер җөмлә белән бирү, осталыкның кыскалыкта икәнлеген раслау өчен халык телнең алтын хәзинәсе булып калырлык гаҗәп күп мәкаль-әйтемнәр иҗат иткән. Алар Кол Галинең "Кыйссаи Йосыф" поэмасында да күпләр. Ләкин шагыйрь, югарыда әйткәнчә, кеше үстергән гөл-бакчадагы әзер чәчәкләрне генә өзеп йөрмәгән кебек, мәкаль-әйтемнәрне дә үзгәртмичә генә кулланмый. Теоретиклар теле белән әйтсәк, һәр нәрсәгә иҗади якын килә белә. Халыктагы "Сабыр иткән – морадына житкән", "Сабыр төбе – сары алтын" кебек мәкальләр нигезендә бөтен бер строфа төзи:

Йосыф әйтер: "Я Зөләйха! Бәне күргел,
Баек Мисыр газизе бәнвән белгел;
Әгәр бәне эстәр ирсәң, Мисра кәлгел, –
Баек бә Мисыр эчрә булгыл имди.
Сабыр берлә эшләгел ушбу эши,
Сабыр берлә эшләнер эшләр башы,
Морадына тиз йитәр сабырлы кеше, –

Бу эш эчрә күрекле сабыр кылгыл имди".

"Сабырлык – Сары алтын", "Сабыр иткән – морадына җиткән" кебек мәкальләр нигезендә Кол Галидән соң иҗат иткән шагыйрьләр дә күп-күп строфалар төзеделәр. Менә М. Колыйдан бер мисал:

Сабыр берлә гөлләр ачылыр, китәр кышлар,
Йомыркадин чыгар, күккә очар кошлар;
Сабыр берлә гәүһәр булыр энже ташлар,
Сабырсыздан кайнаю бэн пешсә булмас.

Югарыда әйтелгәнчә, тел-сурәтләү чаралары, төрле поэтик бизәкләр әсәрнең идея-эчтәлеге һәм ул чагылдырган чорга карап та кулланыла. Г. Тукай, мәсәлән, "фәлсәфи сүзләр" дигән әсәрендә бу мәкаль-әйтемнәр эчтәлегенең киресен бирә: "Сабырлык төбе – Сары алтын", дигән булалар. "Шура" идарәсенең 75әр тиен генә бәһа куеп, "Басмаган шигырьләр мәҗмугасы" вә "тиле ярышы" кеби чүпләр таратуына милләт сабыр итсә дә, сабыр төбеннән сары алтын түгел, сары бәрәңге дә чыкмый әле".

Теге яки бу чорда суз сәнгатенең, сәнгатьле сөйләмнең торышын шул вакытларда иҗат иткән каләм осталарының әсәрләре теле ярдәмендә белеп була. Әлбәттә, телнең иҗатчысы - халык. Телнең бөтен энҗе-мәрҗәннәре халыкның күңел сәхифәләренә языла бара. Ләкин борынгы ата-бабаларыбызның күңел сәхифәләрен без укый алмыйбыз бит. Аларны сүз сәнгате осталарының каләмнәре аша кәгазьгә түгелгән тел гәүһәрләре ярдәме буенча гена билгели алабыз. Димәк, XIII йөздәге сүз сәнгатенең торышын күз алдына китерү өчен "Кыйссаи Йосыф" поэмасының теленә лингвистик анализ ясарга кирәк. Әмма аның сүзлек составы турында төрле, хәтта каршылыклы фикерләр яшәп килә. Немец профессоры Карл Броккельманның раславынча, "Кыйссаи Йосыф" борынгы госманлы төрекләрнең әсәре. Ә инде төрки телләрне өйрәнүче тел галиме Н. А. Баскаков аны борынгы госман теленә якын булган сәлҗүк теле истәлеге дип исәпли. Ә Нәҗип угыз-кыпчак телләре аралашкан урында язылуы турында әйтә. Ш. Мәрҗәни болгар язма истәлекләре дип карый. Б. Ягафәров Идел-Кама Болгар дәүләтендә язылуын раслый. Җ. Алмазов Болгар-татар истәлеге дип әйтә.

Бу карашларның барысында да дөреслек юк түгел. Броккельман әйткәнчә, анда борынгы госманлы төрекләрнең тел үзенчәлекләре дә Баскаков фикеренчә, сәлҗүк элементлары да бар. Ләкин соңгы карашлар чынбарлыкка күбрәк туры килә.

Билгеле ки, поэманың сүзлек составы шул чордагы сүзлек хәзинәсе белән генә чикләнә алмый. Чөнки аның борынгы төрки тел белән дә бәйләнеше бар. Шуңа күрә анда коюя (коега), үкеш (күп), дараюбән (таран), килүбән (килеп) кебек борынгы төрки сүзләрнең булуы табигый хәл. Ләкин күпчелеге – хәзерге гомумкулланыштагы сүзләр: йөз, кара үзе,

ата, юк, ярлы, һич, сүз, сату, богау, куен, кол һ.б.

Мәгълүм ки, бу чорда төрки телләргә гарәп-фарсы сүзләре ташкыны "һөҗүм итә". Хәтта төрки телләргә кимсетеп карау күренеше башлана. XI гасыр филологы М. Кашгарый төрки телләрдәге сүзләрне морфемаларга (Мәгънә кисәкләргә) бүлеп, аларның шактый үскән, алга киткән, гарәп теленнән ким, ярлы булмаган тел икәнлеген исбат итә. Кол Гали дә поэмада гарәп сүзләренең аңлашылмаганын кулланмаска тырышуы турында әйтә: "гарәп, гаҗәм делендә кылдым бәян; укымага, дыңламага улды асан".

Өч стиль теориясе безнең эрага чаклы яшәгән Аристотель тарафыннан өйрәнелә. Югары стильгә "ялтыравыклы" сүзләр кирә. Түбән стильне халык сөйләме тәшкил итә. Урта стиль шуларның икесен берләштерә. Мин биредә һич тә Кол Гали бу теорияләрне белгән дип әйтмим. Әмма лингвистик анализ ясау шагыйрьнең шул принцип белән эш итүен күрсәтә. Мәгънәне тирәнәйтү, образлылыкны көчәйтү, эмоциональлекне арттыру максатында ул борынгы төрки теленнән килгән формаларны мул куллана. Ә инде гарәп теленнән алган поэтизмнары (шәфкатьлелек, мөрәүвәтлек, сәгадәт һ.б.) - хәзерге әдәби тел өчен матур бизәкләр К. Гали түбән стильгә дә мәрәҗәгать итә. Халыкта, мәсәлән, әдәби телдәге "Үлчәп кара әле" диясе урынга "тартып кара әле" дип әйтү хәзер дә бар. "Кыйссаи Йосыф"та: "Тарттырдылар, Йосыф илә тиң кәлмәде". Яки үлчәгәч, алтын Йосыф авырлыгы була алмый. Аслан (һич тә), ою (йоклау), тәгам (ризык) һ.б. гади сөйләм лексикасы шагыйрьнең халык теленә зур игътибар итүен раслый.

Шагыйрь кулланган кыпчак теле сүзләре хәзерге вакытта аерым диалектларда яши. Халь, мәсәлән, татар теленең көнбатыш диалектында (мишәр диалектында) кулланыла. Кыйссаи Йосыфта; "Ушбу халь һич сәңа лаек дәгел". Поэмадагы гыл-гел (Бәян белгел: мән сәнәңвән, сән бенемсән) кушымчалары белән ясалган фигыльләр (баргыл, килгел, кайткыл) хәзерге вакытта кыргыз телендә актив кулланыла.

Поэманың сүзлек хәзинәсе гаҗәп бай. Анда тамыр сүзләр дә (мал, йөз, олы), ясалма булганнары да (каравыш, гөмансыз, эшләмәслек), кушма төрләре дә (унбер, һәргиз – һәрвакыт, үлдән – шулвакыт) бар. Парлы сүзләргә махсус тукталасы килә. Чөнки поэзиядә аларны куллану шагыйрьдән зур осталык таләп итә. Алар ярдәмендә аналитик фикерләрне синтезлап биреп була. Мал (терлек, акча, кулда булган нәрсәләр) һәм хәзинә (казна, дәүләт, байлык) - гарәп теленнән кергән сүзләр. Йосыфның бәясен күрсәтү максаты белән шагыйрь аларны парлаштыра "Бең дәва йөк, мал-хәзинә йөкләттерде". Гомумән алганда. Кол Гали парлы сүзләрнең гаять матур үрнәкләрен бирде: газиз-солтан, энҗе-мәрҗән, тузан-туфрак, мал-мөлкәт, миһырбанлы-шәфкатьле һ.б. Һәрберсенә тирән мәгънә салынган. Шагыйрь патшаны бер урында газиз, икенче урында

солтан дип атый. Өченче бер очракта ул аларны парлый: газиз-солтан: (“Баек, Мисыр газизе-солтан булыр”). Газиз-кадерле, хөрмәтле, кыйммәтле, изге дигән төшенчәләрне аңлата: “Бу игенне газиз белеп һәркем игәр” (М. Колый); патша, хәким мәгънәсендә дә кулланыла. Солтан исә патша, хөкемдар дигәнне аңлата. Кол Галинең патшаны газиз һәм солтан сүзләрен парлап куллануы аның сүзләрнең эчке мәгънәсенә нык игътибар итүен раслый.

Поэмадагы фонетик төрлелекләр дә күп нәрсә турында сөйли. Шагыйрь, мәсәлән, сүзнең борынгы формасы сүне дә куллана: “Хатыннар Зөләйханы гаепләп сүләмәки баянында”. Бу форма хәзерге вакытта Башкортстанда яшәгән татарлар телендә сакланып калган (әдәби телдә сөйләдем, Башкортстан татарлары телендә - сүләдем). Кол Галидә башка төрләре дә бар: “һәрбересе бер дөрле сүз сүзләр имди”.

Телче галимнәр хәзерге телдәге яхшы сүзенең тамыры як, яг, ях булу турында әйтәләр. “Кыйссаи Йосыф”та да аның яг формасы бар:

“Бидгать эштән бәңа зиндан ягдәк имди”. Мадъяр телендә дә яхшы төшенчәсен аңлату өчен аның я һәм як формасы кулланыла.

Мондый мисалларны күп китерергә мөмкин. “Кыйссаи Йосыф” поэмасының сүзлек хәзинәсен, фонетик төрлелекләрен тикшерү тел тарихының күп үзенчәлекләрен ачыклауга ярдәм итә. Төрле грамматик чараларның (мәсәлән, килеш кушымчаларынын) борынгы төрки телдән килгәннәре булу, шул чор өчен характерлы да табылу, хәзерге әдәби телдәгеләрнең барысы да кулланылу бүгенге әдәби телебезнең чишмә башы чыннан да шушы әсәрдән башлануга мисал булып тора. Кайбер сүзләр Болгар чорында һөнәрчелекнең шактый күп төрле булуын раслап торалар. Йолдызчы сүзе, мәсәлән, астрономия белән шөгыльләнгәнлекне аңлата. Шәмче, кылыччы, капчы, икмәкче, тегерменче, күнче, тегүче, кебек сүзләр дә илнең йөзен, халыкның тормыш-көнкүрешен, рәвешен теге яки бу дәрәҗәдә күз алдына китерергә ярдәм итә. Яки: арпа чәчү, арпа икмәге ашау, коры һәм яшел бодай сабаклары, ашлык амбарлары, арык һәм симез сыер, күзгә сөрмә бүләк итү кебек сүзтезмәләргә игътибар итегез.

Гарәп теленнән кабул ителеп, җәмгыять, дәүләт төзелеше, идарә эшләренә (гаилә, нәсел, кабилә, әмир, гавам, шаһит, хөкем, хаким), уку-укыту эшләренә (китап, каләм, мөгаллим, мөдәрис, мәдрәсә), фәнгә караган сүзләр (әдип, әдәбият, табигать), дини эчтәлекле сүзләр (аллаһ дин, иман, гыйбадәт, фарыз, сөннәт, хаҗ, корбан, җәннәт) татар теленең сүзлек хәзинәсендә хаклы урын алдылар.

Кол Гали мәгънәдәш сүзләр (синонимнар) белән эш итүнең дә матур үрнәкләрен күрсәтте. Матурлык төшенчәсе анда нәфис, зиннәтле, хуп җәмал, зифа, гүзәл, сылу, матур, күркәм, күрекле кебек сүзләр белән тәгъбир ителә.

Һәр милли телнең үзенә генә хас фразеологик әйтемнәре була. Алар тормыш-көнкүрешкә, яшәү хосусиятына, икьдисади-сәяси хәлләргә, мәдәнияткә һ.б. төшенчәләргә бәйле рәвештә барлыкка килә. Тел бизәкләренең алтын хәзинәсен тәшкил иткән ул берәмлекләр, теоретиклар теле белән әйтсәк, катып калган форма булып исәпләнәләр. Ләкин сүз сәнгате осталары, әгәр стиль, әсәрнең идея-эчтәлеге таләп итсә, аларны үзгәртәләр дә. Бу үзенчәлек "Кыйссаи Иосыф"та да бар. "Дәрт бар, дәрман юк" дигән фразеологик әйтелмәне, мәсәлән, "Татар теленең фразеологик сүзлеге" исемле хезмәтендә (1989, 238 б.) Н. Исәнбәт болай билгели: "Теләк, омтылыш бар, эшкә ашырырлык көч-куәт юк, хәл юк, чара юк димәктән әйтәм. Моннан мең еллап элек үк бездә таралган борынгы әйтемнәрдән". Без югарыда Кол Галинең халык иҗат иткән мәкаль-әйтемнәрне, төрле сурәтләү чараларын идея-эстетик максатка ничек үзгәртүен, эшкәртүен, үзенчә кулланууын күргән идек. "Катып калган" тел чараларын да шагыйрь "ватып-таркатып", поэзия тукымасына үзенчә яраклаштыра. Әлеге фразеологик әйтелмәне ул "Бу дәрдә һичбер дәрман белүмәзвән" дип ала.

"Катып калган" тел чараларын эшкәртүдә К. Галидән соң иҗат иткән Мөхәммәдьяр, У. Имәни, Г. Кандалый, Г. Тукай кебек шагыйрьләр зур осталык күрсәтте. Бер үк сүз белән ясалган фразеологик әйтелмәләрне төрле шагыйрь төрле стилистик максатында үзенчә куллана: Хәсрәт белән йөрәкне баглау (Кол Гали); йөрәк-бәгыръ кайнап пешү(М.. Колый); йөрәк мае сызып бетү (Г. Кандалый); йөрәк сызлау (Г. Тукай); йөрәк мае сузу (Ш. Бабич); йөрәк жанлану (Ф. Ибраһимов) һ.б.

Сүз сәнгате осталары әлеге бер-берсеннән аерым хәлдә яшәргә тиеш булмаган "катып калган" тезмәләрнең берәр компонентын алып ташларга, аның урынына башка сүз кулланырга да "күп сорамыйлар" – Мәсәлән: халыкта – күңел көзгесе, Г. Ибраһимовта – рух көзгесе, халыкта – диңгез кичү, Г. Ибраһимовта – кан дәрьясы кичү һ.б.

Мондый үзгәртүләр, билгеле, язучының эстетик идеалы, әдәби әсәрнең идея эчтәлеге һәм ул чагылдырган чор, стиль рухына бәйле күренеш. Әлбәттә, Н. Исәнбәт әйткәнчә, фразеологик әйтелмәләрнең барлыкка килүен мең еллар белән генә чикләү дөрес булмас иде. Алар мең-мең еллар тарихына, гасырлар төпкеленә, хәтта уй-хис җитмәс еллар мизгеленә алып китә безнең күңелләрне. Фразеологик әйтелмәләрне халык әле укый-яза белмәгәндә үзенең аң акылы, дөньяга карашы, йөрәк сызлануы, күңел тетрәнүе кушуы буенча иҗат иткән. Кол Галидәге нәфсем эстәр, гакылым кәлмәз, гакылы шашды, йөзе балкыды, шатлык ягъды, мөшкел хәлгә дөшде, каты гыйшык, һуш китү, акыл шашу, күңел ягъды, өстендә нур, хәтерне алу, йөз сулу, ант эчү, күз салу, хәйран булу, һ.б. шуның кебек фразеологик әйтелмәләр шагыйрьнең тел энҗеләренә мөкиббән булуын раслыйлар.

Бу мәкаләдә сүз сәнгатебезнең чишмә башы булган “Кыйссаи Йосыф” поэмасының хәзерге әдәби телгә мөнәсәбәтен теге яки бу күләмдә ачыкларга тырышылды. Сүзне борынгы Кәнган һәм Мисыр далаларында йөргән таңгы җил образыннан башлаган идек. Сүз азагындарак янә әйләнеп кайтасы килә. Дәрдмәнд илен ташлап, чит илгә китәргә уйлагач, менә нинди хисләр кичерә:

Тәгәрәп уйнап,
Буй үскән
Туган илем, исән бул!
Чәч тузгытып
Җай искән
Таңгы җилем, исән бул!
Йөгереп-йөгереп туктаган...
Яулык болгап сыктаган
Нәзкәйбиллем, исән бул!

“Сабах җиле”, “саба җиле” хәзер “таңгы җил”гә әверелде. Әмма ул кадерле җил! Дәрдмәндә ул Ватан төшенчәсе белән бәйле. Исә ул таң җилләре. Аны колач җәеп, хозурланып, борынгы ата-бабаларыбызның рухын, йөрәк тибешен, иманын алып килүче бөек, сихри, тылсымлы көч итеп каршыларга кирәк. “Кыйссаи Йосыф” поэмасының теле турында мәкаләләр язылмады түгел. Ул төрле хезмәтләрдә дә искә алына. Бу өлкәдә күренекле галим Н. Хисамов эшчәнлеге мактауга аеруча нык лаек. Шулай да “Кыйссаи Йосыф” поэмасының теле ныклап, тирән, фәнни, лингвистик анализ ясауга, зур күләмле хезмәт язуга мохтаж. Андагы фонетик төрлелекләр, морфологик чаралар, сүзлек хәзинәсе, мәкаль-әйтемнәр, фразеологик берәмлекләр, сурәтләү-тасвирлау бизәкләре... – барысы да борынгы төрки тел белән дә, хәзерге әдәби тел белән дә бәйләнешле. Аны борынгы төрки тел белән хәзерге әдәби телне чагыштыручы поэтик күпер дип тә атарга мөмкиндер. Бу – бер. Икенчедән, әгәр поэманы әдәби телебезнең чишмә башы дип йөртәбез икән, моны лингвистик планда ныклап раслап була. Өченчедән, поэманың теле шул чордагы кавемнәрнең теле ни дәрәҗәдә икәнлекне исбатларга да ярдәм итә. Поэманың теле бай, дибез. Ни өчен? Шагыйрь сүз сәнгате остасы булганга гынамы? Аның өчен генә түгел, билгеле. Шул чордагы ата-бабаларбызның теле ярлы булса, шагыйрь әсәрен мондый бай тел белән иҗат итә алмас иде. Бу бай тел ата-бабаларыбызның образлы фикер дәрәҗәсе шактый үскән, танып белү офыклары нык киңәйгән, уй-акыл хосусиятлары тирәнәйгән булуын тәсьдыйклап тора.

Телебезнең тамыры бик еракта. Чал тарих төпкелендә. Бу тамырга үткер балта белән дә, үтмәс балта белән дә чапканнар. Әмма өзеп чыгара алмаганнар. Әгәр Болгар чорына чаклы, әле язма әдәби тел барлыкка килгәнче үк халкыбыз поэтик гәүһәр булып балкырлык мең-мең мәкаль,

әйтем, фразеологик берәмлек, сузбизәгеч, башка тасвирлау-сурәтләү чаралары иҗат иткән икән, бу гасырда инде телебезнең тамырлары ныклап кәүсәләнгән, кәүсәләр ботак җибәреп, алар шау яфракка күмелгән дигән сүз.

Шулай итеп, әдәби телебезнең чишмә башын бу чор (XIII гасыр) белән генә чикләү чынбарлыкка туры килеп бетми. Аңа чаклы да язма әсәрләр булгандыр. Җил һәрвакыт сөеп-яратып, иркәләп-назлап, чәчләреннән, сыйпап кына исми бит. Җил вакыт-вакыт коточкыч усал көчкә әверелеп гаделсезлеккә каршы кискен көрәш ача, кеше ышанмастай әллә нинди күңелсезлекләр эшләп ташлый. Тарихның аяусыз җил-давыллары "Кыйссаи Йосыф"ка чаклы булган күп кенә әдәби әсәрләребезне упкыннар куенына яшереп куйганнар. Мәрхәмәтле-шәфкатьле сабах җилләре исеп, ул упкын куенын бервакыт актарыр, бәлки, тарих көзгесе, борынгы ерак ата-бабаларыбызның рухи дөньясы, иҗат җимеше булып исәпләнерлек әле без белмәгән әдәби әсәрләрне алдыбызга китереп салыр. Бик борынгы ата-бабаларыбыздан калган рухи мирасларыбыз күп. Аларның яңадан-яңаларын табып торсак иде.

Күңелләр нуры поэтикасы

Мөхәммәдьяр

Казан ханлыгы чорында яшәгән шагыйрь Мөхәммәдьярның фәнгә "Төхфәи мәрдән" ("Егетләр бүләге", 1539 ел), "Нуры содур" (Күңелләр нуры, 1542) исемле поэмалары мәгълүм. Хәзер "Нуры содур" поэмасының тел-стиль үзенчәлегенә тукталыйк.

Башта ук шуны әйтик: поэма тел-сурәтләү чараларына бик бай. Ул башыннан азагына кадәр диярлек, мәкаль-әйтемнәрдән тора. Шуңа күрә сүзне дә шул мәкаль-әйтемнәрдән, төрле канатлы юллар һәм афоризмнардан башлыйк.

Поэманың беренче бүлегендә гаделлек турында сүз бара. Автор гаделлекне һәркемнең җанында, канында, йөрәк тибешендә, сулышында булырга тиешле "иманы" дип саный. Бер сәгать гаделлекне ул алтмыш ел гыйбадәт кылудан артыграк күрә ("Бер сәгать гадел кылмак яхшырак, кем гыйбадәт алтмыш ел озаграк"). Аныңча, гаделлек белән җиһан төзек, нурлы, нык булыр. Яхшылык – яманлык, матурлык – ямьсезлек, акыллылык-акылсызлык һәм башка капма-каршылыклар – һәрвакыт юлдашлар. Гаделлек – гаделсезлек тә шулай. Шагыйрь моны тирән аңлап эш итә. Гаделлекнең бөеклеген ул антитеза алымнары белән аңлата. Шуның нәтиҗәсендә ул әсәрнең поэтик хисле, эмоциональ, образлы булуына, мәгънә, тирәнлегенә ирешә. Шагыйрь гаделлек, гаделсезлек төшенчәсен күңеленнән, йөрәгеннән үткәреп, ахыр чиктә ил язмышы белән бәйли:

Көфер берлә булмас харап,
Золым берлә екылыр үкеш йөдәп.
Көфер вә кяфир нәфсене кылыр зыян,
Золым берлә булыр ил хәле яман.

Халыкта: "Нәфес – иргә, золым – илгә зыян", – дигән мәкаль бар. Димәк, ир кеше нәфесле булу аркасында ир-егетлек сыйфатына, кешелеклелек дәрәҗәсенә, үзенең хосусиятына зыян китерә. Ә Инде золымга әйләнсә, халкына, ил йөзенә кара яга. Золымлыкны шагыйрь әнә шул мәгънәдә аңлый. Көфер һәм кяфир яшәүдән мәмләкәт (ил) харап булмый, ә золым ил хәлен яманга әйләндерә.

"Ил – ир иңендә, ир – ил иңендә", "Гадел булса гам, ил йөзендә дан" дигән мәкальләрнең эчтәлегенә дә берникадәр туры килә ул юллар. Биредәге "гам" сүзе "кара халык" дигән төшенчәне аңлата.

Мөхәммәдьяр сүзнең эчке сыйфатына, мәгънәсенә, эмоциональ көченә, телнең бөеклегенә, җәмгыятьтә тоткан урынына, аралашу, фикер алышу коралы булуына зур игътибар итә. Әнә шундый фикерләрне ул канатлы юллар, мәкаль-әйтем, афоризмнар кысасына салып бирә:

Кем ирерсән безгә и тел, сән олуг,
Сән төзәнсәң, без төзәнербез камуг.
Игре булсаң сән төзәлмәздип, и тел,
Барчамыз игре булырмыз, аны бел.

Ипине "ипикәй" дигән кебек, шагыйрь сүзгә карата да иркәләү формасы (сүзкәй) куллана: "Ничәләр сүзләмәен сүзкәйне – киттеләр, үзләгәнне күрә белмәй тән тишеп кан эчтеләр".

Халыкта "Оста барда телеңне тый", "Сөйдергән дә тел, көйдергән дә тел", "Теле яманның көне яман", "Телең озын булса, ут ала" кебек мәкальләр бар. Болар барысы да кешене уйлап сөйләргә, әдәпле, инсафлы булу кирәклеген искәртәләр. Әйтик, оста барда телеңне тыймасаң, оятка калырсың, сөйләмең үзеңне сөйдерерлек булмаса көярсең; яман булуы тормышны, яшәешне яман итә; телеңне озайтсаң, бик кыен хәлдә калуың ихтимал һ.б.

Ул төшенчәләрне Мөхәммәдьяр чагыштыру-охшатуга корылган мәкаль-әйтемнәр аша бирә.

Очар ирде нагәһан бер анча каз,
Хуш һава йөзендә кылдылар аваз.
Каләсе (тәрбиячесе) салды карчыгасын
Казны тотты карчыгасы, и җәван...
Һәркем тотды телне – котылды ул,
Телне тотмаган уш тотылды ул...
Тотса ирде телне сахрада каз, –
Тотмас ирде ул дәм эчрә аны баз (карчыга). Сахрадагы каз, телен тотса (тыйса, ягъни кычкырмаса), котылыр иде, карчыгага эләкмәс иде;

шуның кебек, телен тыймаган кеше дә бәлага юлыга, һәлакәткә очрый. “Тартай теленнән таба”, “Йөгәнсез сүз сазга батыра” кебек мәкальләрдә дә шул фикер чагыла.

Әдип үзенең поэмасында “Сабырлык – сары алтын”, “Сабыр иткән – морадына житкән” кебек мәкальләрне куллана:

Сабыр бабын кылаем сезгә бәян.
Сабыр итеңез барча эшдә һәр заман.
Сабыр кылмак иргә ирер хуш һөнәр,
Сабыр кылган кешене тәнре үгәр (мактар).

Мөхәммәдьяр халык телендәге мәкальләрне әзер килеш тә, үзгәртеп тә куллана, стиль таләп итсә, поэтик фикерләүнең рухына карап, үзе дә мәкаль-әйтем, канатлы тәгъбирләр, афоризмнар ижат итә.

Мәкаль-әйтемне мул куллану җиңел түгел. Образлылыкка, мәгьнә тирәнлегенә ирешү алымы буларак, ул әсәрнең идея-эстетик юнәлешенә, шагыйрьнең поэтик фикерләү һәм аң даирәсенә, объектив чынбарлыкны тасвирлау осталыгына бәйле. Югарыда телгә алынган гаделлек, яхшылык, кешелеклелек, изгелеклелек идеяләрен Мөхәммәдьяр халкының үз тормышы, яшәеше, көнкүреше, рухи дөньясына бәйле рәвештә туган мәкаль-әйтемнәре аша чагылдыра.

Әгәр әзер мәкаль шагыйрьнең эстетик идеалына ярашмаса, аны ул үзгәртә яки мәгънәсе саклаган хәлдә, эчтәлеген бөтенләй башка сүзләр белән бирә. “Нуры содур”да - яхшылык, гаделлек, намуслылык идеяләре гел мәкаль-әйтемнәр аша чагылдырыла.

Поэмада фразеологик әйтелмәләр дә күп: мөбәрәк булсын, эшләр хуш булу, илгә гаделлек кылу, гаделлекгән күп мал хуш килү, ахирәттә хуш кылу, гаеп итү, мәсхәрә кылу, йөз карау, телдән чыккан башка килү, һава йөзендә аваз кылу һ.б. алар да гаделлек, намуслы булу идеяләрен чагылдыруга ярдәм итә:

Гадел берлә ил гыймарәт уш,
Барча эшләр булыр аның берлә хуш.
Гадел булыр барча эш башы – белең,
Гадел берлә димә бәс эш кылың.

Китерелгән өзекнең һәр юлында фразеологик әйтелмә бар: гадел берлә ил гыймарәт булу, эшләр хуш булу, гадел эшнең башы гадел булу, гадел белән даими – эш кылу. Боларның һәммәсе дә, мәгънәви яктан үзара органик мөнәсәбәткә кереп, шагыйрьнең эстетик концепциясенә буйсыналар “Яхшылык иккән саулык урыр”, “Яхшылык белән җиңәрсең, көч белән булмас”, “Яхшылык ит тә диңгезгә ташла, балык белер, балык белмәсә, халык белер” һ.б. мәкальләр белән аваздаш. Мөхәммәдьяр: “Эшнең башы – гаделлек”, – ди. (Хәзер исә: “Эшнең башы – идея”, – диләр.

Шунысы әһәмиятле, Мөхәммәдъяр әсәрләрендәге фразеологик

әйтелмәләрнең күбесе киң кулланылышка кереп киткән. Аларны без М. Колый, Г. Кандалый, Г. Тукай кебек шагыйрьләр иҗатында да очратабыз.

Метафоралар, башлыча, хис-тойгы, эчке кичереш, ягъни күңел дөньясы, ә чагыштырулар исә күбесенчә акыл, фикер эшчәнлеге белән бәйле. Хис-тойгы, эчке кичерешләрне чагылдыру чарасы булган метафоралар, нигездә, матур яңгырашлы сүзләр, поэтизмнар ярдәмендә ясала. "Нуры содур"да да ул шулай. Мәсәлән:

И сәхвавәт мәгъдәненең җәүһәре,
И сәгадәт диңгезенең гәүһәре,
Уш сәхават бабаны кылып бәян,
Көч йитәрчә кыл аем барча гаян.

Тыңлагыз имди сәхавәт сүзләрен, Таки күргәнсез сәгадәт йөзләрен. Кем сәхавәт берлә булыр ир сәгыйд, Ул сәхавәт даимә булыр мәзид (арту).

Биредәге сәхавәт (юмартлык) мәгъдәненең (чыганагының) җәүһәре, сәгадәт (бәхет) диңгезенең гәүһәре кебек тезмәләр –метафоралар. Юмартлык чыганагының җәүһәрләре, бәхет диңгезенең гәүһәрләре дигән метафораларның эчке мәгънәсе гаделлек, намуслылык, яхшылык турындагы мәкаль-әйтемнәрнеке белән тыгыз мөнәсәбәттә тора. Юмартлык һәм гаделлек идеяләре бер-берсеннән аерылгысыз төшенчәләр. Шагыйрь юмартлык чыганагында – җәүһәр, ә бәхет диңгезендә гәүһәр күрә. "Юмартлык сүзләрендә сәгадәт йөзләре бар", – ди. Бу метафоралар аша шагыйрь кешенең күңел дөньясына, эчке хисләренә, йөрәк тибешенә анализ ясый. "Барча гаепләрне сәхавәт (юмартлык) ябар" дигән юллардан без әнә шуны аңлыйбыз. Гомумән, метафоралар аша шагыйрь кешенең күркәм сыйфатларын, күңелендәге матур хис-тойгыларын күрсәтә. Шунысы характерлы, аның метафоралары аз сүз белән күп мәгънә аңлатуга, җанлы картина тудыруга, тирән идеяләрне образлы тасвирлауга ярдәм итә. Мәсәлән:

И хәл (оят) багының ул таза гөле,
Хәзрәтенең ("сезнең" дигән мәгънәдә)
Ирер мәнзиле (урыны)!
Ишетәнез уш хәя бабы сүзен:
Ир хәя берлә күрер дәүләт йөзен.

Мәкаль-әйтемнәрдәге кебек, метафораларда да шагыйрь антитеза алымыннан файдалана. Мәсәлән, ул намуслыкны оят бакчасы дип атый. Аны намуссызлыкка каршы куя. Оят бакчасының таза гөле дигән метафорада кеше күңелендәге саф тойгы, матур хыял кебек күркәм сыйфатлар чагылдырыла. Автор раславынча, оят бакчасының таза гөле – бәхет урыны да ул. Икенче төрле әйтсәк, оятлылык, намуслы кешелеклелек бәхет китерә, шуның белән кеше дәүләт йөзен күрә. Шул рәвешчә, оятлылык төшенчәсен шагыйрь ил язмышы белән бәйли.

Оятсызлык исә кешене түбәнлеккә төшерә.

Поэманың лексик составы да бай гына. Анда поэтизмнар (шәфкать, җәүһәр, сәгадәт, гәүһәр, зәгъфран, җәннәт), гади сөйләм сүзләре (мәгъмур – төзек, асан, билә – белән), борынгы төрки теленнән үк килгән сүзләр (бөтидәм – яздым, үкеш – күп), гарәп-фарсы алынмалары (солтан, шаһ, вәзир), гомумкулланылыштагы сүзләр (иртә, кич, тел һ.б.) дә бар. Аларны шагыйрь әсәрнең билгеле бер мәгънәне ачыклау яки стилистик максатта куллана. "Солтан" сүзе халыкта мәртәбәлелек, уңганлык, егетлекне аңлата. Мәсәлән: "Ул бит егетләр солтаны". Мөхәммәдьярда газиз сүзе шөһрәтле, көчле, егәрле, ә солтан, мәлик дигән сүзләр патша мәгънәсендә кулланыла. (Бер солтан — бер патша). Борынгы язмаларда газиз, солтан, мәлик кебек сүзләр халыкның патшага булган җылы хис-тойгыларын, зур ышанычын, олылавын белдергән. Ләкин алар дә илнең кадерлеләрәге, намуслылык, акыллы эш итү кебек төшенчәләргә бәйләнгән.

Биредә шуны да әйтик: "Нуры содур"дагы күп кенә сүзләр хәзер кеше исеменә әйләнеп китте: Гаян (ачык), Мәлик (патша), Нияз (үтенеч, теләк), Гани (бай), Садыйк (тугры кеше), Мөбәрәк (бәхетле), Мәгъдән (чыганак), Сәгадәт (бәхет), Мөгътәбәр (хөрмәтле), Вафа (сүздә тору), Газиз (кадерле).

Халык җырларында зәгъфран сүзе еш кулланыла. "Нуры содур"да ул сары төс мәгънәсен аңлата: "Ул җәзирә (атау) утлары зәгъфран иде, Күреклүгендә җәннәт-ризван (оҗмах) иде".

Поэмада хәзерге вакытта диалектизмга әйләнгән сүзләр дә (мәсәлән, алчак) очрый. (Башкорт әдәби телендә исә ул актив лексик берәмлек. Мәсәлән: алчак кеше — якты йөзле кеше). Шундый сүзләрнең Башкортстанда яшәүче татарлар телендә сакланып калганнары да бар. Шуңа мисал итеп, худ, худди сүзен күрсәтергә була: худди әйтисе — нәкъ әтисе дигән мәгънәдә йөри. Мөхәммәдьярда: Адәми худ - кеше үзе һ.б.

Сүзлек составы, төзелеше, структурасы ягыннан да поэманың теле хәзерге әдәби телгә якын тора. Анда тамыр (бер, бу, бар), ясалма (намәдар, атакы, көчек, барча), кушма (һәрбер, һәркем), парлы (иртә-кич, мал-туар, алтын-көмеш, рәхим-шәфкать, кечек-олуг, кичә-көндез, язын-кышын, михнәт-камуг, әл-азак (кул-аяк), җәннәт-ризван һ.б. ш.), тезмә сүзләр (бәян итү, сүз үтәү, гадел кылу һ.б.) кулланылган.

Монда парлы сүзләр аеруча игътибарга лаек. Рәхим-шәфкать — икесе дә гарәп теленнән кергән сүзләр. Рәхим аяучан, кеше өчен ачынучан дигән мәгънәләр белдерә, шәфкать сүзе исә аяу, мәрхәмәт итү дигәнне аңлата. Димәк, мәгънәләре бер-берсенә бик якын. Ләкин аларның да мәгънә аермалары бар. Мәсәлән, без "Шәфкать итегез" дип түгел, "Рәхим итегез" дип сөйләшәбез. Әгәр "шәфкать итегез" дисәк, ягымлылык күрсәтү түгел, бәлки кешенең үзеннән яхшылык өмет итү булып

аңлашылыр иде. Аларны парлап куллану (рәхим-шәфкать) мәгънәне көчәйтә, хис-тойгыны, эмоциональлекне арттыра:

Рәхим-шәфкать кылгучы гамәлгә хуш,
Лотфыңыздан (шәфкатьегездән) тотар өмет барча уш.
Ярлы илгә рәхим-шәфкать кылгыйсыз, —
Тәңредин аңларга рәхим булгансыз.

Күренә ки, мондый сүзләр дә үзләренең эчке мәгънәләре белән мәкаль-әйтемнәр һәм метафоралардагы гаделлек, юмартлык төшенчәләренә туры килә. (Чөнки гаделлек, юмартлык-рәхимлелек-шәфкатьлелек төшенчәләренә якын тора). Ахыр чиктә шагыйрьнең әлеге чаралар ярдәмендә әйтергә теләгәне шул: ил язмышы халык язмышы белән бәйләнгән, ярлы илгә рәхим-шәфкать кирәк.

Йомгаклап шуны әйтергә мөмкин, Мөхәммәдьяр поэмаларының теленә шулай анализ ясау шагыйрьнең сәнгатьле сөйләм чаралары белән ничек эш итүен, халык мәкаль-әйтемнәреннән, фразеологик әйтелмәләрдән ничек файдалануын, аның эстетик идеалын, чынбарлыкны чагылдыру үзенчәлеген ачыкларга, укучыларда гаделлек, инсафлылык, намуслылык, юмартлык, кешелеклелек, туган телгә мәхәббәт тәрбияләргә ярдәм итә. Күңел нуры анда поэтик чара сыйфатында кулланыла.

Каләмнән түгелгән җәүһәрләр

Утыз Имәни

Утыз Имәни "Бурыч — дуслыкны кисү кайчысы" исемле поэмасында: "Күп җәүһәрләр түгелде бу каләмнән", — ди. Бирелә сүз поэтик җәүһәрләр турында бара. Ерак гасыр, чал тарих, ата-баба моңын шагыйрь поэтик эшкәртеп, халыкның үзенә бүләк итә. Мөхәммәдьяр, Мәүлә Колый кебек шагыйрьләрдән соң иҗат иткән Утыз Имәни поэтик телне тагын бер баскычка югары күтәрә.

Ул татар милли әдәби теле формалашып килгән чорда иҗат итә. Әдәбият тарихына ул иске төрки тел белән яңа татар әдәби теле арасына поэтик күпер салучы буларак кереп калды. Г. Кандалый, Г. Тукай кебек мәшһүр шагыйрьләр, башка сүз сәнгате осталары бу күперне ныгытучылар булды.

Утыз Имәни – зур фикер иясе. Ул, әдәби иҗаттан тыш, тел, философия, хокук, экономика, медицина, астрономия фәннәре белән дә шөгыльләнгән. Гыйлемне, поэтик фикерләүне, мәълүматны ул олы акыллы затлардан алуы хакында әйтә:

Аларның яннарында тыңлап утырдым.
Тирән диңгезгә чумып, энҗеләр алдым;
Гамәл кылу өчен күңелемәш салдым,
Мәгариф бакчасыннан җимешләр җыйдым.

Утыз Имәни мәгърифәтне тел-фикер һәм аны мәгариф бакчасында җимеш итеп үстерүен искәртеп үтә. Әмма акыл иярәренең поэтик фикерләве нәтиҗәсендә барлыкка килгән тел җәүһәрләре (сүз-энҗеләр, мәкаль-әйтем, төрле гыйбарәләр, фразеологик әйтелмә, тасвирлау чаралары) шигырь тукымасына эзер килеш кенә килеп керми. Аларның кулланылышы әсәрнең идея-эчтәлегенә, чорга, шагыйрьнең эстетик идеалына, үзе яшәгән вакыттагы халыкның тормыш-көнкүрешенә, эчке дөньясына, рухи халәтенә бәйле. Утыз Имәни поэтик фразеологияне эшкәртүдә аеруча зур осталык күрсәтә. Халык телендә йөри торган "гаеп итмә", "ләгънәт укыма" кебек тәгъбирләрне ул үзенчә куллана. Мәсәлән; "Бәлки мәрхәмәтең белән гаебемә пәрдә яп, Каһәр һәм ләгънәт уты белән рухымны көйдермә", — ди.

Образлылыкны, сәнгатьлелекне арттыру, мәгънәне көчәйтү максатында шагыйрь халыкның традицион фразеологик әйтелмәләренә яңа сүзләр өсти: "гөнаһка бату"ны — гөнаһ диңгезенә бату, "Хәйлә кору"ны — хәйлә җәтмәсе кору, "колакка туку"ны —колакка сер якуты туку, "тел тешләтү"не — телгә тик тору мөһере салу, "хәйлә кору"ны — хәйлә чокырына төшү, "нәфесне җиңү"не — нәфес караңгылыгын җиңү формасында кулланып, аларның эстетик-экспрессив көчен, мәгънәсен, эмоциональлеген тирәнәйтүгә ирешә. Шагыйрь урыны белән традицион фразеологик әйтелмәләрне дә куллана.

Утыз Имәни турында профессор М. Госманов болай ди: "Озын гомеренең ике өлеше ике гасырга бер дәрәҗәдә диярлек тигез килгән әдип иҗаты тарихыбыздагы ике чорның каршылыклы сыйфатларын, үзенчәлекләрен берьюлы чагылдыра, хәтта аларны чишелмәслек төен рәвешендә бергә укмаштырып бирә. Шул ягы белән ул әлеге ике чор арасындагы күперне, ягъни рухи дөньябызның искедән яңага, торгынлыктан хәрәкәткә, аңнарда хөкем сөргән динилектән дөньявилыкка күчү процессындагы бер этапны тәшкил итә". Шагыйрь үзе иҗат иткән гыйбарәләр, канатлы тәгъбирләр, афоризмнар да шул чорның каршылыклы сыйфатларын чагылдыра. "Шәехләр юлында йөрү". "Мәгърифәт чәчәгенең исен иснәү", "Нәфес караңгылыгын җиңү", "Суфичылык баскычларын үтү" дигән гыйбарәләрне ул үзе иҗат иткән. Шушыларның бөтенесен ул "төш күрү", "акыл җую", "дәгъва итү" дигән әйтелмәләр белән алыштырып бирә.

Ул шәехләр юлында һич йөрмәгән,
Мәгърифәт чәчәгенең исен иснәмәгән,
Нәфес караңгылыгын җиңмәгән,
Суфилык баскычларының берсен дә үтмәгән.
Төштә бер әйбер күреп, ул акылын җуяр,
Батырланып, шәехлек дәгъва итәр.

Болар шул чордагы тормыш каршылыкларын чагылдыруга, аларга

бәя бирүгә хезмәт итәләр. Утыз Имәни мәгърифәтчелек идеяләрен алга сөргән. Аның “Мәгърифәт чәчәгенең исен иснәү” дигән гыйбарәсе шуңа бәйле. Шагыйрь кешелеклелек сыйфатларын, әдәплелекне, гаделлекне яклый, үз мәнфәгатен генә кайгыртучы тар карашлы, түбән җанлы, надан, мескен бәндәләрне тәнкыйть итә. Нәфес караңгылыгын җиңәргә өндәве әнә шуларга юнәлгән. “фәлсәфә мәсләгенә йөз тоту”, “гыйлем белән чүлне бакчага әйләндерү”, “сафлык иясеннән аерылу”, “караңгы кабергә нур иңдерү”, “кешедән ядкарь даласында буш калу” “дөнья ишеген бикләп кую”, “гыйлем әһеле сурәтенә керү”, “фәлсәфә гыйлеме белән гомер итү” кебек гыйбарәләр дә аның үзенеке. Алар да әлеге “мәгърифәт чәчәгенең исен иснәү”, “нәфес караңгылыгын җиңү” дигән әйтелмәләрнең эчке мәгънәсе белән тыгыз мөнәсәбәттә торалар. Утыз Имәни иҗатында без “наданлык уты көйрәтү”, “билгә тынычлык путасы бәйләү”, “күнел пәрдәсе ачылу”, “әшнәлек җебе өзелү”, “сабырлык биналарын җимерү”, “коры дәгъва белән кайнау”, “хөрмәт диңгезеннән тамчы йоту”, “чыдамлык касәсеннән ачы су эчү”, “логика һәм хикмәттә бәхәсләшү”, “җәннәт нуры югалту”, “комсызлык икмәге белән карын туймау” кебек гыйбарәләр дә очратабыз. Алар шагыйрьнең идея-эстетик зәвыгы, дөньяга карашы, танып белү даирәсенең гаять киң булуын күрсәтәләр.

Шагыйрь мәкаль-әйтемнәргә дә еш мөрәҗәгать иткән. Ләкин ул аларны әзер килеш кулланмый диярлек: халыктагыны я үзгәртә, я үзе яңаны иҗат итә. Монда да ул чорның каршылыкларын, халыкның эстетик зәвык дәрәҗәсен, аң даирәсен искә ала. Мәкаль-әйтемне эшкәртү Кол Галидән ук килә. Халыктагы “сабырлык-сары алтын”, “сабыр иткән морадына җиткән” кебек мәкальләр нигезендә Кол Гали бөтен бер строфа төзи:

Сабыр берлә эшләтел ушбу эши.
Сабыр берлә эшләнер эшләр башы,
Морадына тиз йитәр сабырлы кеше, —
Бу эш эчрә күрекле сабыр кылгыл имди.

Сабырлык мәсьәләсен Кол Гали Йосыф һәм Зөләйха мәхәббәтенә бәйләп бирсә, Мәүлә Колый исә аны табигать законнары җирлегенә күчерә:

Сабыр берлә гөлләр ачылыр, китәр кышлар,
Йомыркадан чыкар, күккә очар кошлар;
Сабыр берлә гәүһәр булыр энҗе ташлар,
Сабырсыздан кайнаю бән пешсә булмас.

Бу мәкаль Утыз Имәнидә дә очрый. Аны ул төрле вариантларда куллана. Бер урында ул — шатлык чыганагы: “Әйттеләр: “Сабырлык — шатлык ачкычы ул!”; икенчесендә — халык шәфкатье: “Хактан башка берәү сиңа шәфкать күрсәтмәс, сабыр итә алмый күп вакытлар

җәфаланырсыз"; өченчесендә — камиллек яулау төшенчәсе: "Сабыр иткән кеше камиллек табар" һ.б. Күренә ки, "Сабыр иткән морадына житкән" дигән халык мәкаленең эчтәлеген төрле шагыйрь төрле стилистик максатта файдаланган. Утыз Имәнидә аның идея-эстетик функциясе шактый киң. Биредә "сабырлык" төшенчәсе шул чордагы шәхесне әдәпле, мәдәни, камил, авырлыкларны җиңәргә ярдәм итә торган илаһи бөек көчкә әверелә. "Камиллек табар" дигәндә исә шәхеснең төрле яклап формалашуына басым ясала. Аныңча, шәхес белемле, күркәм холыклы матур күңелле, юмарт, физик һәм рухи яктан нык булсын, иленә халкына, дөреслеккә хыянәт итмәсен.

Утыз Имәни яктылыкка, матурлыкка, сафлыкка омтыла һәм башкаларны да шуңа өнди. Матурлыкны ул гөлләр, кояш нурлары, энҗе, гәүһәр, мәрмәр, якут ташларына тиңли. Шуны аңламый торган бәндәләрне тирес корты, ярканат, ишәк дип атый: "Тирес корты гөл суының исен яратмас"; "Ярканат кояш нурын сөймәс"; "Атлас кисә дә, ишәк ишәк булып кала"; "Ишәк сәйлән белән уралып бизәнсә дә, кеше аңа энҗе итеп карамас".

Капма-каршы идеяләрне чагылдырганда, шагыйрь антитеза формасы куллана: "Гыйлем нур ул, күңелләрне нурландыра, Наданлык — ут ул, күңелләрне яндыра".

Утыз Имәни сүзне үлчәп, матурлыкның кодрәтен белеп эш итә. Матурлыкка, сафлыкка, әдәплелеккә, белемгә өндәгәндә ул кешене "олы жан", "саф энҗе", "сафлык иясе", "гәүһәр кеше", "кыйммәтле Кеше", "күңеленә нур иңгән ир", "һөнәр иясе", "камиллек иясе" дип атаган. "Әһел" сүзе белән генә дә күп кенә сүзтезмәләр ясаган: суфилык әһеле, дәрт әһеле, хакыйкать әһеле, дәрәҗә әһеле, сөннәт әһеле һ.б.

Мәгънәне, хис-тойгыны, эмоциональлекне арттыру өчен, шагыйрь сүзләрне парлап та куллана. Халыкның "колак белән тыңла" дигән тәгъбирен Утыз имәни исә "җан-колак белән тыңла", ди.

Поэзиядә тирән мәгънәле парлы сүзләр куллану Мәүлә Колыйдан ук килә: гыйззәт-хөрмәт. Утыз Имәнидә дә андый сүзләр күп. Мәсәлән: үгет-нәсыйхәт бакчасы, шәригать-сөннәт кагыйдәләре, дау-иңрәү авазы, җәбер-җәфа чигү, максат-мәгънә аңлау, ярдәм-шәфкать итү, гафу-рәхәт насыйп булу, җәбер-мәшәкать йөкләү, түрә калдык-постыгы, золым-афәт тарату, наданлык тузан-пычрагы, нәфес-шайтан эзе, нәфес-җүләрне тыю, хур-зар булу һ.б. Боларның мәгънәсе әсәрдә, поэтик тукыма эчендә генә аңлашыла. "Үгет-нәсыйхәт" дигәндә шагыйрь кешеләр күңеленә якты нур, рух, ләззәт бирә торган үгет-нәсыйхәтне күздә тота һәм аңа бакча сүзен өстәп, аның мәгънәсен көчәйтә. Шулай итеп, шагыйрь яктылык бакчасына керергә өнди. Бу нурлы бакча матур, зур, саф тормышны символлаштыра.

Сүз мәгънәсенә карата шагыйрь гаять таләпчән. Ул болай ди: "Һәр

сүзнең асылы бар һәм вакыты бар. Аңлап сөйлә сүзеңне; и дус кеше! Сүз угын син төбәмичә атма. Атсаң, туры ат, читкә җибәрмә, Диңгезнең иң тирән җиренә чумарга кирәк, Мәгънә энҗеләрен күңеленә тутырырга кирәк, Мәгънә энҗеләрен белеп эш ит, энҗене таш мәрҗән дип ялгышма".

Утыз Имәни иҗатында мондый образлы тәгъбирләр, метафора, эпитет, чагыштырулар бик күп.Аларны санап чыгу да мөмкин түгел. Чыннан да, җәүһәр чәчкән Утыз Имәни каләме!

Чишмә башы — моң башы

С. Юлаев

Чишмә! Бу сүзнең эчке мәгънәсенә поэтик энҗе, табигать гәүһәре, матурлык мәрҗәне салынган. Шуңа күрә халык: "Чишмә башы — моң башы" — дип әйтәдер. Аңа бәйле рәвештә иҗат ителгән лирик җыр, поэтик бизәк, гыйбарә (афоризм), сурәтләү-тасвирлау чарасы санап беткесез. Чишмә элек-электән яшьләрне кавыштыру, вәгъдә бирешү, мәхәббәт хисләрен уртаклашу урыны булган. Чишмә суы — кеше тәненә — матурлык, байлык-муллык, рухи хаҗәтлелек символы да.

Чишмә — ага-ага инеш һәм елгага әверелә. Елга исә диңгезгә коя. Димәк, бәләкәй генә чишмә ифрат киң дөньяга сәяхәт итә. Поэзия дә шулай. Тау күкрәген бәреп чыккан чишмә кебек, шагыйрь йөрәгеннән ургылып чыккан поэтик моң мең-миллионнар күңеленә рухи илаһилык, җан азыгы, яшәү кодрәте ялкыны булып ята.

Башкорт поэзиясенең чишмә башы шактый еракта — гасырлар төпкеллегендә: халык җыры гәүһәрләрендә, кобаерларда, "Урал батыр" дастанында һ.б. Салават Юлаев ул гәүһәрләргә яңа энҗе бөртекләре сала, поэтик офыкларны бермә-бер киңәйтеп җибәрә, халык телең сәнгатьчә эшкәртүдә шактый зур маһирлык күрсәтә. Бәләкәй генә гөлләмә бәйләмендә дә зур поэтик көчкә ия булган канатлы юллар, мәкаль-әйтемнәр җанлы картина тудыру, образлылыкка ирешүгә ярдәм итә. Алар туган ил, халык язмышы, шагыйрьнең эстетик идеалы белән бәйле. "Бугәчәүгә кушылып, ир-батырга куш булып" дигән шигырендә ул халыктагы "Батырмын, дип, кем әйтми, — яу килгәндә юне юк..." дигән батырлык һәм куркаклык төшенчәләрен тәгъбир итү өчен куллана.

"Ил намусы — ир муенында", — дигән борынгы ата-бабайлар. Халык гомер-бакый үз улларының ил мәнфәгате, Ватан язмышы белән яшәп, батыр йөрәкле, күркәм сыйфатлы булуын, авыр мәлләрдә куркып-каушап калмавын теләгән. Салават Юлаев исә батырлык өлгесен кылычы белән дә, каләме ярдәмендә дә күрсәтте. Бик күп көрәшләрдә дан казанган башкорт халкы батырлыгының йөзек кашы булган шагыйрь Салават Юлаев килгәндә әнисенең итәк астында яшеренеп калган куркак җанлы

тилеләр өчен дә әченә. Бу – табигый хәл. Батыр йөрәкле ир-егетләр ил язмышы өчен соңгы тамчы каннары тамганчы көрәшергә әзер торсалар, андыйларны гомер буе данласалар, алар шул югарылыкта тормаучы куркаклар өчен сызланып яшиләр. Ә бит тыныч тормышта үч алып батыр дәрәҗәсендә торучылар дөнья тулы. Яу килгәндә алар кыя таш артына яшеренә. Мондыйлар 1773-1775 елгы крестьяннар күтәрелеше, 1812 елгы Ватан сугышы, 1941-1945 Бөек Ватан сугышы, чорында да булды. Салават Юлаевның: “Батырмын, дип, кем әйтми, — Яу килгәндә юне юк...” — дип әйтүе, шулай итеп, туган илне, күз карасыдай газиз җирне, ата-бабалар әманәт итеп калдырган туфракны саклау барлык халык эше булырга тиешлекне искәртә.

Билгеле, бу әйтем халык телендә Салават Юлаевка чаклы да кулланылган. Әмма ил язмышын иман итеп яшәгән каһарман шагыйрь аны үз чорының сулышын тирәнрәк ачыклау җәһәтеннән файдалана. Ул бүгенге көндә дә бик урынлы яңгырый.

Халык теле гәүһәрләрен иренмичә, җентекләп җыю белән һәр шагыйрь шөгыльләнә. Бу — җитди һәм мөһим эш. Ләкин һәрвакыт иҗат иткән мәкаль-әйтем, поэтик бизәк, төрле тасвир чараларың әзер килеш, үзгәртмичә куллану нәтиҗәсендә бер генә шагыйрь дә сүз сәнгате остасы булу дәрәҗәсенә күтәрелә алмаган. Салават Юлаев бу хакта, бәлки, уйланмагандыр да. Шигъри талант, поэтик тукыманы үзенчә “чигүләргә” тырышу, сүзгә артык таләпчән булу, әсәрнең идея-эчтәлеге, сәнгатьлелек дәрәҗәсе халыктагыны үзгәртеп алуны таләп иткәннәр. Шагыйрь вакыт-вакыт строфаны мәкаль-әйтемнәр белән төзи:

Күк лачынының баласы
Бауда үлә талпынып,
Яхшы атаның баласы
Шәһит үлә яу йөреп.
Карчыга үтмәс урманнан
Лачын үтә таң белән.
Михнәт белән көн күргәнче,
Яуда үлик дан белән!

Халыкта “Батырлык яуда беленер”, “Егет үзе өчен туар, иле өчен үләр”, “Батырның үзе үлсә дә, даны үлми” кебек мәкаль-әйтемнәр бар. Салават Юлаевның бу строфасында канатлы юллары (афоризмнары) әнә шуларга тап килә. Шагыйрь, әсәрнең идея-эчтәлеге һәм стиле таләп иткәнчә, аларны үзгәртеп кенә калмый, ә бәлки яңа поэтик бизәкләр өстәп, тәңгәл килә торган мәгънәләр белән куертып, шигъри хис-тойгыны күпкә арттырып җибәрә.

Яу йөреп шәһит үлү бик борынгыдан килә. Ул — ата-бабалар эше. Бу сыйфат киләчәк буын ир-егетләргә мирас итеп калдырыла. Моны язмышы өчен янып яшәгән яхшы ата балалары эшли. Шуның кебек, авыр

хәлгә дучар булса, күк лачынның баласы да, дошманына бирелмичә бауда талпынып үлә.

Лачын — халык телендә батырлык символы. Шуңа күрә курку белмәс йөрәкле кешеләрне лачын белән чагыштыралар. Монда яу йөреп уңган яхшы ата баласының бауда талпынып үлгән лачын баласына охшатылуы әлеге халык мәкальләре нигезендә әйтергә теләгән фикернең поэтик көч-куәтен күпкә арттырып җибәрә. Халык җырларында да өченче дүртенче юллардагы мәгънә беренче, икенче юлларда бирелгән я табигать, я тормыш-көнкүреш хәлләре белән тәңгәл куеп сурәтләнүчән.

Бу мәгънәне көчәйтеп кенә калмый, эстетик тәэсирлелекне дә бермә-бер арттыра.

"Михнәт белән көн күргәнче, яуда үлик дан белән" дигән юлларның гәрчә мәгънәсе көчле булса да, эстетик йогынтысы ул кадәр түгел кебек. Ә инде "Карчыга үлмәс урманнан лачын үтә таң белән" дигән юллар исә мәгънәгә эстетик сыйфат өсти. Карчыга үтә алмаслык калын, кара урманны таңгы мәлдә үк лачын үтә алачак. Бу кошлар да кешеләргә ишарә итү җәһәтеннән сайланган. Карчыга да яман кош түгел. Шулай да дәрәҗәсе лачынныкыннан түбәнрәк. Лачын әлеге дә баягы яхшы ата балаларын да символлаштыра.

Монда "Яхшы атаның баласы шәһит үлә яу йөреп", "Михнәт белән көн күргәнче, яуда үлик дан белән" дигән юллар билгеле мәкаль-әйтемнәр нигезендә язылса, "Күк лачынның баласы яуда үлә таң белән" дигәннәре — шагыйрьнең үз табышлары. Алар да мәкаль-әйтем формасында иҗат ителгәннәр.

Халыкта "Ил язмышы — ир иңендә, ир язмышы — ил иңендә" дигән мәкаль бар. Ил һәм ир — бер-берсеннән аерылгысыз. Аларның, күчерелмә мәгънәдә әйтсәк, йөрәк тамырлары бер-берсенә язмыш җепләре белән бәйләнгән. Борынгы башкорт кобаерларында, халык җырларында, "Урал батыр" поэмасында бу хакта гаҗәп күп мәкаль-әйтемнәр кулланыла. Аларда балырлык һәм куркаклык төшенчәләре капма-каршы (антитеза) фикерләр аша тасвирланучан. Туган Җирне саклау — ир-егетнең иң изге мокаддәс бурычы, күркәм сыйфаты. "Биек тауның үлгәне" дигән кобаердан бер өзек:

Ирмен дигән ир кеше
Бурсыктай посып янмас ул,
Көнгә күзе чагылган
Ябалактай качмас ул.
Яу килгәнен күргәндә,
Бәбкә йоныны калкытып,
Җиләс искән җилдә дә
Шаулап торган усактай,
Йөрәкләре калтырап,

Нишләргә дә аптырап,
Яудан торып калмас ул,
Яудан читтә калмас ул.

Шулай итеп, халык элек-электән үз улларының батыр йөрәкле, көчле беләкле булуын, ил язмышы өчен янып яшәвен теләгән. Курку калтырану, үз мәнфәгате өчен генә яшәү хурлык саналган. Ул хакта ифрат күп мәкаль-әйтемнәр иҗат ителгән. Бу строфада да шул мәкаль-әйтемнәрнең эчтәлекләре синтезлап бирелгән.

Димәк, бу идея Салават Юлаев поэзиясендә чал тарихтан, гасырлар төпкеленнән, бик кадимге халыкларның йөрәк сулышыннан эркелеп килеп керә. Ил-Җир язмышы очен җанын, канын, барлык кодрәтен биргән шагыйрь әсәрләренең һәр юлында диярлек халык иҗат иткән мәкаль-әйтемнәрнең эчтәлеге барлыгы сизелә. Әлбәттә, кабатлап булса да әйтик эчтәлеге сакланган хәлдә, алар төзелешләре ягыннан үзгәртелеп, башка лексик-грамматик чаралар ярдәмендә тәгъбир ителәләр. Янә бер мисал:

Туй барганда, түш киереп,
Көрәшкә чыккан — батырмы?
Икәүдән-икәү алышып,
Кордашын еккан — батырмы?
Халыкка җаны кушылган.
Дошманнан илен курчыган,
Иярләп атка атланган.
Ажгыртып яуга ташланган, —
Илнең батыры шул булыр,
Илнең күрке шул булыр.
Атка менегез, ирләр, агалар.
Ачылсын әйдә иске яралар!
Яраларны ирек уңалтыр,
Явыз дошман башын югалтыр!
Курыкмас булса ирләр ярадан,
Ук та үтмәс безнең арадан.

Халыкта "Ат дагасыз, батыр ярасыз булмый", "Атланган батыр төшмәс" кебек мәкаль-әйтемнәр бар. Бу строфада шулар һәм аларга охшаш бик күп мәкаль-әйтемнәрнең эчтәлеге салынган. Без әле батырлык һәм матурлык, кешелеклелек нидә икәнен аңлап бетерә алмыйбыз. Бу яхшы сыйфатларны бәгъзе берәүнең теленә карап кына чамалый торган гадәтебез дә бар. Яки түш киереп әтәчләнгән ахмакны да батырлар сафына бастырырга ашыгабыз. Туй барганда туш киереп мәйданга чыккан, кордашын еккан батыр буламы? Шагыйрь әйткәнчә, халкына җаны кушылган, атка атланган, ажгырып дошманга ташланганнар гына ил батыры, ил күрке була ала.

Дошман явы, йот, кан коеш Салават Юлаевка чаклы да була. Җир ананы даими рәвештә җәрәхәтләп, җәфалап торганнар. Әмма ул яраларны беркайчан да ирек яуламый уңалтып булмаячак. Иске яраларның ачылуыннан куркып, ирек яулаудан беркайчан да чигенмәскә кирәк.

Шагыйрьнең бу кыйммәтле сүзләре бүген аерата көчле яңгырый. Шулай итеп, Салават Юлаев — шагыйрь-көрәшче генә түгел, нәфис сүз остасы да. Ул халык иҗат иткән мәкаль-әйтемнәрне шул килеш тә куллана, үзе дә яңаларын уйлап таба. Бу аның тел диңгезендә бер аркылы, бер буй иренмичә йөзүен, анын төбендәге энҗе-мәрҗәннәрне армый-талмый җыюын раслый.

Кечкенә бер мәкаләдә барысын да чагылдыру мөмкинлеге юк. Монда шагыйрьнең мәкаль-әйтемнәр белән ничек оста, иҗади эш итүен генә яктыртырга тырыштык. Ләкин Салават Юлаев образлылыкка шулар аша ирешә икән дигән төшенчә калмасын. Аның поэзия тукымасындагы чагыштыру, метафора, эпитет һ.б. тел-сурәтләү чаралары зур эстетик көчкә ия.

Шагыйрьнең поэтик мирасы зур түгел. Шулай да булган кадәренчә генә дә безнең өчен кыйммәтле хәзинә булып исәпләнә.

Фәлсәфи фикер тирәнлеге, уйлау офыкларының киңлеге, әсәрләрнең сәнгатьчә эшләнеш дәрәҗәсе бүгенге каләм осталарына да өлге-үрнәк булып торырлык. Бу поэтик чирәмне ныклап күтәрү өчен, безнеңчә, аның шигырьләренә төпле лингвистик анализ ясарга кирәк. Моның өчен аерым мәкалә генә түгел, зуррак хезмәт язу таләп итеЛә.

Таң җиле — хисләр образы

Г. Кандалый

Татар әдәбиятында дөньяви поэзияне башлап җибәргән шагыйрь Габделҗәббар Кандалый шигырьләренең гомумхалык теленә якын, образлы тәгъбирләргә бай булуын, аның халык җырларындагы сурәтләү чараларын ничек куллануын яхшы беләбез. Башта шигырьләрендәге фразеологик әйтемнәргә игътибар итик: йөрәк мае сызылу, кан калмау, гарык булу, чиргә сабышу, гакыл җитмәү, коллыкка калу, гарьлеккә төшү, күңел уйнату, җан түзмәү, җан тынмау, хәсрәт чигү, янып-көю, сагыштан көеп-кору, җан кайнау, сафа сөрү, каргышка тару, теңкә котыру, авыз тулы кан булу, гыйшык төшү, күз белән каш итеп тоту, үзәк өзелү, яманат күтәрү, зар булу, интизар булу, зар-интизар булу һ.б.

Болар үзләре генә дә шагыйрьнең тел хәзинәсендәге байлыкка җитди игътибар итүен күрсәтә. Алар образлылыкка ирешү, поэтик телне халык теленә якынайту, лирик геройның хис-тойгысын, эчке кичерешен, рухи дөньясын ачу өчен хезмәт итә. Бу тәгъбирләрнең күбесе бик борынгы заманнардан ук халыкның җанлы сөйләмендә, җырларында,

әдәби әсәрдә кулланылып килгән. Г. Кандалый шигырьләрендә дә мондый халыкчан тел бизәкләре күп.

Телнең эчке мөмкинлеге, хосусияты чикләнмәгән. Сәнгатьле сөйләмдә тәгъбир (фраза), сурәтләү чарасы, кыскасы, бөтен тел берәмлеге бер-берсе белән эчке мөнәсәбәткә кереп, гомуми бер эстетик максатка буйсына. Әнә шул процесста образлы тәгъбирне төзүче компонентлар төрле мәгънәдәге бүтән сүзләр белән аралашып, фикерне тулыландыру төгәлрәк тәгъбир итү вазыйфасын да үти. Мәсәлән, "Сәхипҗамалга" поэмасында гарьлеккә калу дигән әйтелмә: "Йөрерсең лә бата-ката, төшеп зилләткә (түбәнлеккә — С.П.), гарьлеккә", дип бирелә. Гарьлеккә калу төрлечә булырга мөмкин. Ул кешенең үз мәнфәгатенә, субъектив сәбәпләргә дә бәйле. "Гарьлеккә төшү", "бата-ката йөрү" дигән әйтелмә белән эчке бәйләнешкә керә. Шуның аркасында гарьлеккә калуның объектив сәбәпләре ачыклана, ягъни бата-ката йөрүгә Сәхипҗамал үзе түгел, бәлки шул чордагы тормыш-көнкүреш, социаль шартлар гаепле булуы ачыклана. Моннан без поэтик сөйләмдә фразеологик әйтелмәләрнең башка тел чаралары, шулай ук әсәрнең идея-эчтәлеге һәм ул чагылдырган чор белән эчке бәйләнешкә керүен дә күрәбез.

Поэзиядә авторның традицион образларны, төрле тел чараларын үзгәртүе, гадәттә, ритм, рифма, стильгә бәйле була. "Сәхипҗамалга" поэмасыннан бер мисал:

Эш эшләп унике аең, гомер буең, кышын-җәең.
Сызып бетеп йөрәк маең, каның да калмый кашыкка.
Кыекча башыңа чорнап, утырасың
лабаса җырлап,
Кулың, битен камыл тырнап,
Юлыкып билчән ашлыкка.

Күренә ки, биредә язма әдәби тел барлыкка килгәнче ук булган йөрәк мае сызылу, соңгы кан тамганчы кебек тәгъбирләр алынган. Алар халык телендә авыр язмышны тасвирлау өчен кулланыла. Шагыйрь соңгы тамчы кан тамганчы тәгъбирен каның да калмый кашыкка дип үзгәртә. Бу үзгәртүне дә рифма (кашыкка — ашлыкка) өчен генә эшләгән, дип уйлау дөрес булмас.

Кашык халык телендә күп мәгънәдә йөртелгән: артык кашык (артык кеше), гаиләдә биш кашык (биш кеше), бер кашык он калмау, онны кашыклап өләшү һ.б. Соңгы икесе авыр, ярлы тормышны чагылдыра. Татар кашыгы дип әйтү дә бар. Кандалыйның тамчы кан калмау дигән әйтелмәдәге "тамчы"ны "кашык" сүзе белән алыштыруы мәгънәне тагын да көчәйтә төшкән, ләкин әйтелмәнең халыкчанлыгына зыян китермәгән, киресенчә, тормыш-көнкүреше белән бәйләнеше ныгыган.

Терелэй сую дигән әйтелмә дә бик борынгы; Анда "сую" сүзе

борынгы төрки телдән ук килә. Аны хәзерге вакытта торган мәгънәсендә аңларга ярамый. Ул "Кыйссаи Йосыф" поэмасында салдыру дигән мәгънәдә бирелә: "Күлмәкени икнендән суярлар имди" (Күлмәкне өстеннән салдыралар). Халык, "тереләй" сүзен ташлап, "сую"ны гына куллана. "Суйма", "суйдың", "авыр хәлгә куйма", "авыр хәлдә калдырды" дигәнне аңлата, Кандалый да әлеге әйтелмәнең шул компонентын гына ала.

Ярамый, әнкәй, суярга, итен тозлап та куярга,
Шулукта ярга ярәшерсез, и әнкәй лә.

Г. Кандалый поэзиясенә "җан", "кан" сүзләре катнашында ясалган фразеологик әйтелмәләрне дә әнә шул рәвешчә карап чыгарга мөмкин булыр иде.

Монда бер нәрсәне искәртеп үтәргә кирәк: андый тел сурәтләү чараларын анализлаганда аларны әдәби әсәрнең идея-эчтәлеге, анда тасвирланган чор, халык теле, лирик геройның күңел дөньясы, шагыйрьнең эстетик карашлары белән бәйләп карарга кирәк.

Г. Кандалыйның халык җырларындагы сурәтләү чараларын үзенең әсәрләрендә ничек куллануына игътибар итик. Моңа Кандалыйдан күп мисаллар китереп була. Әйтик, күп җырларда аның сәнгатьлелеген, эмоциональлеген көчәйтүгә хезмәт итә торган традицион чара буларак, йомшак таң җиле образы кулланыла. Ирәм багындамы үстен, йөрәкем бәгырьне кистең, Саба йиле кеби исдең ки, сахраларда, чүлләрдә. Мәхәббәт хисләрен табигать күренеше — сахраларда, чүлләрдә искән йомшак тан җиле — ярдәмендә тәгъбир итү поэтик сөйләм офыкларын киңәйтә, аның мәгънәсен тирәнәйтә, халыкчанлыгын арттыра. Кандалыйда таң җиле — хисләр образы.

Зифа буй, нечкә бил кебек традицион эпитетлар, авыздан энҗеләр чәчү, алтын алма кебек метафоралар лирик героиның эчке кичерешен, хис-тойгысын чагылдыру, шигырьнең поэтик яңгырашын, укучы күңеленә эстетик тәэсир итү дәрәҗәсен көчәйтү өчен хезмәт итә. "Җаным", "җанкаем", "чибәрем", "матурым", "алтыным!" кебек сүзләрдә дә халыкның күңел рухын, матур эчке тойгыларын, хисләрен, сурәтләү объектына мөнәсәбәтне белдерәләр. Чагыштыру объекты сыйфатында сайланган былбыл ("аузың дәхи былбылдай"), хур кызы ("хур кызыча мимылдай"), чишмә ("Акай күз яшьләре чишмә") кебек халык җырларыннан алынган чараларны да шагыйрь әнә шундый максатларда файдалана.

Кавыша алмаудан көчле сагыш тойгылары кичерүне Сак белән Сок язмышына охшату да халык телендә, җырларда күп очрый. Моңа үзенең шигырьләрендә Кандалый да мөрәҗәгать итә: "Ки, охшап Сак билә Сокка болай тормакымыз унмай..." Ә инде Йосыф белән Зөләйханы чагыштыру объекты итеп алу нәтиҗәсендә шагыйрь безне бик борынгы легендалардагы

мәхәббәт дөньясына кертеп җибәрә: Юсыф берлә Зәләйха тик атымыз калды санарга".

Мәкаль-әйтемнәрне шагыйрь еш кына борынгы ата-бабаларыбыз исеменнән әйттерә. Бу исә аларның эмоциональлеген, халыкчанлыгын, тәэсирлелеген арттыра. Мәсәлән: "Борынгылар шулай димеш, балыкчының арты юеш". Биредә кулланылган әйтелмәдә лирик геройның күңел хисе, эчке дөньясы, әсәрнең эчтәлеге һәм чор рухы, халыкның тормыш-көнкүреше чагылыш таба. Әйтик, балыкчының арты юеш дип, балыкчының хезмәте суга бәйләнгән булганга гына әйтелми. Көн-төн балык тотса да, ул барыбер ярлы, тормышын рәтли алмый, дигән мәгънәне аңлата мәкаль.

Әнә шундый мәкаль-әйтемнәргә нигезләнеп, бөтен бер строфа һәм анарны үзгәртү традициясе яшәп килә. Кол Галинең "Кыйссаи Йосыф", Мөхәммәдьярның "Төхфәи мәрдән", "Нуры содур" поэмаларында андый күренешләр күзәтелә. Бу алымга Г. Канладый оста мөрәҗәгать иткән. Мәсәлән, "үткән эш кире кайтмас" дигән мәкальне ул үзенчә үзгәртә, аны метафорик сөйләм белән "нығыта". "Еласаң да кире дүнмәс, бу хәсрәтең уты сүнмәс, Сәнең чән кеше үкенмәс, ни күрсәң дә, абыстай ла".

Мәгълүм ки, Г. Каңдалый татар милли әдәби теле формалашып килгән чорда иҗат иткән. Аның лексикасы бай, халыкчан. Тарихта беренче буларак, ул поэтик стиль рухына урыс сүзләрен җайлаштыра. Аларны халык телендәгечә кулланырга тырыша: мажик (мужик), анфалит (инвалид), пушты (почта).

Борынгы төрки теленнән килеп, гади сөйләм лексикасына әйләнеп киткән кайбер сүзләр дә аның поэтик стилендә матур яңгыраш тапты. Халыкта "чук-чук сәлам" дип хат язу совет чоры елларында да озак дәвам итте. Г. Каңдалый шигырьләрендәге "чук" сүзеннән дә әнә шул халык теле рухы сизелеп тора. ("Йибәрсәң хатларын чук, кавышмай жанымыз тынмай"). Югарыда телгә алынган гарык булу, теңкә кору кебек тәгъбирләр дә гади сөйләм өчен характерлы.

Ул матур яңгырашлы (хур кызы, хыял дәрьясы, былбыл, алтын, гәүһәр, энҗе) поэтизмнарга гына түгел, хәзерге күзлектән караганда диалектизм булып санала торган тел берәмлекләрен дә мул кулланды. Моны да халык телендәге бай формаларның төрлесенә игътибар итәргә тырышу нәтиҗәсе итеп карарга кирәк: ерлай (җырлый), йил (җил), йәй (җәй). Башкортстанда яшәүче татарлар телендә, мәсәлән: белә (әдәби телдә — белән). Кандалыйда: "Туфрак билә ката" (туфрак белән ката). "Кыйссаи Йосыф" поэмасында ир-егетлек төшенчәсе алып йөрәкле дигән) эпитет ярдәмендә генә белдерелгән. Ә Г. Кандалый исә шул төшенчәне бирердәй башка сүзләрне да таба. Ул, мәсәлән, Башкортстан татарлары телендә көчлелек, батырлык, хезмәт каһарманы символы мәгънәләрендә кулланыла торган, хәзерге вакытта кеше исеменә дә әйләнеп киткән

азамат сүзенә мөрәҗәгать итә. “Кыяматкәчә азаматы кала сөйләргә телләрдә” (Кыяматкәчә егетлек даны, ирлеге кала сөйләргә телләрдә).

Төрле образлы сүзләр, тәгъбирләр, гомумкулланыштагы гади сөйләм лексикасы, диалектизмнар поэтик стильдә аерым хәлдә яшәми, үзара яки башка сүзләр белән бәйләнешкә кереп, әсәрнең идея-эстетик эчтәлеге тулыландыралар. Шуның нәтиҗәсендә билгеле бер система төзиләр.

Тел-сурәтләү чараларына анализ вакытында аларның кулланышындагы үзенчәлекләр ачыла. Кандалыйның поэтик телендә без әнә шуларның кайберләрен күздән кичердек.

Тукай әсәрләре тукымасында тукылган гәүһәрләр

Г. Тукай

Тукай! Бу сүзне ишетү белән, күңелдә ниндидер илаһилык, иялелек, рух нуры барлыкка килә. “Синең шигырең якты кояш кебек” дигән иде ул Пушкин шигырьләре турында. Лермонтов поэзиясендә Байрон югарылыгын яулау максатын куя. Тукай аның шушы сүзләрен “эләктереп” ала. Соңга таба аның фәлсәфи-шигъри фикер йөртү офыклары даирәсендә Пушкин, Лермонтов, Тукай өч йолдыз булып кабына. Кояш, Йолдыз, Җир йөрәген халык йөрәге белән бәйләү осталыгына иреште Тукай!

Яктылык югарыдан төшә. Ул яктылык эчендә мөбарәк тәсбих төймәләредәй тезелеп киткән бәхет бар, имеш. Күктә, югарыда ни генә булмас, очсыз-кырыйсыз күк бит ул. Шигърият гәүһәрләрен күк тәхетеннән, гарыше-көрсидән, аның аръягыннан да эзли Тукай. Җир белән Күк йөрәге мәхәббәт чылбыры белән тоташ икәнлекне тоя ул. Аның бөек, шөһрәтле талантын аңлап, әллә табигать үзе бүләк иткән ана серле-сихри шигърият көчен, әллә кайнар хис-тойгысы, аң-акылы, йөрәк ярсуы белән үзе бәреп кергән шигърият гәүһәре тулы табигать дөньясына? Ул бит күңелен ерак-ерак тарих төпкеленә сәяхәт иттерә. Ерак ата-бабаларыбызның поэтик фикерләү тамырын эзли. Тамыры нинди — кәүсәсе шундый. Кәүсәсенә карап ботак җибәрә агач. Нык ботак шаулап яфрак яра. Поэзиябезнең тамыры — җир йөрәгендә. Кәүсәсе — халкыбыз күңелендә. Ботаклары шаулап яфрак ярган. Шул яфраклар саныңча хәзерге шагыйрьләребез. Әмма Тукай поэзиянең алтын баганасы булып кала килә.

Борынгы кыпчак далаларында искән сабах җиле (таңгы йомшак, ләтыйфь җил) төрки кавемнәр өчен уртак символик образ булып хезмәт итә. Кеше кайгысын, хәсрәтен, йөрәк серен сабах җиленә сөйли. Көчле, мәрхәмәтле, шәфкатьле, шул ук вакытта усал, ярсу була бу җил. Бәладән саклап калу өчен буд кавемен уз шәфкатьле канаты астына алса, гад

кавемең фаҗига сазлыгына батыра. Улы Йосыф югалу кайгысыннан Ягъкуб пәйгамбәрнең күзләре сукрая. Йөрәк ярасын сабах җиленә сөйли Ягъкуб пәйгамбәр:

Акрын искел, сабах йиле, нә үтәрсән,
Хакыйкать Йосыфамнан ис дотар сән;
Җәрәхәтем уңалдырмага сән йитәрсән,
Син искәли шат-хөррәм улдым имди.

Сабах җиле рухи бер шифа-шәфкатьлелек булып, Ягъкуб пәйгамбәрнең куенына сарыла, аның кайгылы йөзен иркәли, чәчләреннән сыйпый. Көннәрдән бер көнне гөнаһсыз пәйгамбәр рухы белән җил бергә кушылгач, Ягъкубның күзләре ачыла. Җил Ягъкубка Йосыфның дөньяда барлыгы, кешелекле, кечелекле, каһарман йөрәкле гадел, намуслы, шәфкатьле, мөрәүвәтле булуы турындагы хәбәрне алып килә. Шулай итеп, сабах җиле асыл сүз-сурәткә, изге кеше сыйфатына әверелә: Кол Галинең “Кыйссаи Йосыф” поэмасында (Болгар чоры, XIII йөз), Мөхәммәдьяр әсәрләрендә (Казан ханлыгы чоры, XVI йөз), Утыз Имәни һ.б.лар шигърияттендә, аларның эстетик идеалларына ярашлы рәвештә, төрле мәгънәви хис-тойгылар нигезендә, билгеле бер өслүби чара булып кулланыла; Г. Кандалыйда мәхәббәт кебек мөкатдәс, садә, самими хис-тойгылар ташучы хәбәрче булып санала. Дәрдмәндә җил ил корбанын сөрә. Такташта җил фәрештәне бу гөнаһлы илдән китәргә өнди Тукайның “Көзге җилләр”ендә җил бөтен ил фаҗигасе өчен әрнеп җылый;

Көзге төн. Мин йоклый алмыйм. Өй түрендә җил җылый.
Җил җыламый, ак үлемнең куркусыннан ил җылый.

Биредә җил образы — аклык белән каралык арасында. Яктылыкның югарыдан төшүен аңлату өчен йолдызлар да телгә алына. Төн караңгы. Бәхет тә караңгы. Әмма йолдызлар яктырак яна. Шушы идеяне аңлату өчен, эпиграф рәвешендә, русчадан ике юл шигырь дә китерә: “Яктырак йолдыз янадыр, төн кара булган саең; Ядыма тәңрем төшә, бәхетем кара булган саен”. Ил белән бергә балалар да, назлы нечкә билләр дә, шәфкатьле анабыз —мәрхәмәтле Җир үзе дә җылый. Җан алырга кызганудан Газраил җылый. Ибраһим вә Исмәгыйль пәйгамбәрләр җылый. Шагыйрь, шулай итеп, җил образына бәйле рәвештә, ил. җир шары фаҗигасен генә түгел, бөтен дөнья, галәм афәтен хәбәр итә. Шигырь шул сүз белән тәмамлана да: “Җил хәбәр ул: ач үлемнен куркусыннан ил җылый”. Шагыйрьнең русчадан ирекле тәрҗемә ителгән “Царь — голод, яхут ачлык падишаһ” дигән әсәре дә ачлыктан җылаган җил образы белән аваздаштыр ул. Монда да шундый эпиграф: “Дөньяда бер падишаһ бар ки, ул падишаһ гаять шәфкатьсездер, аның исеме дә ачлыктыр”. Бу әсәр академик Бахтан тәрҗемә ителгән. Тукайда аның шундый маузуглары яктыртыла: “Берләшмәк, эшне бүлмәк, алмашмак, товар”, “Товарның кыйммәте”, “Акчалар”, “Сорау-сорату”, “чыгару”,

“конкуренция”. Шигырендә дә, икътисадый мәсьәләләргә багышланган фәнни-публицистик хезмәтендә дә хәятнең кара давылы дөньяны фаҗигагә алып баручы рухи һәм матди ачлык буларак карала Тукайда “Көзге җилләрдә”дә дә, “Ачлык падишаһ”та да гаделсезлек-каралык сыйныф вәкилен (байлар, ярлылар) ике бизмәнгә салып үлчәп тасвирлана. “Көзге җилләр”дә: “куйса монда картлар төшкән тешен алтын белән бер телем икмәк, дип, анда назлы нечкә бил җылый”. “Ачлык падишаһ”та: “Берәүләр кан тирләргә батып эшлиләр, берәүләр бернәрсә дә эшләми, берәүләр ачыгалар, һәртөрле авырулардан чебеннәр шикелле каталар (үләләр); икенчеләре биек-биек пулатларда гына торып, алтын-көмеш савытлардан гына ашыйлар; бәгъзеләр хәсрәтләнәләр һәм зәхмәт чигәләр; бәгъзеләр куаналар, шатланалар”. Тукайның хис-тойгылар ташкынын кайнаткан бу кара давыл бүген дә күпләрнең күңел дөньясын парә-парә яралый түгелме?

Сәнгатьле сөйләмдә аз сүз белән күп мәгънә аңлату, җанлы картина тудыру, образлылыкка ирешү максаты куела. Образлылык (сүз-сурәт), идеялелек (мәгънә), эмоциональлек (хис-тойгы) әсәр тукымасында бер йомгак булып кәрәзләнергә тиеш. Шуларның берсе генә житешмәсен, поэтик кәрәз кителә. Бал корты кәрәзе кебек нәкышләнми әсәр. Кол Галидә җил — образ. Мәгънәсе яки идеясе – кешелеклелек, эмоциональлеге яки хис-тойгы белдерүе — йөрәккә тәэсир итү. Тукайда Җил — образ. Идеясе — рухи вә матди байлык-ярлылыкны чагылдыру. Эмоциональлеге — тәэсир көче.

Җансыз әйберләрне җанландыруны галимнәр сынландыру дип атый. Сынландыру — сурәтләү чарасы. Фразеология, чагыштыру, метафора, эпитетлар да шуңа керә. Язучының сүз сәнгате остасы булуын исбат итү өчен сурәтләү-тасвирлау чаралары, нигездә, өч төрле яссылыкта карала: халык үзе иҗат иткән (традицион), үзгәртелгән (трансформацияләнгән), әдип үзе уйлап тапкан (индивидуаль) образлар белән оста, мәгънәле эш итү.

Тукай Байрон, Пушкин, Лермонтовлар поэзиясе белән рухлана. Көнчыгыш әдәбиятыннан шигъри азык ала. Әмма төрки телле халыклар шагыйрьләре соңынан Тукайның үзеннән өйрәнәләр. Бу нәкъ кояшның җирдәге суларны парландыра-парландыра алып, үзенә кире шифалы яңгыр итеп, бүләк сыйфатында кайтарып биргән кебек. Кырас җиле белән көрәшә-көрәшә Тянь-Шань таулары куенында яшәгән кыргызлар арасында да, Казахстан далаларында да, Үзбәкстанның эссе кояш нурларында да Тукай моңы яңгырый. Күңелдәге шигъри моңын былбыл итен очырды ул шул якларга. Вакыт-вакыт уртак традицион сүз-сурәт (образ) белән эш итсә дә, аларга үз күңел гәүһәрен, үз моңын, үз өслүби (стиль) ялкынын, эстетик кайнарлыгын сала белде. Галимнәр теле белән әйтсәк, трансформацияләп, яңартып кулланды. Алтын да — традицион

образ. Аның белән борынгы ата-бабаларыбыз "Сабыр төбе — сары алтын" дигән мәкаль иҗат иткән. Кол Гали шуның нигезендә бөтен бер строфа төзи:

Сабыр берлә эшләгел ошбу эши,
Сабыр берлә эшләнер эшләр башы;
Морадына тиз йитәр сабырлы кеше,
Бу эш эчрә күрекле сабыр кылгыл имди.

Йосыфның Зөләйхага әйткән сүзләре бу. Мәүлә Колыйда ул төрле традицион образлар белән бизәкләнеп бирелә:

Сабыр берлә гөлләр ачылыр, китәр кышлар.
Йомыркадан чыкар, күккә очар кошлар,
Сабыр берлә гәүһәр булыр энҗе ташлар,
Сабырсыздан кайнаю бәйн пешсә булмас.

Исә җилләр, ага сулар, үтә вакыт, искелек җиңелә, яңалык җиңә бара Бөтен галәм хәрәкәттә. Үзгәрә. Яңара. Камилләшә. Тел дә шулай. Ана җан, кан, илаһилылык биреп торучы поэтик бизәкләр дә шулай. Сәнгатьле сөйләмдә аны каләм осталары үзгәртә. Әсәр тукымасында сүзләр дә заман дулкынына йотылып, көтелмәгән ягы белән әйләнә. "Сабыр төбе — сары алтын" дигәнне Тукай менә ничек үзгәртә: "Сабырлык төбе — сару алтын" дигән булалар. "Шура" идарәсенең 75әр тиен генә бәһа биреп "Басмаган шигырьләр мәҗмугасы" вә "Тиле ярышы" кеби чүпләр таратуына милләт сабыр итсә дә, сабыр төбеннән сары алтын түгел сары бәрәңге дә чыкмый әле" ("Фәлсәфи сүзләр").

Әсәрнең идея-эчтәлегенә, ул чагылдырган чорга, үзенең эстетик идеалына яраклаштырып үзгәрткән, үзе дә яңаларын иҗат иткән мәкаль-әйтемнәр күп Тукай әсәрләре тукымасында. Мәкальләргә якын торган фразеологик тәгъбирләр дә бихисап. Аларны галимнәр "катып калган" тел берәмлекләре дип исәпли. Трай тибү, салпы якка салам кыстыру, җиң салындыру кебекләре чыннан да "катып калганнар". Ләкин дөньяда катып калган бер генә җисем, күренеш тә юк. Фразеологик тәгъбирләр дә шулай. Үзгәрә. Яңартыла. Нәфис сүз сәнгате осталары аларның яңадан-яңаларын иҗат итә. Р. Бикмөхәммәт "поэзиябезнең сулмас чәчәкләре" исемле хезмәтендә (Казан, 1960) егерменче гасыр башында, яки милли әдәби тел оешкан-формалашкан чорда, татар фразеологиясен иң нык эшкәртүче итеп Тукайны күрсәткән иде. "Өзелгән өмид" исемле шигырендә генә дә 30дан артык фразеологик тәгъбир бар. Шуларның дүртесе — халыкныкы яки традицион (күз карашы, яшь вакыт үтү, гомер яртысы җитү, тулган ай), өчесе — үзгәртелгән яки трансформацияләнгән (күз тегеп багу, дәрт белән каләм сызу, кеше гомере сүнү), 24е — Тукайның үзе иҗат иткән яки индивидуаль фразеологик тәгъбирләр.

Үзгәртү әсәрнең эчтәлегенә, ул чагылдырган тарихи шартларга бәйле. Әйтик, күп ыру, кавем, кабилә, халык нигезендә, утлы-давыллы

каршылыкларны жиңә-жиңә, шөкер, егерменче йөз башында татар милләте оешып ала. Әгәр шулай булмаса, Тукай бу шигырендә милли агач дигән фразелогия иҗат итмәс иде: "Күпме моңлансам кунып милли агачлар өстенә, Барсы корган, бер генә юк җанлысы, яфраклысы". Милләтнең тамыры ерак-ерак гасырлар төпкелендә икәнлекне анлый Тукай. Бу тамырны кырмыска оясы урынына туздырырга күпме генә тырышмасыннар, кәүсәсенә канлы балта белән күпме генә чапмасыннар-бөтенләй үк имгәтә алмадылар барыбер, ярасын уңалта-уңалта, яңадан-яңа ботаклар, яфраклар ярды. Тик ул яфраклар Тукай заманында бик зәгыйфь иделәр әле.

Әйбер төсе үзгәрү, тормыш күге, мәхәббәт чаткысы очмау, саз уйнау, моңлы саз белән аерылышу, күңел кошы, дөнья читеннән тарсынып очу, җиһанга шат ярату, раббының ят яратуы, милли агачлар өстенә кунып моңлану, моң кору, моңның җанлысы булмау, салкын яр булмау, әнинең елмаеп вафат булуы, гаиләгә ят кеше китерүе, иң ахыры кәррә үбү, мәхәббәт сакчысы, бар күңелләрдән җылы булу, йомшак кабер ташы, күз яшенең иң ачы һәм татлысының кабер ташына тамуы кебек фразеологик берәмлекләрнең һәммәсе тирән фәнни анализ ясауны таләп итә. Тукай иҗат иткән бу индивидуаль фразеологиләрне кайсы яктан гына карама (ясалышы, төзелеш, составы, мәгънәсе, эмоциональлеге, экспрессивлыгы, образлылык куәте), шушы өлкәдә эшләгән теләсә нинди галимне сокландыра ала. "Катып калмаганлык"ны, татар теленең гаҗәп бай, аның энҗе-гәүһәрләргә ифрат мул булуын фразеологик тәгъбирләр аша гына да исбат итә Тукай.

Егерменче йөз башында, шул чордагы тарихи шартларга бәйле рәвештә, яңа канлы көрәшләрне җиңә-җиңә, татар әдәби теленең канаты шактый киңәеп китә, контаминацияләнгән яки җәенке фразеологик әйтелмәләр барлыкка килә. Тукайдагы күз яшенең иң ачы һәм татлысының кабер ташына тамуы дигән катлаулы сүзтезмә дүрт фраза нигезендә контаминацияләнгән: күз яше+ачы күз яше+татлы яше+күз яшенең кабер ташына тамуы. Контаминацияләнгән фразеологияләрнең матур үрнәген поэзиядә Г. Тукай, прозада Г. Ибраһимов күрсәтте. Г. Ибраһимовта: дәртле күзләрнең тамырдагы канны ихтиярсыз кузгатуы, көрәш утының ялкыннары эчендә иске тормыш чүпләре янып җимерелә бару, мәхәббәт дулкыннарыннан исергән башны кая куярга белмәү һ.б.

Болын — чәчәксез, тел бизәксез булмый. Тел бизәкләре (эпитетлар)нә дә нык бай татар теле. Аның матур үрнәкләре беренче мәшһүр-классик әсәребез "Кыйссаи Йосыф"та (XIII йөз) да бар. Зөләйханың керфек очында эленеп торган гәүһәр яшь — юкка-барга елаган яшь түгел ул. Мәхәббәт кебек кайнар хис-тойгылардан йөрәктә гәүһәр булып сәйләнләнеп чыккан гәүһәр яшь бит ул. Кешене йөрәкле эпитеты белән эзләү әүвәл-әүвәлдән килә. Риваять каһарманы Алыпны

эпитет сыйфатында файдаланып, аны Йосыфның җисмәни көчен күрсәтү җәһәтеннән куллана Кол Гали: алып йөрәкле Йосыф. Шәфкатьле, мөрәүвәтле, гыйффәтле кебек мантыйкый яки логик эпитетлар Йосыфның кешелеклелек сыйфатларын ачыклый. Димәк, традицион эпитетларны мәгънә, өслүби, сүз-сурәтлелек, эмоциональлек, экспрессивлык максатларда үзгәртү-трансформацияләү поэзиябезнең чишмә башы булган "Кыйссаи Йосыф"тан ук килә. Бу шул вакытта гына түгел аңа чаклы, гасырлар-гасырлар элек үк, бик борынгы кавем ата-бабаларыбызның сәнгатьле сөйләмгә, образлы фикер йөртүгә оста булулары турында сөйли.

"Кыйссаи Йосыф"тагы гәүһәр яшь Тукайда да бар. Тукайда аның стилистик-экспрессив канаты тагын да киңрәк. Чөнки ул мәхәббәт тойгылары, интим хисләр белән генә чикләнми, аның эчке мәгънәсе, сурәтлелек нигезе, эмоциональлек табигате шагыйрь яшәгән чор, андагы сәяси-иҗтимагый, тормыш-көнкүреш хәлләре белән генә дә түгел, шагыйрьнең эстетик идеалында даими булып торган гөнаһсыз дөнья, тәңре хөкеме белән дә бәйле:

Кичерелсәче, тәңрем, бәгърем, әти, әни,
Дәү әнием, апайларым, бабай, әби;
Хозурында гәүһәр яшем түгеп телим,
Кабул әйлә, тәңрем, әле мин бик "нәни".

Тукайның күп кенә сүзбизәгечләре татар кызларын мәхәббәт күленә манып алган дәрәҗәдә матурлый: оҗмах куен, мәрмәр муен, зөбәрҗәт күз, тәмле сүз, татлы сүз, кәүсәр ирен, нечкә бил, чулпан кыз һ.б. Шуның белән бергә, Тукай иске карашлы, мөнәфыйк, алама затларның эчке дөньясын, рухи халәтен кире хис-тойгы уята торган эпитетлар белән да сыйфатлый: гөмбә баш, соры корт, чебен җан, чүмеч баш, иләк авыз, таш йөрәк һ.б.

Нинди генә жанр булмасын (поэзия, проза, публицистика), бер үк туган тел хәзинәсендәге сүз гәүһәрләре белән иҗат ителә. Шулай да һәр жанрның үзенчәлеге, эчке табигате, серле хосусияты бар. Бу хосусиятлык тел-өслүб хасиятенә дә кагыла. Повесть һәм романнарда, мәсәлән, урыны-урыны белән тасвирламалар, хикәядәгегә караганда, шактый киң була. Шигырьдә аз сүз белән күп мәгънә аңлату, җанлы картина тудыру, хис-тойгы көчәйтүгә аеруча зур игътибар ителә. Матур әдәбият стиле белән публицистик стиль арасында җитди аерма да бар. Беренчесендә сурәтләү-тасвирлау чаралары, төрле поэтик бизәкләр мул булучан. Анда каләм остасының хыял-фантазиясенә тулы ирек бирелә. Әдәби әсәрнең эстетик зәвык тәрбияләү сыйфатын образлы, нәфис, сәнгатьле телдән аерып карап булмый. Публицистик стильдә фикерләрнең логик яктан дөреслегенә игътибар итәргә тырышыла. Анда сурәтләү чаралары куллану чикләнә. Ләкин моңа чын, ихлас дөреслек итеп карамаска кирәктер. Әдәби әсәрдә

хәбәрнамә (публицистика)гә хас күренешләр булган кебек, хәбәрнамәләр өчен сәнгатьле сөйләм һич тә ят түгел. “Мөбарәк тәсбих өзелде” — шуның бер гүзәл үрнәге. Ул Л. Н. Толстой мәрхүм үлгәч языла. Тукай бу үлемне бик авыр кичерә. Ул кичерешне тасвирлау өчен шигырь үлчәвенең генә тар булуын әйтә: “Ушбәны яздырды нәрсәне вөжданымның көчләве, мәсьәлә бик зур, сыйдырмый тар шигырьләр үлчәве”. Бу үзе үк язучы-художникның жанрны вакыйга һәм күренешләргә бәйле рәвештә сайлый белүен раслый. Хәбәрнамә өслүбендә язылса да, ул барыбер кайнар хис-тойгы, йөрәк сыкрануы, күңел тетрәнүе, шигъри тел, эчке кичерешләр давылы белән иҗат ителгән, Толстойның үлеме бөтен Русиягә килгән афәт буларак сурәтләнә. Шуңа күрә сүз Русия кояшыннан башлана. Әле Толстой исән. Инде ноябрь ае керсә дә, Русия кояшы бүтән еллардагыча нурын киметми, дөнья йөзенә чыраен сытып, салкынлык бирергә ашыкмый, Русиянең агар сулары бозланмый, үзәк өзгеч җилләр дә исми, ары да китми, бер зур һәлакәт булачагын алдан сизгән җанварлар кебек, табигать тирән бер хәвем һәм дәһшәт эчендә. Ни өчен? Толстой җәнапләре түшәктә. Бу авыр кайгыны шагыйрь әнә шулай бөтен Русия табигатенә бәйле рәвештә ясалган метафора аша сурәтли. Толстой вафат булгач, кояш та йөзен чыта, сулар да бозлана, ачы җилләр дә исә, кошлар да жылы якка оча.

Билгеле, “табигать кичерешләре” — кешеләр кичерше. Әгәр Тукай аны туры мәгънәсендә язса, бу кадәр тәэсирле булмас иде. “Русия кояшы” дип әйтү үзе хис-тойгы уята. “Русия кешеләре” дисәк, экспрессивлык кими. Биредә шагыйрь күчерелмәлелек яки метафораның шундый катлаулы төре белән эш итә. Метафора биредә сүз-сурәт тә ясый, мәгънәне дә көчәйтә, хис-тойгыны да арттыра.

Мәгълүм ки, кеше кичерешләрен табигать күренешләре, кошлар дөньясы белән бәйләп бирү Тукайның күп әсәрләрендә бар.

Казах акыны Абай: “Сүзнең эче — алтын, тышы — көмеш”, — дигән. Алтында тирән акыл, көмештә тышкы ялтыравык (анысы да кирәк) булу турында уйлагандыр ул. Тукай әсәрләре тукымасына тукылган сүз гәүһәрләрендә дә шушы үзенчәлек бар бит. Аның шулай икәнлеген без кайбер сурәтләү-тасвирлау чараларында да күрдек. Шулай да, суда йөзгән балык кебек, татарның бай чагыштырулар дулкынында киң колач салып, бик оста, соклангыч өлгер йөзә белде Тукай. Хәер, чагыштыруның үзен дә галимнәр “киң колачлы категория” дип йөртә. Аның киңлеге шунда: ул кулланылмаган бер генә фән дә юк. “Чагыштыру — танып-белүнең анасы”, — дигән борынгылар. Шул үзенчәлеге буенча хәзер ул философия фәнендә чагылыш (отражение), сиземләү (ощущение), танып-белү (познание) категорияләре белән бер рәттә өйрәнелә. Телчеләр аның нинди лексик-грамматик чаралар, катлаулы синтаксик төзелмәләр белән ясалуына игътибар итә. Әдәбиятчыларны аның образлылык, идеялелек,

эмоциональлек хосусияты, эстетик сыйфаты, сурәтләү-тасвирлау чарасы булу үзенчәлеге кызыксындыра. Татар телендә тимерәү гөле, кәккүк чәчәге, тавык җиме үләне, күркә үләне, бака үләне, ахшамсафа гөле, хәтфә гөле, тукранбаш, үги ана яфрагы, төчкерек үләне, фәрештә уты үләне, йөрәк яфрак, сөңге яфрак, йомырка яфрак, кочак яфрак, ирен чәчәк, башак чәчәк, себерке чәчәк, калпак чәчәк, кәҗә сакалы, каз тәпие, кызыл төймәлекәй, каз чәче, чучка тигәнәге, аш Казаны, аю колагы — эт эчәгесе, кузгалак һ.б. үлән, чәчкә, гөлләр чагыштыру юлы белән ясалган. Фразеологик әйтелмә, мәкаль-әйтем, сынландыру, эпитет, метафора һ.б.лар чагыштыру нигезендә барлыкка килгән. Борынгылар: “Чагыштыру — танып-белүнең анасы”, — дигәннәр икән, алман халкының немецларның аңа уз карашы бар: “һәр чагыштыру аксый”, — диләр алар. Французлар исә һәр чагыштыруның дәлилләү була алмавы турында фикер йөртә. Чагыштыруның барлык сыйфатлары безнең эрага кадәр яшәгән юнан яки грек галиме Аристотель тарафыннан ныклап өйрәнелүе аның барлык телләр диңгезендә чыннан да алтын балыктай йөзеп йөрүе турында сөйли. Тукайның чагыштыру белән җиңел, өлгер эш итүен мин елына бер генә мәртәбә күренеп киткән Өлкәр йолдызы белән чагыштырыр идем.

Янә шул үзенчәлекне дә әйтергә мөмкиндер. Г. Тукайның сурәтләү-тасвирлау чаралары бер-берсе белән дә, төрле лексик мәгънәле (исем, сыйфат, сан, рәвеш, алмашлык, фигыль) сүзләр белән дә эчке яктан органик мөнәсәбәткә керәләр. Ул мөнәсәбәтлелектә сүз-сурәтлелек тә, мәгънә дә, хис-тойгы да бар. Алар, ничектер, бер-берсе белән чылбыр дүңгәләкләредәй бәйләнә.

Поэтика чылбыры дип атарга да мөмкиндер аны. Тукай үзе яраткан мөбарәк тәсвих төймәләре дияргә була. “Мужик йокысы” исемле шигырендә болай ди шагыйрь: “Синең өй бадчыктай, Бөкрәйгән карчыктай”. Бәләкәй өйне тавык кетәгенә охшату әүвәл-әүвәлдән килә. Шулай да бөкрәйгән карчык — образлырак. Шул чордагы бөтен ярлылыкны күз алдына китереп бастыра бит ул. Әлеге “Көзге җилләр”дәге җил бармак белән төртсәң аварга торган бөкре карчыктай өй өчен дә әрнеп җылый бит ул. “Ачлык падишаһ”тагы хәерчелек тә шуның белән бәйләнгән. Менә эштән чыгарылган татар кызы. Ул чатта баганага сөялгән. Аның бөтен кайгысы, йөрәк тетрәнүе, күңел ярасы сары яфракка әверелгән йөзендә чагыла: “Сөялгәнсең чатта баганага, Яфрак төсле сары йөзләрең”. Яфрак көзен саргая. “Көзге җилләр”дәге җил татар кызының бу авыр язмышы өчен дә җылый. Ачлыктан чебендәй каткан ир, бөкрәйгән карчыктай балчык өй, сары яфрактай йөз — барысы да яралы йөрәкле, авыр язмышлы, караңгы көнле ил фаҗигасе. Кол Галидәге гәүһәр яшь — мәхәббәткә бәйле образ. Тукайдагы яфрак төсле сары йөз — бөтен ил афәтен чагылдырып торучы образ. Чагыштыру өчен алынган

өч әйбер-предмет (чебен, өй, яфрак) стилистик яктан әнә нинди киң канатлы Тукайда.

Бөтен табигатьнең үзендә дә, аның кочагында яшәгән кешеләр күңелендә дә, югарыда телгә алынган гөл, үләннәрдә дә күпме серлелек, сихрилек. Карбыз эчендәнге бәләкәй генә кара орлыкта да зур тарих вакыйганы чагыштырып күрсәтү хәсияте яшеренгән икән. “Карбыз — Пуришкевич вә этбагының (иярченнәренең) башы. Эче тулы кара орлык”. Халыкта мондый чагыштыру юк. Кем ул Пуришкевич? Дәүләт думасында иң уң канаттагы депутат, монархист. Кыска гына чагыштыру. Ләкин бик серле. Эчендә зур мәгънә. Азатлыкка теше-тырнагы белән каршы торган монархист реакция елларында, җилкәсенә заман бүрәнәсе төшүдән куркып, кызыллана башлый, хөкүмәтне халыкка хөррият бирмәүдә гаепли. Карбызның эче кып-кызыл булса да, ул кызыллыкта кап-кара орлык эшләнгән бит. Кара орлык — кара уй ул. Ил каралыгын яшерергә маташучы мөнәфыйк уй. Ә менә кавын — татар гөләмәсенең башы. Аның орлыгында башка хикмәт бар икән: “Кавын — бу җимеш татар гөләмәсенең башы. Моның орлыгын ярган кеше сиксән хокып тәмугта яначак. Һәр хокып сиксән ел бугай”. Бу соңгы мисал Тукайның “Хәзер җиләк-җимеш вакыты” исемле әсәреннән алынды.

Анда янә чөгендер, бәрәңге, кабак, кәбестә, арыш, бодай, солы, арпа, сарымсак, миләш, шомырт, борчак, җир җиләге, кура җиләге, суган, шалкан кебек җиләк-җимешләр чагыштыру объекты итеп алына. Алар эчендә чагыштыру өчен гаҗәп кызык зәррә, күзәнәк, төртке бар Аларны бөркет күзле, сандугач колаклы Тукай тиз таба ала. Әнә нинди икән чагыштырудагы өслүби хосусиятның танып-белү белән бәйләнеше. Әсәр азагында ул зәррә, күзәнәк, төрткеләрдәге хәрәкәтне, ныклылыкны аңлауның авырлыгын Тукай үзе дә яшерми. Шалкан турында язганда ул болай ди: “Шалкан-кызлар күкрәге. Авыл егетләренең күн бияләй кеби каты кулларына шулай тоела, ди. Йомшагырак куллы кеше помидор дияр иде. Ләкин авыл Гайнетдине белән бәхәс итеп буламыни!” — ди дә авызыңны каплый. Кызыл вә кара карлыганны, бүтән исем табудан “гаҗиз” булганлыгымнан, ашый торган мәрҗән дип кенә атыйм.

Барлык җиләк-җимешнең хәлен чорт белеп бетерә аның! Аны мин түгел, башына җилпуч күтәреп: “Малина! Малина! Хорош! Малина! Бикторый! Бикторый!” дип кычкыручы мөттәхассыйс (белгеч — **С. П.**) Казан татары да белә алмас”.

Менә ни өчен, немецлар әйткәнчә, һәр чагыштыру аксый, французлар әйткәнчә, һәр чагыштыру дәлилләү була алмый икән. Безнең әсәрләрдәге “аксаган” чагыштыруларны җыя башласаң, Бөек Ватан сугышы елларында гарипләнеп аксаган солдатлар санынча гына түгел.

“Гыйшык уты” исемле әсәрендә Тукай әллә нинди, әллә кайдагы әйбер-предметларның эчке һәм тышкы сыйфатларын өйрәнеп чагыштыру

ясый: мәскәүески дуга кеби кәкре каш, Себер заводларында житешкән чем-кара атлар койрыгыдай озын чәч, кытайский чынаяк төсле зур күзләр, галанский мич кебек йөзләр, бохар кавыннарыннан да йомры башлар, Җаек, Оренбург ягыннан килгән куй мае берлән генә майланган сач, Агыйдел камышлары арасында качып чебен аулаган бакалар төсле, Шам шәриф мәдрәсәләре почмагына корылган чаршаулар кеби киң аклы күлмәк, мәккәи Мөкәррәмә вә Мәдинәи мөнәүвәрә төяләре авызындагы “зәгъфыраннар” кеби чәйнәгән сагызларың, Сәет-Баттал Газиның киерелгән җәясе кеби авыз ерып көлү һ.б.

Шушы урында әлеге Өлкәр йолдызны янә искә аласы килә. Ул башка йолдызлардагы хәл-әхвәлләрне тикшереп оча, имеш. Әллә Тукайның күзе йолдыз үземе? Барлык геометрик җисемнәрнең йөрәгенә нур булып керәме? Шулай икән, Тукайны җанлы һәм җансыз җисемнәр табибы дип атарга да мөмкин бит.

Әдәби әсәрләр телен өйрәнү белән мин Казан дәүләт педагогия институтының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә укыган елларда кызыксына башладым. Студент чакта “М. Җәлил поэзиясендә чагыштырулар һәм аларнын әдәби әсәрнен идея-эчтәлеген ачудагы роле” дигән темага фәнни мәкалә язарга җөрьәт иттем. Ул, шөкер, бернинди үзгәрешсез басылып чыкты (Казан, “Совет мәктәбе”, 1956, №1). Аннан әдәби телебезнең энҗе-мәрҗәннәрен, гәүһәрләрен Тукай Тел диңгезеннән чүпләргә керештем. Казан дәүләт университетының татар теле бүлегендә проф. М. Зәкиев җитәкчелегендә аспирантурада укыганда “Татар телендә чагыштырулар” дигән темага кандидатлык диссертациясе язып якладым. Хезмәтнең үзәгендә (башыннан алып азагынча). — Тукайдан алынган мисаллар. Чөнки башкаларның әсәрләреннән эзләгән иң кирәкле чагыштыру формасын табып булмый. Бер генә мисал. А. И. Ефимов “О языке художественных произведений” дигән хезмәтендә рус телендә синтаксик бөтеннәрдә белдерелгән катлаулы чагыштыруларның 3 төрен күрсәтә. Бармы болар татарда? Җиң сызганып, тирләп-пешеп, шуларны эзләргә керештем. Нәкъ рус телендәгечә булган 3 катлаулы чагыштыру төзелмәсен Тукайдан таптым. Шатлыкның чиге юк. Мин, гүя рус телендәге синтаксик бөтеннәрдә белдерә торган чагыштыруларның татар телендә дә булганлык яңалыгын гына ачмадым, әлеге Өлкәр йолдызның үзен тотып алу бәхетенә ирештем. Фикер йөртәм: татар теле — бай, шуңа күрә Тукай теле бай!

Тукта! Алай гына да түгел бу. Күңелем белән чал тарихка сәяхәт ясыйм. Кыпчак далаларында йөрим. Әлеге сабах җиле белән киңәшләшәм. Сабах җиле колакка бер хәбәр әйтә. Ислам дине кабул ителгәч, төрки телләргә гарәп сүзләре дулкын-дулкын булып агыла. Шуннан төрки телләр “ярлылыкта” гаепләнә башлый. Иң бай тел — гарәп теле, янәсе. Төрки телләрдә фәнни хезмәт тә, әдәби әсәрләр дә язып

булмый, имеш. Чынлык белән ялганлыкны Ходай аера. Хаклык өскә чыга. Хаклыкка хөкем юк. Унберенче йөз галиме Мәхмүт Кашгарый хакыйкатьне исбатлый торган Алла илчесеме әллә. Исем белән фигыльләрне җыеп, аларны мәгънәле кисәкләргә яки морфемалар бүлеп, төрки телләрнең бик ерак тамырлы бай тел икәнлеген, морфологик яктан нык катлаулануын, гарәп теленнән бер дә ким булмавын исбатлый.

Чү! Нигә мин Кыпчак далаларында адашып йөрим әле? Каюм Насыйри бабабыз бар лабаса. Фигыльләр буенча гына фикер йөрткәндә, татар теленең дөньядагы иң бай телләр сафында торырга хаклы гына түгел, алардан өстен яклары булу турында да әйтә бит ул.

Шуларны уйлап, янә җиң сызганып, дигәндәй, синтаксик бөтеннәрдә белдерелгән катлаулы чагыштыру формаларының янадан-яңа төрләрен эзләргә тотындым. Чокына торгач, Тукайдан янә дүртне таптым. Татар телендә, димәк, җидәү икән алар. Менә нindиләр: тәңгәл чагыштыру, кире чагыштыру, капма-каршы чагыштыру, читләтеп чагыштыру, нәтиҗәле чагыштыру, җәенке чагыштыру, катлаулы чагыштыру. Алар бик күп урынны ала. Шуңа күрә мисаллар китереп тормыйбыз.

Кабатлап әйтик: татар теле — бай тел. Шулай түгел икән, Тукай теле бай булмас иде. Тукайга булган мәхәббәтем — татар милләтенә карата булган мәхәббәтем кебек. Тукай теле диңгезенә шул кайнар мәхәббәтем белән чумам. Ул диңгез төбеннән алып чыккан тел гәүһәрләрен халыкка бирергә тырышам. “Тукай сатирасындагы чагыштырулар”, “Тукай әсәрләрендә чагыштырулар”, “Бәйлекләр ярдәмендә ясалган чагыштырулар (мисаллар Тукай әсәрләреннән)” кебек фәнни хезмәтләр бастырдым. Башкорт дәүләт педагогия институты (хәзер университет) “Мәктәптә Г. Тукай әсәрләре телен өйрәнү” дигән уку-укыту әсбабымны бастырып чыгарды. Рәхмәт аларга!

Гомәр Бәширов әйткәнчә (җаны җәннәттә булсын), егерменче гасыр башында татар поэзиясен Г. Тукай, татар прозасын Г. Ибраһимов ачты. Мин аларның телен тәңгәл өйрәнәм. Тукай теле берьяклап бай. Ибраһимов теле икенче яклап бай. Алар арасындагы аермалылык куп очракта очраша. Чагыштыру формалары икесендә дә 50 чамасы. Мәсьәлә санда түгел дия күрмәгез. Кайберәүләрдә ул 5-6дан да артмый. Гел бер төрле ризык-нигъмәткә ризалашып яшәгән ярлы кеше кебек, гел бер төрле форманы кабатлыйлар. Алары да “аксак” була. Тукай белән Ибраһимов кебек горур затлар “аксау” белән килешми, үзләрен Сәет-Батталның киерелгән җәяседәй тоталар. Тукай теле бай. Бу — бәхәссез. Ләкин аның белән генә барыбер татар теленең байлыгын бөтен тулылыгы белән күз алдына китереп бетереп булмый әле. Моның өчен Г. Ибраһимов кирәк, 2003 елда рус телендә “Роль Г. Ибрагимова в развитии татарского литературного языка” исемле шактый калын китабым дөнья күрде (13

табак) “Татар теле шулай баймыни соң ул?” — дип гаҗәпләнде мөхәррирем. Л. Н. Толстой дәрәҗәсенә куйды Г. Ибраһимовны. Тукай Пушкиннар сафында, Ибраһимов — Толстойлар сафында. Татар халкының бөеклеге түгелмени бу?

Тел – милләт көзгесе. Милләтебезнең бөеклеген сүз сәнгате осталары теле аша да күрсәтергә вакыт җиткәндер. Тукай теле турында Г. Әмиров докторлык диссертациясе яклаган иде. Ләкин ул теле аша Тукайның эстетик идеалы дөньясына керә алмады. Шуңа күрә Тукай теле турындагы докторлык диссертациясе дөнья күрмәде, заман давылы алып килгән ком астында күмелеп калды. Бу мине нык борчый. Кояштай балкыган дүрт шәхес турында фикер йөртәбез: руста — Пушкин, татарда — Тукай, казахта — Абай, әзербайҗанда — Ахундов. Пушкин теле турында дөнья күргән калын-калын томнарның, яклаган докторлык, кандидатлык диссертацияләренең саны юк. Сыздыкованың Абай теле турында бастырган хезмәте дә данлыклы. “Тукайның шигъри осталыгы” (Ә. Исхак, Казан, 1963) турында язылды, әлбәттә. Ләкин ул бүгенге көн таләпләре югарылыгында түгел. Тукай теле чын мәгънәсендә тирән, фәнни, лингвистик анализ ясауга мохтаҗ. Шул җәһәттән мин фәкыйрегез Уфада 2004 елда калын гына (12 табак) янә бер хезмәт нәшер итте. “Г. Тукай поэтикасында чагыштырулар” дип атала ул. Шушы ук елда “Г. Ибраһимов поэтикасында фразеологияләр” дигән китабым да дөнья күрде. Шушы ике хезмәтемдә (атамалары ук охшаш) татар даны нурын төрки даирәсенә генә түгел, әллә кайларга таратучы ике бөек шәхеснең рухи дөньясы, эстетик иманы, милләт каһарманы булу тойгысы, талант ялкыны, йөрәк кодрәте кавыша. Кавыша, кул бирешә һәм кочаклаша. Татар сүз сәнгате үсеше ягыннан гына караганда да, ай белән кояш нурында ләззәтләнеп яшәгәнебез кебек, аларның икесеннән дә бертигез рухи шифа алып шатланышабыз. Баланың ата-анага бердәй мәхәббәт вә сөю илә карагандай, Тукай теле турында язам икән — Ибраһимовка, Ибраһимов теле турында язам икән — Тукайга табынам. Чөнки алар бер-берсен тулыландыра. Энҗегә — мәрҗән, мәрҗәнгә энҗе өстәгәндәй. Хөрмәтле милләттәшләрем! Алар арасында чөй кагудан тукталыйк, зинһар! Вакланмыйк! Аларның үзләре кебек горур булыйк! Айга күпме генә йодрык күрсәтмә, аннан гына аның бер генә зәррәсе дә кителми. Үз дәрәҗәң кителә.

Соңгы сүз. Тукайның тел диңгезенә һаман чумам әле. Бер аркылы, бер буй йөзеп, төбенә үк төшәм. Аннан сүз гәүһәре чүплим. Бу диңгез бик киң дә, тирән дә. Шифалы да. Анда чумып чыксаң, үзеңне оҗмахтагы Кәүсәр күлендә коенгандай хозурлык тоясың. Тик минем Тукай теле турында бастырган мәкаләләрем, уку-укыту әсбабым, “Тукай поэтикасында чагыштырулар” дигән хезмәтем мәшһүр сүз сәнгате остасының талантын бик аз ачыклый әле. Ә инде бу мәкаләдәге мисаллар

— Тукай теле диңгезеннән бер тамчы су алып күрсәтү генә. Тукай язы ел да үткәрелә. Яхшы. Әмма Тукай бөеклеге коры сүзләр белән генә аңлатыла. Дөресен генә әйткәндә, аңа да көч-кодрәтебез җитми. Күтәрелмәгән чирәм уңыш бирми. Тукайның образлы, сәнгатьле, бай теле — күтәрелмәгән чирәм әле. Мин сөрә генә башладым шикелле. Башкалар да кушылыр, бәлки. Тукайга булган мәхәббәтебезне "коры" сүз белән генә түгел, аңа карата зур иҗтиһадлылык белән күрсәтик!

Дәрдмәнднең сүз алтыны

Сүз! Ул — язучының төп коралы. Бу корал эчендә алтын бар. Дәрдмәндне "алтынчы" дип тә йөрткәннәр. Ул — алтын приискалары хуҗасы. "Шагыйрьнең алтын приискасында" дигән повесть та яза М. Гафури. Җирне казып, балчык арасыннан алтын бөртекләре тапкан нинди авырлыклар кичерелсә, сүз эчендәге алтынның кыйммәтен мәгънәсен ачаклау өчен дә шундый ук мәшәкать - кыенлыклар белән газапланырга туры килә. Сүз кадерен белү әллә шуннан киләме Дәрдмәндкә?

Сүз эчендәге алтынны төрле сүз сәнгате остасы төрле өслүби (стилистик) максатта куллана. Дәрдмәнднең Татарстан китап нәшрияты тарафыннан 1980 елда чыгарылган җыентыгы "Исә җилләр" дип атала. Җил эчендә нинди стилистик алтын бар? Нәрсәне аңлата бу атама-җилләр, үтә гомерме? Аны бит теләсә нинди шагыйрьгә карата кулланып була. Дәрдмәнд җил образына күп мөрәҗәгать итә. Эстетик идеалын чагылдыру өчен кирәкме? Алай дисәң, җил Тукайда да, Такташта да, Г. Ибраһимовта да, М.Җәлилдә дә күп бит.

Алай гына да түгел. Борынгы ата-бабаларыбыз яшәгән Кыпчак яланындагы җил символик образ сыйфатында файдаланылган. Бу җил кыпчакларга тагын да ераграк тарихтан исеп килә. Аның шулай икәнлеген Ягькуб пәйгамбәр сагышы аша да беләбез. Мәгълүм ки, Ягькуб пәйгамбәрнең йөрәк парәседәй якын күргән сөекле, миһырбанлы, шәфкатьле улы Йосыфны туганнары коега сала. Кайгыдан Ягькуб пәйгамбәрнең рухы сына, сабырлык уты сүнә, ахыр чиктә күзләре сукрая. Ул чорда күп кавем өчен символик сүз-сурәткә (образга) әверелгән иртәнге сабах җиленә кайгысын сөйли пәйгамбәр:

Акрын искел, сабах йиле, нә үтәрсән,
Хакыйкать Йосыфымнан ис дотар сән.
Җәрәхәтем уңалдырмага сән исәрсән,
Сән искәли шат-хөррәм улдым имди.

Алсу таңнар матурлыгына төренеп искән иртәнге, латиф, йомшак сабах җиле пәйгамбәрнең чәчкәләреннән сыйпый, куеннарына тула, бит очларыннан үбә, Йосыфның дөньяда барлыгы, кешелекле, миһырбанлы, батыр йөрәкле булуы турында сөйли. Шуннан пәйгамбәрнең югалган күз

нурлары кире кайта, күңеле матур хис-тойгылар белән шатлана, йөрәге тынычлык хозурлыгы белән бәлзәмләнә. Аның күзләре күрә башлый.

Дәрдмәндтә "сабах", фонетик яктан бераз җыйнакланып, "саба" дип кулланыла башлый. Ничек кенә булмасын, бик борынгы ата-бабаларыбызның изге, мәрхәмәтле, шәфкатьле бу җиле нәфис сүз сәнгатендәге образлылык (кеше сыйфатына керүе), идеялелек (мәгънә аңлатуы), эмоциональлек (хис-тойгы белдерүе) сыйфатын югалтмый. Кандалыйда ул мәхәббәт хәбәрчесе буларак файдаланыла. Дәрдмәндтә дә шул вазифаны үти. Мәгәр өслүби алтын кинәя, кыйммәтләнә, зурая бара. Әлбәттә, ул шагыйрьнең җир астыннан җисмәни көч белән казып алган алтыны, түгел, аң-акылы, хис-тойгысы даирәсендә кайнаткан рухи алтыны. Чөнки ул Ватан төшенчәсе, туган җир бавыры белән бәйле:

Әгәр барсаң, саба җил, безнең илгә,
Сәламнәр әйт, сәлам ул нечкә белгә!
Төшендә юл өчен чәчкәен тарасын,
Гарипнең кайтырындан фал карасын.
Ходаеннан кавышмаклык сорасын,
Сәләмнәр әйт, сәлам ул нечкә билгә!

“Җил йөрәкне җилкетә", "җил чәчтән сыйпый", "җил иркәли", "җил хәбәр сөйли" ...нинди генә гыйбарәләр ясалмый "җил" сүзе белән. Дәрдмәндтә җил егермәләп урында кулланыла. Әдәби әсәрнең һәр тукымасына ул үз эчендәге алтыны белән килеп керә. Һәр алтын мөкатдәс, илаһи, яшерен хис-тойгылар белән бәйле. Казып алынган алтынның гәүһәр сыйфатын тиз генә белә алмагандай, сүз эчендәге алтынның да өслүби дәрәҗәсен җәһәт кенә ачыклап булмый. Хәзерге егермеләп җилнең берсенә генә тукталмыйк. Егерменче гасыр башында бигрәк тә 1905-07 еллардан соң, дөнья хәле, яшәү рәвеше, сәяси рух, ижтимагый фикерләү, шул чордагы тарихи шартларга бәйле буларак кинәт кенә үзгереп китә. Бәгъзе зыялының бер күзе - туган туфракта, икенчесе — чит илдә. Ничек кенә авыр тоелмасын, күзләр аерыла туган җирдән, язмыш аларны чит илгә канатландыра. Дәрдмәнд тә канатын очарга ныгыта. "Видаг!" дигән шигырендә ул шундый юллар яза:

Тәгәрәп-аунап
Буй үскән
Туган илем, исән бул!
Чәч кузгатып
Җай искән
Таңгы җилем, исән бул!
Йөгреп-Йөгреп
Туктаган...
Яулык болгап
Сыктаган

Нәзкәй билем, исән бул!

Хәзер "саба җил" түгел инде. "Саба" элекке латиф, хис-тойгы кодрәтен, йөрәк шифасы булу сәләтен югалтып бара. Шулай да "таңгы җил" барыбер эмоциональлек белән бәйле. Таң җиле белән хушлашу — Ватан белән аерылышу. Әмма беркая да китми Дәрдмәнд. Сөекле, яраткан, җаныдай якын күргән туган илендә кала. Чәч кузгатып җай искән тан җиле Ватан кулы дип кабул ителә. Нәзкәй бил — мәхәббәт алтыны.

Шигърият, билгеле, күчерелмә мәгънәлелекне ярата. Бу очракта сүз эчендә яшеренеп яткан алтын бөртегенең күп мәгънәсе ачыклана. Аз сүз белән күп мәгънә аңлата торган нәфис сүз сәнгате остасы Дәрдмәнд аларның төрле хосусиятләрен күрсәтә. Йосыф Баласагуни "Котодгу белек"тә (XI гасыр) болай дигән иде:

Азмы дәүләт-илләр җан-тәслим итте,
Үлмәс тойган патшалар бар да китте.

Бу — табигый хәл. Бернәрсә дә мәңгелек түгел. Туа. Камилләшә. Бетә. Моңы Йосыф Баласагуни, сүз эчендәге алтынны эзләп тормыйча турыдан-туры әйтә. Дәрдмәнд өслүбе өчен ул бик килешеп бетми. Ул күчерелмәлелек белән эш итә. "Без" дигән шигыреннән ике юл:

Исә җилләр, күчә комнар бетә эз...
Дәрыйгъ, мәхзүн күңел, без дә бетәбез!

Җил образы биредә зур үзгәреш булачакны аңлата. Әнә шунда яшерелгән мәгънә алтыны. Укы. Эзлә. Тап. Г. Ибраһимов әйткәнчә сәнгатьле сөйләмдә әдип мәгънәне яки идеяне үзе түгел, аның сүзләре аңлатып торырга тиеш. Бу югары сәнгати осталык белән бәйле. Барыбызга да мәгълүм "Кораб" исемле шигырендә бу осталыкның классик үрнәген күрсәтте Дәрдмәнд. Шигырь дә җыйнак. Строфа да. Сүзләрдәге мәгънә нык тыгыз. Берничә төр ашлык бөртекләре җыелмасы талкып пешерелгән талкандай тәмле, үзле, туклыклы.

Шаулый диңгез..
Җил өрәдер.
Җилкәнен киргән кораб!
Төн вә көндез
Ул йөздер:
Юл бара ят ил карап...
Купты тулкын -
Ил корабын җил сөрә!..
Чыкты җилләр.
Кайсы юллар, нинди упкын
Тарта безне җан сорап?!.

Г. Ибраһимов "Безнең көннәр" романын шулай башлый: "Төн караңгы. Дөнья тын. Ләкин диңгез шаулый". Диңгез — матурлык,

батырлык, гайрәтлелек символы. "Шаулый диңгез..." ди Дәрдмәнд. Чәчмә әсәрдә шигъри сәнгатьлелек, шигърияттә прозага хас эпик киңлекне күрсәтүче ике классик диңгез шаулавы аша киләчәктә зур тормыш шаңдавы булачакны искәртә. Г. Ибраһимов романындагы дулкын сүзе сюжет чалбырының җанына, канына, йөрәк тибешенә бәйләнеп китә. Әллә күпме зур тарихи вакайгаларны, сәяси иҗтимагый хәлләрне, тормыш көнкүрешен, әсәр каһарманнарының рухи дөньясын ачыклауга ярдәм итә. Ике классикта да дулкын сүзендәге стилистик көчне җил куәтли.

Югарыда җилнең Тукайда да, Такташта да бихисап булуы хакында әйтелгән иде. "Көзге җилләр" исемле шигырендә Тукай болай ди:

Көзге төн.
Мин йоклый алмыйм.
Өй түрендә җил җылый.
Җил җыламый, ач
Үлемнең куркуыннан ил җылый.

Биредә дә җил образы кеше сыйфатын гәүдәләндерә. Идеясе — шул чордагы хәерчелекне чагылдыру. Эмоциональлеге — хис-тойгыга тәэсир итү. Фәлсәфә фәненең гомумилек, бердәнберлек, аерымлылык теорияләре калыбына салып карасак, гомумилек өстенлек ала. Сүз Ватан язмышы турында бара.

Такташның "Газраиллар" дигән шигырендә дә шул ук мәүзуг яки тема. Шигырь 1916 елда язылган "Газраиллар" (1914 нче елгы Европа сугышына каршы) диелгән. Димәк, 15 яшьлек Такташ беренче империалистик сугышка анализ ясый. Шигырьнең җан, кан агышында – фәрештә һәм җил образы. Тау өстендә утыра фәрештә. Уйга баткан. Канатлары талган килеш җиргә яткан. Маңгаенда — нурлы йолдыз. Күзләренең шәүләсеннән офыкларда таңнар аткан. Фәрештә моннан күп еллар элек бу Йолдызга (җиргә) күктән очып килгән була. Җирне җәннәт итә. Янә әйләнеп килсә, сөякләрдән өелгән таулар, каннан җыелган күлләр күрә. Сугыш. Үлем. Җил болай ди: "Фәрештәкәй, кач бу илдән! Монда вәхшәт! Монда үлем! Монда патша - газраиллар".

Димәк, Дәрдмәндтә җил ил корабын сөрүче, Тукайда ил хәерчелеге өчен елаучы, Такташта ил вәхшәтен фәрештәгә сөйләүче сын-образ буларак файдаланыла. Җыеп әйткәндә, өч классикның эстетик идеалын Ватан язмышындагы җил образы аша тасвирлана. Стилистик "паспорт" бирү ягыннан караганда, кем җиле көчлерәк икәнлекне ачыклау да кыен кебек. Тукай җиле ил эчендә ду килеп исә. Такташ җиле дә шулай. Ләкин аларның хәрәкәте билгеле бер вакыт белән чикләнә. Ә Дәрдмәндтә ул күңелне киләчәк ерак офыклар даирәсенә алып китә. Әле дә кайсы юллар нинди упкын жансорап тарту турында уйланабыз.

Ватан сүзенең эчке мәгънәсендәге алтынны сәнгатьчә чагылдыру

өчен каләм остасының илаһилыгы очраша. Ләкин аларның сүз иманында үз хосусиятлек бар. Өслүб шул яктан аерыла. Шулай да аның орлыгы тамыры, нигезе — халыкта. Туган туфракта. Ил куенында. Туфрагыннан аерылып кайда гына китмәсен, үз җилен сагына кеше. Бу хакта аның җыры бар:

Исә җилләр, исә җилләр,
Ул минем җилем түгел;
Чит илләрдә бик ямансу,
Уз җилен сагына күңел.

Ил алтыннар, көмешләр, чәчкәле болыннар;ундырышлы җирләр, серле урманнар, аккошлы күлләр, саф сулы елгалар белән матур, бай, хозур. Кешенең кендеге, җаны, каны, тәне, рухы, илаһы шулар белән бәйле. Ватан җиле — гади җил түгел. Аның шулай икәнлеген ерак тарихта халкыбыз иҗат иткән җырлар да чагылдырып тора. Без аны Дәрдмәндтә, Тукайда, Такташта да күрәбез. Янә Г. Ибраһимовта җил карт агачны төбе-тамыры белән алып ыргыта. М. Җәлилдә җил Бөек Ватан сугышында батырлыклар күрсәткән солдатлар турындагы хәбәрне алып килә. С. Хәкимдә җил эшче-нефтьче характерын ачыклауга ярдәм итә. М. Галинең "Кояш җиле" исемле поэмасында җил җир кешенең космос булган мөнәсәбәтен белдерә.

Димәк, җилнең стилистик колачы һаман киңәя бара. Бу киңлектә Дәрдмәнднең эстетик идеалы һаман хәрәкәт итә. Күчерелмә мәгънәдә әйтелгән "Ил корабын җил сөрү"не вакыт белән генә чикләп булмый.

Дөньяда поэзиянең беренче таҗы булып исәпләнгән Байрон осталыгы бар Дәрдмәндтә. Лермонтов яза башлаганда ук шигърияттә Байрон югарылыгын яулау максатын куя. "Пушкин, Лермонтов, Тукай өч йолдыз ул", — ди Тукай. Дәрдмәнднең сүз алтынын белеп эш итүе бөтен дөньяга мәгълүм. Мәскәүнең "Художественная литература"да чыгарылган җыентыкта Дәрдмәнднең 13 шигыре бирелә.

Нәфис сүз сәнгате остасы булу ягыннан караганда, без аны теләсә нинди жанрда иҗат итүче белән чагыштыра алабыз. Төрле лексик мәгънәле сүзләрнең (исем, сыйфат, рәвеш, алмашлык, фигыль) эчке мәгънәсендәге алтынны аңлап эш итә ул. Әйтик. Г. Ибраһимов “Көтүчеләр" хикәясендә "Мин түбәннән күтәрелдем" ди. Ә "Казыл чәчәкләр" әсәрендә шул ук җөмлә "без" алмашлыгы белән башлана. Ни өчен? Нигә Дәрдмәнд бер әсәрен "Без" дип атый? Мин (берлек), "без" (күплек) алмашлыкларының эчке мәгънәсендә сүз алтыны сере бар.

Шигърияттә сүз алтыны зур мәгънә белән бәйле. Югарыда телгә алынган сүз-сүрәт (образлылык), мәгънә (идеялелек), хис-тойгы (эмоциональлек) бирсә генә җитмәсен, поэзия яфраксыз агачтай була.

Ватан — зур төшенчә. Әмма эмоциональлекне дә ярата. "Каһым түрә" дигән тарихи риваятьтә ил нәзек билгә чагыштырыла: "Һай, илкәем,

нәзек билкәем". Дәрдмәндтә: "Нәзкәй билем, исән бул!", "Сәләмнәр әйт, сәлам ул нечкә билгә!"

Дәрдмәнд алсу таңга, зәңгәр күктәге зәбәрҗәт йолдызларга, нурлы айга кайнар кояшка эчке бер хис-тойгы йөрәк мөкиббәнлеге, күңел шәфәгатьлеге белән карый, һәр күренештән образлылык алтыны эзли. Ул алтынны үз йөрәге, ил йөрәге, дөнья йөрәге, галәм йөрәге белән оста бәйли, югары стиль, түбән стиль, урта стиль сүзләрен әсәр тукамасына яраклаштыруның классик өлгеләрен күрсәтә. Бер мәкальдә аларның барсына да тукталу мөмкинлеге юк. Кыскасы, шагыйрьнең сүз алтынына ныклы анализ кирәк. Моның өчен шактый калын хезмәт язу таләп ителә.

Бер сүздә мең бизәк
М. Гафури

Телнең коммуникатив (фикер алышу), эстетик (матурлык) вазыйфасы бар. Һәр һөнәр иясе: врач, агроном, укытучы, инженер... хәзинәсендәге бер үк сүзләр ярдәмендә фикер алыша. Фикер алышуга ярдәм иткән шул сүзләр әдәби әсәр тукымасында язучы тарафыннан төрле стилистик-экспрессив максатта кулланыла. Сүзләр ярдәмендә төрле поэтик бизәкләр барлыкка килә, герой-персонажларның дөньяга карашы, рухи дөньясы, психологик кичерешләре, әдәби әсәрнең идея эчтәлеге ачыклана. Тормыш-көнкүрештә кулланылып йөргән гади генә сүз дә образ-символ дәрәҗәсенә күтәрелә. Чын мәгънәсендә нәфис сүз сәнгате остасы булган язучы бер үк сүзне төрле контекстта төрле стилистик чара сыйфатында файдалана белә. Икенче төрле әйтсәк, сүз анда көтелмәгән ягы белән ачыла. Бер үк сүз белән яңа мәгънә аңлатканда сүзнең яңа, эчке сыйфаты ачыклана яки "иске" сүзгә яңа мәгънә салына. М. Гафури "Беренче май" дигән шигырендә болай ди: Әмма бу бәйрәмдә эчми дә матур гөлләр өзәм, Иске сүзләрне жыеп, шуннан яңа жырлар тезәм. Бу шигырь 1922 елда язылган. Чынлап та, анда бер генә яңа (неологизм) сүз дә юк. "Иске" сүзләр яңа төшенчә алган. Юл, мәсәлән, гомумкулланылышлы гади сүз. Бу шигырьнең поэтик тукымасында ул иске, караңгы тормышны җиңү, матурлык, яңалык төзү, халыкның физик һәм рухи көчен, җегәрлеген, каһарманлыгын чагылдыру символына әйләнгән.

Гөл халык телендә, жырларда, гомумән, сәнгатьле сөйләмдә матурлык символы сыйфатында кулланыла. Бу әсәрдә ул, минемчә, батырлык символы да. Авторның матур гөлләр өзәм дип әйтүе шигъри юллар өчен поэтик яңгырашлы, эчке мәгънәгә бай булган, тәэсирле, эмоциональ сүзләр эзләвен аңлата. Гөл кебек сүзләр белән язылган әсәр халык күңеленә зур идея, эстетик зәвык, яшәү рухы бирергә тиеш. Бу шигырьнең икенче бер урынында шагыйрь нәкъ шул хакта әйтә дә:

Зур идея, изге юл өстенә
Кадап куеп гөлләр бәйләмен,
Җырлап-җырлап чиксез шатлык белән
Итик зур җиңү бәйрәмен.

Әлеге киң юл зур идея белән эчке яктан органик мөнәсәбәткә керә. Зур идея, изге юл өстенә кадап куелган гөлләр бәйләме — матурлык һәм батырлык символы, чөнки ул җир йөзендә прогрессив көчләрнең җиңүен, матур тормышның тантана итүен символлаштыра.

М. Гафурида кояш, энҗе, йолдыз, имән, су, яшен, ай, дулкын, болыт, алтын, көмеш, якут, гәүһәр, бакча, күз, кан, чәчкә, җил, нур, чишмә, тамчы, күз нуры, капка, лачын, арыслан, былбыл, сандугач, ут, давыл, күңел, көн, йөрәк, кар, уй, дәрәҗә кебек конкрет һәм абстракт исемнәр, төрле-төрле яңа мәгънә белдереп, төрле сурәт ясау, образ тудыру максатында кулланылалар.

Сүзнең эчке мәгънәсен, образлылык нигезен, эстетик куәтен, стилистик максатта кулланылганда нинди яңа сыйфатлар белән характерлавын тирәнрәк аңлау өчен, аны язучының берничә әсәре тукымасында карау яхшы. Әлбәттә, образлылык, күчерелмә мәгънәлелек сүзнең семантик нигезендә барлыкка килә. Сүз төркеме булу ягыннан карасак, алтын — конкрет исем. Халык телендә ул матурлык кыйммәтлелек, сафлык, ныклык, дәрәҗәлелек символы булып йөри. Әдәби әсәрдә исә башка мәгънәдә дә кулланылырга мөмкин. М. Гафури мәсәлән, 1905-1917 елларда язган шигырьләрендә аны егермегә якын урында куллана, һәр урында ул яңа мәгънә аңлата. Туган җирне, туган туфракны зурлау: "И җирем, алтын кеби күренә синең туфракларың" ("Сабанчының җыры"); хакыйкатьне аңлату: "Җир өстендә кайчан бетәр алтын, шунда чыгар хаклык" ("Хакыйкать"); сатлык җаннарны фаш итү: "Кем бар соң сары алтынга сатылмаган, үз-үзен алтын белән шат кылмаган" ("Сатлыклар"); намус, вөждан, күңел сафлыгын саклау: "Вөжданымны сатмыйм алтын, көмеш һәм энҗегә" ("Вөждан теләге") һ.б.

Сүзнең эчке серен, гаҗәп нечкә нюансларын, сәнгатьле сөйләмдә күптөрле җанлы картина, образ тудыру мөмкинлекләрен тагын да ныграк аңлау өчен, аның берничә язучы тарафыннан нинди максатта фаланылуына да игътибар итәргә кирәк. Дөрес, ул кайчакта вакыт белән дә чикләнә. Әйтик, җәй дә, көз дә без мамыктай ап-ак карны, кар бураннарын, кар өемнәрен сагынабыз. Кар күп яуган елда икмәк уңа. Димәк, кар — байлык, муллык, бәхет китерүче дә. Әгәр бу сүз оста язучы каләменә эләксә, аны әллә күпме стилистик-экспрессив максатларда файдаланырга мөмкин. "Буранда" шигырендә М. Гафури кар диңгезе дигән сүзтезмә куллана. Кар Диңгезе. Давыл. Буран. Тыгыз караңгылык уртасында бер авыл. Төн. Авыл йоклый. Ә табигать үзенекен итә. Җил-давыл, буран котыра. Кар диңгезе дөнья киңлеген тасвирлау өчен

кулланылган. Ә йоклаган авыл, уянып, олы тормыш диңгезенә чыкмыйча калмас.

Г. Ибраһимов "Безнең көннәр" романында кар бәйрәме дигән сүзтезмә куллана: "Күгелҗем төтен болыты белән капланган бүлмәдән килеп чыгуга, Булатны шундый матур дөнья, шундый ак кар бәйрәме урап алды. Ул бер ел Урал башкортларында учитель булып торган иде. Уразгул атлы дәртле карт аучы аны чаңгыга өйрәтте. Зур таулар, бүрегә сунарчылык өчен йөрүнең тәмен татытты". Бу вакыйга Казан шәһәрендә бара. Бүлмәдә революцион көрәш турында сүз барган. Аннан чыгуга Булатны (аның прототибы — беренче татар большевигы Хөсәен Ямашев) кар бәйрәме чолгап ала, һәм ул Урал башкортларындагы кышны хәтерләтә. Димәк, кар бәйрәме Казан шәһәре, Башкортстан җирендәге вакыйгаларны бәйли. Шулар ярдәмендә герой-персонажның рухи дөньясы ачыклана. Шулай итеп, кар бәйрәме бу өзектә киләчәк якты тормышны символлаштыра. Кар бәйрәмен ак сыйфаты белән характерлау бу төшенчәне тагын да көчәйтә.

Сыйфатлар турында берничә сүз. Шомырттай кара күзләр, карлыгач канатыдай кара кашлар, дулкынлы кара чәчләр дигәндә, мәсәлән, кара сүзе матурлык төшенчәсе белән бәйле. Кара күзләр, кара кашлар халык телендә, җырларда матурлык символы булып та китте. Халык телендә бу сыйфат башка мәгънәдә дә кулланыла: кара кайгы, кара көн, кара йөрәк. XX гасыр башында ул изүче сыйныфларны сыйфатлау өчен кулланыла башлады: кара бай. "Авылыбызда ... кара бай бар иде" (Г. Ибраһимов). Кара бай дигәндә кара сүзе комсыз, саран, халыкны нык изүче, үз мәнфәгатьләре өчен генә яшәүче, кешеләр күңеленә кара ягучы ифрат яман байны күз алдына китерәбез.

М. Гафури бу сыйфатны илледән артык урында куллана, һәр контексттта бу билгеле бер эстетик максатта файдаланыла, көтелмәгән ягы белән ачыла. Башта аларның берничәсен сүзтезмәләрдә карыйк: кара йөз, кара җир, кара елан, кара кан, кара чәч, кара урман, кара капчык, кара болыт кара кабер, кара күзләр, кара су, кара сызык, кара икмәк, кара төн, кара пәрдә, кара дөнья, кара кул, кара эчләр, кара йөрәк, кара юрган, кара сәхифә һ.б.

"Бакчада" дигән шигырендә М. Гафури бу сүзне матурлык символы сыйфатында куллана: "зифа буйлы матурлар, кара чәчләр".

Бакчада гел кара чәчлеләрнең генә булуы мөмкин түгел. Кара чәч дигәндә кара сүзе бөтен матур чәчләрне "типиклаштыра".

Шагыйрь аз суз белән күп мәгънә аңлата, жанлы картина тудыра. Монда бер төркем кешеләрне тасвирлау өчен күп язарга кирәк булыр иде, әмма "зифа буйлы матурлар, кара чәчләр" барысын да аңлатып тора.

Кара сүзе "Җәй башы" дигән шигырьдә матурлык, нурлылык, куркынычлылык төшенчәләрен сәнгатьчә берләштереп бирү җәһәтеннән

дә файдаланыла:

Кара болыт һавада төрле төстә —

Матур да, нурлы да һәм куркыныч та.

М. Гафурида кара капчык ("Хәерче") — ярлы кешенең кара кайгысы кара ташлар ("Яманнар мөхбәсеннән качмак бәяны") — яманлыкны, кара кабер ("Газабы кабер бәяны") — яшәү һәм үлем турында уйлануны, кара сызык ("Бу да калмасын") — җәмгыятьтәге изүче һәм изелүче сыйныф арасындагы киртәләрне белдерә.

Әлбәттә, аларның эчке мәгънәсен, образлылык нигезен, экспрессив-стилистик үзенчәлеген, ни өчен кулланылганын әсәр тукымасында башка сүзләр, сурәтләү-тасвирлау чаралары белән бәйләп караганда гына аңлап була. Кара таш нинди таш ул? Табигать тарафыннан карайтылган ташмы? Әллә мунча ташымы? Образлылык, эмоциональлек, идеялелек өчен нигә ташны карага мана язучы? Әлеге табигать бүләге – елкылдап торган кап-кара таш күз явыңны алырлык матур була бит ул. Ләкин язучы бу урында кара сүзенең кире сыйфатын сайлаган:

Кара ташлар юу белән агармас,

Шулай ук ул кеше халыкка бармас.

Кара таш шагыйрьнең поэтик фикерләвендә символ дәрәҗәсенә күтәрелә. Икенче төрле әйтсәк, ул начарлык символына әверелә. Рәхимсез, мәрхәмәтсез, халыкны аяк астына салып тапаучыларны образлы тасвирлау объектына әйләнә. Шулай итеп, әсәр тукымасындагы һәр сүзнең мәгънәсен җентекле анализ ясау нәтиҗәсендә генә ныклап аңлап була.

Язучының сүзне энҗегә, мәрҗәнгә, асылташка, гәүһәргә, алтынга тиңләве юкка гына түгел. Халык та бит: "Табып әйтелгән сүз алтыннан ким булмас", — ди. Шушы сыйфатны Г. Ибраһимов "Кызыл чәчәкләр" повестенда бәйрәм дигән исемне ачыклау өчен куллана: нindидер бәйрәм — кайгылы бәйрәм, кара, бик кара бәйрәм". Кара бәйрәм дип халыкта гомумән юк. Бәйрәм — күңел ачу, тантана итү, матур күркәм хисләр белән яшәү көне. Ни өчен язучы бәйрәмне карага “мана”? Патша Русиясендә яшьләрне армиягә озату көне бу. Әсәрнең идея эчтәлеген, ул чагылдырган чорны, патша армиясендә хезмәт итүнең авырлыгын, михнәтен, зур газап икәнлеген белмәгән кеше кара сүзенең ни өчен кулланылганын аңламаска да мөмкин. Сүз кадерен белгән язучы монда озын-озак сөйләп тормый. Барсын да бер сыйфат (кара) аңлатып тора. Армиягә озатканда бәйрәм булу табигый. Әмма кара дигән сүз кулланмаса, патшага хезмәт итүнең никадәр газаплы булуы аңлашылмас иде.

Г. Ибраһимовның "Тирән тамырлар" дигән романында кара сүзе кискен сыйнфый көрәшкә әзерләнгән халык массасын чагылдыра: кара дулкын (халык дулкыны — **С. П.**). Ә инде "Безнең көннәр" романында

кара өлгереп килгән демонстрациянең башлану чорын тасвирлый. "Бу арада кара демонстрация циркның капкалары, коймалары тирәсен үзенең тәреләре, патша сурәтләре, чалмалары, өч төстәге флаглары, поплары, муллалары, өс-башларын алыштырган полицейскийлары, охранка агентлары белән бөтенләй чолгап алган иде инде". Г. Ибраһимовтан янә мисаллар: кара гайбәт, кара куркыныч, кара көч, кара тормыш, кара уйдырма, кара авыл, кара язмыш, кара юл, кара бәхет, кара хыял һ.б.

Халыкның: "Бер сүздә мең бизәк", — дип арттырып әйтүендә дә хикмәт бар икән шул.

Сүздән энҗе коючы

Г. Бәширов

Гомәр Бәширов — нәфис сүз остасы. Сузне энҗе бөртекләре урынына кадерләүче, һәр сүз эчендә энҗе барлыгын аңлап язучы. Алай дигәч тә, тышкы яктан энҗедәй ялтыравыклы, "күз явын алырлык", матур-матур сүзләр сайлау турында фикер йөртелми. Баллы сүз баш әйләндерә, дип тә әйтә халык. Туган телнең гасырлардан-гасырларга тупланып килгән бай сүзлек хәзинәсе бар. Анда, галимнәр теле белән әйтсәк, ниндиләре генә юк: гомумкулланылыштагы сүзләр, поэтизм, нейтраль лексика, архаизм искергән сүзләр), неологизм (яңа сүзләр), гади сөйләм лексикасы, әмма сүзләр... Әдәби әсәрдә, стиль таләп итсә, аларның барысы да кирәк. Гомәр Бәширов әсәрләрендә дә без аларның һәртөрлесен очратабыз: поэтизм (энҗе, сайрау, дулкын), гарәп сүзе (вәкарь), архаизм (сөбханалла, иман, фида кылу), гади сөйләм лексикасы (бакчы, маташу, авыз еру), рус сүзләре (диствительни, наверняка, безобразие) һ.б. Әсәр тукымасында алар аерым хәлдә яшәми, башка сүз һәм сурәтләү чаралары белән эчке яктан органик мөнәсәбәткә кереп, билгеле бер эстетик функция үти. Архаизм, рус, гарәп сүзләрен, гади сөйләм лексикасын әдип бик кирәктә, күбрәк төрле персонажларның холык-фигыльләрен ачыклый төшү максатында куллана. "Намус" романындагы Сәйфи, мәсәлән, ничек сөйләшә? Ай-яй! — диде, — диствительни, мулдан икән үзеңнең исәп". Бозып әйтелгән рус сүзе Сәйфинең холкын-фигылен дә күрсәтеп тора.

Образ-персонажның эчке, рухи дөньясын ачыклыймы, аның портретын тасвирлыймы, табигать күренешләрен, төрле вакыйгаларны сурәтлиме — һәр очракта язучы аз сүз белән күп мәгънә аңлатырга, җанлы картина тудырырга тырыша. Моның өчен, билгеле, төрле сүз-әйбер, сүз-образ җәлеп ителә. Кайбер очракта гомумкулланылыштагы гади генә сүзләр дә зур эмоциональ-экспрессив көчкә ия була. "Намус" романыннан бер мисал: "Кем белә, Сталинградта хәзер, ихтимал, таш өстендә таш калмагандыр". Таш өстендә таш калмау — һич көчәнми, гади

генә, халыкча әйтелгән сүзләр. Сугышның коточкыч картинасын чагылдыра ул. Шул сүзләр аша без җимерек йортларны, янып яткан танкларны, кыскасы, зур фаҗигагә дучар булган шәһәрне күз алдына китерәбез.

Традицион сурәтләү чаралары гасырлардан-гасырларга, әсәрләрдән-әсәрләргә күчеп килә. Чорга, тарихи шартка, социаль күренешләргә, әсәрнең идея-эчтәлегенә, стильгә бәйле рәвештә алар тышкы һәм эчке яктан үзгәрә дә. Шуның белән бергә, яңа чор яна сурәтләү чаралары таләп итә. Ул тел һәм культура, техника һәм икътисади үсешкә бәйле. Гомәр Бәширов әсәрләрен укыганда хәзерге таләпчән укучы бу мәсьәләгә дә игътибар итми калмыйдыр.

Г. Бәширов иҗатында традицион тасвир чаралары күп очрый: болын күбәләгедәй уенчык, күгәрчендәй гөрләшеп тору, арысландай егетләр, пыяладай боз, карлыган төсле кара күз, курчак өе кебек матур булмә һ.б. Әмма халык телендә, җырларда, моңа чаклы күп язучылар тарафыннан кулланылып, "төсе уңган" әзер поэтик чаралар белән генә иҗат итү оста язучыны канәгатьләндерми. Ул аларны үзенчә яңартырга омтыла. Бу вакытта телбизәк тышкы (формаль) һәм эчке (мәгънәви) яктан үзгәрүгә дучар була. Язучы, билгеле, инде бу сурәтләү чарасы укучыны туйдырган, шуңа күрә, мәгънәсен саклап, башка сүзләр белән бирим әле, дип уйламаска да мөмкин. Әсәрнең рухы, персонаж, сюжет-композиция, яңача тасвирлануга мохтаҗлык шуны таләп итә. Халык, мәсәлән, юлны тасмага охшатучан. Г. Бәширов "Намус" романында тасманы соры дигән сыйфат белән ачыклый: "Мәүлиха түтинең иреннәре, нидер пышылдап, тиз-тиз кыймылдый. Ул, бераз саный да, күзләрен кыса төшеп, җемелдәп яткан киң кыр ягына карап ала. Әнә шул яктан кыр өстеннән соры тасмадай боргаланып узган язгы җепшек юл белән озакламыйча аларның бригадалары кайтырга тиеш". Язгы җепшек юл — абстракт төшенчә, картина, күзаллау юк. Тасмадай боргалану да искитәрми. Ә кышкы юлны тасмага охшату мөмкин түгел, юлның шомалыгын күз алдына китерү өчен, аны көзге белән чагыштыру гына бар. Мопассан әйткәнчә, һәр әйберне тәгъбир итүче сүз, характерлаучы сыйфат, җанландыручы фигыль була. Шул исем, шул сыйфат, шул фигыльне тапмыйча калмаска кирәк. Әйберне якынча алу, җанландыру, сыйфатлау белән беркайчан да канәгатьләндерергә ярамый. Стендал Бальзакка язган бер хатында исем алдыннан яки аннан соң сыйфат кую өчен еш кына унбиш минутлап уйлануы турында әйтә... Югарыда телгә алынган "соры тасма"да, поэтик бизәк буларак, Мәүлиха түтинең уй-хисләрен, рухи халәтен ачыклауга ярдәм итә. Ул бит шушы җирнең, туган туфракның яшәүгә дәрт, илһам, куәт бирә торган илаһи бер тылсымын татып үскән. Эш вакытында соры тасмадай боргаланып узган язгы җепшек юлга карап алу аның күңеленә садәлек өсти, чөнки әсәр тукымасында "соры" сүзе сурәткә әверелә,

образлы картина тудыра, эстетик вазифа үти.

Шулай итеп, халыктагы гыйбарәләрне төрлечә үзгәртә язучы. Ул үзе дә төрле тасвир чаралары иҗат итә. Бусы тагын да авыррак, тел диңгезе төбенә төшеп эзләнүне таләп итә. "Каз бәбкәләредәй муенын сузган бодай кыяклары", — дип автор бер урында. Күңеле белән җиргә береккән кеше, бодай кыягы дигән сүзне ишеткәч, хис-тойгыга бирелмичә кала алмый. Чөнки бодай кыягы аның җандай якын күргән кырларын күз алдына китереп бастыра. Аларны муенын сузган каз бәбкәсенә чагыштыру да тышкы матурлык өчен генә кирәк булган дип уйларга ярамый. Күпме эчке мәгънә бу чагыштыруларда! Бәбкәне дә даими карап, тәрбияләп, күзәтеп торып үстерәләр. Иген дә шулай. Бәбкәгә балага булган тәрбия кирәк. Җитмәсә, бу чагыштыруны язучы икмәкнең иң кыйммәт, аеруча кадерле вакытында ("Намус"та) куллана. Шуның белән ул хезмәткә мәхәббәт уята, хезмәтнең эстетикасын ача. Мондый мисалларны Г. Бәшировтан бик күп китерергә мөмкин булыр иде. Аның автор хикәяләвен һәм персонажлар телен дә игътибарсыз калдырып булмый. Автор хикәяләвендә үк персонажның кем, нинди рәк табигатьле кеше икәнлеген сизәсең, шуннан ул шәхеснең үз сөйләмен ишетәсе килә башлый; ишеткәч, әлеге сиземләү раслана да куя. Киресенчә дә була. Үз характерын ачып салырдай сүзләр белән башта персонаж сөйли. Аннан аның эчке дөньясы автор хикәяләвендә тагын да ныграк ачыклана. Шул ике нәрсә арасында билгеле бер динамика, диалектик берлек яши. Бер генә мисал: "Аның майлы күзләре мутланып ялтырыйлар. Кан бәреп торган калын иреннәре үзалдына тетрәнеп-тетрәнеп китә. Әпипә, яшел кашлы көмеш йөзек кигән кыска бармагы белән ялкау гына орлык чүпли-чүпли, Мәүлиха түтигә карап алгач, тамак төбе белән генә тагын бер көлеп куйды. Җайлабрак утырды да, әллә Мәүлиха түтине үчекләп, әллә вакыт уздырыр өчен:

— Әле тегендә ата каз каңгылдагач исемә төште, — дип мәзәк сөйләргә тотынды. — Былтыр яз мин үзебезнең мишәр ягына бардым ие бит, бакчи, Шәйморзага. Күршеләргә шылай, килен төшкән икән. Да. "Әпипә түтәй, дир, атакай йортыннан ана каз алып килдем ие, дир, мондагы ата каз шуны сүми генә бит, дир. Ишегалды буйлап ысылдый-ысылдый куып ери. Шуның берәр әмәлен белмисеңме?" — дир".

Мутланып елтыраган майлы күзнең эчке дөньясы персонажның үз сөйләмендә әнә ничек ачыклана. Автор аларны тагын үз сүзләре белән ныгытып куя: "Әпипә, кашларын сикертә-сикертә, тәмле итеп сөйли, гүя, үз сүзләренең рәхәтенә үзе үк оеп киткәндәй, ара-тирә авызын чәпелдәтеп куя, күзләрен йомгалый".

Нәфисә, Айсылу, Сөмбел һәм башкалар турында язганда хикәяләвендәге интонация, аһәң дә үзгәрә, персонажлар да уз телләрендә сөйләшә.

Гомәр Бәшировның тагын бер үзенчәлеге итеп шуны күрсәтергә була: аның теле грамматик яктан төзек. Җөмләнең аерымланган кисәкләрен генә алыйк. Аларны сәнгатьчә куллана белү язучыдан зур осталык сорый. Кайбер язучының әсәрендә ул бик сирәк очрый. Моның матур үрнәкләрен прозада Г. Ибраһимов күрсәткән иде. Гомәр Бәширов аерымланган кисәкле соклангыч җөмләләр төзи. Мәсәлән: "Ул (Нәфисә — **С. П.**), үзенең җитеп килә торган бер кыз булуын бөтенләй онытып хәлдә, муенсасының гәрәбәләрен аралый-аралый, сабыйлар беркатлыгы белән зәңгәр күкнең төпсез тирәнлегенә, күз алдына җәелеп яткан киң табигать күренешенә хәйран калып, исе китеп карый иде". Бер җөмлә эчендә күпме аерымланган кисәк!. Шулар ярдәмендә күпме җанлы картина барлыкка килгән! Без, үзебез дә сизмәстән, табигатьнең матур, серле дөньясына да кереп китәбез, Нәфисәнең саф, садә, хисле күңелен, кайнар тойгы ташып торган рухи байлыгын күреп шатланабыз.

Соңгы вакытта кыска җөмлә белән язуның өстенлеге турында сүз китте. Җыйнаклыкка, кыскалыкка берәү дә каршы түгел. "Кыска сүз — алтын, озын сүз — балтун", — ди халык. Әдәбиятта кыскалык өчен көрәш күптән килә. Ләкин гел кыска җөмләләр белән эш итү дә формализмга алып бара, фикер өзелә, мәгънә ягы "аксый" башлый.

Бүз җөе белән, сүз җае белән, дип тә әйтә бит халык. Телнең җае бар. Җөмләнең кыскасы да, озыны да кирәк. Әмма ул урынлы булсын. Язучының теле һәм стиле хакында сөйләшкәндә, без бу мәсьәләләрне күп вакыт урап үтәбез. Академик В. В. Виноградов лингвистик поэтикага телнең барлык элементларын кертә: фонетика, морфология, синтаксис, лексик-фразеологик состав, сурәтләү чаралары, ритм, тон, аһәң һ.б. Сәнгатьле сөйләмдә алар, бер-берсе белән табигый бәйләнеп, язучының эстетик концепциясенә буйсынырга тиеш. Гомәр Бәширов әсәрләрендә телнең төрле формасын, грамматик чараларын җайга китереп язуына кадәр сокландыра (урынтын, уздыргалыйлар, беркайчанга).

Бу осталык үзеннән-үзе генә килми, әлбәттә. Г. Ибраһимов шагыйрь булу өчен башта анадан шагыйрь булып туарга кирәклек турында әйтә. Аннары талант өстенә дөньяга прогрессив караш таләп ителүен искәртә. Талант телгә дә бәйләнгән. Тел - язучының төп коралы. Сүз сәнгате остасы булу өчен язучы-галим дәрәҗәсенә күтәрелү зарури. Г. Бәширов әнә шундый сыйфатларга ия. Икенче төрле әйтсәк, телнең нигезен белүче. "Тел турында кайбер фикерләр" исемле мәкаләсендә болай ди: "Нинди юллар белән генә баетмый язучы үзенең телен! Бу яктан аны алтын һәм асылташлар эзләүчеләр белән тиңләргә мөмкин булыр иде. Андый язучы яки тел белгече сирәк очрый торган берәр кадерле сүз очраткан саен, аны, асылташ табучы галим шикелле, әйләндерә-әйләндерә карап, аңа соклана, ул аның тарихы, хәзерге тормышы, киләчәге белән кызыксына, матурлыгыннан яки

тапкырлыгыннан ләззәт таба, куана". Сүзне җиң сызганып, тирләп-пешеп дигәндәй, әнә шулай эзләмәсә, әдип мондый фикер әйтә алмас иде. Абай да бит: "Сүзнең эче — алтын, тышы — көмеш", — дигән.

Җыйнап әйтсәк, телнең бай лексик составы, фонетикасы, морфологиясе, синтаксисы, фразеологиясе, мәкаль-әйтемнәре, тасвирлау чаралары — кыскасы, бөтен бер элементы Г. Бәширов әсәрләрендә сәнгатьчә яңгыраш тапты. Сүздән энже коя ул!

Җилнең шигърияттәге илаһилыгы
Һ. Такташ

Җил! Аның җитди сүз-сурәт (образ) ясау, куәтле мәгънә белдерү (идеялелек), йөрәк-күңелләрдә кайнар хис-тойгы (эмоциональлек) уяту илаһилыгы турында язып та, сөйләп тә аңлату бик кыен. Ул кешелек җәмгыяте барлыкка килгәнче үк искән. Караңгы төннәр, кояшлы көннәр, яңгырлы көзләр, кар-буранлы кышларда, галәм киңлекләрендә үз шөгылен башкарган. Биек-биек тауларны сикереп-сикереп үтеп, бозлы дәрьяларны йөзә-йөзә кичеп, өстенә таш яуса да үз бәхетен эзләп алга ыргылган. Каһарман атабыз Адәм колагына изге хәбәр сөйли бер вакыт җил: "И, баһадир ир-егет, бәхетең мәхәббәттә, тап шуны", — ди. Киң күкрәкле, солтанат кыяфәтле, бөркетнекедәй үткер күзле, сандугачныкыдай сак колаклы, алып йөрәкле даһи Адәм юлын дәвам итә. Чәчләрен Тулпар ялыдай җилфердәтә-җилфердәтә, давыл-гарасатларны ера-ера, йолдыз тизлегендә "очкан" булачак анабыз һаваны очрата. Кавышу. Танышу. Кочаклашу. Сөешү. Кинәт давыл, гарасат, табигать көйсезлеге тына. Ялтырап Кояш чыга. Кайнар мәхәббәт Кояш кайнарлыгына кушылып башлана. Ә Җил тарих сәхнәсендәге мәхәббәтне күреп, аның зураячагына, урчиячәгенә шатланып кул чаба.

Еллар, гасырлар бер-бер артлы үтә тора. Җил пәйгамбәрләр дөньясында зур, изге эш башкара. Улы Йосыф югалгач, Ягъкуб пәйгамбәрнең кайгыдан күзләре сукрая. Бу кайгысын кат-кат сабах Җиленә (иртәнге йомшак, ләтыйфь җил) сөйли Ягъкуб. Сабах җиле эзләп таба Йосыфны. Исән икән. Ул да, әтисенә охшап, кешелекле, изге күңелле, матур йөрәкле пәйгамбәр булган. Моны Җил Ягъкубка сөйләп бирә. Җил алып килгән изге хәбәрдән соң Ягъкуб пәйгамбәрнең күзләре ачыла.

Егерменче йөз башы. Тукайның "Көзге җилләр" исемле шигырендә Җил халыкның авыр, газаплы, михнәтле тормышы өчен елап йөри. Җил Русиядагы бөтен караңгы хәятне күреп сыкрана. Менә 1914 империалистик сугыш башлана. Бу хакта 15 яшьлек Һади Такташ 1916 елда "Газраиллар" дигән шигырь яза. Җәя эченә ("1914нче елгы Европа сугышына каршы") дип куя. Җир шарын Такташ "йолдыз" дип атый.

Вакыйгага фәрештә дә катнаша. Фәрештә, уйга батып, тау өстендә утыра. Йолдызлардан йолдызларга очып талган канатлары җиргә яткан. Маңгаенда — нурлы Йолдыз. Күзләренең шәүләсеннән офыкларда таңнар ата. Алсу таңнар аша башка ерак илләр күренеп тора. Җил, яшерен генә килеп, аңа хәбәр сөйли, бу илдән китәргә киңәш бирә. Сигез юлдан торган беренче строфа болай:

Тау өстендә утырган ул, уйга баткан; Канатлары талган килеш җил яткан; Маңгаенда — нурлы йолдыз; күзләренең Шәүләсеннән офыклар таңнар аткан. Таңнар аткан, күренеп тора ерак илләр; Яшерен генә аңа килеп сөйли җилләр: — Фәрештәкәй, кач бу илдән! Монда вәхшәт, Монда үлем, монда патша-газраилләр!.

Кол Галидә (XIII йөз) сабах җиле кеше сыйфатына кереп (образлылык), кешелеклелек (идеялелек) турында сөйләп күңелләрне тетрәндерә (эмоциональлек), Һади Такташта җил образының идеялелеге, эмоциональлеге бөтен ил фаҗигасе өчен борчылудан зурая. Борынгы ата-бабаларыбызның: "Ил язмышы — ир иңендә, ир язмышы — ил иңендә", — дигән мәкальнең эчтәлеге хәзер бетеп бара. Чөнки бу илдә хәзер патша тәхетендә газраиллар хуҗа. Биредә халыкның: "Иле нинди — патшасы шундый", — дигән мәкаленә дә игътибар итәргә туры килә. Аны халык киресенчә дә әйтә: "Патшасы нинди — иле шундый".

"Теләгәнең фәрештәнең амин дигән чагына туры килсен", — дип әйтү бар халыкта. Димәк, ул изге эшләргә амин тотып тора. Һәркемнең ике иңбашында — ике фәрештә. Уң яктагысы — уңай, сул яктагысы кире сыйфатыңны язып бара: ул гарше көрсидәге гөнаһсызлар иленә озатыла. Яхшылыгың үзеңә мең өлеш артык булып кире кайта. Ул, зур бәхеткә әверелеп, үзеңә генә түгел, ата-анаңа (әгәр исән булсалар), якын туганнарыңа, аларның балаларына чәчелә. Яманлыгың да шулай. Күпкә арттырылып, үз башыңа кайта. Үлгән булсаң, туганнарыңны рәнҗетә. Фәрештәнең нинди авыр, серле, яшерен эш алып барганлыгы аңлашыла булса кирәк. Такташта аның бөтен ил, дөнья, галәм язмышы өчен борчылганлыгы сурәтләнә. Аның шулай икәнлеген түбәндәге юлларда күрәбез:

Ул фәрештә моннан бик күп еллар элек
Бу йолдызга күптән очып килгән иде.
Төзер өчен мәңге рәхәт-бәхет багын,
Кызыл гөлләр чәчеп, сулар сипкән иде.
Сипкән иде...
Җырлый-җырлый мәхәббәт һәм күк көйләрен,
Җир йолдызын тезеп җәннәт иткән иде;
Бизәр өчен җәннәтен ул, гөлләр өчен,
Тагын очып кире күккә киткән иде.
Киткән иде...

Күчеп тиз-тиз бер йолдыздан бер йолдызга,
Бик күп еллар матур гөлләр җыеп йөрде...
Кайтса кире җир өстенә: нинди вәхшәт!
Сөякләрдән таулар, каннан күлләр күрде.
Котырган ил... болгый-болгый кулларында
Яңарта сөңгеләрен. Юлларында
Үлгән ирләр өелеп кала, аунап шунда;

Җәһәннәмдәй утлар уйный уңда-сулда. Димәк, һәр кешенең, һәр илнең, дөньяның, бөтен галәмнең фәрештәсе бар. Бер йолдыздан икенче йолдызга күчеп очып йөргән фәрештә шуны аңлата. Фәрештә образы шагыйрьгә эпик киңлек өчен кирәк булган. Кол Галидә ил пәйгамбәрләр, Такташта фәрештәләр белән эш итә. Икесендә дә җил хәбәр ташучы. Кол Галидә җил аерым шәхесләр белән эш итә. Такташта аның эчке мәгънәсе киңрәк. Чөнки җил бөтен дөнья даирәсе белән эш итә. Ул хәтта, җирдәге вәхшәтне башка йолдыз, планеталарга чагышытырып сөйли. Фәрештәгә җил бу илдән китәргә куша. Бу җилнең атабыз Адәм, анабыз Һаваны кавыштырып, очсыз-кырыйсыз кыпчак далаларында исә-исә, Кандалыйда мәхәббәт кебек изге хис-тойгылар белән ләззәтләнеп, Тукайда ярлыларның күз яшьләре белән чылангач, Такташта дөньякүләм хәбәрчесенә әверелә. Җил чал тарихтан бирле мөбәрәк тәсбих төймәләредәй тезелеп килә. Һәр чорны бер төймә дип алсак, һәр төймәнең эчендә гасырлар җаны бар.

Такташның патшаларны "газраилләр" дип атавы бик дөрес. Чөнки сугыш патшалар өчен кирәк, бөтен ил ачлык, хәерчелек, фаҗига кичерә. Ә патша үз тәхете таҗында кикереп утыра. Хаклык өскә калка, ялган төпкә бата, дип әйткән лә ул борынгылар, әмма өстәге патшалар аны укытмыйлар, төпкә батырып яшиләр. Халык патшадан көчлерәк, әлбәттә. Тик ул көчен күрсәтә генә белми, шуңа күрә "Газраилләр"дә сурәтләнгәнчә, хәят иле — матур йолдыз янып сүнә, гөл балалары тапталып көлгә дүнә, матур кырлар бәхет-җәннәт урманнары гакылсызлар йорты булып әверелә.

Аз сүз белән күп мәгънә аңлату, җанлы картина тудыруның классик үрнәге бар бу шигырьдә. Сүз-сурәт, аның мәгънәсе, хис-тойгысы сокландыра. Эпитет, метафора, сынландыру һ.б. сурәтләү-тасвирлау чаралары идея-эчтәлек белән бәйле. Бер шигырь кысасына романлык вакыйга сыйган. Анда шагыйрьнең ялкынлы кайнар йөрәге, шашкын, ярсу күңеле, эстетик идеалы, фәлсәфи фикерләү офыкларының киңлеге. Җил фәрештә образлары сәнгатьлелек дәрәҗәсе өчен сайланган. Унбиш яшьлек Һадиның эчендә дөнья зурлык шигъри хәзинә булу шаккатыра.

Һ. Такташ татар поэзиясенә җил булып исеп керде. Тамбов урманнары уртасындагы җилләрдә шаулаган усак яфраклары озатып калды аны. Март аеның сузылып яткан җирдән кар ашаган нечкә билле

җилләре йөрәгенә мәңгелек дәрт биргәндер, күңеленә сихри моң салгандыр. Авыл табигатеннән башланган бу җилләр шагыйрьне зур көрәш мәйданына алып чыга:

Китәм хәзер канлы үлем кырларына!
Сөйлим хаклык мәзлум адәм улларына!
Биреп канлы кызыл байрак кулларына,
Ачам сугыш, салам киртә юлларына! — ди. Мәгәр таңда искән сабах җилне (йомшак җил,ләтыйфь җил, саф җил) ул беркайчан да ташламый үзе белән ала. "Урман кызы"ннан бер мисал:

Әй, таң кызы! Сиңа талган юлчың
Таңда искән йомшак җил белән
Сәламнәр җибәрә. Иртә белән
Син килерсең шунда, бик беләм,
Тик мин булмам.
Сеңлем, әй, Әминәм!
Соңгы ядкарь итеп күл янында
Гөлләр өзеп куям бер күләм.
Аны сөйгән гөл-чәчәкләр! Ул килгәндә
Тәгъзим итеп башыгыз иярсез.
"Сине өзелеп сөйгән юлчы абыең
Еракларга китте", диярсез.

Бөтен дөнья зур мәхәббәткә корылган. Бөтен галәм мәхәббәт тантанасы белән яши. Мәхәббәт авырлыкларны җиңәргә ярдәм итә. Такташның зур мәхәббәте Тамбов урманнары уртасындагы шаулаган усакларның алтынсу яфракларыннан, март аеның җиргә сузылып ятып кар ашаган нечкә билле җилләрне йөрәге белән яратудан килә. Хәзер инде ул яраткан җиле белән мәхәббәт дөньясына да кереп китте. Аның мәхәббәте туган җир, туган ил, дөнья язмышы белән бәйле. Җил образы, Такташның шәмен сүндереп, шагыйрьне көрәш турында нык уйланырга мәҗбүр итә:

Төн.
Тиле җил!
Ник тәрәзәмнән кереп,
Яндырып куйган шәмемне сүндереп,
Син качып киттең?!
Минем ак кәгазь өстендә калды кулларым,
Ялгышып, бертуктамый язган
Сихерле юлларым...

Биредә һәр сүз нык уйланырга мәҗбүр итә. Ни өчен утны сүндерә җил? Шагыйрь бертуктаусыз язып, ак кәгазьгә ялгыш фикерләр төшерә икән. Шигырь болай тәмамлана:

Без черек йөкләрне өстән ташлыйбыз

(Кайсылар безне үлемдәй каплаган).
Ишетәсезме?
Без яңа юл башлыйбыз
Мәңге утларга, кояшларга табан!

Хәзер җилнең шагыйрь шәмен сүндерүе аңлашыла булса кирәк, дошман корган бик күп киртәләрне җимерә-җимерә алга таләп итә. Кешеләргә якты маяк күрсәтүче шагыйрь ялгышмаска тиеш.

Тасвирлау-сурәтләү чаралары әсәрнең идея-эчтәлеге белән генә түгел, ул чагылдырган чорга да бәйле була. Әгәр Тукайда җил образы үзе яшәгән чордагы авыр тормыш өчен сыкранып, елап, әрнеп исә икән, Такташта инде ул искелекне туздыручы, яңалык алып килүче символик көч сыйфатында файдаланыла. Шулай да җил батыр көрәшчегә тиз генә әверелми әле. Борынын сузып, ишекләрдән нан (икмәк) сорап йөри. Бу очракта аның эчке мәгънәсе Русия ачлыгы өчен елаган Тукай җиленә якын тора. Икенче төрле әйтсәк, "Сыркыды авылы" шигырендә җилнең нан сорап йөрүе Россиядәге хәерчелекнең бер күренеше ул. Димәк, Такташтагы җил образы эволюцион үзгәреш чоры кичерә. Сурәтләү-тасвирлау чараларының эчке мәгънәсе үзгәрү метод һәм стильләргә дә бәйле. Ул үзенчәлек классик әдәбиятта да бар. Рус филологлары, мәсәлән, Лермонтов иҗатын икегә бүлеп карый: Лермонтов — романтик, Лермонтов — реалист. Аның романтик, реалист булуы әсәр тукымасында тел-сурәтләү чараларын куллануында да сизелә. Шундый ук үзенчәлек Г. Ибраһимов иҗатында да бар. Ибраһимов — романтик, Ибраһимов — реалист. Романтик — Ибраһимов абстракт мәгънәле тел-сурәтләү чаралары белән дә эш итә. Ә инде Ибраһимов — реалист аннан котыла. Вакытында бу мәсьәләгә тәнкыйтьчеләр дә игътибар итә. Г. Ибраһимов ул хакта үзе дә язып чыга. Мондый үзгәреш Такташның "Такташ үлде" исемле шигырендә башка күп кенә әсәрләрендә дә бар. Егерменче гасырның егерменче елларыннан соң Такташ җиле хезмәт батырына әверелә:

Җил.
Җил бүген хезмәт батыры,
Урамда кар көри,
Җил — молодец!
Карт авылны
“Ду-у-у" килеп күмеп йөри.
Җил бүген ач,
Җил ишектән
Нан сорап борнын суза,
Җил — пионер,
Морҗалардан бай кулакларны янап,
Йодрыгын селкеп уза:

— У-у-у-у-у-у-у...
Кар туза...
Искелек,
Коръән,
Иман сеңгән диварлары җил белән
Селкенә. — Ләхәүлә!
(Йортта),
Тышта кышкы җил көлә.

Җилнең хезмәт батыры булуы, кар көрәве карт, караңгы авылны күмеп йөрүе, аның пионерга әверелүе... — барысы шул чорны (шигырь 1925 елда басыла) күз алдына китерүгә ярдәм итә. Әйтелгәнчә, аның әле нан сорап йөрүе дә табигый. Чөнки ачлык дәвам итә. Ә җилгә эш күп. Моржалардан бай кулакларны янап, йодрыгын селкеп уза: кар туза... искелек, коръән, иман сеңгән диварларны җил белән селкетә.

Җилнең искелек, коръән рухлы иман сеңгән диварларны селкетүендә шагыйрь эстетик идеалының серле яклары да бар. Ул шул чордагы коммунистик идеология белән бәйле. Чөнки ул елларда "Алла юк", "дин юк" дигән сүзләр саескан тыкылдавы шикелле яңгырап тордылар. Бу очракта шагыйрь җиленең ялгышуы да мөмкин. Аның ялгышуы шагыйрьнең дөньяга карашы белән бәйле. Мәгәр Такташ "коръән", "иман" кебек сүзләргә үз карашын өзеп кенә әйтми. Җилнең селкетүе — аларга карата булган җәмәгатьчелек фикере.

Димәк, җилнең шигърияттәге илаһилыгы беренче классик әсәребез Кол Галинең "Кыйссаи Йосыф" поэмасыннан (XIII йөз) ук килә. Анын матур үрнәкләре Тукайда да күп (Көзге төн. Мин йоклый алмыйм. Өй түрендә җил елый. Җил еламый, ач үлемнең кайгысыннан ил елый); Дәрдмәнднең "Кораб" исемле шигыреннән мисал:

Шаулый диңгез...
Җил өрәдер... Җилкәнен киргән кораб!
Төн вә көндез
Ул йөрәдер:
Юл бара ят ил карап...

* * *

Чыкты җилләр,
Купты тулкын —
Ил корабын җил сөрә!.
Кайсы юллар, Нинди упкын
Тарта безне җан сорап!

Дәрдмәнд, Тукай, Такташ җилләренең эчке мәгънәсе туган ил белән бәйле. Такташта җилнең образлылык илаһилыгы киңрәк тә кебек. Чөнки җил фәрештәгә Русиядагы хәлләр турында башка ил-йолдызларда күргәненә чагыштырып сөйли. Тукай җиле бер илдәге хәерчелекне

чагыштыру белән чикләнә. Дәрмәндтәге җилнең ил корабын сөрүе Такташтагы җилнең фәрештәгә биргән киңәше белән аваздаш. Дәрдмәнднең "Видагъ" (Аерылышу) исемле шигырендәге таң җиле ватанга бәйле булган зур мәхәббәт белән бәйле:

Тәгәрәп аунап
Буй үскән
Туган илем, исән бул!
Чәч кузгатып
Җай искән
Таңгы җилем, исән бул!
Йөгереп-йөгереп
Туктаган...
Яулык болгап
Сыктаган
Нәзкәй билем, исән бул!

Дәрдмәнд чит илгә китәргә җыена. Бу шигырендә аңлашылмаган, абстракт мәгънәле сурәтләү-тасвирлау чаралары юк. Гади генә сүзләр дә тиран эчтәлекле. Ул тәгәрәп аунап үскән туган иле белән хушлаша. Чәч кузгатып җай искән таң җиле белән саубуллаша. Таң җиле белән саубуллашу — туган ил белән аерылышу. Димәк, җил образы, "Кораб"тагы сыман, барыбер туган илне символлаштыра. "Йөгереп-йөгереп туктаган, яулык болгап сыктаган нәзкәй билдә" — шагыйрьнең зур мәхәббәте.

Такташ җиле турында сүз йөрткәндә, башка сүз сәнгате осталарының җиленә дә мөрәҗәгать итәргә туры килә. Әгәр чагыштыру танып-белүнең анасы икән, без һәр ана йөрәгенә мәхәббәтле күз белән карарга тиешбез.

Тәгаен, Такташның үзен генә алып фикер йөртсәк, әйтелгәнчә, җил образы аның "Газраилләр" дигән беренче шигыреннән алып соңгы әсәрләренә кадәр житди өслүбе алым буларак кулланыла. Икенче төрле әйтсәк, Такташ шигърияте үзәгендә җил образы поэтик чылбыр булып сузыла. Янә кабатлап булса да әйтик, Такташ татар шигърияте капкасын җил-давыл кебек килеп бәрелеп ачты, аз гына вакыт эчендә, поэзия өлкәсендә ут уйнатып, аның ишеген шапылдатып ябып та китте. Аның җилләре әле һаман исә. Җил канатында Такташның моңы да тарала. Бүгенге оста телле шагыйрь, ул моңны һаман эләктереп алып, ак кәгазь битләренә поэтик гәүһәр итеп төшерә. Әлбәттә, ул Такташча ук килеп чыкмый.

Кызганыч, Такташның образлы, халыкчан, сәнгатьле теле һаман әле фәнни яктан өйрәнелмәгән. Аның һәр сүзе эчендә алтын бар. Аны сүтеп карарга кирәк. Бер мәкаләдә бу эшне барлык яктан да башкарып чыгып булмый.

Канатлы сүзләр поэтикасы
М. Җәлил

Бик борынгы заман кешеләре сүзләрне туры мәгънәсендә кулланган. Әйбер-җисемнәргә (предметларга) атама биргәндә, сүз төркеме буларак, исемнәр барлыкка килә (чишмә, гөл, сандугач, каен, тал), Фигыль аларның хәрәкәтен белдерә: ага, сайрый, үсә. Сыйфат йә төсен, йә тәмен, йә башка үзенчәлекләрен тасвирлый: ак каен, бөдрә тал, салкын чишмә һ.б. Тора-бара, танып-белү үсү нәтиҗәсендә чагыштыру мөмкинлеге барлыкка килгәч, сүзләр күчерелмә мәгънәдә дә файдаланыла башлый. Болын чәчәксез, тел бизәксез булмас, дигәндәй, тел яңадан, фразеологик әйтелмә, мәкаль-әйтем, эпитет, метафора, чагыштыру, сынландыру һ.б. сурәтләү-тасвирлау чаралары исәбенә байый башлый. Аларның һәркайсы турында фәнни хезмәтләр языла. Бер-берсеннән аерып карау җәһәтеннән махсус терминнар табыла. Шулай да бу мәсьәлә һаман хәл ителеп бетмәгән әле. "Чагыштыру — шул ук метафора", "Метафора - шул ук чагыштыру" дигән фикерләр йөри. Озак еллар мәкаль белән әйтем фразеологик әйтелмәләр эчендә каралды. Рус филологлары аларны "крылатые слова" дип йөрттеләр. Татарларда — "канатлы сүзләр". Русларда да, татарларда да "афоризм" дигән термин һаман әле — гамәлдә. Мондый мәсьәләне чишү бу хезмәт вазифасына керми. Татар филологларында аның белән Х. Курбатов, В. Хаков, И. Бәширова һ.б.-лар шөгыльләнә. Безнең максат — нәфис сүз сәнгате осталарының канатлы сүзләр поэтикасын ни дәрәҗәдә аңлап эш итүләрен тикшерү. М. Җәлил шигъриятендә алар күп очрый. "Моабит дәфтәре" андый тел чараларына аеруча бай. "Батырлык турында" дигән шигыренә игътибар итик. Ул бик озын түгел. Язып күрсәтсәк тә, әллә ни күп урын алмас.

Беләм, егет, синең җырыңда
Күп иленә сөю, якынлык.
Тик әйт: авыр сугыш юлында
Син күрсәттең нинди батырлык?

Син бастыңмы сафка кыенлык,
Кайгы йөген илең тартканда?
Кыенлыкта күренә кыюлык,
Ил батырны сыный батканда.

Ирлек сорый көрәш егеттән
Ирешер өчен бөек өмиткә.
Ирек китәр качсаң, ирлектән,
Ирлек белән иреш ирекка.

Коткарырмы ялыну елаулар
Тоткын итсә дошман йөрәкне?
Буа калмас ләкин богаулар
Кылыч йөртә белгән беләкне!

Ни мәгънә бар эзсез яшәүдә
Түбәнлектә, тарлык, киңлектә?
Яшәү хозурлыгы хөрлектә,
Гомер озынлыгы ирлектә.

Ил онытмас, бирмәс каныңны
Ватан өчен изге көрәшкә.
Хаин каны тама чиләккә,
Батыр каны тама йөрәккә.

Батыр үлә, үлмәс ат алып,
Батырлыклар белән макталып.
Исемең калсын, үзең үлсәң дә,
Тарихларда укып ятларлык.

Канатлы сүзләрне кош баласы белән дә чагыштырырга мөмкиндер. Ул канатлангач очып китә. Канатлы сүз ниндидер акыллы башның алтын сүзләре белән ясала. Акыллы авызыннан чыккач, кемнеңдер колагына барып кереп, күңел хәзинәсендә лаеклы урын ала. Йөртә-йөртә аның күңеленнән очып киткәч, башкалар күңеленә кереп нәкышләнә. Канатлы сүзләр шуннан соң ирекле кошка әверелә. Такташ яшьлекнең яшел бакчасына ныклап аяк басмас борын ук татар поэзиясе йөрәгенә жил булып исеп килеп кергән кебек, Җәлил дә зур шигъриятнең ишеген бала чакта ук ярсып ача. Образ белән язарга, аз сүз белән күп мәгънә белдерергә тырыша. Бала чагы, яшьлеге нинди елларга туры килүне белдерү өчен бик озын шигырь язарга кирәк булыр иде. Муса аны нибары ике эпитет белән чагылдыру осталыгына ирешә:

Сандугачлы алсу таңда түгел,
Син давыллы төндә кабындың.

Давыллы төн шагыйрь яшәгән чордагы караңгы тормышны, авыр көрәшне, каршылыклы елларны символлаштыра. Шул давыл эчендә баса ул көрәшчеләр сафына. Чыныга. Корычлана. Поэтик очкынын ялкынга әвереләдерә Давыл-ялкын аны Бөек Ватан сугышы утына алып китә. Яралану. Дошман кулына эләгү. Фашист балтасы баш очында эленеп торганда да кайнар хис-гойгысы, мәгърур йөрәге, аң-акыл илаһилыгы кушуы буенча патриотик рух ялкыны белән сугарылган шигырьләр яза. Канатлы сүзләр, туган иленнән бер-бер артлы очып килеп, иң әүвәл аң-акылында эшкәртелә, аннан соң, энҗе-мәрҗән бөртекләре булып, каләм

кәгазьгә төшерелеп кәрәзләнә. Баксаң, алар халыктан, Кол Галидән (XIII йөз). Мөхәммәдьярдан (XVI йөз), Утыз Имәнидән, Кандалыйдан, Тукайдан икән. Тик Муса Җәлил, мәгънәләрен саклаган хәлдә, аларны "вата-җимерә", "ипли-сипли", әсәрнең идея-эчтәлеген чагылдырган чор таләп иткәнчә, үз эстетик идеалына яраштырып яза "Батыр яуда беленер" дигән әйтемне, мәсәлән, халык бик борынгы заманнарда ук әйткән. Ул инде шагыйрьләр, прозаиклар тарафыннан мең мәртәбә чәйнәлгән. Давыллы, утлы сугыш тәэсирен бер батыр белән чикләү мәгънәне нык тарайта. Шуңа күрә М. Җәлил аны "Ил батырны сыный батканда" дип үзгәртә. Ил сүзе мәгънә канатын күпкә киңәйтә. Ул Дәрдмәнд "Кораб"ындагы, Тукайның "Көзге җилләр"ендә, Такташ "Газраилләр"ендәге Ватан язмышы төшенчәсе белән бәйле. Аларда ил образы төрле сурәтләү чаралары ярдәмендә тасвирланса, Җәлилдә ул туп-туры әйтелә. Әмма "батканда" дигән метафора ил канатына күчерелмәлелек өсти. 1941 елда Германия фашизмы илебезнең йөрәгенә — Мәскәүгә килеп җитте. Илебез, Җәлил әйткәнчә, чыннан да, батып барды. Мондый очракта "Батыр яуда беленә" дип кенә котылып булмый. Батырның батып барганда сыналуы эмоциональ-экспрессив яктан бик нык көчле әйтелгән. Беренче карашка "тупас" кына тоелган "батканда" фигыле М. Җәлилдә әнә нинди зур мәгънәгә ия.

Мондый үзгәртүне без Кол Галинең "Кыйссаи Йосыф" поэмасында (XIII Йөз) һ.б. каләм осталары әсәрләрендә дә күрдек. Димәк, М. Җәлил традициялелекне дәвам итә. "Көрәш кыюларны ярата" ди халык. М. Җәлилдә ул китапчарак: "Ирлек сорый көрәш егеттән". Бу очракта да халыкныкы М. Җәлилгә караганда мәгънә, идея, эмоциональ-экспрессив яктан көчсезрәк. Көрәшнең кыюларны яратуы табигый хәл. Шулай да һәр кыюлык күрсәтәм дип ялгышкан солдат, сержант, офицерлар күп булды. Ул "чирдән" генерал, маршаллар да котыла алмады хәтта. М. Җәлил әйткәнчә, "көрәш егеттән ирлек сорый" икән, монысы инде моңача Тарих бабай күрмәгән авыр, канлы, утлы сугыш өчен бик тапкыр әйтелгән. "Ирлек" сүзе бөтен Совет Армиясенең корычтай ныклыгы турында сөйли. Кабатлап булса да әйтик: теләсә нинди "кыюлык" "ирлек" була алмый. А. Потебня сүзләрнең эчке мәгънәсен "внутренняя форма" дип атаган иде. Виноградов "план содержания" термины кулланды. Бу терминнарны Җәлил белгәнме, юкмы — анысы бер Алланың үзенә генә мәгълүм. Мәгәр һәр сүзнең эчке мәгънәсен аңлап язды шагыйрь.

"Курыкма үлемнән, курык оятка калудан" ди халык. "Үлемнән курыкмасаң — ирек, курыксаң — коллык" дигәне дә бар. Бу мәкальләрне халык бик борынгы заманнарда ук иҗат иткән. Үлемнән куркып оятка калучылар Бөек Ватан сугышында да булмады түгел. Аларның кайберләре хәрби трибунал тарафыннан атылды хәтта. Ирек өчен үлемнән курыкмаска кирәк. Курыксаң — коллык. Әгәр бер ил икенче

илнең колына әверелсә, бу инде — түбәнлек. Җәлил, аз сүз белән куп мәгънә бирергә теләп, бу мәкальләрнең эчтәлеген янә кыскарта "Ирек китәр, качсаң ирлектән". Ирлекнең мәгънәсе, шулай итеп, кеше язмышы, халык язмышы, ил язмышы белән бәйле. Совет Армиясе, фашизмны җиңеп, ирлекнең куәтен бөтен дөньяга күрсәтте.

“Егет көче беләктә дә, йөрәктә дә" дигән мәкальне дә халык күптән иҗат иткән. М. Җәлилне бу мәкаль дә канәгатьләндерә алмый. Аның мәгънәсен ул бөтенләй башка сүзләр белән бирә: "Буа алмас ләкин богаулар кылыч йөртә белгән беләкне". Егет кешенең көче беләктә дә, йөрәктә дә икәнлеге мәгълүм инде ул. Болай әйтеп, М. Җәлил эстетик зәвыгы һаман үсә барган бүгенге укучыны һич тә шаккатыра алмас иде. Гитлерның бөтен хыялы, корган планы Россия халкын пычрак табаны астында яшәтү иде бит. М. Җәлилнең бу мәкальгә "Буа алмас ләкин богаулар" дигән канатлы сүзләр өстәве -Совет Аримясенең корычтай ныклыгына ышануы.

Канатлы сүзләрнең мәгънәләрен, образлылыгын, хис-тойгыга булган сыйфатларын көчәйтү өчен М. Җәлил гомумкулланылыштагы, гади сөйләмдәге, гарәп-фарсыдан кергән лексик берәмлекләрне җәлеп итә. "Яшәү хозурлыгы хөрлектә" дигәндә, мәсәлән, яшәү – татарныкы, хозур, хөр — гарәпнеке. Моны халык гади генә итеп әйтә: "Күңел күтәренкелеге — зур байлык". Болай да матур, шигъри, халыкчан яңгырый. Ул — динчәрәк тә. Күңелгә, йөрәккә, эстетик зәвыкка ятышлы. Шулай да М. Җәлилне ул канәгатьләндерми. Чөнки поэтик яңгырашы ничек кенә көчле булмасын, мәгънәсе М. Җәлилнекенә караганда таррак. Яшәү хозурлыгы, күңел күтәренкелеге белән генә чикләнми. Ут эчендә яшәү хозурлыгы турында уйлану — киләчәктә зур тормышны яңача кору өчен борчылу.

“Егет үзе өчен туар, иле өчен үләр" дигән әйтем дә бик борынгы ата-бабаларыбыз иҗаты. Сугышлар гел булып торган. Көрәш өчен батыр йөрәкле ир-егетләр таләп ителгән. М. Җәлил, бу әйтемнең мәгънәсен саклаган хәлдә, шундый канатлы юллар яза: "Ил онытмас, бирсәң каныңны Ватан өчен изге көрәшкә". Үлү сүзен килештереп бетерми шагыйрь. Аны кан бирү белән алыштыра, һәм дөрес тә. Кан бирү барысын аңлатып тора. Дошманны җиңү өчен һәркемнең үлүе мәҗбүри түгел.

Халыкта “Батырның үзе үлсә дә эзе кала", "Аюның үзе үлсә дә "теше кала” дигән мәкальләр бар. Боларны мәгънәдәш яки синоним әйтелмәләр дип карарга мөмкин. Шулай да алар арасында җитди аерымлыклар да сизелә. Беренчесе — туры мәгънәлелек. Ул аңлашылып тора. Икенчесе — күчерелмә мәгънәле. "Эзе кала" белән “теше кала" — бер үк төшенчә кебек, ләкин “теше кала" — "усаллагы кала" белән синонимлаша, ул аерым кеше хакында гына әйтелергә мөмкин. Бу ике

мәкаль-әйтем төшенчәсен нииндидер абстракт мәгънәле сүзләр яки сурәтләү чаралары белән катлауландырмый шагыйрь, гади генә итеп әйтә: "Исемең калсын, үзең үлсәң дә, тарихларда укып ятларлык". Фанилыктан — мәңгелеккә якты исем калдырып китү, ак дөньяда кара эз калдырмау — кеше өчен зур гөнаһсызлык. "Тарихларда укып ятларлык эз калдыру" — кеше өчен тагын да илаһирак. Аның шулай икәнлеген М. Җәлил үлемгә дә хәтта җырлап барып, үзенең батырлык каһарманы булуы белән дә исбат итте. Ул милләт горурлыгына әверелде. Аның күп шигырьләрен башка милләт халыклары да яттан белә хәзер. Аны тарих бабай да зурлый. Милләт горурлыгы гына түгел, ил горурлыгы, тынычлык сөюче, матур тормыш төзүче, балаларына, оныкларына, бөтен яшәешкә зур бәхет теләүче барлык илләр горурлыгы ул! Бу шигырьне М. Җәлилнең үзе өчен коеп калдырган һәйкәле дип карарга кирәктер. Бер шигырьдә генә күпме канатлы юллар, афоризмнар, мәкаль-әйтемнәр, халыктагы тел гәүһәрләрен иҗади эшкәртү! Халыктагы сигез мәкальнең эчтәлеген шагыйрь үз эстетик идеалына яраклаштыра.

Шигырьдәге күп кенә сүзләрнең эчке мәгънәсе лингвистик-филолог анализ ясауны таләп итеп тора. "Сүз эчендә энҗе бар" дип тә сөйләшәбез Күп очракта, ул энҗене тапкач, аның мәгънәсен аңлый алмый торабыз. Югарыда таң сүзенең, сандугачлы алсу, төннең давыллы дигән эпитетлар ярдәмендә ачыкланып, шактый зур вакыйгаларны чагылдыруын күргән идек. Изге эпитеты татар теленә дини эчтәлек белән алына: изге җан, изге кеше, изге эш. 1941-1945 елларда барган коточкыч, җимергеч, утлы, канлы, дәһшәтле сугышны изге дип атый М. Җәлил: "Ватан өчен изге көрәш". Гитлер да аны изге дип саташты. Муссолини фашизмның зыялылар тәрбияләве турында әйткән иде. Гитлерның изгелек эшләве - Аурупада күтәрелгән фашизм шәүләсенең коммунизм шәүләсен юк итү, аннан соң бөтен дөньяны яулап алу. Мәгълүм ки, аның "изге" эше җимергеч явызлык белән тәмамланды. Совет Армиясенең изгелеге дөньяны кара пәрдә белән төрергә хыялланган фашизмның көлен күккә очырды. Шагыйрьнең аны коръәннән килгән мәгънәсе белән изге көрәш дип атавы — чынбарлык илаһилыгы.

Шагыйрьнең теге яки бу мәкаль-әйтемнәргә, сурәтләү-тасвирлау чараларына, поэтик бизәкләргә күбрәк игътибар итүе аның үз эстетик идеалына, иҗтимагый-сәяси хәлләргә бәйле. Кол Галидә (Болгар чоры), мәсәлән, мәкаль-әйтемнәр күбрәк мәхәббәт кебек изге хис-тойгыларга бәйле рәвештә эшкәртелә. Мөхәммәдьярда (Казан ханлыгы чоры) мәкаль-әйтемнәр яхшылык, әдәплелек, күркәмлек турында сөйли. Тукайда ил, халык язмышы белән бәйле. Бу санап киткәннәрнең барысы да М. Җәлилдә дә бар. Шулай да анда батырлык турында язу өстенлек ала. Чөнки моны чор таләп итте. Аның шулай икәнлеген "Батырлык турында" дигән шигырь дә исбат итеп тора. Язучының тел-стиль хосусияте аның

дөньяга карашы системасы икәнлекне М. Җәлил баш очында канлы балта эленеп торганда да исбат итте.

"Батырлык турында" исемле шигырь антонимик яки капма-каршы фикерләр көрәшен чагылдыруга корылган. Анда батырлык — куркаклык идеяләре тасвирлана. Аның шулай икәнлеге канатлы төзелмәләр (конструкцияләр) кысасындагы аерым лексик берәмлекләрдә үк сизелеп тора: кыенлык — кыюлык, батырлык —куркаклык, ирек — коллык, богау — кылыч, туу-үлү һ.б.

Синонимик сүзләр мәгънә көчәйтү җәһәтеннән файдаланыла. Алар да шигырьдә мөбарәк тәсбих төймәләредәй тезелеп китә. Беренче строфада сөю, якынлык сүзләре синонимлашкан (күп илеңә сөю, якынлык). Шул ук куплеттагы батырлык (син күрсәттең нинди батырлык) сүзенә икенче строфадагы кыюлык (кыенлыкта күренә кыюлык), өченче строфадагы ирлек (ирлек сорый көрәш егеттән) сузләренең мәгънәсе туры килә. Дүртенче строфадагы ялыну сүзе (коткарырмы ялыну, елаулар) елау, бишенче строфадагы түбәнлек, тарлык, кимлек (ни мәгънә бар эзсез яшәүдә түбәнлектә, тарлык, кимлектә) сүзләр белән синонимлаша. Ялыну елау һәр очракта синоним була алмый. Бала елый, Айгөл ялына дигәндә ул сүзләр мәгънә ягыннан бөтенләй ераклаша. М. Җәлилдә исә алар синонимлаша. Дошман алдында түбәнсенеп елау аннан рәхимлек теләнеп ялыну ул.

М. Җәлил бу шигырьдә халыкның алтын бәрабәренә торырдай мәкаль-әйтемнәрен эшкәртеп кенә калмый, антонимик тәңгәл чагыштыруларга нигезләнеп, үзе дә яңаларны (индивидуаль) иҗат итә:

Хаин каны тама чиләккә.
Батыр каны тама йөрәккә.

Бу — М. Җәлилнең үз мәкале. Моны халыкның бик күп гасырлар буе батырлык һәм куркаклык турында иҗат иткән бихисап мәкаль-әйтемнәрнең тажы яки синтезы дип әйтергә мөмкин.

Аз сүз белән күп мәгънә аңлату, образ, жанлы картина тудыру, эмоциональлеккә, экспрессивлыкка ирешү өчен М. Җәлил мәкаль-әйтем белән генә эш иткән дигән фикер калмасын. Аның әсәрләре чагыштыру, метафора, эпитет, сынландыру кебек сурәтләү-тасвирлау чараларына да бай. Бер мәкаләдә аларның барысына да тукталу мөмкинлеге юк. Шулай да "Кылыч" шигыреннән бер строфа китерик әле:

Зифа буйлы купшы офицер
Яшь хатынның сүзен ишетте.
Гайрәтләнеп көяз башкисәр
Каты ябып керде ишекне,

Биредә зифа эпитеты шагыйрь тарафыннан матурлык өчен дип уйларга ярамый. Бездә, мәсәлән, ир-егетне тасвирлау өчен ул кулланылмый диярлек. Аның матурлыгы зифа буйга гына кайтып

калмый. Ә инде чандыр, тал чыбыгыдай бөгелеп-сыгылып торган йомшак гәүдәле немец офицерына ул килешә. Бу очракта зифа эпитетында берникадәр ирония барлыгы да сизелә. Көяз, купшы эпитеты да күбрәк хатын-кызны характерлау өчен кулланыла. Немец офицерлары өчен ерткычлык кына түгел, көязлек тә, купшылык та хас иде. Кыскасы, өч эпитет немец офицерын төрле яктан танып-белүгә ярдәм итә. Фашистка карата кулланылган башка һәр сүз ерткычлыгын аңлатып тора: башкисәр, гайрәтләнү, ишекне каты ябу. Шуларның барысына яшь хатын контраст куела. Бу строфада һәр лексик берәмлек аерым немец офицерын гына түгел, теләсә нинди фашистны күз алдына китереп бастыруга ярдәм итә.

М. Җәлил иҗаты турында күп язылды. Ләкин аның тел-стиль чаралары фәнни яктан һаман ныклап өйрәнелмәгән әле. М. Җәлил нәфис сүз сәнгате остасы, һәр сүзенең эчке мәгънәсе җитди тикшерүне таләп итә. Язылсын иде шундый хезмәт!

"Канатлы сүзләр поэтикасы" дидем. Мәгәр "поэтика" сүзен “поэзия” белән бутарга ярамый. Поэтикага барлык жанрлар да (проза, поэзия, драма әсәрләре) керә. Әйтик, "Поэтика Чехова" дигән хезмәт бар. Поэтика, академик В. Виноградов әйткәнчә, телнең барлык тармакларын стилистик төрлелекләрне, сурәтләү-тасвирлау чараларын, төрле поэтик бизәкләрне, әсәрнең идея-эчтәлеген, сюжет-композицияне һ.б.-ларны үз кочагына ала. "Поэтика" дигән термин биредә шул хакта уйлап кулланылды.

Сүз йолдыз булып та кабына

С. Хәким

Сибгат Хәким "Зөбәрҗәт, алтыннарың" исемле шигырендә (1938 ел) болай дип язган иде:

Йолдызлар булып кабынды
Мәхәббәт ялкыннары.
Кирәкми, бер якта торсын
Зөбәрҗәт, алтыннарың.

Бер строфада күпме шигърият: йолдыз кабыну, мәхәббәт, ялкын, зөбәрҗәт, алтын. Алар җирдәге мәхәббәт турында җырлый һәм шул ук вакытта синең күңелеңне дә йолдызлар иле белән бәйли. Бу мәхәббәт хисе барлык зөбәрҗәт, алтыннардан кыйммәт — чөнки шундый ихлас, кайнар сөюне Ватан биргән. Әнә кайда шагыйрь җырларының чишмәсе — хәзинәсе. Поэтик көч, һәр сүзнең эчке мәгънәсен, стилистик-эмоциональ төсмерен, образлылык, сурәтлелек нигезен, эстетик сыйфатын аңлау җәһәтеннән караганда, әлеге чагыштыру әсәр тукымасында матур бизәк тышкы эффект өчен кулланылмаган. Бу традицион образ-символ ясау тел чаралары шагыйрьнең күңел

поэтикасын, рухи халәтен, дөньясын күрсәтү өчен файдаланылган. "Кирәкми, бер якта торсын", дип, гади генә әйтүдә дә күпме шигърият, тирән мәгънә!

Табып әйтелгән сүз алтыннан ким булмас, ди халык. Сүзне халык зөбәрҗәт, энҗе-мәрҗән, гәүһәр кебек затлы әйберләр белән чагыштыра. Поэзия әнә шулай "алтын", "зөбәрҗәт", "энҗе-мәрҗәннәрне" эзләп табып, акыл һәм йөрәк белән анализлап, аннары әсәр тукымасына җыйнын белүдән туа. Бер тел чарасына "яшел чирәм" җәеп, икенчесенә каш җыерып, түбәнсетеп карау ярамый. Мәсьәлә телнең барлык парына, беренче карашка хәтта шигърият зәвыгына туры килмәс кебекләренә дә әсәр тукымасында хаклы урын бирә белүдә. Моның соклангыч үрнәкләрен поэзиядә Г. Тукай эшләгән иде. С. Хәким дә теләсә нинди тел чарасын поэзия рухына килештерә белә. Тикмәстән, үткәргәчтен, түңгәләгән кебек сүзләр аерым алганда поэзия өчен һич тә отышлы түгел кебек. Әмма "Мине сөйсәң", "Пар ат", "Кысла һәм бака" исемле әсәрләрендә С. Хәким аларга бик лаеклы стилистик "паспорт" бирә. Бу телебезнең ерак гасырлар төпкелендә туган, хәзер инде "модадан" чыгып баручы тел формаларына да зур ихтирам, кадер-хөрмәт, гаҗәеп бер мөкиббәнлек белән караудан килә. Сүзләрне грамматик мөнәсәбәткә кертеп, мәгънә бөтенлеген тәэмин итүче килеш кушымчалары да С. Хәким поэзиясендә шигъри ритм, рифманы искә алып кулланыла. Телебезнең эчке хосусияты нечкәлекләрен дә искә ала шагыйрь. Зур поэзия хакында сүз йөрткәндә, болар вак мәсьәлә булып күренергә мөмкин. Әгәр ташчы бер генә кирпечне дөрес салмаса да, аның тезелеш эше эстетикасын әле бөтен күңеле белән аңлап җиткермәве күренә. Моның өчен ул мастердан шелтә ала. Поэзиядә бер генә грамматик чара әсәр рухына ярашмаганлыгын сиздерсә дә, аның эстетик сыйфаты күпкә кими. Шуңа күрә нәфис сүз сәнгате осталары телнең һәр"вак" элементына зур игътибар итүчән. Тел материалын үзенчәлекле куллана белү нәтиҗәсендә индивидуаль стиль барлыкка килә. С. Хәкимнең үзенә генә хас индивидуаль стиле бар. Бу яктан ул күпләргә үрнәк остаз.

"Шагыйрьнең балачагы" поэмасындагы:

Мин геолог түгел, тик шулай да
Катлаулы һәм нечкә эшем бар,
Йөрәкләрдә яткан энҗеләрне
Эзләп таба торган көчем бар.

— кебек юлларны укыгач, бу фикер тагын да ныграк раслана.

Халык йөрәгеннән алган энҗене аның үзенә яңадан бик күп мәртәбәләр матуррак итеп кайтарып бирергә кирәк. Бу осталык поэтик телнең сәнгатьлелек дәрәҗәсен аңлап эш итүгә бәйләнгән. Өстә күренеп яткан алтынны алудан түгел. Идея-эчтәлек, образлылык, сәнгатьлелек өчен сүз сайлаганда С. Хәким шул ысул буенча эш итә. Күзгә бәрелеп

тормаган сүзләрне эзли, аларны шигырендә төрле стилистик-эмоциональ төсмерләр бирү өчен файдалана.

Шигъри әсәр өчен ят тоелган, гади сөйләм теле булып исәпләнгән төрле сүзләрне куллану борынгыдан килә. Алар Казан ханлыгы чоры шагыйре Мөхәммәдьярның "Төхфәи Мәрдан", "Нуры содур" (гарык булу) поэмаларында да бар. Бу типтагы сүзләр белән (капшау, маташу) Г. Тукай иркен эш итә. Аларның эчке мәгънәсе, стилистик мөмкинлеге С. Хәким әсәрләрендә дә көтелмәгән яктан ачыла. Йөз чыту, санга сукмау, эләктерү, йөзе кара, пыр туздыру, төрту, теңкәгә тию, магарыч кебек сүзләр "зөбәрҗәт", "алтыннар"га күләгә төшерер кебек. Ләкин һич тә алай түгел. Киресенчә, алар "алтын", "зөбәрҗәтләрдәге бизәкләр белән бик ипле аралашып киләләр. Яшел, зәңгәр, ал, кызыл, көрән кебек сыйфатлар белән чагыштырганда, мәсәлән, сорының поэтик бизәклелек дәрәҗәсе түбән кебек. Икенче төрле әйтсәк, ул матур төс түгел. Ә менә Г. Бәширов "Намус" романында шул сыйфат ярдәмендә сурәт ясый: "...Соры тасмадай боргаланып узган язгы җепшек юл..." С. Хәким "Курск дугасы" поэмасында бу сыйфат белән сугыш картинасын күз алдына китереп бастыра:

Син сорыйсың, агай, тормышыңны
Өйрәндең дип каян башларга.
Ә мин озак, озак итеп карыйм
Төтен сеңгән соры ташларга.

Төтен сеңгән соры ташлар Курск дугасындагы коточкыч дәһшәтле сугыш фаҗигасе турында сөйли. Соры сүзен алып ташласаң, сурәт югала. Рус (связной, заявление, питомник) һәм гарәп (мәгърур, шөһрәт, мәшһүр) сүзләре, төрле фразеологик әйтелмәләр (күз явын алу, тел ачылу, күңел нечкәрү, йөрәк әрнү, иза чигү, тел очында тору, бил сыгылу, җан өзелү) билгеле бер стилистик максатта кулланылып, шагыйрьнең гомум эстетик концепциясенә буйсына.

Сүз сүзне матурлый, дип тә әйтә халык. Бу очракта да телнең тыштан ялтыравы түгел, эчке матурлыгы, мәгънә бөтенлеге күздә тотыла. Ачы яшь ди С. Хәким "Югалган эзләр"дә, яшь кешене көйдергән кайгы-хәсрәтне, моң-зарны белдереп. Гомумән, каләм осталары аз сүз белән күп мәгънә аңлата алалар. "Володя ант итә" дигән шигырьдә С. Хәким Русияне бер җәенке эпитет белән бирү осталыгына ирешкән:

Изелгән киң рус кырлары
Тынып калдылар,
Гүя зур юллар өстендә
Утлар яндылар.

Киң рус кырлары безгә мәгълүм. Ә менә изелгән сүзе иске Россия халкының авыр, караңгы, михнәтле тормышта яшәвен күз алдына китереп бастыра.

Шагыйрь һәр поэтик бизәкне идея-эчтәлегенә туры китереп, чагылдырылган чорның рухы, үзенчәлегенә карап файдалана, аларның барын да сизмисең. Чөнки тасвирлау бизәкләре сүзнең эчке мәгънәсе белән аерып алгысыз дәрәҗәдә табигый мөнәсәбәткә керә. "Дала җыры" поэмасында, мәсәлән, бөкрәеп җиргә утырган картның кайгысы болай да аңлашыла. "Күтәрә алмаслык кайгы" дип тә әйтә халык. С. Хәким бу төшенчәне "Борчулы төн ике иңен баскан" дигән метафора белән аңлата. Яки аның "Егерме бишенче август" исемле шигыренең беренче строфасына игътибар итик:

Якты шатлыклы, борчулы —
Төрле көн бар язмышта;
Мусаның кара шәүләсе
Калка һәр ел августта.

М. Җәлил турында күп язылды. Шуларның барысыннан соң әнә ничек — язмыш төшенчәсен: "Мусаның канлы шәүләсе Калка һәр ел августта", — дигән метафора белән конкретлаштырып әйтә шагыйрь.

С. Хәким традицион образ-символлар белән иркен эш итә. Җил образы мәсәлән, халык иҗатыннан ук килә. "Көзге җилләр" шигырендә Тукай аны капиталистик җәмгыятьтәге авыр тормышны чагылдыру максатында файдалана. Җил Һ. Такташта, Г. Ибраһимовта искелекне җимерүче символик көч буларак кулланыла. С. Хәкимнең "Верховой" исемле шигырендә җил ярдәмендә эшченең какшамас көчле образын сурәтли. Кыш. Кырда буран. Якындагы вышканы да күреп булмый. Сызгырып искән җил верховойның көчен сыный, аны йолкып алып ташларга тели. Мондый каты, көчле буранга вышка да чыдамас төсле. Әмма кеше түзә. Барлык табигать көйсезлекләренә каршы оста көрәшә: "тау өстеннән җил сызгырып исә, әйдә, көчен сынасын. Верховойны йолкып ташлый алмас, вышкаң гына түзсен, чыдасын". Бу эшчедә давыллы елларда чыныккан ныклык чагыла кебек. Ул җил образы катнашлыгында бирелә.

Чорга, әсәрнең идея-эчтәлегенә бәйле рәвештә туган яңа сурәтләү чаралары да С. Хәким поэзиясендә шактый. Ләкин шагыйрьнең сүз сәнгате остасы булу дәрәҗәсенә күтәрелүе — һич тә поэтик бизәкләр белән мавыгуы түгел. Гадилектә. Пушкин, мәсәлән, чагыштыруларны яратмаган. Толстой гади генә сүзләр белән күп мәгънә белдерү, җанлы картина тудыру, сәнгатьлелеккә ирешүне хуплаган. С. Хәкимнең:

Хезмәттән соң камыл төпләрендә
Йоклый изрәп җәйнең тынлыгы

— кебек юллары шуңа тартым. Көне буе эш кайнаган кырлар тынып калган. Шушы тынлыкны шагыйрь берничә сүз белән сурәтләү осталыгына ирешә.

Шагыйрьнең үзенә хас индивидуаль стилен билгеләүдә бер юл бар.

Ул туган тел хәзинәсендәге бөтен байлыкны поэтик юлларда үзенчәлекле куллана белүгә бәйләнгән. Шагыйрьләр бер-берсеннән дә өйрәнә. Бу күренешне Агыйдел белән Каманың кушылуына охшатасы килә. Алар бер-берсен озак эзләп кавышсалар да, әдәплелек саклап торган кыз белән егеттәй, һаман кушылмый агалар әле. Агыйдел ягында — ак, Кама ягында — каракучкыл су. Искиткеч матур, поэтик картина! Тора-бара алар Иделана куенына аерылгысыз "җаннар" булып барып керәләр. Поэзиядә дә шулай бит. Тукай җилне — өй түрендә, С. Хәким "Татарлар елмаеп үлделәр"дә өй янында елата ("Өемнең янында жил елый"). Аерым юлларны укыганда Такташ, Җәлил шигырьләре күңелгә килә. Шагыйрьгә Пушкин, Лермонтов, Некрасов, Есенин йогынтыларын сизү дә кыен түгел. Ләкин, барыннан да бигрәк, аның стилендә Тукай һәм Такташлар моңы аралашып китә кебек. Әмма әлеге аралашу — Агыйдел белән Кама елгасының бер-берсенә тәмам кушылып бетүе кебек үк. С. Хәким үзенә чаклы булган шагыйрьләрнең стилен сиздерми дәвам итә. Бу аның осталыгына гына түгел, традицияләрне үзенчә үстерә, камилләштерә белүенә бәйләнгән.

С. Хәкимнең шигъри хәзинәсендә зөбәрҗәт, алтыннар күп. Шуңа күрә аларны тулысынча бәяләп бетерү һич мөмкин түгел. Шагыйрьнең поэтик теле махсус тикшерүгә мохтаҗ.

Олы шагыйрьнең сәнгатьле теле

С. Кудаш

Һәр сүз сәнгате остасы тел диңгезенең иң тирән җиренә чумарга ярата. Чума да аның төбеннән сүз энҗеләре эзли. Таба алмаса әрни, сызлана, үзен-үзе кая куярга белмичә өзгәләнә. Шуннан ул бу киң диңгез кочагында бер аркылы, бер буй йөзәргә тотына. Эзләнә. Ярсый. Шашкын балыктай кылана, һаман да таба алмаса, янә тирәнгә чума. Инде бу юлы сүз-энҗене эләктерә алмаса, янә тирәнгә чума. Инде бу юлы энҗемәрҗәнне эләктерә алган икән, ул — бәхетле. Әмма яңа энҗе белән әсәр тукымасын чигүләргә ашыкмый әле ул. Үзенә чаклы булган сүз сәнгате осталары аны кулланганмы? Шул хакта уйлана. Әгәр кулланган икән, хәзер инде аңа бу сүз-энҗенең башка яңа асыл сыйфатларын эзләп баш ватарга кирәк.

Тормыш диңгезендә дә, тел диңгезендә дә армый-талмый оста йөзүче, халык күңелендә яшәү кодрәте өлгесе калдырып киткән, үзен үлемсез шөһрәт итә алган Сәйфи Кудашны мин сүз гәүһәрләренә үтә җитди караучы әнә шундый каләм осталарының берсе дип исәплим. 1913 елда язылган “Бәхет эзләгәндә” дигән тәүге шигырендә үк ул үзен чын мәгънәсендә сүз сәнгате маһиры итеп таныта алды. Җиде генә строфадан торган бу шигырьдә шул чорны халык йөрәгеннән ургылып чыккан моң

аһәңе дә, гасырлардан-гасырларга җырларда яңгыратып килгән тормыш-яшәү фәлсәфәсе дә, яхшылык-яманлык, кешелеклелек — кешелексезлек, шәфкатьлелек — шәфкатьсезлек турында уйланулар да бар. Төрле-төрле сүзбизәгеч (эпитет), чагыштыру-охшату, сүзалмаштыргыч (метафора), тәгъбир бирәмлеге (фразеология), капма-каршы мәгънәле сүзләр антонимнар), мәгънәдәшләр (синонимнар) әсәрләрнең йөрәк тамырына җан-кан өсти. Янә шунысы игътибарга лаек: шагыйрь халык иҗат иткән тел бизәкләрен (традицион сурәтләү чараларын) әзер килеш тә файдалана, аларны үзгәртеп тә куллана, әсәр һәм ул чагылдырган чор сулышына җайлаштырып, үзе дә яңаларын уйлап таба: ал кояшка төшкән кайгылар, уйсу җирләр тулырлык күз яше, бәгырьләрдән кара каннар таму, язмышның явыз кулында кысылу, өмет кошының канаты каерылу, бәхет йолдызына очу, сәҗдәләргә иелеп багыну, өзелгән өметләр ялгану һ.б.

Бай, матур, гүзәл Башкортстан җирендә үскән мең төрле чәчәк Урал күкрәгенә ярып чыгып аккан көмеш чишмәләр, нәзекәй билле кыз йөрешен хәтерләтеп аккан Агыйдел һ.б. елгалар, әллә күпме кыйммәтле әйберләр поэтик символ дәрәҗәсенә күтәрелде. Ә җил шуларның һәммәсен йомшак куллары белән ихлас назлап исә. Юк, ул гына да түгел. Җил изге хәбәр ташучы да, кешеләр язмышын хәл итүче бөек көч тә куәтенә гайрәт салучы каһарманнарча дан җырлаган кодрәт тә. Сәйфи Кудашның “Язгы җил” дигән шигырендә җил кеше сыйфатына керә. Язгы җил шаулый, шатлана, әрни, көлә, сыкрана, шыңшый, елый. Ни өчен? “Көзге җилләр” дигән шигырендә Г. Тукай да елаткан иде җилне'

Көзге төн.
Мин йоклый алмыйм.
Өй түрендә җил елый;
Җил еламый: ач үлемнең куркуыннан ил елый.

Тукайда — көзге җилләр, Сәйфи Кудашта — язгы җилләр. Ни өчен Тукай көзге җилне сайлаган? Көз муллык чоры лабаса. Әмма ләкин ул чордагы ярлы халык өчен кайгы-михнәт мәле дә булган ул. Көләч җәй шаулап үтте. Кара көз җитте. Ә ярлы-ябагайның бурасында ишле балага кашыклап өләшерлек тә ризык юк. Язга ул менә-менә аяк сузам дип көчкә-илалла барып чыга. Язгы җил моңа һич тә битараф түгел. Язгы җил дә, кеше сыйфатына кереп, елап-елап йөри. Тукай белән чагыштырып караганда, Сәйфи Кудашта җилнең башкачарак максатта файдаланырга тиешлеге аңлашылып тора. Шигырь 1916 елда язылган. Димәк, җил беренче империалистик сугыш китергән хәерчелекләрне күреп елый:

Җил сөйли, сыкрый, елый.
Вәхшәт, золымнан зарлана.
Дөньяда хаклык, хакыйкать —
Юклыгыннан каргана.
Елаша ач, тол, ятим —

Мескен, фәкыйрьләр дөньясы;
Җирне каплаган һәлакәт,
Кайный кан, яшь елгасы.

Монда язгы су урынына солдатлар каны ага. Ерткычлар ямьле дөньяны тар-мар итәләр. Менә нигә язгы җил сыкрана.

Шагыйрьнең эпиграф итеп халык җырын файдалануы да очраклы түгел. Ул әсәрнең идея-эчтәлегенә, кан агышына кушылып китеп, яңгырашны, мәгънәне көчәйтергә ярдәм итә:

Сандугачкай сайрый: "Чут-чут, — дип.
— Кунар гөлкәйләрем юк-юк, — дип.
Мин дә шулай җырлыйм былбылдай,
"Үз бәхеткәйләрем юк-юк!" — дип.

Җансыз әйберләрнең җанландырылып бирелүе әдәбият теориясендә сынландыру дип атала: кояш елмая, йолдызлар күз кыса, диңгез шаулый, җил елый, буран котыра, ай йомшак нурлары белән иркәли җир белән күк серләшә һ.б. Сәйфи Кудаш сурәтләү-тасвирлау чарасының бу төре белән күп мәгънә аңлата, идея-эчтәлекне тирәнрәк ача, образлылыкка, эмоциональлеккә ирешә, сәнгатьлелекне яулый. Бу үзенчәлек шагыйрьнең башлангыч иҗатында ук күзәтелә: кышның ыжгыр суык белән масаюы, язның гөл кочаклап килүе, чәчәкләрнең назланып утыруы, курайның бәгырьләрне өзүе, җилнең вәхшәт күреп зарлануы һ.б. Сәйфи Кудаш иҗатының башлангыч чорында ук поэзиядә коры сүзләр белән генә эш итмәде, поэтик фикерләвен ул нинди дә булса махсус бер үзенчәлекле әйбер-предмет, күренеш-вакыйгага бәйләп бирә. Бу исә аның эстетик идеалын, дөньяга карашын, йөрәк тибешен тирәнрәк аңлауга ярдәм итә. Шагыйрьнең поэтик гәүһәрләре арасында фразеологик берәмлекләр, мәкаль-әйтемнәр аеруча зур сәнгать көченә ия. Әмма аларны да шагыйрь бик сирәк очракта гына әзер килеш куллана. Ул, күрәсең, кулга каләм алып яза башлаганда ук халык иҗат иткән поэтик чараларны һәрвакыт үзгәртмичә файдалануны чәйнәп бирәгәнне йоту кебек булуны аңлагандыр. 1916 елда язылган "Салчылар" дигән шигырьгә игътибар итик. Анда да башта халык җыры эпиграф итеп кулланыла:

Идел өстендә сал килә,
Сал өстендә мал килә.
Ул малларны тапкан чакта,
Яшь йөрәктән кан килә.

Сызылып кына җәйге ал таң ата. Таңгы җил белән урман шаулый. Өлкән ил белән исәнләшеп, нурлар чәчә-чәчә, кояш көлеп чыга. Яфраклар шыбырдашып сөйләшә. Идел өсте җем-җем нурлана. Чәчәкләрдән тәмле исләр аңкый. Үләннәрдән көмеш чык тама. Сандугачлар ярсып, ямьгә юанып, дәртләнеп саз кылларын чирткәч, әрәмәләр, бөдрә чуклы таллар катланып куялар.

Табигатьтә никадәр җанлылык, хозурлык, хис-тойгыларыңны даими кайнатып торырдай гүзәллек. Әнә шул күркәмлекләр эчендә, Иделнең талгын кочагында салмак кына сал агып килә. Сал өстендә ике җан иясе. Алар моң дәрьясында изри. Берсе шыңгырдатып курай тарта, икенчесе — койрыктагысы — җыр суза:

Аккош карап оча күлләргә,
Сандугачлар куна гөлләргә;
Күрмәгәнгә, дуслар, күрсәтмәсен,
Ярдәм бирсен ходай күргәнгә,
Кычкыра да кәккүк, ай кычкыра
Буз елгакайларың буенда.
Әйтегез лә, дуслар, шул кәккүккә,
Кычкырмыйча торсын быелга!

Бу шигырьне укыганда, үзең дә сизмәстән, Башкортстанның бай, күркәм, матур табигатьле кочагына чумып хозурланасың. Шул табигать кочагында сыкраган курай моны, тормыш авырлыгы матур яңгыраган йөрәк җыры күңелләрне тетрәтә. Ә шулай да сал өстендәге ике адәми зат, казганып табылган малның йөрәккә кан саудырганын аңласалар да, туган җирнең искиткеч матур табигатенә, туган илнең язмышына һич тә битараф түгелләр. Киресенчә, аларның моң-зары, кайгы-хәсрәте, йөрәк сыкрануы ахыр чиктә батырлык-каһарманлык, илне зурлау төшенчәсе белән бәйләнә. Халыкта туган илне, аны саклаучы корыч йөрәкле ирләрне данлаган күп кенә мәкаль-әйтемнәр бар: "Айбарлы ирләр бар чагында, базынмас дошман илемә"; "Батыр кирәк яу килгәндә, түрә кирәк дау килгәндә"; "Ат туйган җирендә, ир туган җирендә" һ.б. Сәйфи Кудаш шул төшенчәләр нигезендә үзе яңа мәкаль әйтем иҗат итә һәм шулар аша бөтен бер строфа төзи:

Кызыл гына төлке — таулар күрке,
Батыр да гына егет — ил күрке,
Батыр да гына егет — илдән китсә,
Шунда бетә, дускай, ил күрке.

Яшь шагыйрь ил, халык язмышы турында әнә ничек зур уйлый. 1916 елда әйтелгән фикерләр бүгенге тормыш-көнкүреш, иҗтимагый-сәяси хәлләр белән аваздаш. Батыр да гына егетләр илдән китә тора, гөлчәчәк эчендә балкып утырган вак авыллар комга сеңгән су урынына юк була, нәтиҗәдә ил күрке сүнә бара. Бу хакта бик борынгы ата-бабаларыбыз да нык борчылган. "Ир бала үзе өчен туа, иле өчен үлә", — дигәне дә бар. Ә инде егетләр батырлыгының ил күрке булуын табигатьнең бер матур, җанлы, шигъри күренеше белән чагыштырып бирү — кызыл гына таулар күрке — сәнгатьчелекне бермә-бер арттыра.

Шагыйрьнең язгы җил аша ничек образлылыкка ирешүен, идея-эчтәлекне ачуын, эмоциональлекне арттыруын күргән идек инде. Яз —

шагыйрь иҗатының чишмә башы. Язның көзе булмыйча калмый, әлбәттә. Шагыйрьнең дә көзе булырга тиеш. Сәйфи Кудаш аны төрле күчерелмә мәгънәдәге сүзләр белән аңлата. Гомерен ул кибәнгә дә чагыштыра. Кибән кою — тормыш кору. Кибән коя башлау — тормыш язы. 1985 елда язылган "Кибән кояш..." дигән шигырендә, яшьлек елларындагы кебек янә җир образына мөрәҗәгать итә шагыйрь. Әмма бу инде яшьлекне символлаштыручы яз җиле түгел, ә бәлки картлык килүне хәтерләтүче көзге җил.

Көзге җилләр гомерем тирәгенең
Ай буе тетмәсен теттеләр.
Туксан беренчемнең ел яфрагын
Шытырдатып өзеп киттеләр.

Җил образы шагыйрьнең тәүге шигырьләреннән үк башланып, соңгы иҗатына кадәр стилистик чара сыйфатында кулланыла, һәр очракта ул бу традицион образны идея-эчтәлеккә яраклаштыра белә. Әлбәттә, аның тукымасында башка образ-символлар да зур эмоциональ көчкә ия. Ахыр чиктә шагыйрь бу кырыс, усал тормыш мәйданында үзе җил-давыл булып керә.

Гизәр өчен гомернең чүлләрен
Давылланып җилләр булып истем
Кичәр өчен тормыш диңгезләрен
Кул кабартып көймәләрне иштем.

Шагыйрьнең яшьлегенә тагын да әйләнеп кайтыйк әле. 1916 елда язылган "Дим" дигән шигырендә шундый юллар бар:

Монарланып күренә ап-ак яры,
Күкрәк киереп, көчле батырдай,
Һәйкәл кебек торган карт тирәкләр
Башкортларның гомерен хәтерли.

Мондагы чагыштыруларның нинди тирән мәгънә аңлатуын аңлау кыен түгел. Дим елгасы — җырларда матурлык һәм батырлык символы. Аның күкрәк киереп, көчле батырдай торуы шуны раслый, һәйкәл кебек торган карт тирәкләрнең башкортлар гомерен хәлерләтүе дә зур поэтик көчкә ия. Башкорт халкының героик үткәнлеге, каһарманлыгы, ил язмышы өчен барган авыр көрәшләрдә күрсәткән батырлыгы тарих сәхифәләренә языла килгән. Шагыйрь менә шуны илнең бай, күркәм, матур табигатенә бәйләп бирә. Монда образлылык та, идеялелек тә, эмоциональлек тә ярылып ята.

Сәйфи Кудаш — Башкортстанның халык шагыйре. Бу бөек исемгә ул, минемчә, ике төрле юл белән ирешә. Беренчесе — гомере буе халык моңнарын җырлавы белән. Икенчесе — рәсми рәвештә бирелү. Мәгълүм ки, беренче очрак отышлы. Чөнки гәрчә рәсми рәвештә түрәләр бирмәсә дә, ул инде халык шагыйре иде. Моны раслау өчен иҗатының башлангыч

һәм соңгы чорыннан кайбер мисаллар китердек. Шагыйрьнең эстетик идеалы, поэтик фикер офыкларының киңлеге, аң-даирәсе халык теле диңгезе белән бәйле. Иҗатының кибәнен очлаганда, соңгы вакытта моның матур өлгеләрен ул аеруча нык күрсәтте. Халыктагыча мәкальәйтем формалары алган канатлы юллары аны чын мәгънәсендә сүз сәнгате остасы итеп танытты. Поэтик тукымасында намус, кешелеклелек, игелеклелек төшенчәләре гаҗәп көчле яңгыраш тапты. Әмма алар үгетнәсыйхәт юлы белән түгел, поэтик чаралар ярдәмендә гамәлгә ашырылды;

Әгәр керсәң начар уй белән син
Чәчәккә бик бай бер бакчага,
Төшмәс күзең уталмыйча калган
Зәгыйфь чүп затыннан башкага.

Әйе, гөл-бакчада да чүп үләннәре булуы мөмкин. Әмма бакчага кергәч, матурлыкны, гүзәллекне, күркәмлекне сөйгән кешенең күзе әле ин әүвәл аларга түгел, күкрәп утырган чәчәкләргә төшә.

Яхшы күңелле кешеләр дә шулай. Алар алтын базыннан чүп, тырнак арасыннан кер эзләми, ә бәлки матурлык, күркәмлек, гүзәллек кызыксындыра анарны.

Яшәү, гомер итү, тормыш кору пыяладай шома юлдан шуып үтү генә түгел. Йөз яшькә якын яшәгән шагыйрь бу хакта чын мәгънәсендә тирән уйлана. Ул болай ди:

Әгәр күлең сай булса,
Баткакка тиз күмелер.
Күпме тирән чумсаң да,
Барыбер артың күренер.

Яшәргә дәрте аз булган, хезмәт сөймәгән, ялкау кешенең күле була, икенче төрле әйтсәк, аның тормышы баткакка күмелә. Ә картлык көнендә күпме генә тирәнгә чумарга тырышмасын, артына буялган пычрак барыбер күренәчәк.

Йомгаклап шуны әйтәсе килә. Сәйфи Кудашның теле халыкчан, шул ук вакытта ул сәнгатьле, җанлы, образлы. Халыктагы тел гәүһәрләреннән поэтик гөлләмәне оста ясый белсә, аларны халыкка тагын да сәнгатьлерәк итеп кайтара алды.

Сәнгатьлелекнең сере

М. Кәрим

Шигърияттә (поэзиядә) сәнгатьлелекне ачыклау бик җиңел түгел. Анда, минемчә, болындагы мең төрле чәчәкләр төсе, аларда безгә күренмәгән илаһи эчке җан, тереклек-серлелек, тышкы балкышматурлык, мең-миллион газаплар аша тау күкрәген ертып чыккан чишмә

моңы, аның назлы кыз Йөрешен хәтерләтеп агуы, урман шавы, андагы яфракларның серләшүе, сандугачлар сайрашуы, тургайлар җыры, иген кырлары, талгын гына искән җилдә башаклар шыбырдашуы, галәм киңлеге, бөтен дөнья сулышы һәм шагыйрьнең олы, кайнар йөрәге, хистойгы ташкыны, күңел даирәсе, уй-акыл-фикер кодрәте бар. Болар һәм шуларга охшаш биниһая күптөрле җисем-әйбер, күренеш-вакыйга, хәл-әхвәл, барлык хәяти яшәеш уптым илаһи бөтен бер шигъри-поэтик йомгак тәшкил итә. Шагыйрь кеше күзе күрмәс җирдән энҗе-мәрҗән эзләп тапкан мисыр күгәрчене кебек, кеше күңеленнән барлык җисем-әйберләрдән, дөнья киңлегеннән поэтик гәүһәр чүпли. Алар халык телендә, җырларда, мәкаль-әйтемнәрдә, әкият-риваятьләрдә дә күп. Димәк, шигъри энҗене шагыйрьгә иң әүвәл халык үзе бүләк итә. Бәйрәм ашы – кара каршы. Шагыйрь халык иҗат иткән поэтик энҗеләрне дә ныграк иплэп-сипләп, матурлый-матурлый, мәгънәсен тирәнәйтеп, аның үзенә кире бирә. Зур шагыйрь, азык көтеп авызын ачып торган кош баласыдай, халык иҗат иткән поэтик табышлар белән генә канәгатьләнми. Ул әсәрнең идея-эчтәлеге, җаны-каны, сәнгатьлелек дәрәҗәсе таләп итсә, халык телендәге поэтик бизәкләргә үзе дә яңа төсләр өсти. Әгәр бу да канәгатьләндермәсә, үзе яңадан-яңаларны иҗат итә. Мондый үзенчәлек сүз сәнгате осталарының беренче әсәрләрендә үк күзәтелә. Мостай Кәримнең 1936 елда язылган “Дулкыннар” шигыренә игътибар итик.

Апрель киче зәңгәр пәрдә тарта. Идел битенә төн сыена. Аксыл айның тоныкнурларыннан дулкыннар көмешләнә һәм алар сикерешеп уйный башлый. Шагыйрь — көймәдә. Ул шаян дулкыннарга гашыйк. Ишкәкче дусты тиз арада ярлар белән араны ерагайта. Ә язгы Идел бөтерелеп ага да ага. дулкыннар көймәгә үрмәли. Бу үзенчә бер поэтик күренеш-манзара. Ни өчен яза моны шагыйрь? Гаҗәп бай, матур, хозур табигатьле Башкортстан җиренең бер күренеш мизгеле белән укучыны ләззәтләндерергә, сихерләргә телиме? Анысы да кирәк. Табигать гүзәллеге күңелгә рухи байлык, эстетик гүзәллек өсти. Шулай да шагыйрьнең әйтәсе килгәне ул гына түгел. Аның мәгънәсе тирәнрәк. Ул яшьлек матурлыгы турында җырлый. Канатларын каккан дулкыннар аңа яшьлегедәй матур күренә:

Язгы Идел бөтерелеп ага,
Дулкын көймәбезгә үрелә,
Канатларын каккан шул дулкыннар
Яшьлегемдәй матур күренә.

Яшьлекне гөлгә, чәчәккә, таңга... — тагын да әллә ниләргә чагыштыралар. Әмма халык җырларында яшьлек күп очракта язуларның барысыннан да матуррак итеп тасвирлана. Бер генә мисал:

Яшь чагымда күкрәгемә

Чәчәкләр кадамадым;
Чөнки яшьлегемдәй матур
Чәчәкләр табалмадым.

Бу шигырьдә дә шулай: яшьлек дулкыннар кебек кенә матур түгел, ә киресенчә... яки яшьлек чагыштыргысыз. Ул барыннан да өстен. Ә инде дулкыннарда яшьлек матурлыгын күрү — эчке поэтик көчкә ия. Яшьлек — матурлык кына түгел, гайрәтлелек, көчлелек, гаярьлек чоры да. Бу шигырьне шагыйрь унҗиде яшьлек чагында язган. Йөрәкнең дулкынланган, ярсыган чагы. Аннаң соң инде шагыйрь тормыш дулкыннары эченә кереп китә. Дулкын сүзе аның бик күп әсәрләрендә символ буларак кулланыла. Аның эчке мәгънәсе әсәрдән-әсәргә һаман тирәнәя бара. “Диңгез ярында” (Пушкин рәсеменә) исемле шигыреннән (1937) бер өзек:

Сул кулын как кыя ташка терәп,
Дулкыннарга текәп күзләрен,
Әллә инде азатлыкны шагыйрь
Диңгез давылыннан эзләде.

Галимҗан Ибраһимов та “Яз башы” дигән беренче хикәясендә дулкын сүзен табигать күренешен тасвирлау җәһәтеннән файдалана: “Әнә ерак таулар, урманнар, әнә матур гына дулкынланып күренә торган уҗым басуы...”. Ә инде башка әсәрләрендә дулкын кешеләрнең эчке халәтен, рухи дөньясын, тормыш-көнкүрешне, иҗтимагый-сәяси хәлләрне, революцион көрәшне чагылдыру өчен кулланыла. “Безнең көннәр” романыннан бер мисал: “Олы Русия диңгезендә күтәрелгән куәтле революция дулкыннары...”

Мостай Кәрим чагыштырулар белән аеруча иркен, оста эш итә. Мәгълүм ки, һәр милләтнең үзенә генә хас традицион чагыштырулары була. Алар башкорт телендә дә, татар телендә дә шактый күп: арысландай егет, мамыктай кар, җиләктәй кыз, талдай нечкә бил һ.б. Чагыштыруда билгеле булганча, ике әйбер-күренеш бирелә. Шуның берсе чагыштырылучы (субъект) дип йөртелә. Субъектның үзенчәлекле билгесен, асыл сыйфатын, эчке һәм тышкы күренешен ачыклау өчен объект табу читен. Моның өчен күп эзләнергә, әйберләрдәге гаҗәп серле якларны белергә кирәк. М. Кәримнең “Тукайга” (1938) исемле шигыреннән мисаллар китерик:

Якты көнгә чыгып житә алмый,
Күмелеп калган шахтер шикелле,
Сөйгән монологын сөйләп бетми,
Тынып калган актер шикелле,
Агуланган тынчу караңгыда
Янып бетми сүнгән шәм кебек,
Сәхрәдәге язгы елга кебек,

Ташты да ул, тынды яшь егет,
Язгы кырау яфракларын бөргәч,
Күкрәгеп дә шиңгән гөл кебек,
Искелекнең тынчу һавасында
Тыны бетеп үлде яшь егет...

Г. Тукай турында татар, башкорт шагыйрьләре күп шигыйрь язды. Поэмалар иҗат ителде. Аның эчке дөньясы, кешелеклелек сыйфатлары, яшәү рәвеше, инсаниятлелек йөзе төрле-төрле әйбер-күренешләргә (объектларга) чагыштырылып ачыкланды. Унтугыз яшьлек М. Кәрим чагыштырулары шуларның берсенә дә охшамаган. Шул чордагы тормышны шагыйрь караңгы шахтага чагыштыра. Мәгълүм ки, шахта хуҗалары эшчене баз кебек караңгы, упкындай тирән, менә-менә җимерелергә торан шахталарда эшләтте. Шахталар җимерелеп, күпләр шунда харап булды. Тукайны шуларга чагыштыру гаять куп мәгънә аңлата. Беренчедән, шагыйрь яшәгән авыр, караңгы, котсыз тормышны, икенчедән, шул караңгылыкта иза чиккән Тукайның үзен күз алдына китерәбез.

Тукай бик яшьли мәрхүм булды. Моны сөйгән монологын сөйләп бетерми тынган актерга чагыштыру да күп нәрсә турында сөйли. Актер — нәфис сәнгате остасы. Ул һәр сүзнең һәр авазын җиренә җиткереп, эчке мәгънәсен ачарлык итеп, тамашачы күңеленә тәмам сеңдерер дәрәҗәдә сөйли. Әйтәсе монологын әйтеп бетерә алмый сәхнә белән хушлашканнары да була. Тукай — нәфис сүз сәнгате остасы. Актер халык күңелен хис-тойгыларга бай, мәгънәле сөйләме белән яуласа, шагыйрь бу максатка каләм остасы буларак ирешә. Беренчесен — сандугачка, икенчесен сүз рәссамына тиңләргә мөмкиндер. Мондыйны фән телендә "индивидуаль чагыштыру" дип йөртәләр. Яки ул халыкта юк. Бу — шагыйрьнең үз табышы. Озак, җитди уйлану, сүз катламнарын кат-кат актару нәтиҗәсендә барлыкка килгән. Нәкъ әлеге кеше күзе күрмәгән энҗе-гәүһәрне эзләп тапкан Мисыр күгәрчене кебек.

Сүз сәнгате осталары чагыштыруны чор үзгәлегенә карап та төзи. Тукай гомерен агулаган тынчу караңгыдагы янып бетми сүнгән шәмгә охшату да моны раслап тора. Безнең күз алдына караңгы базда сүнәр-сүнмәс янып торган шәм килеп баса, Тукай яшәгән чор өчен бик табигый ул. Хәзер инде шәм бөтенләй кулланылмый диярлек. Шәм, лампа сүзләрен Тукай үзе дә куллана иде: "мин язам, шунда күрәм: лампа эчендә май кими, алда кәгазьгә ташыйлар - күңелемә уйлар сыймый".

"Сәхрәдәге язгы елга кебек, ташты да ул, тынды яшь егет" дигәне М. Кәримнең үзе уйлап тапкан чагыштыруы. Сәхрәдәге язгы елганың гаҗәп нык ташкыны безгә мәгълүм. Тукайның да поэзия ташкыны шулай көчле, ярсу, давыллы-дулкынны булды. Яшь егетнең дә йөрәге шул чамалы тибә бит. Тукай поэзия ташкыны арасында ярсу яшь егет иде ул.

Тукай гомер таңын — гомер язын күрде. Гомер уртасы — гомер кояшы, яшәү ахшамы аңа насыйп булмады. М. Кәримнең “Язгы кырау” сүз тезмәсен куллану юкка гына түгел. “Язгы кырау яфракларын бөргәч, капыл гына шиңгән гөл кебек” дигән чагыштыру да — М. Кәримнең үз табышы. Теоретиклар теле белән әйтсәк, индивидуаль чагыштыру. Ул да чагыштыруларда бирелгән мәгънәне, стилистик-экспрессив куәтне тагын да көчәйтә төшә. Ә инде “Искелекнең тынчу һавасында Тыны бетеп үлде яшь егет” дигәне исә шуларның һәммәсен йомгаклап ачыклап куя.

М. Кәрим Тукай яшәгән чорны хәзерге көн белән дә бик оста бәйли:

Без давыллар булып, күгебезне
Кара болытлардан тазарттык,
Без — икенче туфан,
Җиребезне
Искелектән юып яңарттык.
Тукай җыры безнең белән килде,
Җыры ялкын аның бүген дә,
Тукай… ул бит безнең якты йолдыз
Поэзиянең яңа күгендә.

Әйе, поэзиянең яңа күгендә якты йолдыз булачагын Тукай үзе дә сизгән! Ул Пушкин, Лермонтов һәм үзенең поэзия күгендә өч йолдыз булуы турында язган иде. Олы шәхесләрне үзе дә йолдызга чагыштырып зурлады: “Көч белән бергә гүзәллекне җыйган диңгез кеби” ул иде өстен вә кул җитмәс кеше, йолдыз кеби” (“Хөрмәтле Хәсәен ядкяре”).

Табигатьтә мең-миллион төрле төсләр, төрлелек, серлелек, шигъриятьлелек. Борын-борын заманнарда ук адәм баласы ул серлелеккә уй-хисе, йөрәк тойгысы, аң-акылы белән үтеп керергә тырышкан. Ул үз йөрәгенең табигать йөрәге белән бәйле булу хосусиятен аңлаган. Җыр, әкият, риваятьләрдә ул җансыз әйбер-күренешләрне дә җанландырып-сынландырып биргән: җил елый, диңгез ыңгыраша, таулар серләшә, йолдызлар күз кыса, чишмәләр җырлый һ.б. Болар әдәбият теориясендә сынландыру дип атала. Мостай Кәрим зур иҗатының чишмә башында, яки башлангыч чорында ук сурәтләү-тасвирлау чарасының бу төреннән бик уңышлы файдалана. Өстән караганда алар тышкы матурлык, нәфислелек, җете буяу өчен генә кулланылган кебек. Ләкин һич тә алай түгел, һәрберсе тирән мәгънәгә ия. “Төн турында уй” (1939) исемле шигырен алыйк:

Ай йөзтүбән ятып жирне күзли,
Урамнарга тынлык тарала,
Тойгыларга тулы хокук биреп,
Төн карарга чыктым калага.

Шигырь сынландыру-җанландыру белән башлана. Айның йөзтүбән

ятуы мөмкин түгел. Димәк, җанлы әйбердә (кешедә) булган сыйфат айга күчерелә. Шушы урында Такташтан бер мисал китерик: "Март аеның нечкә билле җиле сузылып ятып җирдән кар ашый".

М. Кәрим ни өчен кала төнен сурәтләү максатын куйган? Башкалабыз Уфаның сихри матурлыгын сурәтләү-тасвирлау җәһәтеннән. Болар сынландыру алымы белән алып барыла. Керфек ачар өчен сиреньнәрнең йокымсырап таң көтүе, топольләрнең шәһәр турында хикәят сөйләве, монда кайчандыр кыргый дала булуны әйтүләре, Иделнең сыкрап агуы, каеннарның канат җәеп шаулавы — шуларга охшаш тагын төрле тасвирламалар укып ләззәтләнәсең. Ләкин шагыйрь бүгенгегә капма-каршы (контраст) куеп, шәһәрнең үткән авыр тормышын чагылдырырга да онытмый:

Төн. Тынлыкка сеңеп бу урында
Монашкалар гимны сузылган,
Шундый төнне башкорт аркасыннан
Камчы үрергә каеш сузылган.

Бөтен Уфа тарихын, аның фаҗигале ерак үткәнен, бүгенге тормышын - шагыйрь ун строфада биреп бетерү осталыгына ирешә. Автор табигать эчендә йөзә. Аның йөрәге каланың матур бер төн йөрәге белән бәйле. Бу шигырьдә бер романга сыярлык аң-акыл, хис-тойгы бар. Уфаның искиткеч матурлыгы, сихри яме, гүзәллеге турында бик күп шигырьләр язылды. Ләкин аларның күбесе әлеге "матур", "гүзәл", "күркәм" кебек поэтизмнар (матур яңгырашлы сүзләр) белән иҗат ителә. М. Кәримдә исә бу хакта сурәтләү чаралары сөйли. Аларның һәрберсе диярлек индивидуаль-авторның үзенеке. Таң матурлыгын төрле сурәтләү чаралары белән тасвирладылар. М. Кәримнең бу шигырендә ул кызыл диңгез булып җәелә:

Хәлсезләнеп ерак йолдыз сүнә,
Айдан соңгы нурлар түгелә,
Кызыл диңгез булып таң җәелә
Республика һәм кала күгендә.

М. Кәрим — зур поэтик, фәлсәфи фикерләр белән язучы шагыйрь. Аны туган халкы, ил, ватан язмышы борчый. Ил кендеге булган ата-аналар турында да күп язды ул. Әмма һәр урында диярлек вакыйга-күренешләр, сәяси-иҗтимагый хәлләр кычкырып торган коры сүзләр белән түгел, поэтик чаралар ярдәмендә тасвирлана. "Туган җирдә" (1939) шигыреннән бер мисал:

Әти
Һаман ата арыслан ул,
Баскан җирдә ташны елата,
Әни
Әүвәлгечә

Кайгысын да,

Шатлыгын да яшькә чылата.

Көчле ирне арысланга чагыштыру халык телендә дә бар. Шуңа күрә ул укучыны әллә ни шаккатыра алмый. Ә менә баскан җирдә ташны елату — бу сынландыру инде авторның үзенеке. Бер сынландыру (ташны елату) ярдәмендә шагыйрь әнә нинди поэтик көчкә ия була.

Мисаллар Мостай Кәримнең Башкортстан китап нәшрияты тарафыннан 1970 елда татарча басылып чыккан җыентыгыннан алынды. Аңа баш сүзне Гайса Хөсәенов язган. Ул "Соклангыч поэзия иле" дип атала. Менә шуннан бер өзек: "Мостай Кәрим поэзиясе — башкорт чәчәннәренең кобаерларына, җырларына, дастаннарына хас булганча, тирән мәгънәле халыкчан фәлсәфәгә гаҗәп бай, олы тойгылы иҗат. Аның иң яхшы шигырьләренең һәм поэмаларының тамырлары, чыганагы биек таулардан алган саф сулы чишмәләр шикелле, башкорт халык поэзиясенә барып тоташа. Халык поэзиясе чишмәсе аның иҗатын иң асыл сыйфатлар белән сугарса, шагыйрь аларны үз күңеле аша үткәреп, тагын да баетып, яңадаң халыкның үзенә кайтарып бирә, аның күңелен, эстетик зәвыкларын нәфисли".

Күпме генә фикер йөртмик, бәхәсләшмик, әсәрләрнең сәнгатьлелек дәрәҗәсе, беренче чиратта, сүз-тел сәнгатьлелегенә бәйләнгән. Язучы, шагыйрь сүзнең ямен-тәмен, матурлыгын, нәфислеген, кайсы урында ничек кулланырга кирәклеген, эчке мәгънәсен, эстетик кыйммәтен, серле якларын аңлап эш итәргә тиеш.

Соңгы вакытта укытучылар алдына җирле материаллардан файдалану мәсьәләсе бөтен кискенлеге белән куелды. Бу мәкалә шуның бер үрнәге була ала. Тукайны үткәндә М. Кәримнең "Тукайга" дигән шигырен уку, андагы сурәтләү чараларының мәгънәсен аңлату гаҗәп отышлы булыр иде. М. Кәримне Тукайдан, Такташтан өйрәнмәгәндер дип әйтү кыен. Хәтта бер-берсенә охшаш сурәтләү чаралары да очрый. Тукайда: "ак күмәч берлән ашарлык саф һава". М. Кәримдә: "Кымыз кебек тәмле һава..." ("Язгы тавышлар"). Такташта: "...Ахры мәңге онталмамын усак яфраклары шаулавын". М. Кәримдә: "Каршымда усак яфраклары Талгын гына чаба кул".

М. Кәримдә миллилек тә, һәрнәрсәгә үзенчә килү сыйфаты да көчле. Башкорт кымызы бөтен дөньяга билгеле, һава да дәва, кымыз да. Шуна күрә шагыйрьнең Башкортстан һавасын кымызга чагыштыруында хаклыктан башка бернәрсә дә юк. Усак яфракларының кул чабуы да ышандыра.

Мисаллар шагыйрьнең башлангыч иҗат чорыннан алынды. Сугыш чоры поэзиясе, аннан соңгылары бөтенләй кертелмәде. Мин моның белән М. Кәримнең иҗат таңында ук сүз һәм аның асыл сыйфатына, аларның серле-тылсымлы көченә, сәнгатьлелек дәрәҗәсенә ничек җитди игътибар

итүен расларга тырыштым. Чишмәнең башы нинди, суның агышы да шундый, диләр. Саф, көчле, гайрәтле поэтик чишмә олы поэзия диңгезенә, күчерелмә мәгънәдә әйтсәк, киң күкрәгән киереп барып кушылды. Ә инде сәнгатьлелекнең сере — поэтик тел белән фикерләүнең бердәм булуында.

Исә җилләр, ага сулар...
М. Гали

Җил! Нинди генә сыйфатларга керми ул: бер фасыл, шәфкатьле-мәрхәмәтле ананың йомшак кулларын хәтерләтеп, чәчләреннән сыйпап куя; бәгъзе мәлдә, җылы агым булып, тылсымлы мәхәббәтен аңлатырга теләгән сөю илаһилыгы төсле, куеннарыңа килеп сарыла; синен белән бераз шаярып алгач, Йөрәгендә янган ут-ялкынны сүндереп, баш бирмәгән шаян-көләч кыздай, кайдадыр китә дә югала. Бу сәгадәтле минутларда кеше үзен вакыт-вакыт бишектә ана җыр-моңын тыңлап изрәгән бала хөкемендә хис итә. Менә ни өчен бәндәләр, җилгә йөрәк серен: кайгы-шатлыгын, сөюен-сөелүен, күргән михнәт-хәсрәтен сөйләп, күңелен бушата. Әнә, ни өчен кеше йөрәге белән табигать йөрәге бер-берсен аңлап тибә. Алар фани һәм ахирәт дөньясының мәңге өзелмәс илаһи "канун" чылбыры белән тоташ. Күк бүләк иткән матурлыкны җиргә өләшеп сибүче дә җил бит. Шуңадыр, бәлки, җил халыкның йөрәк төпкелленнән, күңел түреннән чыккан күп кенә җыр-моңына, кан-яшь агышына да әверелә. Әдәби әсәрләр тукымасында ул, җанлы кеше сыйфаты-кыяфәтенә кереп, сүз белән сурәт ясау, зур мәгънә-төшенчә аңлату, хис-тойгы уяту, эстетик зәвык максатында файдаланыла; әдәбият белгечләре аны "җанландыру" дип атыйлар да. Кол Галинең "Кыйссаи Йосыф" поэмасында җил, җанландырылып яки кеше сурәтенә кереп, изге хәбәр ташып йөри. Сабах җиле (таңгы йомшак җил) Якупка агалары тарафыннан коега салынган улы Йосыфның дөньяда барлыгы, бәндәләр бәхете өчен яшәүче илаһи зат, кешелекле, кечелекле, шәфкатьле булуы турындагы шатлыклы хәбәрне алып килә. Акрын гына искән йомшак сабах җиле, бәхет фәрештәседәй назлап-иркәләп, улы Йосыф югалу кайгысыннан сукранган Якупның күзләрен ачып китә.

Башкорт халкының данлыклы милли каһарманы Салават Юлаевның "Туган илем" дигән шигырендә җил, тоткында искиткеч, авыр хәлләр кичергәндә, туган якларын өзелеп сагынган чакларда, шагыйрьнең күңел ваткыч җан иясенә — якын дусына әверелә:

Туган яктан җил иссә,
Ул мина хәбәр китерсә,
Туган-үскән җирләрдән,
Өзелеп сөйгән илемнән, —

Минем туган кырлардан,
Балдай татлы сулардан,
Яланнардан, урманнан,
Күккә ашкан Уралдан
Миңа хәбәр китерә.

Сүз сәнгате осталары җилнең шигъриятлелек табигатен, кеше акылына хас серле-тылсымлы төсмерләрен, җанлылык хосусиятын төрле яклап ачыкларга тырышалар. Без аның матур өлгеләрен М. Акмулла, М. Гафури, М. Кәрим, Н. Нәҗми һ.б. шагыйрьләрнең әсәрләрендә дә күрәбез. Үзен чын мәгънәсендә поэтик сүз-хис остасы итеп таныткан, сүздән поэтик фикер гөлләмәсе үрә белгән талантлы шагыйрь Муса Гали эле иҗатының башлангыч чорында ук хыялында җылы Җилгә әверелеп, Зифа камышларга кагыла-кагыла "исә", зәңгәр күлләрнең моңсу ямен тоеп күзәтә:

Мин хыялда җылы җил булып,
Камышларга кагылып искәнмен,
Моңсу ямен зәнгәр күлләрнең
Бала чактан тоеп үскәнмен.

Җил-Шагыйрь-Кеше янә Җир елмаюы, чоңгылларда рәшә биюе, зәңгәр көмбәз, тулган ай нуры белән әсәрләнә. Тик Җил-Шагыйрь монда, матурлыкка соклану хис-тойгысы белән изрәп, гөлдән-гөлгә кунаклап йөрүче җилбәзәк күбәләк кенә түгел. Ул шушы илаһи матурлык дөньясына үзен, үлән сыман, бәрәкәтле Җир күкрәгеннән шытып чыккандай хис итә. Шуңа күрә кояш җылысын да, кыш чилләсен дә ул җаны итә, аның гөлләренә канын түгә.

Җирем, сине җаным иткәнмен,
Гөләреңә каным түккәнмен,
Миңа теләсә ни боер син,
Сиңа кирәк өчен үскәнмен.

Шулай итеп, Кеше йөрәге белән Табигать йөрәгенең чылбырдай тоташ булу фәлсәфәсе ачыклана монда. Ә инде аларның йөрәкләрен тоташтыручы Җил, теоретиклар теле белән әйтсәк, образ һәм җанлы картина тудыру, идея-эчтәлекне ачу, аз сүз белән күп мәгънә аңлату, эмоциональлекне арттыруда зур стилистик-экспрессив чара булып исәпләнә.

Янә әдәбият фәне күзлегеннән карасак, Җил җанландыру-сынландыру гына түгел, метафора, чагыштыру, эпитет һ.б. сурәтләү чаралары ясауда да матур поэтик бизәк вазифасын үти. Муса Галинең шигъри юлларында алар төрле төстәге җепләр белән чигелгән бизәкле тукыманы хәтерләтеп тора. Нинди генә поэтик чара сыйфатында кулланылмасын, Җил, билгеле, шәфкатьле ана кебек, сине һаман-һаман иркәләп-назлап кына тормый, ачуы килсә, аяусыз каты куллары белән

чабып та җибәрә, башыңа тондырып, аягыңнан егып та ташлый: диңгезләрне чайкалдырып, анда тау-тау дулкыннар ясарга, әллә ничә йөз еллар тамырланып утырган агачларны йолкып ыргытырга көче җитә. Муса Галинең "Җил, көзге җил" дигән шигырендә Җил яз, җәй айларында һәр агачны иркәләп йөри, урман эчләрне төяк итеп, алтын яфракларга башын сала, үзе дә хозурлана, матурлыкка ямь өстәп тә кинәнә. Ә көз көне Җил, өшегән җанына урын таба алмыйча, кинәт кенә усаллана да китә:

Җил, көзге җил...
Уянды да капыл, күкрәк сугып,
Ул дөньяга янап җилкенде
Һәм аяусыз салкын кулы белән
Яфракларны йолкып бетерде,
Җил, көзге җил...
Ул жанына бүген тынгы тапмый.
Башын тотып олый юларда.
Чөнки аны сөйгән шат яфраклар
Аунап ята юеш кырларда.

Җил, әнә нинди җанлы картинаны күз алдына китереп бастыра. Г. Тукай "Көзге җилләр" дигән шигырендә үзе яшәгән чорның авырлыгын Җил образы аша сурәтләгән иде: "Көзге төн. Мин йоклый алмыйм. Өй түрендә җил елый. Җил еламый, ач үлемнән куркуыннан ил елый".

М. Галинең "Кояш җиле" исемле романтик поэмасында Җил аеруча зур сәнгать көченә ия. Мәгълүм ки. Җир, кояш "чапанына" тотынып, галактикабызда секундына утыз километр тизлек белән оча. Галәм җиле Җир кешеләренең күңелен элек-электән, бик кадимге заманнарда ук, үзенә чакырып, дусларча кул болгап, сәламләп торган. Менә Җир кешесе җиде кат күк серен, андагы могҗизаларны ныклап өйрәнә башлады. Анын йөзенә миллион-миллиард еллар буе бөртекләп җыйган энҗе-мәрҗәннәрне — "туфракны" алып төштеләр. "Кояш җиле" дигән поэмасында Кояш җиле Җир-баласын җитәкләп килү белән генә канәгатьләнми, аның кешеләрен галәм киңлекләренә сәяхәт иттереп ләззәтләндерә. Әлбәттә, җир кешесенең җаны-тәне, кендеге, уй-хисләре җиргә береккән. Күктә, галәм киңлекләрендә сәяхәт итсә дә, башка планеталарда яшәүчеләрнең тормыш-көнкүрешен капшап караса да, андагы илаһилык белән хозурланса да, Кеше Җирен сагына, үз иле җилләренең моңына мохтаҗ:

Бөркет булып ярым галәм төнен,
Кояш җилен, метеор яшенен.
Эзлим йолдызның бәхет өчен
"Юл ачык!" дигәнен, яшелен.
Елмаюың кирәк миңа, иркәм,

Тонык манараларның артында.
Кирәк җыры илем җилләренең
Син атлаган юллар хакында.

Шулай итеп, Җил образы М. Гали поэзиясендә символик сурәт төсенә әверелеп, лирик геройның эстетик идеалын, рухи бөеклеген, поэтик позициясен ачыклауга ярдәм итә.

Күп нәрсәләр халык җырларында, әкият, риваятьләрдә традицион образ буларак кулланылып йөри. Андыйларга Җил генә түгел, табигать бүләге булып исәпләнгән тал, чишмә, йолдыз, ай, кояш, таң, сандугач, елга, диңгез, күл, камыш һ.б. шундый бик күп төрле башка сын-әйберләр дә керә. Әлбәттә, алар тарафыннан ясалган традицион образлар белән һәрвакыт әзер килеш эш итү шагыйрьнең сүз сәнгате остасы булуын расламый әле. Әсәрнең фикер-эчтәлеге, ул чагылдырган чорга карап, традицион образлар каләм осталары тарафыннан үзгәртелеп тә кулланыла. Шуның белән бергә, әдип үзе дә яңадан-яңа поэтик бизәкләр, сурәтләү чаралары иҗат итә. М. Галинең поэтик тел остасы булу дәрәҗәсенә күтәрелүе дә шуңа бәйләнгәндер. Фразеологик берәмлекләр, мәсәлән, телдә катып калган формалар булып исәпләнә. Икенче төрле әйтсәк, алар үзгәрешкә бирелми. Әмма сүз сәнгате осталары андый "Катып калган" караш белән һич тә килешә алмый. М. Гали, мәсәлән, халыктагы "йөрәккә кысу" дигән фразеологик берәмлек нигезендә бөтен бер строфа төзи:

Чөнки мин Җирдә үк чыныктым, аларны,
Антиларны жинә-җиңә,
Ватып мәңгелек догматларны,
Җир шарын
Алдым мин кысып үз йөрәгемә.

Шагыйрь яңадан-яңа контаминацияләнгән (берничә фразадан оешкан) фразелогик берәмлекләр дә иҗат итә. Алар "Кояш җиле" поэмасында аеруча күп: кешелек өчен серләр бөртеген утлы сәйлән итеп тезү, акыл шарыннан сүнмәс зиһеннең тирәнәюе, җиһан пәрдәсен ярып кычкыру, кан тамырыннан ут йөгертү, метеорның күкне утлы тасмага бизәп килүе, йөрәккә йолдызлар көйләгән моңнарны җыеп салу, бер генә аккош та күрмәгән нурларны җыеп алу, бар төсләрнең сихри уйнауларын күңелгә бикләү һ.б.

Әйтелгәнчә, сүз сәнгате осталары тасвирлау-сурәтләү чараларын шигъри бизәкләрне төрле-төрле әйбер-предметларга нигезләп ясый. Ә менә ул әйберләр-исемнәрнең эчке һәм тышык үзенчәлеген, характерлы билгеләрен, асыл сыйфатларын ачыклауга сүз бизәгечләр яки эпитетлар зур ярдәм итә. М. Гали аларны тышкы эффектлылык, ялтыравыклылык матурлык өчен генә кулланмый, ә бәлки шулар аша аз сүз белән күп мәгънә белдерү, әсәрнең идея-эчтәлеген тагын да тирәнрәк ачу максатына

ирешә. “Кояш җиле”ндәге “Сырхау Русиянең Ятим далалары...” дигән юлларга гына игътибар итик. Поэма 1968 елда иҗат ителгән. Бу чорда әле якты киләчәккә зур ышаныч белән яши идек. Әмма Русия барыбер сырхау иде әле. Бу эпитет — бер сүз — мәңге-мәңге аякка баса алмаган, өч революция, гражданнар сугышы, колхозлашу чоры, дәһшәтле Бөек Ватан сугышы, аннан соңгы авыр еллар картинасын күз алдына китереп бастыра. Ни өчен далалар ятим? Чөнки аларны үз баласы кебек кадерләп тотучы хуҗалар юк. Әнә шул сырхау Русия, ятим далалар безне бүген тормыш упкынына китереп терәде дә инде. Шагыйрьнең ике генә эпитеты да әнә шулай тирән уйланырга мәҗбүр итә.

М. Гали контраст яки капма-каршы мәгънәле эпитетларны бик уңышлы куллана. Ак, әйтик, халык телендә бәхет, матурлык, саф тойгылар сыйфатында файдаланылса, ә инде кара төс — киресенчә... М. Гали бу ике сыйфат-эпитетны, стилистик максаттан чыгып, әсәрнең идея-эчтәлеге һәм чор таләп иткәнчә, поэтик тукымага үзенчә яраклаштыра:

Һәлакәттән куркып тормышны,
Җиргә орлык сондым — мин кеше,
Кечем белән яу-яр кайтарып,
Коллыкка ут аттым — мин кеше,
Кара бураэнаны актарып,
Ак бәхетем таптым — мин кеше!

Кара буразна туры һәм күчерелмә мәгънәдә аңлашылырга мөмкин. Кара буразнаны актармасаң, яхшы иген өмет итмә. Тормышның кара буразналарын он-талкан итеп актарып бетерми торып, ак бәхеткә ирешү мөмкин түгел. Ничек кенә булмасын, бу ике эпитет яшәү нигезенең фәлсәфи тамырларын аңларга кирәклекне искәртә. Шагыйрьнең “очкыр канат”, “чобар ак юл”, “зәңгәр, кызыл, ал тавыш”, “явыз гөмбә, болыт”, “гөнаһлы планета”, “салкын гасыр” кебек сүзбәйләнешләрдәге эпитетларның һәрберсе тирән анализ ясауга мохтаҗ. Чөнки “гөнаһлы планета”, “салкын гасыр” бик күп һәм тирән мәгънә аңлата. “Сүз эчендә энҗе бар”, — ди халык. Бу очракта “энҗе” сүзнең матурлыгын гына түгел, тирән мәгънәле булуын да исбатлап тора. М. Галинең бер эпитеты гына да бөтен бер гасырга бәһа бирергә ярдәм итә. Бу инде шагыйрьнең чын мәгънәсендә сүз сәнгате остасы булуын раслый.

Эстетик зәвыгы, дөньяга карашы, фикер йөртү офыклары һаман киңәя, үсә барган хәзерге заман укучысының таләпчән күңеле инде әдәби әсәрләр тукымасында йөз-мең кат кулланылып, тәмам ялкыткан, төсе киткән, “буявы” уңган тел бизәкләрен бик кабул итәсе килми. Әгәр очраса, даими ашап ялкыткан аш урынына күреп, укучы чыраен сытып кына куярга да мөмкин. Бу, билгеле, әдәби әсәрнең идея-эчтәлегенә, ул чагылдырган чорга, язучының эстетик идеалына да бәйле. Зур диңгездә күбрәк зур корабльләр генә йөзгән кебек, тирән фәлсәфи фикерләр белән

язылган әсәрнең “буй-сынына” вак-төяк зәгыйфь сурәтләү-тасвирлау чаралары җан-кан суты бирә алмый. Мондый очракта әдип халык тарафыннан иҗат ителгән традицион образларны эшкәртү, аларны үзгәртү, ипләү-сипләү генә канәгатьләндерми, үзе яңаларны уйлап табарга мәҗбүр була. Бу, билгеле, стильгә дә бәйле күренеш. Аристотель әйткәнчә, түбән стильдә һич кирәкмәгәнгә ялтыравыклы сүз бизәгечләр куллану стильнең ямен-тәмен генә җибәрә, һәм, киресенчә, җыен юк-бар сүз югары, тантаналы стильнең кадерен генә китәрә.

Муса Гали, сүз сәнгате остасы буларак, күп очракта поэтик бизәкләрне үзе иҗат итәргә тырыша. “Кояш җиле” поэмасыннан бер мисал:

Аксакалга килдем, ул ат белән
Печән төяп кайткан. Арыган.
Бит, куллары аның карт имәндәй.
Тирән сырлар сузып ярылган.
Күпме бәла, күпме яра күргән,
Тик багышы һаман сөйкемле;
Җәрәхәтләр тулы бите-башы -
Җир шарының үзе шикелле.

Имән — халык телендә — ныклык, гаярьлек, батырлык символы. Әмма шагыйрь бу традицион образны, стиль таләп иткәнчә, үзенчә үзгәртеп файдалана.

Җирне солдат белән чагыштыру да зур эмоциональ көчкә ия.

Белмим мин бу карт дөньяда
Җирдән дә саграк солдатны.
Шуңа да афәтләр өзә алмый
Зәп-зәңгәр ореол-балдакны.

Югарыда кеше йөрәгенең табигать йөрәге белән бәйле булуы турында әйтелгән иде. Шагыйрь энҗе-мәрҗән, гәүһәр бөртекләрен дә, елга, күл, диңгез, океанны да, Җир шарының тоташ үзен дә, вакыт-вакыт хәтта бөтен галактика, галәмне дә йөрәгенә сыйдыра ала. Аның күңелендә җил давыллар да уйный, көмеш, энҗе сулы саф чишмәләр дә чылтырап ага.

“Чишмә һәм җыр” дигән шигырьне М. Гали 1955 елда ук язган иде. Менә аның беренче строфасы:

Тын эңгердә ялгыз мин тыңладым
Саф чишмәнең дәртле агышын,
Алып китмәсме дип комеш сулар,
Энҗе сулар күңел сагышын.
Акса чишмә шаулап, эркелеп,
Ага, диләр, аны җыр кебек.

Чәчләрне сыйпап искән йомшак таң җиле, җыр булып аккан чишмә

суы, табигатьнең башка сихри күренешләре шагыйрьнең шигъри тукымасында зур поэтик көчкә әверелә.

М. Галинең поэтик теле, күренүенчә, тирән лингвистик анализ, фәнни тикшеренү ясауны, күләмле хезмәт язуны таләп итеп тора. Әгәр поэтик бизәкләрнең күктәге йолдызлар санынча булуын әйтсәк, без шул йолдызларның берничәсен генә күрсәтергә тырышытк.

Исә җилләр, ага сулар... Җилләр һаман-һаман исәчәк. Сулар һаман-һаман агачак. Шагыйрь яраткан Җил, матур кыз сынлы фәрештәгә әверелеп, ике канатына күп-күп поэтик гәүһәрләр төяп китереп торсын. Шагыйрь яраткан саф чишмә, гүзәл су кызына әйләнеп, яңадан-яңа поэтик табышлар тапсын!

Моң эчендә асылташ

И. Юзеев

Моң! Бу сүз күңелне галибанә балкып аткан алсу таңнарга, Кояшның илаһи җылы нурларында хозурланган көн үзәгенә, кызгылт-комач шәфәкъ бизәгенә, айлы кичнең йолдызлар белән чигелгән зәңгәр күк гөмбәзенә... тагы әллә нинди сихри, серле, могҗизалы дөньяга сәяхәт иттерә. Хәер, бөтен галәм моң өрфиясе эчендә изридер ул. Дөнья үзе моң катыш яралгандыр, бәлки... Җир белән күкнең кайнар мәхәббәт җимеше булган адәм баласы да үз моңы белән туа. Моңнар темасы композиторның көй-уйнау коралына күчә, шагыйрьнең шигърияте тукымасында кәрәзләнә.

Илдар Юзеевны еш кына "моңлы шагыйрь", "яшьлек шагыйре”, "тормыш шагыйре" дип атыйлар. Шагыйрь иҗатында фәлсәфи фикер, аң дулкыны, яшәү турында уйлану "коры" сүзләр белән әйтелми, төрле поэтик бизәк, сурәтләү-тасвирлау чарасы, мәгънә, моң ярдәмендә гамәлләшә. Моң шагыйрьгә тормыш фәлсәфәсен символлаштыруга ярдәм итә.

Бер уйласаң, тормыш үзе моңнан торадыр әле. Анда — матурлык та, илаһилык та, мәхәббәт тә... барысы да бар. Илдар Юзеевның "Таныш моңнар" поэмасының исеме үк шуларга ишарә ясый. Халык йөрәгенә ул моң дулкыны булып ябырылды. Меңнәр, миллионнар шашып укыды аны. Ун елдан артык радиодан яңгырап торды. Халык аны, чыннан да, тормыш моңы дип кабул итте. Заман давылы турында язылган сәхнә драмасы кебек яңгырый иде ул радиода. Безнең якларда Резидә дигән исем ишетелми иде әле. Поэма басылганнан һәм радиодан тапшырылганнан соң, язгы ләйсән яңгырдан чистарып калган җир битендә баш калкыткан чәчәкләр кебек, Резидә исеме күбәйде дә китте. Резидә исеме халык күңеленә моң булып керде. Димәк, халык моңын җырлый белгән шагыйрь. Шул моң кәгазьгә яки басмага шагыйрьнең каләм очыннан

гәүһәр булып түгелә. "Борчылу" исемле шигырьдә аның чыннан да шулай икәнлеген күрәбез.

Әрсез дигән атым таралмаган,
Тик аласын алдым.
Ни алдым:
Күктән — нурлар.
Җирдән — тәмнәр,
Табигатьтән моң алдым.
Каеннан — су,
Таңнардан — чык,
Кыңгыраудан чың алдым.

Үз йөрәгендәге моңны табигать йөрәгендәге моң белән бәйләп язу Кол Гали, Мөхәммәдьяр, Утыз Имәни, Кандалыйлар заманыннан килә. Аның матур өлге-үрнәкләрен Г. Тукай, Г. Ибраһимов күрсәтте. "Күктә ни булмас дисең, очсыз-кырыйсыз күк бит ул", — ди дә Тукай шигырьләрен җир моңы, күк йөзе моңы белән бәйләп яза. "Диңгездә" исемле хикәясендә Г. Ибраһимов болай ди: "Карыйсың да үзеңне, дөньяңны онытасың, хыялың, гүя, сине икенче дөньяларга, матурлык, изгелек белән, шигърият белән тулган яңа илаһи галәмнәргә алып китә". Матурлык, изгелек, шигърият белән тулган яңа илаһи галәм нинди ул? Зур галимнәр, алтың башлар бу хакта һаман баш вата. Бу — бер. Икенчедән, шул фикернең эмоциональ-экспрессив куәтен Г. Ибраһимов "моң" сүзе белән көчәйтеп куя: "Бераздан диңгез төбеннән моң гына нурлы ай күтәрелә".

Илдар Юзеевның әлеге строфасындагы җир йөрәге белән күк йөрәге Тоташ икәнлек турыңдагы поэтик фәлсәфәсе Тукай һәм Ибраһимовлар фикере белән аваздаш бит. Күктән — нур, җирдән тәм ала шагыйрь. Әмма көндезге кояш нуры, төнге ай нуры гына түгел бу. Кояш-ата, үз планета-балаларын ияртеп, тулпар-коштай оча-җилә бирә. Чиксез галәмдә моңлы галактикалар бихисап. Алар үзәгендә — кояш кайнарлыгыннан меңе, артык кайнар, кояш зурлыгыннан йөз-йөз кат зур булып, мөбәрәк тәсбих төймәләредәй тезелгән биниһая гигант йолдызлар. Ә күк, фән һәм дин раславынча, җиде кат. Ләкин алай гына да түгел ул. Фән аның яңадан-яңаларын эзли, билгесез чиклеккә караш ташлый, хыял-фантазиясен әллә кайларга сәяхәт иттерә...

Шагыйрь күңеленә нурны әнә шулардан ала. Ә шагыйрь барысын да чәйнәп салмый. Бу хакта Г. Ибраһимовның да әйткән фикерләре бар. Аныңча, язучы, шагыйрь идеяне үзе әйтеп бирергә тиеш түгел (соңгы вакытта шагыйрьләр моның белән нык мавыга), Моны аның сүз серләре әйтеп торсын. "Сүзнең эче — алтын, тышы — көмеш", — дигәнне Абай шуңа әйткәндер. Бу очракта Илдарның "нур", "тәм" дигән сүзләре эчендә, чыннан да, гаять серле фикер алтыны бар. Аз сүз белән күп мәгънә

аңлатуның гүзәл бер үрнәге бу. Илдарга хас булганча, гади генә әйтелгән, әлбәттә. Шигърият гадилегендәге матурлык бу. "Җир тәме" дигәнне халык аңлый. Бу хакта ул уйлана, баш вата, бөтен матди байлыкларны барлый, хозурлана да хәтта. Ә инде күк нуры аның өчен — рухи байлыклар хәзинәсе. Ләкин күктән нур, җирдән тәм генә түгел, табигатьтән "моң" да ала шагыйрь. Моң "нур", "тәм" сүзләренә яңа эстетик зәвык өсти. Шагыйрь йөрәгенә алынган бу моң, зур фәлсәфи мәгънәгә әверелеп, поэтик юллар тукымасында нәкышләнә. Димәк, моңга бәйләнешле фикер шагыйрьнең күңел сандыгында бикләнеп калмый, басмага күчә, аннан соң миллионлаган укучылар йөрәгенә эстетик шифа булып ята. Бу фикернең каен сулары, таң чыклары бер-берсенә керешә, нәтиҗәдә акыл һәм хис дулкыны барлыкка килә.

"Таныш моңнар"дагы яшь егет белән яшь кыз арасындагы мәхәббәтне чагылдыручы моң, өслүби-стилистик алым буларак, Илдар Юзеевның поэтик дөньясында һаман дәвам итә. Аның моңы вакыт-вакыт атабыз Адәм, анабыз һава кавышкан, дөнья яралган чакларга да сәяхәт итеп ала. Без аның шулай икәнлеген "Мәхәббәт китабы" исемле поэмасыннан укып беләбез:

"Мәхәббәт" дип әйтү белән, беләм:
Яңа җырлар көтәбез җырчыдан...
Мәхәббәт ул — телдән төшми торган
Иң борынгы моңлы җыр сыман.
Уй-хисләрнең иң җылысын эзләп,
Саф дөньяга карап юл чыгам.

Әйе, моңлы җырлар бик борынгыдан килә. Аларның мәхәббәт белән бәйле булганнары да бихисап. Шагыйрь уй-хисләрнең иң җылысын эзләп, саф дөньяга карап юлга чыга. Мәхәббәткә ничә яшь булу турында сорагач, мәгарәдәге ташлар да, тынып калган вулканнар да, иске каберләр дә, дөнья тарихлары да җавап бирми. "Мирас" журналының бер санында Зыя Камалиның "Акыл һәм инану фәлсәфәсе" дигән хезмәте басылып чыккан иде. Автор анда кешенең акылы, уй-хисе, талант-сәләте, моңы... һәммәсе үзе белән бергә туу турында әйткән иде. Уңган ана баланы карынында чакта ук тәрбияли башлый. Биш айдан бала күңеле тышкы дөнья белән бәйләнә. Шул чорда ук ул ананың җыр-моңын да кабул итә ала. Димәк, якты дөньяга моң белән дә туа. Шагыйрь болай ди:

"Мәхәббәткә ничә яшь?" дисәгез
Мәгарәдә ташлар дәшмәстер...
Мин җырларны тыңлыйм: ул, мөгаен,
Моңлы көйләр белән яшьтәштер.

Ананың илаһи-самими мәхәббәте балага карынында чагында ук җыр-моң белән дә бирелә икән, бу очракта сөю-мәхәббәт, чыннан да, моңлы көйләр белән дә яшьтәш булып чыга,

Тормышта барысы да капма-каршы: яхшылык — яманлык, шәфкатьлелек — шәфкатьсезлек, аклык — каралык... Шагыйрьнең моңы да гел генә фәрештәләр канатына төялеп килгән саф-ак тойгылар түгел. Аларның кара-тискәре булганнары да бар. Яки моң, яшәеш кануннары таләп иткәнчә, капма-каршылыклар давылында тирбәлә. Хәер, бу үзенчәлек шагыйрьдә "Таныш моңнар"дан ук килә. Ә инде "Мәхәббәт китабы"нда моң-галәм яшәеше ташкынының уртасында:

Кыргый багланышлар хөкем сөргән,
Тыныч кына аккан дөньяда.
Иң көчле дәрт, шатлык туган,
Фаҗигаләр арткан дөньяда.

Абай әйткәндәй, әгәр сүзнең эче алтын, тышы көмеш булса, телнең асыл гәүһәрләре булып исәпләнгән фразеологик әйтелмәләр ул алтын һәм көмешкә яңа сыйфат-ялтыравык өсти. Алар халык иҗатында, беренче язма әсәрләрдә дә күп очрый.

Татар фразеологиясен Тукай, Такташ, Туфан, Хәкимнәр бик нык эшкәртә... Илдар Юзеев та аның матур үрнәкләрен күрсәтә. "Мәхәббәт китабы" поэмасында шагыйрь моңы соңгы чиктә хәзерге чорның авыр, тирән, социаль-фәлсәфи каршылыкларын гаҗәп үткен, образлы, мәгънәле, хис-тойгыларга бай фразеологик әйтелмәләр ярдәмендә чагылдырыла.

Югары аң хөкем сөргән җирнең йөзен
вакытлыча караңгылык чорнап алган.
Йоклый адәм балалары изрәп-арып,
миллиард акыл һәм миллиард җан ялга талган.
Берәү матурлыкны төзеп арган,
берәүләре төзегәнне өзеп арган.
Иксез-чиксез яхшылыкны күтәргән җир,
иксез-чиксез явызлыкны үткәргән җир
бервакытны яманлыктан сыгылыр сыман,
сыгылыр да күк йөзенә егылыр сыман.
Ычкынмый җир... нидер аны тотып тора,
явызлыклар яхшылыкны йотып тора...
Ә яхшылык һаман, һаман шытып тора, –
аек акыл һәм җан җирне тотып тора.

Шушы юлларда 12 фразеологик әйтелмә бар. Халыктагы "чорнап алган", "изрәп йоклый", "йотып тора" кебекләре әзер килеш кулланылган. Ләкин гел әзер белән эш итү чәйнәп биргәнне йоту була. Ул шагыйрьнең сүз сәнгате остасы икәнлеген расламый. Шуңа күрә әдип аларны үзгәртә дә. Илдарда да шулай. Аның фразеологик әйтелмәләрен төзүче сүзләр арасына башка лексик берәмлекләр керә, йә булмаса бер сүз белән алыштырыла. Халыктагы "яхшылык җирдә ятмый" дигәнне автор

"яхшылык һаман, һаман шытып тора" дип үзгәртә. Илдар үзе дә яна фразеология ясый: "югары аң хөкем сөрү", "жансыз ялга талу", "матурлык төзеп ару", "төзелгәнне өзеп ару", "жирнең явызлыкны, яхшылыкны йотуы", "җирне аек акыл тотып тору".

Фәнни телдә моның термины да бар: халык иҗат иткәне — "традицион", үзгәртелгәне — "тарнсформацияләнгән", язучы үзе иҗат иткәне — "индивидуаль". Илдар күбрәк соңгы икесе белән эш итә. Аның шулай икәнен югарыдагы өзек тә күрсәтеп тора. Андый мисаллар башка әсәрләрендә дә бик күп. Аларны санап чыгу максатын куймадык, бер мәкаләдә бу мөмкин дә түгел. Кыскасы, татар фразеологиясен эшкәртүдә Илдар Юзеев классик өлге-үрнәк күрсәтте. Шушы бер өзектәге фразеологик әйтелмәләрдә генә күпме сүз-сурәт, мәгънә, хис-тойгы. Алар җырлап тора. Көй-моң белән сугарылган. Мон биредә югары аң белән бәйле.

Шигърияткә җан, кан өстәүче, андагы "тәмле" сүзләргә канат куючы, образлылыкны мәгънә һәм хис-тойгы ягыннан янә көчәйтеп җибәрүче, әсәргә яңа эстетик сыйфатлар өстәүче сурәтләү-тасвирлау чаралары белән эш итүдә дә Илдар Юзеев югары сәнгатьлелек маһирлыгы күрсәтте. Аның поэтик тукымасында халык иҗат иткән традицион чагыштыру, метафора, эпитетлар да бар. Шулай да ул мең мәртәбә чәйнәлгән, тапталган, бизәге җуелган, "укасы коелган" сурәтләү-тасвирлау чараларыннан качарга, телнең эчке үсеш кануннарына "комачауламаслык" итеп, үзе яңаларын иҗат итәргә тырыша. Бу, бәлки, "качу" да түгелдер. Яңача уйлау, янача фикер йөртү, яңа эстетик идеалларның яңа поэтик бизәкләр эзләргә мәҗбүр итүедер. Әсәрнең идея-эчтәлеге, ул чагылдырган чор, яңа эстетик сыйфатлар таләп итә моны. Хәер, бүгенге хәл-әхвәл, тормыш-көнкүреш* вакыйгаларны гына түгел, дөнья яралгандагы җан ияләрен тасвирлаганда да яңа сурәтләү чаралары белән эщ итәргә тырыша шагыйрь. "Мәхәббәт китабы" поэмасындагы "Адәм белән Һава очрашуы" бүлеген алыйк. Җир йөзендә әле бер генә йөрәк бар: Адәм яши. Ә табигатьтә өстен көчләр – ерткычлар. Шәфкатьсезлек, акылсыз дәрт хөкем сөрә. Җир буйлатып Адәм бер ялгызы килә. Ком-сәхрәләр, дала-кырлар, таулар аша карурманнар, дәръя-сулар артта кала.

Бервакытны сызылып алсу таң атканда,
Могҗизадан хәйран калып туктый Адәм.
Туктый Адәм, күзләр зуп-зур ачылганнар.
Авыр күсәк ихтыярсыз төшә кулдан...
Нәрсә соң бу: күпме гомер кичереп тә
Җир йөзендә мондый хәлне күргәне юк:
тай ялыдай елым-елым ике толым...
Кара күзләр — ап-ак карда ике йөзем

Тулган айдай күкрәкләре тирбәләләр,
Чәчәк сыман ачыла гөл-керфекләр...
Җиргә яңа туган сыман карый Адәм:
Бу нинди ямь, нинди балкыш күрелмәгән..
Серле дөнья тәкъдим итә баласына
Табигатьнең бар сафлыгын, нәфислеген,
Юкка гына эзләгәнсең зәңгәр күктән,
Эзләгәнең син яшәгән җирдә икән...

Анабыз Һаваның кыяфәтен, образ-сыйфатын, куәтен күрергә, күз алдына китерергә кем генә хыялланмый икән?! Аны тасвирларга сурәтләү чарасы табуы да авыр. "Тай ялыдай елым-елым ике толым" дигән чагыштыруда аның тышкы матурлыгы гына түгел, эчке җегәрлеге. елгырлыгы, үткенлеге дә чагылдырыла. Шагыйрьнең тайны сайлавы да образлылык ягыннан бик отышлы. Тай — атларның яшьлек чоры. Киләчәктә барлык балаларның анасы булачак Һаваның яшьлек вакыты. Ул әле яшь тайдай ярсып-ашкынып йөри. Риваятьләрдәге җир һәм күкне бер итеп гизгән Тулпар шикелле, һаваның чәчен тай ялына чагыштыру - үзе җанлы картина, сүз-сурәт, сөйкемле-гүзәл образ. "Елым-елым ике толым" дип әйтү дә әдәбиятта очрамый кебек. "Елым" сүзлектә юк. Аны ялгыз килеш кулланып та булмыйдыр: "елым ике толым" дип әйтеп булмый. Шуңа күрә шагыйрь: парлы яки кабатлаулы сүз ясарга мәҗбүр булган. "Елым-елым ике толым"да матурлык кына түгел, батырлык чаткылар да бар. Күкрәкне (бу очракта хатын-кыз күкрәгендәге ике йомарламны) айга чагыштыру халык телендә дә юк, әдәби әсәрләрдә дә очрамый. Ә менә һава өчен ул килешен тора: аның һәр әгъзасы якты идеаллар белән балкый. Болардан тыш шагыйрь һаваның рухи һәм Җисмәни көчен, гүзәл сыйфатларын сурәтләү-чагылдыру өчен төрле-төрле тасвирлау чаралары куллана. Адәмнең һавага карашында әлеге җир һәм күк йөрәгенең тоташ икәнлеге дә ачыклана:

Җиргә яңа туган сыман карый
Адәм: бу нинди ям, нинди балкыш күрелмәгән...
Серле дөнья тәкъдим итә баласына
Табигатьнең бар сафлыгын, нәфислеген.
Юкка гына эзләгәнсең зәңгәр күктән,
Эзләгәнең син яшәгән җирдә икән...
Ашкынуың, җилкенүең шуңа: җаның
нәзакәтлек, җылылык һәм назлау көткән.

Мәхәббәттә зур шатлык та, олы йөрәклелек тә, бөек хис-тойгылар да, аларга капма-каршы булган җитди авырлык та, борчылу-кайгырулар да, жиңү-җиңелүләр дә... — барысы да бар. Бу идея Илдар Юзеевның "Таныш моңнар"ыннан килә. Шагыйрь дөнья-табигать авырлыкларын җиңә-җиңә кавышкан атабыз Адәм, анабыз Һаваның дөнья зурлык

мәхәббәтен бирә ала, шундый осталыкка ирешә. Дөньяга, яшәешкә, бәндәләргә зур сөю-мәхәббәт килә. Болай ди шагыйрь:

Җирдә туа СӨЮ дигән иң гади хис,
тормыш күрке, гүзәл тойгы, акыллы ям...
Ике җанны очраштырган Табигатькә
һәм очрашкан Адәмгә дан, Һавага дан!
Сею моңы килә! Мәхәббәт моңы килә! Яшәү моңы!

...Гөл бакчасына барып керсәң, мең төрле чәчәкләргә сокланып карап торасың. Барысы да матур. Өзәргә кирәк икән, кайсын сайларга белми аптырыйсың. Илдарның поэтик бакчасында да шундый ук хис-тойгы кичерәсең. Аның үзенә генә хас поэтик бизәкләре шулкадәр күп, анализ өчен кайсын сайларга белми аптырыйсың. Язмабыздагы бу мисаллар зур гөл бакчасыннан өзгән берничә чәчкә кебек кенә.

Нәтиҗә итеп шуны әйтәсе килә: Илдар Юзеев табигатьтән халык йөрәгенә бирелгән бөтен моңны үз йөрәгенә ала да, аны халык йөрәгенә үзләренекеннән дә баерак, матуррак, мулрак итеп кире кайтарып бирә. Поэзиясе һаман тирәнәя бара. Аның поэзиясендә Кол Галиләр, Тукайлар, Такташлар, Хәсән Туфаннар моңы бар. Бүгенге диңгездәй киң татар поэзиясенә дә ул шул моңнар аша килде. Хәзер инде үзенә генә хас бай моң белән тантана итә. Киләчәк буын шагыйрьләргә аның шифалы йогынтысы булмый калмас.

Китапны япканда

Үзеңнең кем икәнлегеңне беләсең килсә, кешедән сора, диләр. “Халык ни әйтер”, — дип сөйләшәләр. Халык әйтсә, хак әйтә. Хакта — дөреслек. Дөреслектә — өстенлек. 90 яшьтә, ниһаять, шул хакыйкатьне ныклап аңладым шикелле. Хакыйкать таш яра, ялганны ярык ялгашка сала. Әдәбият дөньясында да ялганлык, дөреслек гыйззәтлелеге көрәшә. Хәзер халык әдәби әсәр укымый, диләр. Ак белән караның кискен давыллы чорында яшибез. Ничек кенә булмасын, халыкның эстетик зәвыгы үсә, фикер йөртү офыклары киңәя бара. Укыйлар. Әмма аларга замана заңын чагылдыра торган сүз-сурәтле, сүз-фикерле, сүз-тойгылы, аң-акылга гына түгел, йөрәккә, хискә, күңелгә тәэсир итүче әсәрләр кирәк. Башкортстан китап нәшрияты 1965 елда “Яратам сине, тормыш!” дигән әсәремне басып чыгарган иде. Радиода шуны һаман тапшыралар әле. Чөнки халык сорый. Галимҗан Ибраһимов турында язылган трилогиямне (“Пәйгамбәр таңы”, “Күкнең җиденче катында”, “Оҗмахка бер адым” романнары), шөкер, халык яратып кабул итте. Беренче романым “Казан утлары” журналында басылып чыгу белән, Авыргазы районы РОНОсы китап уку конференциясе оештырды. Тарих укытучысы Фәүзия Рахматуллина “Яшәү коръәне” дип атады аны. Бөек Ватан сугышын чагылдырган икенче трилогиям дә халык күңеленә хуш килде (“Язмыш корбаннары”, “Ут эчендәге мәхәббәт”, “Канлы бәхет” романнары). Әдәбият белгече, БДУ профессоры, тәнкыйтьче Мидхәт Гайнуллин: “Бу әсәр әдәбиятыбызда житди, мөһим, хәрби, сәяси проблемаларны тарих реальлегендә дөрес һәм мавыктыргыч сурәтләве белән әдәбиятның зур казанышы дип бәяләнергә лаек” дип язып чыккан иде беренче роман турында. Икенчесенә “Соклангыч роман” дигән бәһа бирде “Кызыл таң” гәзитендә Башкортстан халык язучысы Нәҗип Асанбаев. “И, газиз илем — иманлы Илешем!” исемле китабым буенча китап уку конференциясе Илеш районының 8 авылында үткәрелде. Шулай булгач, “халык хәзер китап укымый” дип әйтергә һич тә телем әйләнми. Рәхмәт халыкка!

Шушы сүзләрне язып утырганда, шагыйрь, драматург Әсхәр Кәшфуллин дустым килеп керде. Лия Габбасова миңа хат җибәргән икән. Зур тантана белән дигәндәй, хатны миңа бирде. Беләм мин әдәбиятка, сәнгатькә бөтен йөрәге, күңеле, җаны, каны белән бирелгән бу иманлы, мәгънәле ханымны. Бай эчтәлекле әсәрләрне укырга ярата иде ул. Шул сыйфатын ул 80 яшькә якынлашып килгәндә дә һаман ташламаган икән әле. Китапка булган мәхәббәт — зур мәрхәмәт. Укыганда очраган сүз-сурәт, сүз-фикер, сүз-тойгы белдерүче сурәтләү-тасвирлау чараларын аерым дәфтәргә язып куя торган гадәте барлыгы да хәтеремдә. Өч романнан торган (“Пәйгамбәр таңы”, “Күкнең җиденче

катында", "Ожмахка бер адым") трилогияне кулына каләм тотып укыган. Образлы гыйбарәләремне язып җибәргән. Гөл бакчадан иң матур чәчкәләрне җыюмы бу? Иң тәмле җимешләрне өзеп алумы? Миңа изгелек итүме? Әгәр шулай икән, **кешелеклелекнең** бөек дәрәҗәсе бит бу! Мин аны сезгә тәкъдим итәм, хөрмәтле укучыларым. Бу әсәрләремне мәктәптә укыта башладылар. Әдәби әсәрләрнең тел-стиль үзенчәлеге мәктәптә дә, югары уку йортларында да аерым фән буларак укытыла башлады хәзер. Лия Габбасованың бу изгелеге — Аллаһы Тәгалә гыйззәтлелеге. Менә ул мисаллар:

Өметсез максат — мәңге йөрер аксап. Ялгызлык белән тик тору — игезләр. Борының белән боз ярып булса да алга бар. Аш дигәндә җан-фәрман, эш дигәндә юк дәрман. Аягы пычрак — өй пычратыр, теле пычрак — кеше пычратыр. Алтын утта, ир авырлыкта чыныгыр. Карага җилкәңне, акка алдыңны куй. Хатын азса — ир башына, түрә азса — ил башына. Хәерсез хатын ир бөлдерер, хәерсез түрә — ил бөлдерер. Үз илең гөлстан, кеше иле — гүрстан. Түрәгә симез калҗа, ярлыга — ябык марҗа. Баллы сүз баш әйләндерә. Ат алганда — авызына, кыз алганда — күзенә кара. Яшь ир беләкле, карт ир келәтле. Карт мәхәббәт таш яра, яшь мәхәббәт йөрәккә яра. Бер хатында 40 ир хәйләсе булыр. Хатын-кыз хәйләсенә шайтан да түзә алмас. Хатын-кызның акылы җил өргәнче 7 төрлегә әйләнә. Ялган мәхәббәт ярык ялгашка утырта. Өметсез хатыннан тиз котыл, өметлесенә нык тотын. Сүзнең хислесе, дусның көчлесе әйбәт. Сукыр фикер сукыр күздән яманрак. Эт көтүе җыйнаулашып өрсә дә, айның чите кителми. Көчледән үчле яман. Картлар йөрәген гыйшык яшәртә. Эче караңгының йөзендә нур булмас. Кызлы йорт — кызыклы йорт. Кыз бала өй зиннәте. Тырыш булган кырыс булыр. 16 яше тулган кыз энә очында бии. Алгы итәгеңне бала бассын, арткы итәгеңне мал бассын. Бала башында бер кайгы, ата башында мең кайгы. Ана бәхете — балада. Көннең аягы озын атлый, мартның буыны шартлый. Булырдайның — буыныннан билгеле. Чәче йомшак кешенең табигате йомшак була. Ипсез ат тәртә сындырыр, холыксыз ир өй туздырыр. Бала багуы — елан агуы. Өстән бишек тирбәтеп, астан баланы чеметә. Биргәннең битенә төкермиләр. Ата юлы белән киткән бала — салуламый. Акыллының маңгае киң булыр. Ир келәт — хатын йозак. Ата йөзе — ил йөзе. Ниятең кәкре булса, юлыңның турылыгы гына файда китермәс. Уйламый әйтелгән бер сүз — аз ашка салынган күп тоз. Алтыдагы — алтмышта. Йолдыз караңгыда якты яна. Ачу — акыл дошманы. Акыллы — тыңлар, исәр — сөйләр. Бүгенге эшне иртәгәгә калдырма. Тәвәккәл — таш яра. Уйлаганнан кире кайту — күрәгеңне югалту. Сәламәтлекнең түре — йокы. Карга оясына бөркет беркайчан да кунмаячак, кар базына кояш беркайчан да төшмәячәк. Ат карагының һөнәре энә урлаудан башлана. Кылчык белән бодайны бергә кушмыйлар.

Хатын-кызның тапканы — ирләрнең жиң какканы. Кайгы — кайгырган саен куера. Саксызлык сазга батыра. Акайган күздә акыл булмас. Күңел — пыяла, дөрес чиртмәсәң уыла. Кызның кырык безе булыр. Ялкаулык — фәкыйрьлекнең башы ул. Максатсыз кеше — яфраксыз агач. Акылсыз башка алтын бүрек тә акыл бирмәс. Тырышып эшлә, дөнья явызлыгын вакытында ныгытып тешлә. Холыксыз ир тормыш ямен ала, хатыны йөрәгенә яра сала. Дөньяның рәхәтеннән михнәт күбрәк. Мәхәббәт бик назлы үсемлек сымак, әгәр аны һаман күз яшьләре белән сугарсаң, бер кайчан да озак яши алмый. Үткән гомер сүнгән күмер. Адәм фәрештә, әрекмән кәбестә булмас. Артык сүз — аркага аркан. Мактану, ялганлау, урлашу — бертуганнар.

Менә тагын бер хат

Хөрмәтле Суфиян Шәмсетдин улы, хәерле көн Сезгә!

Галимҗан Ибраһимов турындагы романнарыгызны уку бәхетенә ирештем. Әсәрләрегезне укучылар ничек кабул итүе, ничек укулары турында белү Сезгә, бәлки,кызыктыр дип, үзем ничек укуым һәм кайбер уй-фикерләремне язып җибәрергә булдым.

Башкорт телендә укыган беренче китабым бу. Укый алмам дип тотынган идем — тиз өйрәндем, шундый тиз өйрәндем, шундый җиңел укыла, бераздан үз (татар) телендә язылган кебек тоясың: безнең телләр бик якын бит.

Җиңел, ләкин тиз укып булмый. Бер сүзен калдырмыйча, хәтта аерым әйтемнәрне, кире кайтып, кабатлап укыдым. Фразеологик сүзлек кебек бит әсәр! Хәйран калырлык!

Теле генә түгел, эчтәлегенең байлыгы, тирәнлеге, мавыктыргычлыгы искиткеч булганга да тиз укый алмыйсың: үзләштерергә, уйланырга кирәк. Урыны белән, туктап, гаҗәпләнеп утырам: “Кеше язганмы моны? Пәйгамбәр түгелме Сез?” — дип. Пәйгамбәр вазифасын үтисез бит: кешене яхшырту, Аллаһы кушканча тәрбияләү...

Сүрәләр, хәдисләр күче бар әсәрегездә: күңелне сугара, сафлый, рухка байлык өсти, зиһенгә нур сибә...

Догалар күп китерелгән, мәгънәләре аңлатылмаган. Ничә ел мәчеттә укып йөреп, бу күләмдә гыйлем алмаган идем. Абыстайларны өндим Сезне укырга.

Мондый китапны бергәләп, кычкырып укыйсы килә. Кичерешләр, уй-тойгылар шулкадәр көчле, үзеңә генә сыймый, бүлешәсе килә, бергә елыйсы, көләсе, яратасы, тетрәнәсе... Хәсәнә кебек, күрше-тирәне, таныш-белешләрне, картын, яшен җыеп, укыр идем.

Әтием китап ярата, шигырь, бәетләр уйлап чыгара иде. Бөтен барлыгы белән бирелеп, ышанып укыр идем. Үкенеч, юклар инде алар.

Әсәрне укымаган, укый алмаганнар җәл. Нинди хәзинәдән мәхрүм

алар. Урысча сөйләшкән шәһәр башкорт, татарларын уйлыйм. Күпләреме үз телендә укый белә? Мин йөргән китапханәдән II томны быел өченче кат алдым (2012, 2013тә алган идем), анда бер минем генә кул эзе калган. Укып карасалар, ишетсәләрме, укымый булдыра алмаслар иде.

Минем бер танышым, Уфа кызы, башкорт телендә авыррак сөйләшә. Китапны илтеп биргән идем, укып китте. Аз-азлап, кычкырып укыйм, ди. Мәкаль-әйтемнәрне күчереп яза-яза, яратып, сокланып, шатланып укый. Туганнарын, танышларын да җәлеп иткән, елый-елый укыйбыз, дип миңа рәхмәт җибәрәләр.

Күзләре белән укымаса, колаклары белән алсыннар иде бу тылсымлы, шифалы әйберне. Нигә радиодан өзекләр биреп, кызыксындырмаска? Олы яшьтәгеләр радио тыңларга ярата. Мин сукырлар белән эшләдем. Нинди рәхмәтле җаннар, рәхмәтле укучы-тыңлаучылар алар. Романнарыгыз йөрәкләренә бәлзәм булып сеңәр иде. Техник чаралар бар, шулар аша җиткерү саваплы эш булыр иде.

Яшьләр, балалар, телевизор экраннарына капланып, күңелләрне какшатучы, хәтта җимерүче төрле “иблис”, “җен-пәри”ләрнең кылануыннан агуланып утырмасын — ишетсен, уйлансын, үрнәкләрен күрсен иде әсәрләрегезнең һәр битендә, юлында диярлек очраган: әдәп, тәүфыйкъ, инсафлылык, кешелеклелек, кечелеклелек, сабырлык, рухи байлык, саф күңеллелек, шәфкатьлелек, гаделлек, эш сөючәнлек, үч алмау һ.б., һ.б. сүзләрне...

Мәктәпләрдә үтәләрме икән тәрбия өчен Аллаһтан җибәрелгән бу олы бүләкне?

Шушындый күңелләрне тазартучы, рухны күтәрүче, изге эшләргә дәртләндерүче, Коръән кебек, тәнгә, җанга шифа иңдерүче яңа әсәрләр көтеп, Аллаһының рәхмәтен һәм ярдәмен теләп — укучыгыз Рәхимә Биктаһирова.

Мин урыс, татар, башкорт телендә язам. Казанда биш романым, пьесалар җыентыгым, “Мәктәптә әдәби әсәрләрнең телен өйрәнү”, “Тел — күңелең көзгесе” исемле китапларым, янә күп кенә әсәрләрем, фәнни хезмәтләрем дөнья күрде. 90 яшемне алар 25 августта билгеләп үтте. Үзем дә катнаштым. Әдәбиятның зур, файдалы, мәгънәле киләчәге турында фикер алыштык. 10 сентябрьдә шундый ук чара Уфада да (З. Вәлиди исемендәге китапханәдә) булып алды. Радиода, телевизорда сөйләү, төрле оешмаларда очрашу шуны күрсәтә: әдәбиятның зур киләчәге борчый халыкны. Менә шушы хакта язып утырганда “Ватаным Татарстан” гәзитендә эшләүче элекке бер шәкертебез шалтыратты. Трубканы куюым булды, бер минут та үттеме, юкмы, янә шалтырау. Янә сөйләшү. Өч ел элек кенә диплом алган, хәзер инде телевидениедә

эшләүче Гөлназ Арысланова. төркемдәше Алина Ямаева белән иртәгә консультация алырга килмәкчеләр (мин әле БДУда профессор-консультант). Быел Мәдәният елы. 2015 — Әдәбият елы булачак.

Мин читләшәм шикелле. "Ак каенлы Илешем" исемле бит китабым. Хәер, Илешнең үзен генә дә Җир йөзендә барган вакыйгалардан аерып карап булмый бит. Шигырь һәм поэмаларда поэмаларга охшап торган мәдхия-эсселәрдә, чәчмә әсәр шигъриятендә Илештән өлге-үрнәк алырлык тәгълимат бар бит. Минемчә, бу тәгълимат сүз сәнгате осталары әсәрләре белән чагыштырып караганда тирәнәя. Чагыштыру — танып белүнең анасы.

Инде китапны "яптым" дигәндә, янә бер мәкалә китереп бирделәр. "Әдәбият дәресләрендә якташ язучыбыз С. Поварисов әсәрләрен өйрәнү" дип атала. Аны районлашым,Үрмәт урта мәктәбенең элекке татар теле һәм әдәбияты укытучысы Нәфисә Латыйпова бер шәкертем аша биреп җибәргән. Нәфисә Латыйпова Үрмәт урта мәктәбендә уку-укыту бүлеге мөдире булып та эшләде. Югары белемле. Аң-акылга, хис-тойгыга, гыйззәтлелеккә бай шәфәгатьле укытучы. Хәзер лаеклы ялда. Ләкин мәктәпләр белән элемтәсен һаман өзми әле ул. Аның шулай икәнлеген, 90 яшем белән котлап, шушы язмасын җибәрүе генә дә әйтеп тора. Бар ул бездә алтын акыллы, ил мәнфәгате, халык рухияты белән яшәүче укытучылар. Бар! Бар!! Бар!!! Укытучылары нинди — иле шундый. Илләр, әйтелгәнчә, ярышка чыкты. 2014 — Мәдәният елы. 2015 — Әдәбият елы булачак.

Бәлки, шуны уйлап та җибәргәндер Нәфисә Латыйпова бу язмасын. Аны укытучылар игътибарына тәкъдим итмәсәм, гөнаһ эшләрмен кебек. Андый мәкаләләр миндә күп, әлбәттә. Булсын. Күптә бәрәкәт!

Укучылар, гадәттә, кыю, принципиаль, аңлы булып үсү турында хыялланалар. Әдәбият дәресләре аларга бу хыялларын тормышка ашыру юлын күрсәтергә, күңелләрендә туган күп төрле катлаулы сорауларга җавап бирергә тиеш.

Әдәбият программаларына кертелгән әсәрләрнең күбесе укучыларда Ватанга турылыклы булу, халыкка хезмәт итү, җәмгыять алдындагы бурычыңны үтәү, коллективизм, кешелеклелек, намуслылык, гаделлек, хезмәткә аңлы мөнәсәбәт, әхлак сафлыгы кебек сыйфатлар тәрбиялиләр.

Әдәбият дәреслекләренә кертелгән әсәрләрне өйрәнгәндә, үзебезнең туган якка багышлап язылган әсәрләрне файдалану, геройларның эчке дөньясын, һәр ике әсәрдәге табигать күренешләрен чагыштыру дәресләрнең тәрбияви ягын тагын да баета, укучыларда үз туган ягына мәхәббәт, кешеләре белән горурлану хисен тагын да көчәйтә.

Әдәбият дәресләрендә якташ язучыбыз Суфиян Поварисов әсәрләрен мин күбрәк кулланырга яратам. "Ни өчен?" — диярсез. Җавапны профессор Мидхәт Гайнуллин сүзләре белән бирәсем килә: "...Булмышы

аның — Илеш җиреннән. Үзе туып үскән эш сөючән, тырыш, гүзәл табигатьле Илеш яклары хезмәт батырларының иҗади лабораториясен пропагандалауга бөтен гомерен сарыф итеп яши. Чынлап та, һәр язучының туган авылы, районы бар. Шулай да С. Поварисов кебек үз яклары белән тыгыз мөнәсәбәттә булган, художество әсәрләре, публицистикасында үзенең иң якын кан кардәшләрен төп геройлары итеп сурәтләгән, үз бәхетен үз куллары белән булдыручы якташларын гомумиләштерүгә иҗатының зур өлешен багышлаган икенче бер язучыны күрсәтү мөмкинме икән? Ул Илеш районына җаны-тәне белән берегеп, районодашларына мөкиббән бирелгән үз язучысы!..” (“Кызыл таң” гәзите.)

Язучы Үрмәттән 7 генә чакрым ераклыкта булган Тыпый авылында туган.

С. Поварисов “Бәхет турында легенда”, “Җир сулышы”, “Авыл язмышы кем кулында?”, “Биш партизан”, “60 яшьлек Илеш” һ, б. әсәрләрендә, публицистик мәкаләләрендә безнең туган якны, халкыбызны ихлас күңелдән бөтен җылылыгын биреп, эчкерсез мәхәббәт белән тасвирлаган. Булган кимчелекләргә тирән борчылу да, аларны бетерүгә ярдәм иту хисе дә тулып ята аларда. Бу әсәрләрдә укучыларга яхшы таныш табигать, иген өчен көрәш картиналары, Үрмәт, Тыпый, Дөмәй һ. б. тирә-як авылларның конкрет кешеләре сурәтләнгән. Аларның кубесе — укучыларның әти-әниләре, әби-бабалары яки туганнары, күршеләре. Укучылар бу геройларның бугенге тормышлары, көнкүрешләре хакында узләре дә өстәп сөйлиләр, җанлы әңгәмә барлыкка килә. “Бәхет турында легенда” китабының алтынчы дәфтәре безнең Үрмәт һәм Тыпый авылларына багышланган. Дәфтәрнең исеме — “Җир-ана кадере”. Дәфтәрдән өзекләр укыла: “...Менә председатель белән урам чатында басып торабыз. Биек-биек тирәкләрнең очларында баеп барган кояшның кызгылт нурлары уйный. Авылның йөзе һаман матурлана бара. Ләкин яшеллек җитми әле...

Минемчә, монда юньчел, үз бәхетен үзе табарга тырышучы эшчән халык яши... Тыпый белән Үрмәт арасында зур түгәрәк күл бар. Анда кыр казлары, кыр үрдәкләре йомырка салып бала чыгара торган иделәр. Бу күлдә назланып кына йөзгән пар аккошларга карап торуның хозурлыгын әйтеп тә, язып та аңлатып булмый. Күл өстендә акчарлаклар япма кебек була торган иде. Ә хәзер күл корыган. Озак моңаеп утырдым мин күл буенда... Шомырт, балан, миләш агачларын сындырып бетергәнбез. Табигать үзе биргән матурлыкны җимереп барабыз бит. Гирбицид сибеп, үләннәрне, агачларны, яшеллекне корытып бетерәбез. Бу юл белән яшь буынны, кешеләрне тәрбияли алмыйбыз. Матурлык матур йортлар салуга гына кайтып калмый. Күкрәп үскән җир бизәге, җир матурлыгы булып исәпләнгән урманда йөз, мең агач кискән кайбер

кеше үз өе янына бер агач утыртырга иренә..." ("Бәхет турында легенда", 161, 165, 166 битләр.) Укучылар белән соңгы еллардагы үзгәрешләр, табигатькә сакчыл караш, агачлар утырту, бакчалар үстерү, язучының фикерләренә балаларның карашы турында сөйләшәбез. Соңгы елларда табигатьне саклау буенча эшләнгән эшләргә тукталабыз. Колхоз, хуҗалык көтүләре урманнарга кертелми башлады, урманнан теләсә ничек агач кисүләр тыелды, карагай, нарат, чыршы үсентеләре утыртылды, укучыларның күбесе бу үсентеләрне үзләре әти-әниләре белән карап, тәрбияләп үстерәләр (китмәнлиләр, җәен печәнен чабалар, корыганнары урынына яңаларын утырталар). Авыл очында питомник бар, анда сырганак һәм башка төрле үсентеләр үстереп, тирә-якларга да таратталар.

Язучының авыл язмышының кеше язмышына бәйле булуын күрсәтеп язган "Авыл язмышы кем кулында?" әсәренең шул исемдәге бүлеге Үрмәт, Тыпый, Бүләр авылларына багышланган. Безнең арада яшәүче кешеләрнең арендаторлык эшчәнлеге яктыртылган. Табигатьнең бик матур җиренә урнашкан Бүләр авылының бетүе, Тыпый авылының Үрмәттән аерылып, яңа "Алга" колхозы төзүе күрсәтелгән.

Безнең программага авыл тормышын, аның гүзәл табигатен, мөлаем кешеләрен сурәтләгән бик күп әсәрләр кертелгән: Г. Бәшировның "Туган ягым — яшел бишек", "Намус", М. Кәримнең "Озын-озак балачак", М. Мәһдиевнең "Кеше китә — җыры кала", "Без — кырык беренче ел балалары", А. Гыйләҗевнең "Әтәч менгән читәнгә", "Җомга көн кич белән" һ. б. Шушы әсәрләрне өйрәнгәндә, С. Поварисовның үз ягыбызга багышлап язган әсәрләрен файдалану шактый уңышлы гына килеп чыга, минемчә.

Прозада авыл тормышы күпьяклы яктыртыла. Октябрь революциясе һәм гражданнар сугышы чорын чагылдырган әсәрләрне өйрәнгәндә, С. Поварисовның Дөмәй авылында кулаклар тарафыннан тереләй күмелгән биш партизан турында язылган "Биш партизан" документаль повестен файдаланам.

"...Шәмсия инәй, Заһит, Шәйсолтан, Ярмөхәммәт, Сабирҗан — бишесе дә күз алдымда басып торалар кебек тоелды.

...Минем дә әйтелмәгән, ләкин әйтелергә тиешле бер сүз бар сыман. Ул бер сүзне мин "Кешелеклелек!" дип атадым. Кеше ни өчен бөек идеалларга тугры булып яши? Бу идеалын ни өчен ул яшәүнең иманы, кредосы итеп куя? Тузан бөртегедәй үз гомере өченме? Түгел... Юк, кеше дөньяга газиз башын саклап яшәр өчен генә килми. Кеше һәрвакыт кешелек җәмгыяте тудырган бөек казанышлар белән рухланып яши, аңа үз өлешен күбрәк бирергә, кешелеклелек дигән илаһи бөек төшенчәнең асылын, серле якларын, кодрәтен аңларга, аңа үз акылын, йөрәк ялкынын, физик һәм рухи көчен бирергә тырыша. Кешелеклелек җир

йөзендә кояш яктысыдай таралып йөри... Әмма ул яктылыкны даими рәвештә кара пәрдәгә төрергә маташучы явыз көчләр дә бар. Кешелеклелекне алар сугыш уты белән көйдермәкче була... Бу дөньяда сугыштан да яманрак, күңелсез хәл юк. Сугыш кешеләрнең күпме еллар буе бөртекләп җыйган кыйммәтле гәүһәрләрен, көн-төн йокламый төзегән матур тормышын, киләчәк кешеләр бәхете өчен жанын бирердәй булып җыйган кадерле хәзинәсен — барысын, барысын утка тота, аналарны ирсез, балаларны атасыз, хатыннарны тол калдыра. Ләкин кешелеклелек һәрвакыт җиңә, өскә чыга, тантана итә. Моның өчен ил баһадирлары башларын җәлләмиләр. Аларның рухи көче, кешелеклелек сыйфатлары гасырлардан гасырларга күчә килә...” (“Биш партизан”, 155-156 нчы битләр.)

Шәмсия инәй (олы улы Заһитны әнисе белән бергә күмәләр, ятим калган ике баласы суга төшеп үлә) кешеләр йөрәгендә изге, саф, киң күңелле, мәрхәмәтле, олы жанлы, бөек хисле ана булып тамырланды. Сандугач, үз идеалына тугры булып, сугышларда катнаша, ике бала алып, тәрбияләп үстерә. Әсәр азагында авторның Сандугач әби белән очрашуы кешелеклелек, намуслылык, изгелек төшенчәләрен тагын да ныграк тирәнәйтә.

Яшь буынны тәрбияләү, һәр нәрсәне җиренә җиткереп эшләү, иманлы булу, мәрхәмәтлелек проблемалары С. Поварисовның башка әсәрләрендә дә кызыл жеп булып сузыла: “Алтын йолдызлы Ләйлә апа”, “Ышанам сиңа!”, “Сөмбел”, “Яратам сине, тормыш!”, “Ташлама мине”, “Очрашырбыз әле”, “Яшьлек еллары”, “Җир сулышы”, “Илеш — Баймак”, “Язмыш корбаннары” һ.б.

Юкка гына профессор Мидхәт Гайнуллин аны “изгелек, кешелеклелек җырчысы”, — дип атамагандыр. XI класста прозаны үткәндә бу әсәрләргә кагылмый үтү мөмкин түгел.

“Ташлама мине”, “Очрашырбыз әле” документаль повестьлары Советлар Союзы Геройлары М. Сыртланова һәм В. Феропонтовка багышланган. Башкортстан батыры, легендага әйләнгән Мәгубә Сыртланованың батырлыгы аеруча бер горурлык, соклану тойгысы белән бирелә: “...Мәгубә газраил белән 782 тапкыр очрашты. 782 үлемне җиңде. Бу зур бәхет! ...Кешелеклелек, гаделлек, дөреслек өчен көрәштә яуланган иң зур бөеклек бу!..”

“Яшьлек еллары” повестенда студентларның уй-хыяллары, аларның үзара мөнәсәбәтләре, психологик эчке дөньялары, мәхәббәт тойгылары сурәтләнә.

Әсәрне хикәяләүче Әкрам, сугышта яраланганнан соң белемгә сусап кайткан, һәрьяклап өлгергән группа старостасы Акмали, ялкау Илдус, профорг Нәҗибә, эчке кичерешләренә төренеп яшәгән Гүзәлия, атаклы укытучы, мавыктыргыч лекцияләре белән студентларда зур кызыксыну

уяткан доцент Җ. Кылычбаев һ. б. образлар язучының практик тормышы һәм күңел җылысы белән сугарылганнар.

"...Менә мин Илеш районында. X класс укучысы Сөмбел белән сөйләшеп торам. Гел югары бәя алып укый икән. Хыял кошын инде ул күп очырып йөрткән: Уфа, Мәскәү, Ленинград... Сөмбел фермага килә. Сыер саварга тотына. Талчыбыгыдай бөгелеп-сыгылып торган гәүдә. Кош тәпиедәй генә куллар. ...Сөмбел "кара" хезмәтнең "ак" ягын, матурлыгын аңлый. Бәхетен ул хезмәттә таба. "Сөмбел" дигән повесть әнә шулай барлыкка килде", — ди автор. Повестьта Сөмбел, Усман кебек авыл яшьләренең тырыш хезмәте, читтән торып белем алулары, алар арасындагы мәхәббәт тасвирлана.

С. Поварисовның әдәби әсәрләрнең телен өйрәнү буенча, тел гыйлеме буенча язылган хезмәтләре дә бик күп. Алар арасында Г. Тукай, Г. Ибраһимов, Һ. Такташ, М. Җәлил, Н. Исәнбәт һ. б. әдипләрнең әсәрләрендәге тел үзенчәлекләре тикшерелгән хезмәтләр бар.

Укучыларны әдәбият белән кызыксындыруда, аларда китап һәм көндәлек матбугат белән мөстәкыйль эшләү күнекмәләре булдыруда, яшәгән җиргә, аның эшчән кешеләренә мәхәббәт тәрбияләүдә туган як материалларыннан файдалануның, якташ язучыбыз С. Поварисовның туган ягыбызны чагылдырган әсәрләрен өйрәнүнең әһәмияте зур.

* * *

Мин яшь чакта укыттым да, китапханәдә дә эшләдем. 80 яшьне куып киләм инде. Хәзер халык укымый, диләр. Укыйбыз. Аллага шөкер! Суфиян Поварисовның Галимҗан Ибраһимов турындагы өч романын кат-кат укып чыктым. Теленең байлыгы хәйран калдыра. Кайбер мәгънәле әйтемнәрен көндәлегемә язып куйдым әле. Менә шуларны сезгә җибәрәм, "Кызыл таң"да армый-талмый хезмәт итүче сүз осталары. Әдәби әсәрләр теле мәктәптә өйрәнелә бит хәзер. Шуларга бер ярдәмем булыр, бәлки. Каләм тибрәтүче яшь язучылар ла өлге, үрнәк алсыннар иде.

Лия ГАББАСОВА.

Өметсез максат – мәңге йөрер аксап. Ялгызлык белән тик тору игезләр. Борының белән боз ярып булса да алга бар. Аш дигәндә жан-фәрман, эш дигәндә юк дарман. Аягы пычрак - өй пычратыр, теле пычрак кеше пычратыр. Алтын утта, ир авырлыкта чыныгыр. Кирага җилкәңне, акка алдыңны куй. Хатын азса – ир башына, түрә азса – ил башына. Хәерсез хатын ир бөлдерер, хәерсез түрә - ил бөлдерер. Үз илең гөлстан, кеше иле – гүрстан. Түрәгә симез калҗа, мужикка ярлы маржа. Баллы сүз баш әйләндерә. Ат алганда – авызына, кыз алганда – күзенә кара. Яшь ир беләкле, карт ир келәтле. Карт мәхәббәттә яра, яшь мәхәббәт йөрәккә яра. Бер хатында 40 ир хәйләсе булыр. Хатын-кыз хәйләсенә шайтан да түзә алмас. Хатын-кызның акылы җил өргәнче җиде төрлегә әйләнә. Ялган

мәхәббәт ярык ялгышка утырта. Өметсез хатыннан тиз котыл, өметлесенә нык тотын. Сүзнең хислесе, дусның көчлесе әйбәт. Сукыр фикер сүздән яманрак. Эт көтүе җыйнаулашып өрсә дә, айның чите кителми. Көчледән үчле яман. Картлар йөрәген гыйшык яшәртә. Эче караңгының йөзендә нур булмас. Кызлы йорт – кызыклы йорт. Кыз бала өй зиннәте. Тырыш булган кырыс булыр. 16 яше тулган кыз энә очында бии. Алгы итәгеңне бала бассын, арткы итәгеңне мал бассын. Бала башында бер кайгы, ата башында мең кайгы. Ана бәхете балада. Көннең аягы озын атлый, мартның буыны шартлый. Булырдайның – буынынннан билгеле. Чәче йомшак кешенең табигате йомшак була. Ипсез ат тәртә сындырыр, холыксыз ир өен туздырыр. Бала багуы – елан агуы. Өстән бишек тәрбәтеп, астан баланы чеметмә. Биргәннең битенә төкермиләр. Ата юлы белән киткән бала – салауламый. Акыллының маңгае киң булыр. Ир келәт – хатын йозак. Ата йөзе – ил йөзе. Ниятең кәкре булса, юлыңның турылыгы гына файда китермәс. Уйланып әйтелгән бер сүз – аз ашка салынган күп тоз. Алтыдагы алтмышта. Йолдыз караңгыда яктырак яна. Ачу – акыл дошманы. Акыллы тыңлар, исәр – сөйләр. Бүгенге эшне иртәгәгә калдырма. Тәвәккәл таш яра. Уйлаганнан кире кайту – көрәгеңне югалту. Сәламәтлекнең түре – йокы. Карга оясына бөркет беркайчан да кунмаячак, кар бозына кояш беркайчан да төшмәячәк. Ат карагының һөнәре энә урлаудан башлана. Кычык белән бодайны бергә кушмыйлар. Хатын-кызның тапканы – ирләрнең җиң какканы. Кайгы – кайгырган саен куера. Саксызлык сазга батыра. Акайган күздә акыл булмас. Күңел – пыяла, дөрес чиртмәсәң уыла. Кызның 40 безе булыр. Ялкаулык – фәкыйрьлекнең башы ул. Максатсыз кеше – яфраксыз агач. Акылсыз башка алтын бүрек тә акыл бирмәс. Тырышып эшлә, дөнья явызлыгын вакытында ныгытып тешлә. Холыксыз ир тормыш ямен ала, хатыны йөрәгенә яра сала. Дөньяның рәхәтеннән михнәте күбрәк. Мәхәббәт бик назлы үсемлек сымак, әгәр аны һаман күз яшьләре белән сугарсаң, бер кайчан да озак яши алмый. Үткән гомер сүнгән күмер. Адәм фәрештә, әрекмән кәбестә булмас. Артык сүз – аркага аркан. Мактану, ялганлау, урлашу – бертуганнар.

* * *

Бу өч ханым (Лия Габбасова, Рәхимә Биктахирова, Нәфисә Латыйпова) халык исеменнән яза. "Халык зур ул" дигән иде Г. Тукай. Нәфисә Латыйпова мәкаләсен "Зур" дигән сүз белән тәмамлый. Мине зурлаудыр инде ул. "Зур язучы" дигән сүзне халыктан ишетү – халыкны йөрәк, кан, җан белән ишетү. Мондый сыйфатка ирешү – Тәңре алдында имтихан бирү. Шушы иманлы имтихан Халык язучысы иткәндер инде мине. Рәхмәт дөреслек тажы әһелләренә! Шул хакта уйланып утырганда, оныгым Алмаз эштән кайтканда почтадан гәзит-журналлар алып керде. Менә "Кызыл таң". "Кулында Прометей уты!" дигән мәкалә. Минем

хакта. "Мирас" татар милли-мәдәни үзәге идарәсе рәисе Дамир Шәрәфиев яза. Янә "китапны ябам" дигән чакта туры килде бу. Җитмәсә, бу китапның чыгуын түземсезләнеп көткән шагыйрь-җырчы Ә. Кәшфуллин тагы да шалтырата. Мәкаләне укып чыккан да, нык охшаткан, китапка кертергә өнди. Яшьләргә файдасы булачак, янәсе. Тыңларга туры килде.

"Юбилейдан соң" дип куелган. 25 августта Казанда 90 яшемне билгеләп үтүдер инде ул. Башта Прометейның кем икәнлегенә аңлатма да бирелә: "Прометей – борынгы грек мифологиясе герое. Аның батырлыгы белән кешелеклелек дөньясы таныш. Бик күпләрне төрле әсәрләр язарга илһамландырган ул. Казанда Башкортстанның халык язучысы Суфиян Поварисовның 90 яшьлек юбилее уңаеннан үткән тантанада кемдер аны Прометей дип атады. Мәгънәле сүзләр, тирән чагыштыру..."

...Моннан 20 еллар элек философия фәннәре кандидаты Ә. Юлдашбаев җитәкчелегендә милли мәсьәләләр буенча махсус оешма эшли башлады. Тугандаш татар һәм башкорт милләтләре арасында дуслык күпере ныгыту максатында Татарстан китап нәшриятында – башкорт, Башкортстан китап нәшриятында татар язучыларының иң асыл әсәрләрен нәшер итү белән дә шөгыльләнде бу оешма. Башкортстан татарларының мәдәни мирасын өйрәнү, тикшерү белән Әлфир Сакаев шөгыльләнә башлады. Мин аның ярдәмчесе булдым. Безгә бу эштә Башкортстан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты кафедрасы укытучысы Суфиян Поварисов нык ярдәм итте. Бу авыр, әмма бик файдалы эштә төп юнәлеш күрсәтте. "Мирас" оешмасы күчмә китапханә булдырды. Анда Суфиян абыйның китаплары зур урын алып тора.

Галим һәм язучы Суфиян Поварисовның 90 яшенә багышланган кичә Казанда Тукай клубында үтте. Аны үткәрүдә Татарпстан Язучылар берлеге рәисе Рәфис Корбанов, Башкортстан Язучылар берлеге рәисе Наил Гаетбаев зур тырышлык салдылар. Без, Башкортстан "Мирас" оешмасы әгъзалары, аларга зур рәхмәт белдерәбез. Казандагы чарада академик М. Зәкиев, профессорлар Ф. Хатипов, Ф. Галиуллин, Татарстанның халык шагыйрьләре Р. Миңнуллин, Р. Гаташ, Р. Харис һәм башкалар. Күренекле шәхесләр Суфиян Поварисов эшчәнлегенә зур бәя бирде.

Чыгышында Суфиян абый үзенең әдәбият һәм фән мәйданында башкаларга үрнәк булып торучы шәхес икәнлеген күрсәтте. Әнә шунда, армый-талмый эшләвен искә алып, кемдер "Прометей" дип атады аны. Шушы ук сүзне Уфада да ишеттек.

Үзенең 90 яшен каршылап, "Гәүһәр күгәрченнәре" трилогиясен тәмамлады, "Ак каенлы Илешемс", поэмасын, "Авылымның алсу таңнары" дигән пьесалар җыентыгын бастырып чыгарды. "И, газиз илем – иманлы Илешем" дигән поэмалар җыентыгы әзерләп куйды. Радио һәм телевидениедә даими чыгыш ясый, китап укучылар белән очраша.

Соклангыч эшләр. Әллә яшен ташымы ул? Җир шарындагы иң асыл-азамат шәхесне иш итәргә йөргән Прометей уты Суфиян Поварисов кулында хәзер.

Дамир ШӘРӘФИЕВ,
"Мирас" татар милли-мәдәни үзәге идарәсе рәисе.

* * *

Мәкаләдә әйтелгәнчә, Прометей турында күп әсәрләр язылды. Яки күп эшләгән, күп язган, шәхси иркәлек, ямьлелек, күңел ачу, рәхәтлекләрдән мәхрүм булып, ялкаулыкның ни икәнлеген белмичә иҗат иткән, ил сулышы, халык язмышы, Тәңре кушуы буенча яшәгән, утта янудан, суга батудан курыкмаган азамат, шәхесләр Прометейга чагыштырылган. Француз язучысы Андре Маруаның "Прометей яки Бальзак тормышы" дигән романы шулай. Мостай Кәримнең "Ташлама утны, Прометей!" исемле әсәре дә шуңа тарта. Тизлекне Эмиль Золя да яраткан. Бер романны язып та бетерә, кабат укып та тормыйча, икенчесенә тотына. Төрки телле халыклар күңелендә алтын багана кебек балкыган Галимҗан Ибраһимов та әдәбият тезгенен нык тота. "Безнең көннәр" исемле зур роман-эпопеяны өч айда яза. Нинди генә эшләр башкармый ул: академик, революционер, тарихчы, философ, укытучы, романист, тәнкыйтьче, әдәбиятчы, телче (морфология, синтаксис буенча уку-укыту әсбабы яза), күп төрле гәзит-журналларның мөхәррире була. Ә бит ул гомер буе үпкә чире белән авырый. 1982 елда Г. Ибраһимов әсәрләренең сәнгатьчә эшләнеше турында Баку фәннәр академиясендә докторлык диссертациясен якладым. Аннан соң бөек язучының авырлыкларны таптый-таптый, имансыз киртәләрне җимерә-җимерә, дөреслек өчен көрәшә-көрәшә яшәве турында трилогия ("Пәйгамбәр таңы", "Күкнең җиденче катында", "Оҗмахка бер адым" романнары) иҗат иттем. Соңгы романда "Прометей" дип атадым Г. Ибраһимовны. Ул моңа лаек. Бөек язучы дөнья әдәбияты даирәсенә "Прометей" утын тотып кереп китә.

...Илеш йорт сала. Илешкә иптәшләр күп табыла. Тора-бара авыл зурая. Аңа Илеш исеме бирелә. Илеш дигән авыл һаман да бар. Исә җилләр. Ага сулар. 1934 елда Илеш дигән район барлыкка килә. Җир культурасы, матур, күркәм, мәгънәле яшәү, кешелекле булу буенча бөтен Русия Федерациясендә өлге-үрнәк күрсәтә. Танышыр, өлге-үрнәк алыр өчен хәтта чит илләрдән дә киләләр. Утта янудан, суга батудан курыкмаган, Илгә иш булып яшәгән данлыклы Илеш бабай Прометей түгелмени. Әллә ялгыш, әллә язмыш, язганнарым 50 томлык. Әгәр "Прометей" дип атыйлар икән, алар белән килешәсе генә кала. Килешү түгел әле ул уңыш өчен көлешү. Килешүнең чиге – иманлы булса гына изге. 90 яшьнең алтын ачкычын кулга алганмын икән, шул хакта чын кешеләрчә уйланырга туры килә. Мәңгелек оҗмахына гөнаһсыз китү хәерле!!!

Литературно-художественное издание

ПОВАРИСОВ Суфиян Шамсутдинович

АК КАЕНЛЫ ИЛЕШЕМ
(юбилярның иҗатына багышлана)

Шигырьләр, поэмалар

Мөхәррир З. Кәримова

Лицензия на издательскую деятельность
ЛР № 021319 от 05.01.99 г.

Подписано в печать 14.10.2014 г. Формат 60x84/16.
Усл. печ.л. 16,79. Уч.-изд.л. 17,52.
Тираж 50 экз. Изд. № 224. Заказ 57н.

Редакционно-издательский центр
Башкирского государственного университета
450076, РБ, г. Уфа, ул. Заки Валиди, 32.
Отпечатано на множительном участке
Башкирского государственного университета
450076, РБ, г. Уфа, ул. Заки Валиди, 32.